# Казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ · 1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

2
ФЕВРАЛЬ
1970

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Ф. ТАБЕЕВ. Юл башы . . . . . . . . . . . . . 3
РАДВАН ӘШ-ШӘҺАЛ. Ленин турында поэма . 9
Ж. БРИЕР. Ленинга сәлам . . . . . . . . . . 10
С. ШАКИР. Смольныйда . . . . . . . . . . 12
В. ДИЕВ. Мәңге тере образ . . . . . . . . . . 18

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Х. ТУФАН. Могикан (кечке поэма). Әй!!. Ил. Ник. Алар өчен дә. Хисләр утын түгел дә бит. Робагыйлар. Шигырьләр . . . . . . . . . . 23
Б. КАМАЛОВ. Күршеләр. Повесть . . . . . . 32
Ә. АТНАБАЕВ. Шатлыкларым, кайгыларым. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 70
✓ Н. ДӘҮЛИ. Ату. Хикәя . . . . . . . . . . . . 74
Р. ХАРИСОВ. Синең йөрәк тә типсен. Шигырьләр. 79
М. ЗАРИПОВ. Соңгы вахта. Хикәя . . . . . . . 84
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Синең моңнарың. Ак таңнарым. Әгәр егет кылса җинаять... Буровойдан кайтып килә. Тәрәзәдән узган гомер карый... Аучымы. Көзге урманда. Шигырьләр . 92
ЯН ВИНЕЦКИЙ. Пушкин һәм Мәрьям. Повесть . 95

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Н. ИХСАНОВ. Батыр эштә беленер. Очерк . . . 127

ХӘСӘН ХӘЙРИГӘ 60 ЯШЬ

Ф. МУСИН. Алгы сафта . . . . . . . . . . . 131
Х. ХӘЙРИ. Роман һәм аның герое . . . . . . . 132

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. БИЛАЛОВ. Татарстанны индустрияләштерү процессында пролетар интернационализм . . 145

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Мәгърифәт нуры . . . . . . . . . . . . 153

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Л. НЕБЕНЦАЛЬ. Муса Җәлилнең көрәштәше . . 158

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ӘГЪЗӘМОВ. Кешелекле солдатлар . . . . 160
М. МАННУРОВА. Хәрби мемуарлар . . . . . . 162

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Р. ФӘХРЕТДИНОВ. Болгар шәһәрләре . . . . . 167

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . 179

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

С. САБИРОВ. Сихер зәхмәте. Яман төер. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . 182
Р. ФӘИЗОВ. Кыбырсык Һабил. Хикәя . . . . . 186

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ш. САДРЕТДИНОВ. С. Рәмиев . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 8/XII-1969 ел. Басарга кул куелды 21/I-1970 ел. ПФ 04009. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87046 экз. Заказ В-619. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.




*ЛЕНИН БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

**Ф. Табеев,**
КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре

# ЮЛ БАШЫ

Казанга килгән чит ил делегация җитәкчеләренең берсе шәһәр белән таныштыручы иптәшкә болай дигән: «Гаҗәеп шәһәрдә яшисез... Йотлыгып укыла торган тарих дәреслегедәй ул. Сугышлар һәм революция тарихы, халыклар һәм сыйныфлар көрәше тарихы, фән һәм культура тарихы».

Ихтимал, борынгы шәһәрләрнең һәркайсында да аның кунакларын тарихны сиземләү хисе көчлерәк билидер. Урамнар һәм йортларның ташлары, кай яклары беләндер елъязма сәхифәләрен хәтерләтеп, күңелләрдә бөек исемнәрне, вакыйгаларны уяталар. Миңа калса, мондый хисләр Казан кунакларын аеруча бер көч белән биләп ала. Бу, әлбәттә, биредә революция полководецлары, фән, әдәбият, сәнгать корифейләре — С. Аксаков һәм Г. Державин, А. Пушкин һәм Л. Толстой, М. Горький һәм В. Маяковский, рус органик химия мәктәбе башлыгы А. Бутлеров һәм бөек геометр Н. Лобачевский, А. Герцен һәм Н. Чернышевский, В. Качалов һәм Ф. Шаляпиннарның яшәве, я булып китүләре, укулары, көрәшләре өчен генә түгел, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең шигъри авазлары яңгыравы, я С. М. Киров, Н. Э. Бауман, рус марксистларының иң беренчеләреннән Н. Федосеевның укуы, Я. Свердловның, 1905 елда, партия кушуы буенча, бирегә килүе өчен генә дә түгел... Әлбәттә, боларның барысы да — Казан белән бәйләнешле бу исемнәрнең һәммәсе дә — бик якын һәм бик кыйммәт безгә. Әйе, шәһәребездә «бервакытта да чирәм үсмәс халык сукмагы» сузылган, изге саналган һәм сакланган, хөрмәт ителгән урамнар, йортлар, бу юбилей елы алды көннәрендә экскурсантлар агымы өзелмәгән истәлекле урыннар күп.

Казан — Ленинның революцион юлы башы, булачак Октябрь юлбашчысының беренче революцион чыныгу алган шәһәр. Казан университеты яныннан, аның мәһабәт ак колонналарына карап узган чагында, бөтен уй-фикерләрең, ихтыярсыздан, Петроград Смольный колонналарына барып тоташа. Фильмнарда күрсәтелгән, поэма, повестьларда җырланган Ленинның онытылмас 1917 ел Октябре төнендәге Смольныйга барган юлы барлык детальләре белән күз алдыңа килеп баса. Уйга каласың: ә бит 30 ел дәвам иткән бу озын юл биредә, Казанда, менә шушы университет бинасында баш-

лана: 1887 ел җәендә, Ульяновлар семьясы, Владимир Ильичка университетка керәсе булгач, Сембердән Казанга күчеп килә. Чөнки бу чагында патшага һөҗүм итүдә катнашкан «дәүләт җинаятьчесе»нең энесе өчен башкала университетларына юл ябык була. Бу хәл турында Анна Ильинична үз истәлекләрендә «башкала университетларының берсенә керү турыдан-туры тыелмаса да, полиция департаменты директоры әнигә, провинция университетында укып, янгызда яшәве яхшырак булыр» дип күрсәтмә бирүе турында сөйли. Шулай итеп, Ульянов өчен Россиядә иң карт университетларның берсе — Казан университеты сайлап алына.

Узган гасыр ахырларындагы университетлы Казан шул заманның зур каласы булып санала һәм аның политик тормышында студентлар зур роль уйныйлар. Казан студенты Д. Каракозов Александр II гә ата — бу вакыйга патша хөкүмәтен «коткы таратучы» университетлы «коткычы» шәһәр өстеннән күзәтүне тагы да көчәйтергә мәҗбүр итә. Сиксәненче еллар уртасында, биредә, укучылар арасында гына түгел, ә алдынгы эшчеләр арасында да, марксистик юнәлештәге беренче түгәрәкләр барлыкка килә. Түгәрәкләрнең тыелган әдәбияттан торган үз китапханәсе була, яшерен типография булдыру турында да хыялланалар алар, бердәм үзәкләре дә була аларның һәм бу үзәк белән, Ленин әйткәнчә, гадәттән тыш талантлы һәм үз эшенә бирелгән революционер Н. Федосеев җитәкчелек итә.

Казан студентлары Россия революцион яшьләре белән тыгыз бәйләнештә була. Алар актив политик эшчәнлеккә омтылалар. М. Горький үзенең «Минем университетларым» әсәрендә Казан яшьләренең рус халкының киләчәге турында өзлексез борчылып, газета мәкаләләре, укыган китапларындагы төп фикерләр, шәһәр һәм университет турындагы вакыйгалар белән дулкынланып яшәүләре хакында яза. Н. Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә!», П. Лавровның «Тарихи хатлар»ы, Д. Писарев мәкаләләре басылган килеш тә, басылмаган кульязма хәлдә дә кулдан-кулга күчеп йөрилэр. Хөкүмәт буйсынмас Россия студентларына каршы кискен чаралар белән җавап бирә. Студентларга нинди генә булмасын җәмгыять, клубларда катнашуны тыйган, «галиҗәнап раслаган» устав — казарма уставы чыгарыла. Жандарм хокуклары бирелгән махсус надзирательләр булдырыла, урта мәктәпләрдә кучер, лакей, повар һәм вак кибетче балаларын алмау турында хурлыклы циркуляр кабул ителә.

Менә шундый бер заманда Ульяновлар семьясы Казанга күчеп килә. Казан студентлары семьясына аяк баскан Владимир Ульянов университет начальствосы исеменә язган прошениесендә барлык мәҗбүриятләрне өстенә алудан тыш, «...бернинди җәмгыятьләрдә дә, мәсәлән, землячестволарда член булып тормаска һәм катнашмаска, хәтта закон тыймаган җәмгыятьләргә дә, һәр очракта, якын начальствоның рөхсәтеннән башка, член булып кермәскә сүз бирәм»,— дип махсус подписка бирергә мәҗбүр була. Подписка бирелә, формаль як үтәлә, әмма Владимир Ильич шунда ук Самара — Сембер землячествосының эшенә актив кушыла.

...Бүгенге студент яшьләребез университетның актлар залына тирән хөрмәт тойгылары белән атлап керәләр. Биредә, 1887 елның декабрендә, студентлар тарафыннан «университетларыбызның хокукларын якларга» чакырган сходка җыела: власть башлыкларының Мәскәү студентлары чыгышына каршы җәза, эзәрлекләү алып баруы турындагы хәбәр Казан студентларында протест уята. Владимир Ильич протест тавышларын, ачу петицияләрен патша ялагайларының йөзенә бәргән беренче һәм баш «коткычы»лар арасында була. Соңгарак, бу хакта инспектор: студент Ульянов «...залга беренчеләрдән булып атылып керде, иптәшләрен ияртеп 2 нче кат коридоры буйлап, башкаларны да дәртләндерү теләге белән, кулларын болгый-болгый чабып узды»,— дип язып бирә. Күп миллионлы хезмәт ияләре массасының булачак юлбашчысы һәм остазы үзенең беренче революцион чыгышы белән беренчеләр арасында була.

Юл башы. Менә шәһәребезнең чокырлы-чакырлы тар урамнары... Бу урамнардан 17 яшендәге студент Ульянов декабрь иртәсендә сходкага ашыга... Шушы ук урамнардан, шушы ук көннең төнендә, аны төрмәгә илтәләр... Беренче кулга алыну...

Урамнар... Бу урамнардан, көймәле арбада, яшерен полиция күзәтүенә алынган студент Ульяновны Кокушкино утарына озаталар. Беренче сөрген.

Никадәр дулкынландыргыч, якты фикерләр уятучан хисләр тудыра күңелләрдә бу урамнар, бу юллар. Бигрәк тә яшь күңелләрдә, яшәү турында уйлый башлаган, олы тормышка беренче адымнарын ясаган яшьләр күңелендә, яшьләр аңында! Шулай шул,

яшь чагында ук үзеңне табу, тормыш юлыңны билгели алу, иртәге көнеңә төпле уйлап карау сәләте бар кешегә дә бирелмәгән.

«Нәрсәгә дип сез бунт күтәрәсез, егет! Алдыгызда — стена!» — дияр Владимир Ульяновка полиция участогына алып баручы пристав. Тормышка әле-әле генә аяк атлаучы 17 яшендәге студент: «Стенасын стена, әмма черек, төртсәң, җимерелергә тора»,— дип ышаныч белән җавап бирер.

Кар каплаган ерак утарда хәлендә дә, Владимир Ильич якынлашып килгән революцион көрәшләргә әзерләнә: Белинский, Чернышевский, Добролюбов һәм Писарев әсәрләрен укый, экономик, политик әдәбиятны, университет курсын өйрәнә-үзләштерә, университетка тагын кайтырга рөхсәт итәрләр дип өметен өзми ул, әмма ышанычы юкка чыга. Рөхсәт итмиләр.

1888 елның көзендә Казанга кайткач Ленин Карл Маркснең «Капитал» әсәрен өйрәнә башлый, революцион рухтагы яшьләр белән бәйләнешен яңарта. Н. Федосеев түгәрәкләренең берсенә керә һәм чак кына кулга алынмыйча кала: 1889 ел җәендә полиция Н. Федосеевны кулга ала, барлык түгәрәкләрен туздыра, тарата, ләкин Владимир Ильич бу вакытта инде Самарада була, Казан белән яз башында ук саубуллаша ул.

Ленин Казанда үзенең революцион эшчәнлеген әнә шулай башлый. Татарстан халкы моның гүзәл җимешләрен Советлар Союзы халыклары белән бергә күрде һәм күреп килә. 30 ел узар һәм Татарстан республикасын төзү мәсьәләсен хәл итү өчен, Казан губернасы делегациясе Мәскәүгә, Кремльгә, Ленин янына килер... 1920 елның 27 маенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Декрет кабул итә: РСФСР өлеше буларак Татарстан АССР төзәргә! Декретка В. И. Ленин кул куйган. Владимир Ильичнең тууына 100 ел тулу көнен без, бөтен эше, уңышы, шатлыгы, уй-хисләре Ленин рухы, Ленин фикерләре белән яктыртылган республикабызның 50 еллыгы алдыннда бәйрәм итәбез.

...Ленин университетка кергәнче үк Казанда булып китә. Ульяновлар җәйге яллары Кокушкинода уздыралар. Казанда булган чагында, Володя Ульянов Кремль манарасына менәргә, гасырлар югарылыгыннан торып искереп беткән чиркәүләре, мәчетләре, кәкре-бөкре урамнары, бер катлы бистәләре, сазлыклы бушлыклары, суы сәегып таралган Казанкасы белән җәелеп утырган шәһәрне күзәтергә яраткан.

Бүген мин, уйларым белән, шул ук югарылыктан Казанга күз ташлыйм. Социалистик Казан — әле 50 яшенә генә якынлашып килгән Татарстанның биш диңгез портына әйләнгән башкаласы — танымаслык үзгәргән, яшәргән, матурланган. Совет кешеләре ирке белән чал Идел дулкыннары борынгы Кремль дивары ярларын сыйпап тирбәлә бүген. В. И. Ленин исемендәге ГЭС, хәтсез зур су саклыгычы булдырып, Идел суын сәеккән Казанка елгасына куып кертте. Елга киңәеп, тирәнәеп китте, ярлары бетонга киенде, аркылысына яңа күперләр сузылды, хезмәт кешеләре җәйге чылдә су кергән, ял иткән пляжлар, шәһәр үзәген Ленин районы белән тоташтырган дамбалар булдырылды. Бүген инде совет кешеләре, бу район турында сүз чыкканда, Ленин районы республика башкаласы Казанның индустриаль һәм культура үсешенең җанлы шаһите, Ленин васыятьләренең тормышка ашырыла баруы, дип сөйлиләр. Әйе, Ленин районы — самолет һәм моторлары, химия предприятиеләре: кино-фотопленкасы, органик синтез заводының күккә ашкан эстакадалары, якты, зур Культура сарайлары, клуб, кино, парклары, көнкүреш хезмәте ательеләре һәм, барыннан да бигрәк, хезмәт сөйгән, эшкә оста кешеләре белән атаклы яңа район. Ленин районы — яшеллеккә күмелгән төзек проспектлар, проспектлары буйлап үсеп барган күпкатлы якты һәм яңа йортлар районы. Боларның барысы да тугандаш республикалар һәм, әлбәттә, Россия Федерациясе хөкүмәте ярдәме белән, элекке аулак шәһәр кырые булып саналган бушлыкта барлыкка килде. Әле күптән түгел, 30 нчы еллар башында гына, биредә җансыз бушлык иде. Казанка аркылы берденбер агач күперчекнең субайлары Кәҗә бистәсенең җиргә сеңә барган бер катлы агач йортларына орынып тора иде, ә арырак шыксыз, сазлыклы дала — Казан арты...

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның «Казан вә Казан арты» дигән шигыренең ачынып язган соңгы юллары искә төшә:

«...Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артына кара:
Нур чәчәсең бар җиргә, үз өзәң кап-кара.

«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампаның һичбер нуры,»
Шул мәкаль монда дөрес шул, ах, аны җен оргыры!»

Бу гүзәл райондагы промышленность биналарының, торак йортлары, мәктәп һәм клубларның беренче нигез ташларын салучылар әле бүген дә Казанда яшәп хезмәт итәләр. Коммунист Алексей Александрович Самов менә 40 ел инде шәһәребездә яңа йортлар сала. Гади йөк ташучыдан башлый ул, аннары ташчы хезмәтен үзләштерә, ә бүген үз эшенең талантлы остасы, комплекслы бригада җитәкчесе... Менә ул Ленин районының Галимҗан Ибраһимов исемендәге проспекты буйлап атлап бара. Янында әтисе юлын сайлаган улы Владимир да атлый. Күз алдында үсеп утырган якты йортларны күрүдән горурланган әти кеше улына болай ди:

«Күрәсеңме, улым, болар барысы да минем өйләр, минем проспект, минем урам, минем микрорайон, без төзедек аларны, утызынчы елдан төзә башладым мин».

Әйе, Ленин яшәгән, яшь Володя күрәшкән заманнардагы сабын кайнатып, ситса тукудан уза алмаган Казан ерак заманда калды инде. Ул заманны без, аеруча яшьләребез, бүген тарих дәресләкләреннән, халык шагыйре Габдулла Тукай шигырьләреннән укып күзаллый алабыз. Менә Тукайның ике генә юллы шигыре, ә нинди зур фаҗигалар шәһәрен тасмерли ул:

«Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан».

Туган шәһәренең фаҗигасен җырлаган бөек шагыйрьнең үз тормышы да фаҗигале булды, чөнки ул авыр, караңгы заманнарда башкача булу мөмкин дә түгел иде: Тукаебызны салкын кабергә китергән чахотка авыруы ул заманның әнә шул «ут, төтен» белән кайнаган Казаны өчен иҗтимагый золым булды...

Бүген без яшәгән Казан — сәламәтлекне саклау буенча Федерациябездә беренче урыннарның берсендә торган социалистик башкала. Казанның үзендә генә дә хезмәт ияләренең сәламәтлекләрен саклауга хезмәт иткән махсус санаторийлар, ял йортлары, фән һәм техниканың иң соңгы сүзе белән корылган больница һәм клиникалар, шул больницаларда, клиникаларда хезмәт итүче бик күп, бик күп врачларыбыз, профессорларыбыз, медицина хезмәткәрләребез бар...

Бүгенге Казан, югарыда санап узганнан тыш, 1970 елда — бөек Ленинның тууына 100 ел тулу елында — 100 миллион нефть бирү кебек почетлы юбилей вәгъдәсен үтәү көрәшенең штабы эшләп яшәгән шәһәр.

Казан — күп төрле юнәлештәге техник прогресс шәһәре ул. Бу прогрессны иҗат итүченең күпчелеге милли кадрлар. Менә шуннан соң инде революциягә чаклы булган Казанның патша Россиясенең илле губернасы арасыннан грамоталыгы ягыннан 44 нче урынны тотуы ничек исеңә төшмәсен! Мәгариф министрлыгының Казан уку-укыту округы попечителе исеменә язган хатында шушындый юллар бар: «Мөселман эшен, уку-укыту заведениеләрен яхшырту, реформа уздыруда читтән булышчанлык күрсәтмичә, үз карамагына калдыру бик дөрес булыр. Үз карамакларына куелган мөселман мәктәпләре элеккечә үк иске карашлардан файдаланып яшәр». Бөтен губернага бердәнбер Казан китапханәсе татарлар өчен ябык була, татарлар аның филиалыннан гына файдалана алалар, ә татар хатын-кызларын филиалга да кертмиләр, бары тик 1913 нче елдан башлап кына, анысы да «якшәмбе көннәрендә генә, көндезге 12 дән 4 кә кадәр» рөхсәт ителә.

Татар халкын рухи бөлгенлеккә дучар иткән патша «мәгарифе» политикасы әнә шундый була. Халкыбызны мондый бөлгенлектән Ленин, Советлар власте коткарды һәм кешелекнең рухи байлыгы хәзинәләренә хуҗа ясады. Бүгенге Казан — күп меңле студентлар, педагог, галимнәр, фән эшлеклеләре шәһәре. Ленин укыган университетны бездә, кайчак, шәһәрдәге иң карт һәм иң яшь бина дип тә йөртәләр. Аның тарихы, узганы һәм бүгенгесе бергә үрелеп бара. Мәсәлән, революциягә кадәр булган 113 ел эчендә университетта татарлар аз укыган булса, бүген аның факультетларында өч меңнән артык татар егетләре һәм кызлары белем ала. Әгәр дә элек университетта татар укытучылары бармак белән генә санарлык булса, бүген университет профессорларыннан М. И. Абдрахманов, Ш. Т. Хәбибуллин, Г. Г. Тумашев, Х. М. Корбангалиевaларның сүзләренә күп кенә илләрнең галимнәре колак салалар.

Галимнәр дөньясында хәзер химиклар, физиклар, математиклар, механикларның Казан мәктәбе кебек төшенчә яши.

Мин университет, авиация, химия-технология институтларының, СССР Фәннәр академиясенең Казан физико-техник институты галимнәреннән күп кенә исемнәрне санап күрсәтә алыр идем. Бу исемнәр арасында татар халкының уллары, кызлары да аз түгел, аларның рус туганнары белән кулга-кул тотынып ирешкән фән югарылыклары турында ата-бабалары хыялланырга да кыймаганнар.

Бу казанышларны аларга бөек Ленин, Совет власте бирде. Менә аларның берсе — татар халкының күренекле улы, химия фәннәре докторы, Дәүләт премиясе лауреаты, Казан химико-технология институтының кафедра мөдире Гыйлем Камайның тормыш юлын гына алып карыйк.

Әнисе — кер юучы, әтисе — бар гомерен улын укытып писарь ясау хыялында янган грузчик. Шулай янып кына кала да ул, улы Гыйльметдиннең тормышында якты һәм бәхетле киләчәккә илткән юл туу көненә җитә алмыйча, 42 яшендә үлеп китә. Грузчик атадан балага мирас булып грузчиклар камыты белән тимер ыргак кала. Бала 8 яшенә җиткәч, әнисе аңа: «Гыйлем, эшли башларга вакыт сиңа!» ди, ягъни: «Улым, мәктәп турында уйлавыңны ташла».

Пароход исемнәрен иҗекләп укырга өйрәнгән яшүсмернең башыннан кичкән газап-михнәтләренең барысын да тәфсилләп тормастан, шуны әйтәсе килә: егетнең беренче укытучылары үзе эшләгән грузчиклар артиленең киң күңелле рус кешеләре була. Язмыш үзе шулай китереп чыгарган диярсең, Камайның мөстәкыйль рәвештә үзе укый белгән беренче сүзе — пароход исеме «Фортуна» була. Мифологик әкиятләрдән мәгълүм булганча, Фортуна — көтелмәгән бәхет образы. Әмма бу көтелмәгән бәхет — Фортуна егеткә бик алай тиз генә якты чырай күрсәтергә чамаламый әле. Егетнең чын бәхете 1917 елда, Ленин өндәве буенча, Казанда Совет властен төзү көннәрендә килә. Яшь Камай Совет властеның нәрсә булуын аның беренче көннәрендә үк күрә, аны учительский семинариягә кабул итәләр, тулай торактан урын бирәләр. Ә аннары Камайның бәхетле язмышы да хезмәт халкының меңнәрчә-меңнәрчә улларыныкы белән бергә үрелеп бара. Комсомол. Гражданнар сугышы. Егерменче ел декабрендә партия сафына алалар аны, ә егерме беренчедә, демобилизацияләп, Мәскәүгә РКП(б) Үзәк Комитетының Төркбюросы карамагына озаталар. Камай Кремльдә була, Ленинны күрә, аның партиянең X съездындагы речен тыңлый. Аннары язмыш аны Себергә ташлый. Партия Камайны Томск университетына укырга җибәрә. Университетны тәмамлагач, сәләтле яшь егетне Казанга, Арбузовка аспирантурага җибәрү турында сүз чыккач, «спец»лардан берсе: «Нәрсә эшлисез сез! Ул элекке грузчик ич, җитмәсә тагы татардан», дип каршы килә. Ләкин «спец»не тыңламыйлар. Гыйлем зур фән юлына аяк баса. Шулай итеп, татар халкы туган илгә талантлы галим бирә. Бүген Гыйлем ага алтмышның аръягында инде һәм ул, үзенең өйрәнчекләре белән, 300 дән артык эксперименталь тикшеренүләр башкарды.

Профессор Камайның тормышында шундый бер истәлекле вакыйга була. Казан университетына ректор булып билгеләнгәч, аны Мәскәүгә, Мәгариф халык комиссары Бубнов иптәшкә чакыралар. Нарком Камайны күрүгә үк танып ала, алар гражданнар сугышы көннәрендә Перекопта очрашкан булалар. Ул чагында Камай политработник, агитатор вазифасын үти. Ике иске таныш узган сугыш көннәрен искә алган чакта, кабинетка Надежда Константиновна Крупская килеп керә. Бубнов аны Камай белән таныштырып: «Бу безнең совет профессорыбыз, татардан», ди һәм Перекопта очрашулары турында да сөйләп бирә. Крупская, Камайны кочаклап, болай ди: «Владимир Ильич сезне күреп ничек шатланган булыр иде».

Бер татар галименең язмышына мин беркадәр киңрәк тукталдым, чөнки бу язмышта халык язмышы да, республика язмышы да бар. Аннары, бу үзенә күрә ниндидер бер аерым биография дә түгел. Казан медицина институтында кафедра мөдире булып Астрахань батрагының кызы Абруя Хәсәеновна Хәмидуллина эшли. Кайчандыр «Спартак» комбинатының смена мастеры булып эшләп, бүген университет кафедрасының җитәкчесе, зур галим булып танылган Гомәр Галиевич Тумашевны «Спартак»чылар бүген дә яхшы хәтерлиләр.

Казан Кремле патша түрәләренең резиденциясе булып саналган заманнарда, капкасында татарларга керүне тыйган язу булган. Бүген бирерә республика Верховный

Советы Президиумы һәм хөкүмәте урнашкан. Бүген Кремль биналарында министрлар — Татарстан хезмәт ияләренең уллары һәм кызлары эшли. Ленинчыл милли политика, илебездә һәртөрле иҗтимагый һәм милли чикләнүләрне мәңгегә бетереп, милли культураларның үсеше өчен чиксез мөмкинлекләр тудырды.

Күренекле татар әдибе Фатих Әмирхан беренче рус революциясе елларында «Гарәфә кич төшемдә» исемле хикәя яза. Төшендә автор татар клубына юлыга һәм татар профессорын, татар композиторын, татарлардан чыккан язучыларны очрата. Әмма бу «очрашу» ул вакытта төшкә генә керерлек, тормышта мөмкин булмаган хыял гына була.

Төш чынбарлыкка әйләнде бүген — Совет власте елларында татар әдәбияты һәм сәнгате мисалы күренмәгән революцион күтәрелешкә иреште. Мондый күтәрелеш, әлбәттә инде, теге яктагы, көнбатыштагы кайбер әфәнделәрнең канына тоз сала, тынычлыкларын ала. Ниндидер бер Б. Мусабай көнбатыш Германиядә чыга торган журналда «Бүгенге заман татар әдәбияты» исемле мәкалә язып бастыра. Нинди генә тузга язмаган хәлләр, нинди генә уйдырмалар юк бу «укымышлы әфәнде»нең мәкаләсендә! Әгәр бу кешенең уйдырмаларына ышанып булсаң, татар прозасы, поэзиясе һәм драматургиясе бик тә авыр «кризис» хәлендә икән. Татарстанның күренекле культура эшлеклеләре исеменә карата никадәр тәхкыйрь сүзләр әйтелгән бу мәкаләдә. Ялганның ялы юк, дигәндәй, Мусабай әфәндене дә, күрәсең, чама сиземләү сәләте бик чамалы... Әйдә, антикоммунизм идеологлары ни теләсәләр, шуны әйтеп тынычлангандай булсыннар! Татар халкы үз язучыларын, композиторларын, художникларын хөрмәт итә, ярата, аларның безнең илдә генә түгел, башка илләрдә дә билгеле булган әсәрләре белән горурлана. СССР Халык артисты Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил турындагы операсын Мәскәүдә дә, Прагада да тыңладылар. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты Советлар Союзы һәм чит илләр театрлары сәхнәсеннән төшми бара. Татарлар белән руслар, Татарстан белән башка тугандаш республикаларның культура эшлеклеләре арасында җимерелмәс дуслык яши һәм ныгыганнан-ныгып үсеп, киңәеп бара.

...Бу көннәрдә безгә күп кенә кунаклар килә. Үзебезнең Советлар Союзыннан да, чит илләрдән дә. Изге урыннарга — Ленин исеме белән бәйләнешле җирләргә хөрмәт итеп баш иярга, Владимир Ильич яшәгән өйне, аның революцион тавышы яңгыраган аудиторияне күрергә дип киләләр алар. Без кунакларга Ленин турында, Владимир Ильичның Казандагы тормышы турында, ленинизмның Татарстандагы тантанасы турында сөйлибез. Безгә күп кенә сораулар бирәләр, безнең иптәшләрнең күбесе бу сорауларга шагыйрь Сибгат Хәкимнең шигъри сүзләре белән җавап бирәләр:

«— Сез кайдан? — дип сорыйсыз.
— Без Иделдән. Җиреннән
Кара алтын ургылыр.
Туфрагына Ленинннан
Мәңгелек бәхет иңгән —
Татарстан шул булыр».

## Радван әш-Шәһал

Ливан шагыйре

# Ленин турында поэма

Каһарманнар Ватанында
Бер үлмәс даһи туды.
Җир шары өлегә белми
Аңа тиң булган улны.
Дөньяның нәкъ йөрәгенә
Салды ул сүнмәс очкын,
Мәңгегә Ирек ялкыны
Җирдә балкысын өчен.
Ул үзе дә халык улы,
Идеалы халыкларның.
Сулыш та алмыйча дөнья
Тууын көткән аның.
Аның турында барын да
Сөйләр өчен галәмгә
Төс тә, сүзләр дә җитмәгән
Рәссамнар, шагыйрьләргә.
Күкләргә омтылып — бөркет
Таулардан күзли киек.
Әмма Ленин даһилыгы
Йолдызлардан да биек.
Тырышлыгы, түземлеге
Киртәләрне җимергән.
Ул җиңалмаган каршылык
Юк ди әле бу җирдә.
Иң мәкерле дошманын да
Тез чүктергән, җиңгән Ул.
Тирән серләр дөньясына
Ачкыч таба белгән Ул.
Аның яшенле сүзләре
Халыкның күзен ачкан.
Җирдә шушы халык көче
Мәгърур океандай ташкан.
Һәм дөньяның бу ташкыны
(Көрәш... михнәте белән)
Бу Бөек кеше алдында
Ачык китаптай булган.

Очкын чәчкән йөзләрендә
Халкына биргән анты
Җәйге таң нурлары булып
Якутлар сыман балкый.
Бөтен галәмне берьюлы
Сыйдырган ул башына,
Алдан күреп, кыю барган
Киләчәкнең каршына.
Алда барган көрәшчегә
Юл кыен һәр адымда...
Тарих үзгәртүчән даһи
Уйлар булган аңында.
Кануннарның тугрыларын,
Гаделләрен өләшкән.
Ярлыга — кыюлык биргән,
Корал биргән көрәшкә.
Дөньяда бар да үзгәрә —
Шундый тәртип Галәмдә.
Вакыт һәрчак алга атлый
Һәм үзгәрә адәм дә:
Көчсезләр — көчле булалар,
Кол — ирек яулап ала.
Изелгән — үз язмышына
Гел хуҗа була бара!
Хәтта ташлар телгә килә,
Ленин!
Корыган агач җимеш бирә,
Ленин!
Синең исемең билән алган
Йөрәк түрен,
Ленин!
Синең уең —
Миллионнарның
Уе бүген,
Ленин!

Әдхәт СИНЕГУЛОВ
тәрҗемәсе.

## Жан Бриер

Гаити шагыйре

## Ленинга сәлам

*Өзек*

Мәскәү, мин сиңа бик ерак җирләрдән киләм,
Күп газаплар чиккән Ватанымның
Кайгысына төренгән, аска иелгән,
Вакытлыча җиңелүләремнең ертык байраклары белән.
Мин ике континент аша уздым,— сөргеннәр газабы аша.
Газиз Гаити җиреннән аерылган
Тамырларымда сыкрый авыр яра.
Мәскәү, мин сиңа киләм —
Гомеремнең гүя иң кирәкле гаванена.
Партбилетым юк янымда, юк — визит карточкам,
Ялтыравыклы тәтиләр — тропик орденнарын такмый киләм.
Бөек Ленин белән күрешергә киләм мин,
Тавышын ишетергә,
Тере Кеше белән,
Киләчәк Тормыш сурәтен тудырган -
Бөек останың үзен күрергә киләм мин.
Теләдем
Тарихның көчле агымына күз салырга,
Анда —
Иң гади киемдәге бөек ирне,
Заманнарның магнит кырында мәңгелек урын алган
Кешене табарга теләдем.
Күрдем — Аның
Горур басып торган сынын
Мәскәүдә, Ташкентта:
Ул һаман да халыкка сөйли, мөрәҗәгать итә.
Мәрмәр киемнән күрдем аны мәйданнарда, музейларда,
Төнге Мәскәү елгасы ярында,
Ленинградта, бурап кар яуганда.
Экраннарда күрдем — вакыт томаны аша,
Тик чын-чыннан Аның белән
Очраштым мин
Эшче кварталында, эшче квартирында,
Бу йортта — ярлылык төсен, өметсезлек пәрәвезен
Эзләп маташмагыз да...
Урындыкта кепка көтә хуҗасын,
Кыршылган курткасы сөйли хезмәт турында.

Юк монда —
Күп тартудан ысланган трубка, хәмер өчен балчык кружка.
Ә бар китаплар, бар репродукция:
Патша властьләре эшчеләрне җыелыштан куа.
Бу әйберләр — Владимир Ульяновныкы да
булa алыр иде бит.
Бары да монда сөйли тик Яшәү турында,—
Бу химия кодрәте түгел,
Тормыш үзе һәм мәхәббәт яулаган аны.
Бары да саф, табигый монда —
Разливтагы шалаш кебек.
Күк чәй — үзбәк чәе монда,
Мәскәүнең кара икмәге...
Зифа буйлы, житен чәчле кыз
Һәм Горькийның «Ана» романыннан
Килеп кергән кебек — сөйкемле хуҗа хатын.—
Аның эшчән куллары,
Сабыйларча мәкерсез күз карашы кебек
Җиһан яшьлеген хәтерләткән пакь куллары.
Тормыш әлифбасын, кунакчыллык ипи-тозын,
Туганлыкның тылсымлы ширбәтен
Суздылар миңа алар.
Ул миңа сөйләгән сүзләргә
Ленин үзе — ни дә булса өстәр иде микән?

Ленин! Сез булыштыгыз миңа —
Ерактан торып, илләр, телләр аша —
Идеалларымның колхозын төзергә;
Фикерләремнең киңлеген,
Поэмаларымның ритм тирәнлеген булдырырга.
Ярдәм итегез, Ленин, миңа,
Язмыш, тарих игез иткән туганнарыма,
Туган җиребезне
Дошман каны белән сугарырга,
Көрәш җырлары язарга,
Безне азатлыкка илтүче өндәү авазын табарга.

Мин Сезне сәламлим, Ленин!

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Самат Шакир

# СМОЛЬНЫЙДА



Өстенә кара костюм кигән, ак күлмәккә галстук таккан, күкрәгенә Кызыл Байрак ордены һәм медальләр кадаган, инде чәчләре коела башлаган, маңгаена да тирән сызыклар төшкән алтмыш биш яшьләрендәге бер кеше Смольныйның ишек алдына керде дә Ленин һәйкәленә карап уйга калды. Әйе, моннан илле ел элек ул бу урында булган һәм Владимир Ильич Ленинны күргән иде. Ул вакытта үндүрт яшьлек малай гына иде бит ул. Ә хәзер — өлкән яшьтәге агай...

Бу кеше — гражданнар сугышы һәм хезмәт ветераны, җырчы Хәмит Төхфәтуллин. Ул Ленинградка килү белән, иң элек, Смольныйга ашыкты. Аның күз алдына 1917 елның декабре килеп басты.

...Петроград. Октябрь революциясенең беренче атналары. Урамнарда буран дулый. Әче җил карларны себерә, капка төпләренә, подъездларга тутыра. Мондый вакытларда гадәттә кешеләр күбрәк өйдә генә утырырга яраталар. Ләкин урамнарда халык күп, хәзер өйдә утырыр вакытмыни! Пролетариат Октябрь революциясенең җиңүенә шатлана, бу турыда бер-берсенә сөйли, һәркемнең телендә — бөек юлбашчы Ленин!

Менә бер төркем кызылгвардеецлар җырлап үтте. Менә ачык машинага утыртып, сак астында, патша офицерларын һәм чиновникларын Петропавловский крепостька алып киттеләр. Невский проспектта бәйрәм шатлыгы. Таш стеналарга революцион лозунглар ябыштырылган, капкаларга һәм балконнарга кызыл флаглар эленгән. Җиңнәренә кызыл тасма бәйләгән эшче дружиналары каядыр ашыга...

Октябрь революциясе бишеге — Петроградта утыз сигезенче көн инде власть эшче һәм крестьяннар кулында. Октябрьның давыллы көннәре әле бүген генә булган диярсең. Әмма ул гигант адымнар белән бик тиз рәвештә бөтен Россиягә таралды.

Өч катлы Смольный бинасы. Революциянең штабы шунда урнашкан. Даһи Ленин шуннан торып революциягә җитәкчелек итте. Әле дә ишек алдында кызылгвардеецлар, кораллы эшчеләр килеп-китеп торалар. Капка төбендә броневиклар. Смольныйның бүлмәләрендә кызу эш кайный: телефоннар шалтырый, газеталар басыла, эшчеләр дружинасы вәкилләренә заданиеләр бирелә, чит илләрдән килгән коммунистларны һәм илчеләрне кабул итәләр. Революциянең йөрәге Смольныйдагы 81 нче бүлмәдә В. И. Ленин эшли. Владимир Ильич Смольныйда милли телләрдә газеталар чыгару өчен үзе эшли торган бу бүлмәне газета редакцияләренә бирә һәм чит ил вәкилләрен кабул итү өчен уңайлырак булган 67 номерлы бүлмәгә күчә. 81 нче бүлмәдә В. И. Ленинның турыдан-туры ярдәме белән татар телендә «Ярлы халык» дигән газета чыгару өчен әзерлек алып барыла. Газетаның редакторы — Камил Төхфәтуллин.

Бүлмәдә редактор телефон аша сөйләшеп торган вакытта, ике матрос кереп, яшүсмер малайның Тәхфәтуллинны чакыруын әйтте. Камил телефон трубкасын куйды да, шинелен тиз генә иңенә салып, зур-зур атлап, матрослар белән чыгып китте. Ишек алдын үтеп, капкага җитүгә, улы Хәмитне танып, кочаклап алды.

— Ничек монда кадәр килеп җитә алдың!

— Аяклар түгел, канатлар китерде,— диде Хәмит.— Мин Петроградка әни белән килдем. Ул квартирада калды.

— Әти ни хәлдә!

— Таза-сау яши. Сиңа бик күп итеп сәлам әйтергә кушты.

Алар сөйләшә-сөйләшә коридорга керделәр. Аннан соң Камил Уральскидагы хәлләрне сорашты.

— Уральскида Совет власте,— диде улы.— Ләкин анда ак казаклар айкалалар. Татар байлары арасында да шул казаклар җырын җырлаучылар күп.



Хәмит ага Тәхфәтуллин.

— Аларның пычрак эшләре барып чыкмас! — диде Камил.

Хәмит әтисенең сүзләрен бик игътибар белән тыңлады. Берникадәр Уральск хәлләрен сорашканнан соң, Камил чәйнек алып чыгып китте. Хәмит өстәлдәге бер язуга күз төшерде. Әтисе русча язылган мәкаләне тәрҗемә итә икән. Әйе, Камил Тәхфәтуллин тәрҗемәче иде.


Ул 1906 елда ук «Интернационал»ның кайбер куплетларын тәрҗемә итеп, Икенче дәүләт думасына сайлау алды җыелышында сөйләгән. Бу турыда 1906 елның 13 декабрь санында «Фикер» газетасында болай дип язганнар:

«Бик күп төрле болгатулар вә халыкны ялгыш сүз илә исертүләр булганны күреп, Камил Мотыйгый, халык эченнән торып, урындыклар өстенә басып, ошбу яндыргыч сүзләрне каты тавыш вә чын ихлас илә диде:

«Гражданнар! Уйлагыз, хәзерге вакыт сезнең өчен бик газиз вакыттыр. Сез үзегезнең хәлегезне төзәтергә теләсәгез, хәзер сезгә тырыша торган вакыт тәмам җитте. Шуның өчен сезгә иң әүвәл үзегезгә лаек вә сезнең хәлегезне белеп, сезне кызганырдай кешене депутатлыкка сайламак тиеш. Сез хәлегезне төзәтергә тырышмасагыз, башка кеше сезнең өчен тырышмас.

Сезгә котылуны һичкем бирмәс.
Нә алла, вә нә патша, вә нә баһадир.
Сез котылмакка җитәрсез үзегезнең кулларыгыз илә.
Сезгә көрәшү лазем. Көрәшү!
Сакланыгыз, хәйләкәр адәмнәрдән!

Шул сүзләрне бетерер-бетермәс җәмәгать, «браво!» тавышлары илә, җир селкетеп кул чабарга тотынды. Камил Мотыйгый да шуннан артык сөйләргә вә җыелышта тормакны хаҗәт күрмичә бәгъзе иптәшләрне алып чыгып китте. Аның артыннан барча җәмәгать чыгып таралды. Руслардан берничә кеше, Камил Мотыйгыйның артыннан «Уральский дневник» редакциясенә барып, халык исеменнән тәшәккерләр иттеләр. Бу кешеләр: «Без кара халык бит, берәүне дә танымыйбыз, сез төшендермәсәгез, бәлки аллә нинди ауларга төшкән булыр идек, рәхмәт сезләргә, моннан соң да булачак мәҗлесләребезгә килүегезне сорыйбыз»,— диделәр».




Петроградта чыгарылган «Ярлы халык» газетасының беренче бите.

**...Озак та үтмәде, Камил кайнар чәй һәм шикәр алып керде. Өстәлнең бер читенә газета җәеп, өрә-өрә чәй эчә башладылар. Хәмит юлдан килгәндә шактый арыган һәм ачыккан иде. Ул тиз генә ике стакан чәйне ялт иттерде. Шикәрле кайнар чәй эчкә җылы кертте, тамак та бераз ялганды. Хәмит тәрәзәгә карап алды. Тышта һаман җил сызгыра, тәрәзә пыялаларына бәрелеп ниндидер ят тавышлар чыгара иде.**

**Кыска гына вакыт эчендә бүлмәгә әллә ничә кеше кереп чыкты. Аларның нинди милләттән булулары турында Хәмиткә әтисе салмак тавыш белән сөйләп бирде.**

**— Смольныйда полякча, инглизчә һәм немецча газеталар чыга. Монда керүчеләр арасында поляк, инглиз һәм немец иптәшләр дә бар. Менә аларның газеталары,— дип, Камил улына берничә газета сузды.— Инде менә тиздән безнең газета да чыгып җитәчәк.**

**Кичке караңгылык төште. Камил Төхфәтуллин, кайбер материалларны карап, төзәтеп чыкты да кулларын уа-уа идән буйлап йөри башлады. Ул нәрсәдер уйлый, ниндидер яңа фикер әйтергә тели иде. Хәмит әтисенең шинеленә, биленә буылган киң каешка, портупеясына һәм наганына күз төшерде. «Әти чын-чыннан солдат булган бит, хәрби кием аңа нинди килешә!» — дип уйлады ул. Аннары Хәмит өстәл өстендә торган «Правда» газетасын кулына алды. Андагы Ленин портретына карап торды һәм эченнән генә уйлады: «Ленинны, мөгаен, әти дә күргәндер».**

**Камил, йөрүеннән туктап, тиз генә өстәл янына килде, урындыкка утырды һәм бер бит кәгазьгә кызу-кызу яза башлады...**

**Смольныйның тәрәзәләре зур. Хәмит алар аша урамны күрергә теләде, ләкин бозлы тәрәзәдән бары тик балкып янган электр утлары гына күренде. Аннары ул өстәл читендә «Җир турында декрет»ны тәрҗемә итүче әтисенә күз төшерде.**

**Хәмитнең әтисе Камил Мотыйгый татарлар арасында атаклы җырчы иде. Аны «Татар Шаляпины» дип йөрттеләр. Концерт залларында, кичәләрдә «Әллүки», «Тәфтиләү», рус җырларыннан «Чайка», «Не возвратная время» җырларын, шулай ук еврей, немец һәм поляк көйләренә татарча язылган җырларны җырлады. Ул Нәҗип Думавиның «Дөньяда» шигырен җыр итеп башкарды. Хәмитнең күңелендә бу җыр әле дә саклана:**

Без килмәдек китәргә, дөньягай,
Килдек гомер итәргә шул, вай дөнья.
Ләкин тормыш бозылган дөньяда,
Кыен гомер итәргә шул, вай дөнья!
Кайда михнәт, мәшәкать дөньяда,
Шунда эшче башыдыр шул, вай дөнья.
Кай җир сасы, кадерсез дөньяда,
Шунда эшче яшидер шул, вай дөнья!
Алла биргән һиммәтнең, дөньяда,
Барын байлар ашыйдыр шул, вай дөнья!

Менә шундый сәхнә кешесенең хәзер хәрби кеше булып китүе бераз гаҗәбрәк тә иде. Хәер, 1905—1906 елларда ук социал-демократик юнәлештәге газета һәм журналлар чыгарган кешенең Октябрь көннәрендә кулына корал алуы һәм патша чиновникларына каршы көрәшүе бик табигый иде. Камил — әнә шундый кеше. Ул — Уральскида «Әл гасрел-җәдит», «Уклар» журналлары, «Фикер» газетасы чыгарган редактор. Шушы газета-журналларда татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай үзенең шигырьләрен бастырды. Хәмитнең әтисе Камил белән Тукай бик дус булганнар. Кечкенә чакта Хәмитнең дә Тукайны күргәне бар.

Редакциягә берничә солдат кереп ниндидер ят телдә сөйләшә башладылар. Патрон тасмалары таккан кораллы кешеләр чыгып китүгә, Хәмит әтисеннән аларның нинди милләт кешеләре булуын сорады. Әтисе елмаеп улына карады һәм йомшак тавыш белән җавап бирде:

— Алар, улым, латышлар. Латыш укчылары һәм матрослары Смольныйны саклыйлар. Алар Ленинның ышанычлы сакчылары. Владимир Ильич аларны бик ярата.

Ленин турында сүз чыккач, Хәмит тагын да җанлана төште. Ул әтисенә бик якын килеп, аның гимнастеркасына тагылган кызыл бантка кызыгып карап, сорау артлы сорау бирә башлады:

— Синең Ленинны күргәнең бармы, әти! Мин дә аны күрә алырмынмы! Ленин хәзер Смольныйдамы!

Әйе, аның Ленинны күп мәртәбәләр күргәне бар, Ленин хәзер дә Смольныйда. шулай булгач, кем белә, бәлки улы Хәмит тә Ленинны күрер, бөек юлбашчының сүзләрен тыңлар. Камил улының аркасыннан җиңелчә генә кагып алды да, зур шатлык һәм горурлану белән, әнә шулар турында сөйләде. Аннан соң өстәп куйды:

— Менә бу бүлмәдә Владимир Ильич үзе эшләде.

— Шушы бүлмәдәме! — дип кабатлап сорады Хәмит.

— Әйе, улым, шушы бүлмәдә.

— Алай булгач, син Ленин бүлмәсендә эшлисең икән!

— Шулай, улым, мин аны берничә тапкыр күрдем. Ә беренче мәртәбә күрүем Финляндиядән кайтып, броневиктан торып речь сөйләгән вакытында булды.

Хәмит әтисенә елмаеп карады:

— Менә син нинди бәхетле кеше икәнсең, әти!

Камил урыныннан торды һәм, шинелен кия-кия улына эндәште:

— Әйдә, квартирага кайтабыз, әнием көтә торгандыр. Юлда барысын да сөйләрмен.

Камил башына солдат бүреген басыбрак киде һәм хәрбиләрчә тиз басып ишеккә таба килде. Хәмит тә үзенең гимназия формасындагы пальтосын төймәләде, «УГ» дигән эмблема куелган фуражкасын киде һәм, әтисеннән үрнәк алып, солдатларча басып апга атлады.

Алар, Смольныйның озын баскычларыннан төшеп, капкага таба киттеләр.

— Әти! — диде Хәмит, якты тәрәзәләргә күрсәтеп,— Владимир Ильич әнә шул бүлмәләрнең берсендә эшли торгандыр! Әнә, балкып торган тәрәзәләр аның бүлмә тәрәзәләредер!

— Әйе, улым. Ленин хәзер өченче каттагы 67 нче бүлмәдә эшли,— диде Камил.

Икенче көнне Хәмит, әтисе белән, яңа гына яуган йомшак кар өстеннән атлап, Смольныйга килде. Төш җитеп килгәндә Хәмит өчен әйтеп бетергесез шатлык булды: әтисе белән бергә, ашханәгә дип, коридор буйлап барганда, бер бүлмәнең ишеге

ачылды һәм аннан кара костюм кигән кечерәк буйлы, пеләш башлы бер кеше чыгып, ике-өч иптәше белән сөйләшә-сөйләшә, кызу гына атлап коридор буйлап китеп барды.

— Ленин! — диде әтисе Хәмиткә.

Хәмит зур дулкынлану белән Ленин киткән якка карады, йөрәге шатлык белән еш-еш типте...

Менә Смольныйда татар телендә «Ярлы халык» газетасы чыга башлады. Хәмит яңа гына типографиядән басылып килгән газеталарны бүлмәләр саен таратып йөрде.

Ленинны күрү өчен ул сәгатьләр буе коридорда һәм баскыч төбендә тора иде. Бервакыт шулай торганда, Ленин һәм хөкүмәт җитәкчеләре ишектән килеп керделәр. Хәмит яртылаш пыялалы ишек артына тиз генә ышыкланды һәм пыяла аркылы юлбашчыга озак карап торды.

...Газета чыгуында дәвам итте. Хәмиткә дә эш җитәрлек иде. 1918 елның 13 гыйнварында газетада шундый мөрәҗәгать бастырылды:

«Газета идарәләренә, китапханә мәләренә, газеталарда язып торучы мөхбир вә мөхәррирләргә һәм дә газетамызны укучы барча иптәшләргә!

«Ярлы халык» газетасы идарәсеннән гомуми үтенеч!

Иптәшләр! «Ярлы халык» газетасының бу номерын бик тиз чыгарырга ашыктымыз сәбәпле һәм Петроградта мөселманча матбага хәзергә бер генә булу сәбәпле, бу номер ярты гына булып чыкты. Киләчәктәге номерлары бөтен рәвештә дүрт битле булып чыгачаклар.

«Ярлы халык» газетасын хәзергә атнасына ике генә мәртәбә чыгарып, соңра һәр көн чыгарып торырга тырышачакбыз. «Ярлы халык» газетасының һәр номеры газета идарәләренә өчәр данә җибәрелә, моңа каршы мәзкүр газеталарның да «Ярлы халык» идарәсенә җибәрелә башлауларын мәзкүр газета идарәләреннән үтенәбез.

«Ярлы халык» газетасының ошбу номерын сату өчен китапханәләргә өч йөз данәдән, идарәмезгә бик яхшы мәгълүм булган һәм җәмәгать хадимнәре булып танылган берничә мөхтәрәм иптәшләргә илле данәдән күндерелде. Шул номерларның сатылган кадәресенең акчаларын, сатылмый калганнарының үзләрен кире «Ярлы халык» идарәсенә, газетамызның башында күрсәтелгән адрес буенча җибәрүләрен вә һәр каюм газетамызга абунә кабул итә башлауларын үтенәбез. Газетамызның башында язылган бәһаләр һич киметелми.

«Ярлы халык» газетасы идарәсенә каләме белән ярдәм итәргә теләүче хөрмәтле мөхәррир һәм мөхбир иптәшләребезне «Ярлы халык» газетасы идарәсенә килүләрен вә бәгъзеләренең үз-үзләреннән торып мәкаләләр җибәрүләрен үтенәбез.

Хөрмәт белән мәсьүл мөхәррир Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин».

Шулай ук газетада Владимир Ильич Ленин тарафыннан язылган җир турында һәм солых турындагы декретларның татарча тәрҗемәсе бастырылып, киң катлау укучыларга таратылды. «Ярлы халык» газетасы Камил Төхфәтуллин тәрҗемәсендә бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның мәкаләләрен халыкка җиткереп торды. Бу турыда шул ук номерда түбәндәге җөмләләр бар:

«Идарәдән.

Ошбу номер илә газетамызны алучыларның җөмләсенә хөкүмәтнең җир хакында, солых хакында чыгарылган декретлары һәм мөселманнарга гаед ителгән хитапнамәсе җибәрелә».

Шушы ук белдерү рус телендә дә бирелгән. Газетаның адресы түбәндәгечә:

«Петроград, Смольный институт, комната № 81, редакция газеты «Ярлы халкъ». Газетаның органы да күрсәтелгән: «Петроградта чыга торган мөселман социалистлар газетасы».

«Ярлы халык»та көн кадагына суга торган большевистик-ленинчыл мәкаләләр күп басыла. Бу мәкаләләр арасында «Учредительный собраниены тарату хакында декрет», «Иран мәмләкәтләреннән Россия гаскәрләрен чыгару хакында» дигәннәре аерата игътибарга лаеклы.

Әнә шул авыр, әчке һәм тышкы дошманнарга каршы кискен көрәш барган көннәрдә ук Камил Төхфәтуллин редакторлыгындагы газета татарлар арасында гына түгел, бәлки казакъ, кыргыз, үзбәк, төркмән, әзербәйҗан, башкорт һәм башка халыклар өчен ленинчыл милли политиканы үткәрүче милли газеталарның берсе була.

Газета Смольныйда өч айга якын чыгарылганнан соң, редактор Камил Төхфәтуллинны Петроград өчен икмәк хәзерләү эше белән Самарага җибәрәләр. Хәмит тә, әтисе белән бергә, Мәскәү аша Самарага килә, анда күп кешеләр белән очраша. Аңардан Ленин турында сорашалар. Әле унбиш яшь белән генә баручы яшүсмер менә шул чакта Петроградта күргәннәренә чын бәяне бирү дәрәҗәсенә җиткән була. Ул Смольныйда булган һәрбер очрашуның тирән мәгънәсен һәм Ленинның зур кеше, даһи булуын инде егет буларак аңлый башлый.

Самарага килүнең беренче көннәрендә үк Камил Төхфәтуллин баш-аягы белән эшкә чума. Яшүсмер Хәмит тә аңа булыша. Ул В. В. Куйбышев җитәкчелегендәге РКП(б)ның Самара губерна Мөселман Комитеты клубында эшли һәм 1918 елның 23 маенда Коммунистлар партиясе сафына керә. Хәмит Төхфәтуллин Мөселман Комиссариатында эшләүче Халыйк Садриның техник секретаре була. Ул япь-яшь килеш каты сугышларда катнаша: унбиш-уналты яшьләрендә разведчик, 25 нче Чапаев дивизиясенең политбүлегендә инструктор, казакъ полкында комиссар була. Фронтта ике мәртәбә яралана. Соңыннан бу кайнар йөрәкле кеше комсомол, партия һәм совет органнарында җаваплы эшләр башкара. Хәмит Төхфәтуллин татар опера һәм балет театрын оештыруда һәм үстерүдә зур тырышлык күрсәтә, директор һәм артист була. Муса Җәлилне шул театрга әдәби бүлек мөдире итеп чакыра һәм алар бергәләп милли опералар тудыру өстендә җиң сызганып эшлиләр.

Хәмит аганың хезмәтләренә партия һәм хөкүмәтебез югары бәя бирде. 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңае белән аңа «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале бирелде. Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгында гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Хәмит ага Төхфәтуллин Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде.

Унбиш яшеннән коммунистлар партиясенә кергән һәм халык бәхете өчен арымыйталмый эшләгән ветеран һаман үзенең данлы юлын дәвам итә.

...Ленинград. Смольный.

Таныш урыннар, таныш бүлмәләр. Менә шушы озын коридордан Ленин узды. Менә шушы 67 бүлмәдә пролетариатның бөек юлбашчысы Ленин эшләде. Хәмит ага Ленинны күрүен кабат-кабат күз алдына китерә. Ә Смольныйның ишек алдында уң кулын алга сузып бөек Ленин һәйкәле тора! Ленин — мәңгелек! Ленин яши!

## Владимир Диев

# МӘҢГЕ ТЕРЕ ОБРАЗ

*Ленинга багышланган драматургия турында*

Юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның 100 еллык бәйрәме совет сәнгатенең барлык тармакларында эшләүчеләр, шул исәптән театрлар һәм драматурглар өчен дә җитди һәм җаваплы имтихан булачак.

Драматургиябез әлеге юбилейга нинди байлык, нинди уңышлар белән килә соң? Бәйрәмгә кадәр калган вакыт эчендә бу сорауларга тулы һәм төпле җаваплар бирелер, дип уйларга кирәк. Хәзергә исә драматурглар һәм театрлар киеренке төстә Ленин турындагы яңа әсәрләр өстендә эшлиләр. А. Штейн, мәсәлән, «Лениниана» дигән шартлы исем белән яңа пьеса яза, МХАТ үз тамашачыларына М. Шатровның «Юбилей» исемле документаль әсәрен күрсәтергә җыена. А. Дубровский, Ленин белән Горькийның бер-берсенә язышкан хатларына нигезләнеп, «Диалог» исемле документаль әсәр тәмамлады. Ул Станиславский исемендәге театрда куелачак. Ленин комсомолы исемендәге театр «Безгә Ленин кушты» дигән пьеса әзерли. Әсәр комсомолның III съезды материалларына нигезләнеп язылган. Н. Вирта, И. Луковский, Ю. Семенов, шулай ук күп кенә башка әдипләребез Октябрь революциясе, Ленин турындагы яңа пьесалар өстендә эшлиләр. Кыскасы, Ленинга багышланган драматургия күп кенә яңа һәм үзенчәлекле әсәрләр белән тулыланыр, дип өметләнергә бөтен нигезләр бар. Шуның белән бергә, моңарчы язылган, матбугатка чыккан яки сәхнәдә куелган әсәрләргә нигезләнеп тә, бүгенге ленинианага хас кайбер гомуми сыйфатлар хакында хөкем йөртергә мөмкин булыр иде.

Ленинга багышланган бүгенге драма әсәрләренә һәм кинофильмнарга нинди үзенчәлекләр һәм характерлы сыйфатлар хас соң? Әгәр Корнейчукның «Хакыйкате», Треневның «Нева ярында»сы, Погодинның «Мылтыклы кеше»се, М. Ромм белән А. Каплерның «Ленин Октябрьда»сы кебек, бөек юлбашчыбызга багышланган беренче әсәрләрдә Ленин һәм Октябрь темасы, ничектер, гомуми пландарак, фронталь тестәрәк яктыртылса, бераз соңрак иҗат ителгән әсәрләрдә, әйтик шул ук Н. Погодинның «Кремль курантлары» пьесасында (1940) һәм «Ленин 1918 елда» (1939) исемле нәфис фильмда инде бу мәсьәләгә авторларның үзенчәлекле карашлары, үзләренчә якын килергә тырышулары, тагын да тирәнрәк итеп әйткәндә, теманы әдәби-субъектив пландарак хәл итәргә омтылулары сизелде. Алга таба Ленин темасын, Ленин образын сәнгатьчә сурәтләү алымнары һәм чаралары өзлексез байый, төрләнә торды. Бүгенге ленинианага, мәсәлән, стиль, жанр һәм интонация формаларының күп төрле булуы характерлы. Ленинга багышланган әсәрләр арасында без зур гомумиләштерү көченә ия булган плакат-паннодан (И. Сельвинский. Зур Кирилл.) халыкчан драмага (Д. Зорин. Мәңгелек чыганак.), документаль хроникадан (М. Шатров. Алтынчы июль) эре социаль полотнога (Н. Погодин. Өченче, патетик.), трагик яңгырашлы «Ленин турында хикәяләр» исемле фильмнан «Аппассионата»га кадәр төрле алымдагы, төрле рухтагы сәнгать үрнәкләре белән очрашабыз.

Бу мөһим теманы чишкәндә һәр художник үз юлы белән барырга хаклы, алай гына да түгел, үз юлы белән барырга тиеш тә. Бу кадәресе — бәхәссез хакыйкать. Әмма мәсьәләнең бәхәсле яклары да байтак әле. Әйтик, Ленин образын ничек һәм нинди ситуацияләргә куеп сурәтләргә! Аны, тарихның иң кульминацион, иң киеренке моментларына куеп, революция корбанының штурвалы алдында, Совет дәүләтенең идарә пульты каршында сурәтләргәме, я булмаса ял вакытларында, тормышның ыгы-зыгысыннан аерылып торган минутларында да күрсәтергәме! Сәнгать әһелләрен һәрвакыт борчып, тынгысызлап килгән сорауларның тагын бер төркеме менә шулар. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, аларга бер төрле генә җавап бирү дөрес тә, тулы да булып бетмәс иде. Әмма теләсә нинди ситуацияләрдә, теләсә нинди хәлләрдә дә Ленин Ленин булып калырга тиеш. Моны һич кенә дә истән чыгарырга ярамый. Аннан соң, Ленин образына мөрәҗәгать итү безнең драматургиянең үсешенә искиткеч уңай йогынты ясарга, образлар системасына Ленин образын кертү әсәргә зур драматизм хисе, андагы конфликтларга зур социаль яңгыраш өстәргә, бер сүз белән әйткәндә, драматургияне рухи баетырга тиеш.

Бүгенге сәнгатьтә Ленинга багышланган фильмнар һәм сәхнә әсәрләре бик хаклы рәвештә әһәмиятле урынны алып торалар. Бу өлкәдә озак еллар буе алып барылган эзләнүләр кызыклы һәм уңышлы нәтиҗәләргә китерә башлады. Күп кенә әсәрләрдә без Ильичның эчке дөньясына үтеп керүдә авторларның яңадан-яңа чаралар табарга тырышуын сизәбез. Ленин еш кына чын-чыннан драматик, ә кайчакларда хәтта трагик характердагы хәлләргә куеп сурәтләнә. Сәнгать әһелләре юлбашчы образын ничек кенә булса да хәзерге чорга якынайтырга, Ленинны бүген дә «барлык тереләрдән тererәк» дип күрсәтергә омтылалар. Ниһаять, бүгенге ленинианага характерлы тагы бер момент: документаль һәм әдәби юнәлешләр арасында үзара аралашу, үзенчәлекле иҗади ярыш бара. Мисалларга күз салыйк.

«Алтынчы июль» [1964] тарихи конкрет фактка таянып язылган. Мәсьәләнең нәкъ әнә шул ягына басым ясап, автор үзе: «Реаль вакыйгалар, тарихи документлар гына Ленинны тормыштагыча итеп күрсәтү өчен материаль бирә алалар дип саныйм»[1],— дигән иде. [Әдәбият, сәнгать әсәрләрендә реаль вакыйгаларга, документальлеккә игътибар итү бигрәк тә соңгы елларда көчәйде һәм аның объектив сәбәпләре бар. Әдәби-документаль жанрларга мөрәҗәгать иткәндә язучыны барыннан да бигрәк һәм беренче чиратта тормыш чынлыгы, хакыйкатьнең асылы кызыксындыра.]

М. Шатров тарихи-революцион үткәнне өстән-өстән генә сурәтләүгә каршы. Шулай ук Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйләнешле фактларны субъектив характерда аңлатуга һәм Ленин хакындагы әсәрләрдә сизелә башлаган артык гадиләштерү тенденциясенә дә каршы чыга. Үз иҗатында ул тулысынча документка таяна, чөнки автор документның драматик көченә тулысынча ышанып эш итә.

Шул ук вакытта документаль юнәлешне төп, бердәнбер юнәлеш дип раслау, әдәби фантазиягә, уйлап чыгаруга корылган әсәрләргә ышанмау белән дә килешеп бетәсе килми. Уйлап чыгару, фантазиягә корылган әсәрләр аша да гаять әһәмиятле ачышларга ирешергә мөмкин. Кыскасы, иҗади фантазия кирәкле түгел дип, аны сызып ташларга бик иртә әле. Документаль драма үрнәге булган «Алтынчы июль» үзе дә моңа ышандырырлык дәлил була ала.

Әсәр башкалабыз Мәскәүдә ике тәүлек дәвамында — 1918 елның 5 һәм 6 июльләрендә — булган вакыйгаларның тәгәл стенограммасы формасында язылган. Брест солыхы мәсьәләсендә большевиклар партиясе белән риза булмаган сул эсерлар нәкъ шул көннәрдә, ягъни 5—6 июль көннәрендә, баш күтәрделәр: алар Германия белән сугыш башлануны хупладылар, коммунистлар партиясенә каршы ачыктан-ачык террор юлына бастылар.

Зур театр бинасында Советларның бишенче съезды бара. Өстәл артында — президиум. Без, залда утыручы тамашачылар, ирексездән үзебез дә утырышта катнашучы делегатларга әверелгәндәй булабыз. Аннары вакыйгалар Мәскәүдәге немец илчелегенә күчә. Анда эсерлар коточкыч провокация оештыралар — Германия илчесе Мирбахны үтерәләр. Хәл чиктән тыш кыенлаша. Сул эсерлар большевикларга каршы ачык-

[1] Өзек Г. И. Моисеенконың «Советская культура» газетасының 1965 елгы 20 апрель санында басылган «Премьера алдыннан» дигән мәкаләсеннән алынды.

тан-ачык хәрәкәт итә башлыйлар. Ленинны һәм аның көрәштәшләрен юк итү, теләсә нинди чаралар белән Брест солыхын өзү, сугышны башлап җибәрү — аларның төп максаты әнә шундый.

Большевикларга, Ленинга әле кичә генә үзләре белән бер сафта, баррикаданың бер ягында торган кешеләр белән көрәшергә туры килә. Әсәрдәге драматик конфликтның көче әнә шунда. Күренешләрнең сәгатьләп, хәтта минутлап диярлек алып барылуы Ленин җилкәсенә төшкән миссиянең никадәр авыр һәм җаваплы булуын аңларга булыша. Монда һәр минут драматизм белән сугарылган. Ленин киеренке атмосферадан бер генә мизгелгә дә чыгып тормый. Пьесага нигез итеп алынган вакыйгаларның кискенлеге автор өчен үзмаксат түгел, әлеге киеренкелек Ленинны, политик даһи буларак, ныграк, тирәнрәк ачып бирү өчен кирәк...

Күптән түгел М. Шатров «Большевиклар» («Утызынчы август») исемле яңа пьеса тәмамлады. Авторның әйтүенә караганда, ул өч пьесадан торган («Егерме бишенче октябрь», «Алтынчы июль» һәм «Утызынчы август») «Революция драмалары» исемле трилогиянең соңгы өченче кисәге. «Большевиклар»да 1918 елда барган вакыйгалар тасвирлана. Әсәрдә гадәттә без аңлый торган характердагы сюжет линиясе бөтенләй юк дияргә була. Менә Халык комиссарлары бер-бер артлы Совнарком утырышына җыелалар, Ленинның килүен көтәләр. Ә ул, ни өчендер, гадәттә булмаганча соңга кала. Шул рәвешчә, Ленинны көткән арада үзара сөйләшә, агымдагы эшләрне тикшерә, бәхәсләшә башлыйлар. Горькийның политик позициясе турында сүз китә, Питер пролетариатына мөнәсәбәт хакында бәхәсләшәләр, монументаль пропаганда, бу әһәмиятле башлангычтагы формалистик, үтә сул тенденцияләр турында фикер йөртәләр.

Михельсон заводында Ильичка һөҗүм оештырылу хәбәре әсәрдәге вакыйгалар барышында кискен борылыш тудыра. Яралы Ленинны Халык комиссарлар советының чираттагы утырышы булырга тиешле бина күршесендәге бүлмәгә, ягъни юлбашчының Кремльдәге үз бүлмәсенә алып керәләр. Болай ул үзе пьесада бер генә тапкыр да күренми, ләкин без һәрвакыт аның каядыр якында гына булуын тоеп-сизеп торабыз, көрәштәш дуслары белән бергә аның сәламәтлеге өчен борчылабыз.

Пьесаның икенче пәрдәсе кискен контрастлар принцибына корылып язылган. Искиткеч шомлы, авыр кайгы... Шул ук вакытта үзеңне кулга алып, сугышчан постта кала белергә дә кирәк. Чөнки революция бер генә минут та көтеп тора алмый, чөнки кичектергесез эшләр һәм мәшәкатьләр дөнья кадәр. Һәркемнең күңелендә каршылыклы көрәш, вөҗдан газабы. Нишләргә! Юлбашчыбыз шундый авыр хәлдә ятканда утырышны башларгамы, юкмы! Менә Я. М. Свердлов очрашуны иртәгә калдырырга тәкъдим итә... Шулай да берникадәр паузадан соң: «Бәлки, кичектергесез мәсьәләләр бардыр! Без аларны игътибарсыз калдыра алмыйбыз»,— дип әйтергә мәҗбүр була. Икмәк турында, ач калган Мәскәүгә ничек ярдәм итү турында үзеннән-үзе бәхәс кызып китә. Берьяктан менә шундый көндәлек эшләр, борчу-мәшәкатьләр... Икенче яктан, Ильичның сәламәтлеге кыл өстендә. Тыштан караганда, болар арасында тирән каршылык та бар кебек. Чынлыкта исә берниндидә каршылык юк. Киресенчә, органик тәңгәллек бар: чөнки эшсезлек, шундый көндә кул кушырып утыру Ленинга, аның эшләренә карата игътибарсызлык булыр иде.

Яралы булса да, Ленин әлеккечә үк үз постында, аның акылы, ихтыяр көче һаман революциягә хезмәт итә. Бу — әсәрдәге төп фикер. Һәм аны белдерү өчен драматург уңышлы алым тапкан. Икенче пәрдә телеграфистка тавышы астында бара. Әнә ул Ленинның әле үзе исән вакытта ук язган телеграмма текстларын тапшыра. Революцион көрәшнең төрле характердагы мәсьәләләренә кагылган бу телеграммаларда шул кадәр һөҗүмчән энергия, эшлекле тон, аларда Ленин фикеренең, Ленин йөрәгенең тибеше шул кадәр ачык чагыла ки, үзеннән-үзе Ленин яшәде, Ленин яши, Ленин яшәячәк дигән фикергә киләсең.

Икенче пәрдәнең, шулай ук бөтен пьесаның иң югары ноктасы кызыл террор турындагы Декретны тикшергән моментка туры килә. Бу бәхәс беренче пәрдәдә булган хәлләргә караганда да катлаулырак шартларда (Ливнада контрреволюцион чуалыш, Воронежда яшерен корал складлары табылу һ. б.) дәвам итә. Һәм ул сугышчан пролетар гуманизм принципларының җиңүе белән тәмамлана.

Пьесаның финалы искиткеч зур тәэсир көченә ия. Менә Ленинның сәламәтләнә

башлавына чын күңелдән сөенгән комиссарлар — Ильичның көрәштәшләре, ант урынына әкрен генә, ләкин зур энергия белән, «Интернационал» сүзләрен кабатлыйлар...

Ленин образын иҗат иткәндә заманында «Кремль курантлары»нда һәм билгеле дәрәҗәдә М. Роммның 30 еллардагы киноленинианасында күренеп үткән лирик тенденцияләрнең алга таба үстерелешен «Ленин турында хикәяләр» исемле нәфис фильмда (С. Юткевич фильмы, 1958 ел) аеруча ачык күрәбез. Әсәр ике кисәктән тора. Беренчесе — «Солдат Мухинның батырлыгы» (М. Вольпин һәм Н. Эрдман сценариесе), икенчесе «Соңгы көз» (Е. Габрилович сценариесе) дип атала. Юлбашчы образын сәнгатьчә ачуда поэтик башлангычның көче аеруы Ильичның соңгы көннәре һәм аның үлеме турында сөйли торган «Соңгы көз» новелласында бигрәк тә ачык күренә.

Бу фильмда Ленин күбрәк гаиләдә, көнкүреш шартларында үзенең эчке уйлары һәм кичерешләренә бирелгән халдә сурәтләнә. Ленин образын бу рәвешчә тасвирлау әсәрнең социаль-философик һәм эмоциональ тәэсир көчен аз гына да киметми. Чөнки фильмның авторлары бик гади һәм бер үк вакытта бөек кешенең, революция житәкчесенең тормышы турында сөйләүне өсләренә алганлыкларын бер генә минутка да онытмыйлар. Бу фильмда шәхси һәм социаль пландагы күренешләр шул кадәр тыгыз бәйләнгәннәр, Ильичның революция, халык интересларына ахырына кадәр бирелгәнлеге, эчке дөньясы шулкадәр ачык һәм күзгә ташланырлык итеп сурәтләнгән, биредә шәхси башлангыч белән социаль пландагы күренешләр арасында киндидер чик эзләү үзе бер мәгънәсезлек булыр иде.

Картинаның бер генә эпизодын искә төшереп үтик: каты авыру хәлендә урында яткан Ленин радио аша чит ил тапшыруын (Е. Габрилович үзе икърар иткәнчә, бу эпизод тулысынча уйлап чыгарылган, чөнки ул вакыттагы радиоалгычлар чит илне тота алмаган) тыңлый, анда Ленинның көннәре санаулы гына, дип лаф оралар. Бу хәбәрне ишеткәч, аның күңелендә шундый давыл күтәрелә, аның фикере шул кадәр ярсуланып эшли башлый: ил ничек яшәр, күпме хәл ителмәгән катлаулы мәсьәләләр калды бит!.. Шундый уйлар, кичерешләр белән борчылган юлбашчы, врачларның катгый тыюына да карамастан, эшчеләр сыйныфының пульсын тагын бер кат тою өчен, заводка барырга мәҗбүр була. Бәлки сценаристка, реаль фактларга каршы барып, Ленинны мондый хәвефле адымга «этәрергә» кирәк тә булмагандыр (Тормышының соңгы айларында Ленин Мәскәүгә килгән, ләкин заводта чыгыш ясамаган, ди Габрилович). Ләкин безнең өчен авторның мәсьәләгә карашы, төп тенденциясе әһәмиятле. Бу нәрсә юлбашчының рухи, эмоциональ дөньясын ачуга багышланган «Аппассионата» исемле телевизион фильмда да нык сизелә.

Фильм шулай ук реаль вакыйгага, ягъни документка нигезләнгән. М. Горький үзенең юлбашчыга багышланган портретында аның Бетховен музыкасын яратып тыңлавы турында да сөйли. Фильмның авторлары, әлеге реаль вакыйгага таянып, Ленин уйлары һәм кичерешләренең туу процессын, аның күңел түрендәге тойгыларын күрсәтү бурычын үз өсләренә алганнар. «Аппассионата» фильмы Бетховен музыкасын тыңлаганда Ленин күңелендә туган уй-кичерешләр турында сөйли.

Һәр художник Ленинның эчке дөньясына үтеп керү өчен яңа алымнар һәм ысуллар эзли. «Кремль курантлары», «Ленин 1918 елда» исемле әсәрләрдә тупланган тәҗрибәгә таянып, аларның һәрберсе үз юлы белән бара, арырак китә. И. Сельвинскийның «Кеше үз язмышыннан өстенрәк» исемле философик трагедиясен төрлечә бәяләргә мөмкин. Тарихчы Г. Жук кебек, әйтик Ленинның үлем турында фикер йөртүләрен «үз-үзен тынычландыра торган идеалистик характердагы күп сүзле философия» [1] дип бәяләп, аларны әсәрдән алып ташларга да мөмкин. Г. Жук нәкъ шулай эшли дә. Шул ук вакытта пьесага бераз башкарак позицияләрдән чыгып та якын килергә мөмкин. Кайбер кимчелекләре булуга да карамастан, ул Ленинның эчке дөньясын аңлату, Ленин уйларының туу процессын ачу эшенә аерым яңалыклар кертә. Драматург шактый перспективалы юл сайлаган. Ленин образын ачуга фәлсәфи, поэтик, субъектив яктан килүнең зур мөмкинлекләре бар. Бу юлдан барып җитди җиңүләргә ирешергә мөмкин һәм ирешелергә тиеш тә.

---

[1] Г. Жук. Киләчәк буыннарның җаваплылыгы. «Советская культура» газетасы. 17 февраль, 1966 ел.

А. Штейнның «Көчле яңгырлар арасында» (1964) пьесасының яңа вариантында да игътибарга лаеклы бер момент бар. Сүз Ленин фикеренең туу процессын күрсәтү өчен кулланылган алымнар турында бара. Ленин йокламый, аны йокысызлык, тәнкыйтьче Н. Потапов сүзләре белән әйткәндә [1], «гасырның йокысызлыгы» борчый. Кронштадттагы чуалыш, ачлык, җимереклек илдәге политик моментны чиктән тыш киеренке хәлгә куя. Кая монда йоклау...

Бүгенге кино сәнгате Ильичның эчке дөньясын ачу чараларын эзләү юлында драматургиягә караганда да алданрак бара. С. Юткевичның Габрилович сценариесе буенча эшләнгән «Ленин Польшада» исемле фильмында (1965) яңаны эзләү, ачыш ясарга омтылу аеруча нык сизелә. «Кремль курантлары» ирешкән традицияләргә таянып, картина фантазиягә киң җирлек бирә, Ленин образына «яңа штрихлар өстәргә» тырыша. Бу картина үзенең стиле белән үк аерылып тора. Ул беренче кадрыннан алып соңгысына кадәр Ленинның эчке монологына нигезләнеп төзелгән.

Ленин турындагы пьесалар һәм кинофильмнарның саны арткannan-арта бара. Шулай да чын-чыннан әдәби ачыш булып саналырлык әсәрләр бик аз әле. Лениниана-да яңаны үзләштерү еш кына тирәнгә үтү хисабына түгел, ә иңгә киңәю хисабына бара: Ленин биографиясенең әле драматургиядә һәм кинода өйрәнелмәгән әһәмиятле этаплары, Ленин яшәгән һәм эшләгән урыннар үзләштерелә. Ленин биографиясенең сәнгать казанышына әверелгән һәр яңа сәхифәсе укучылар һәм тамашачылар тарафыннан һәрвакыт зур кызыксыну һәм рәхмәт хисләре белән кабул ителәчәк. М. Донскойның «Ана турылыклыгы» фильмының (З. Воскресенская сценариесе) зур уңыш казануы очраклы түгел. Ул 1963 елда дәүләт премиясенә лаек булды. Ләкин тамашачы Ленин турындагы яңа әсәрләр белән очрашудан гади информация, бер калыпта эшләнгән вак әйберләр түгел, ә рухи һәм эстетик азык көтә.

Октябрь, Ленин темасы художниклар өчен һәрвакыт иң җитди имтихан булып торды. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу кебек бөек дата алдыннан сәнгать әһелләренең җаваплылыгы, һичшиксез, тагын да артырга тиеш. Художник революциянең үлемсез юлбашчысына мөрәҗәгать итәргә һәрвакыттада да хаклымы! Моның өчен ул иҗади, политик, рухи яктан өлгергәнме! Ленин хакында язар өчен ул катгый эчке ихтыяҗ сизәме! Аның бу әсәре Ильич образын кертүне таләп итәме! Ленин образын гәүдәләндергәнче язучы әнә шул сорауларга җавап бирергә, аннары гына каләмгә тотынырга тиеш.

Менә шундый иҗади таләпчән булмауның бер үрнәге: Кече театрда, Октябрьның 50 еллыгына багышлап, Е. Симоновның «Джон Рид» исемле пьесасы куелды. Әсәр шигырь белән язылган, вакыйгалар Америкада, Мексикада, Россиядә бара. Без төп герой белән бергә йөрибез, ул очрашкан кешеләр белән очрашабыз. Ләкин бу очрашулар кызыксыз. Алар яки купшы (Америкада, Россиядә булган күренешләр) яки мәгънәсез, бизәкле экзотика белән сугарылган. Герой бөтенләй эшлексез, пьесада аның бердәнбер эше — үзенә карата әйтелгән мактау сүзләрен тыңлап тору һәм күзәтү. Пьесада да, постановкада да әдәпсез хискә бирелүчәнлек күп, шигырьләр альбом җыры дәрәҗәсеннән узмаганнар. Пьесада да, спектакльдә дә Ленин образы борчылырлык тәэсир калдыра. Советларның II съезды трибунасыннан чыгыш ясавы да, Джон Рид белән әңгәмәсе дә уңайсызлану, аптырау хисе тудыра. Монда тирән фикерләр дә, кичерешләр дә юк — шуларга охшатырга тырышу гына бар.

Икенче нәрсәне дә истә тотарга кирәк. Ленин турыдан-туры катнашмаса да, Ленин идеяләренең тантанасын, ленинизмның җиңелмәс көчен хәрәкәттә күрсәткән пьесалар һәм кинофильмнар да лениниана белән тыгыз бәйләнгән. Монда без илдә социализм һәм коммунизм төзү, коммунистик әхлакның җиңүе, эшчеләр сыйныфының, колхозчыларның, интеллигенциянең хезмәт батырлыгы, космосны кыю буйсындыручылар турындагы әсәрләрне дә кертәбез. Кызганычка каршы, андый әсәрләр аз әле. Ә халкыбызның бөек Ватан сугышындагы батырлыгы! Тугандаш илләрдә социализм төзү, интернационализм идеяләренең бөеклеге! Изелгән халыкларның империализмга һәм раса дискриминациясенә каршы көрәше! Барлык бу темалар үз гәүдәләнешен табарга тиешләр.

---

[1] Н. Потапов. Ленинга кыен иде... «Театр» журналы. 1965 ел. 9 сан. 80 бит.

## Хәсән Туфан

# МОГИКАН

*Кечке поэма*

«А, ишетегез ла, китерегез,
китерегез мина чәчәкләр!..
*Фатих Әмирхан.* 1921.

Көзнен инде — сары чагы иде,
Безнең исә — яшькелт мәлебез.
Гомернең дә көзе бардыр бит дип
Уйламый да,
Уйламый да идек әле без...

I

...Урамнарда — көзге Казан киче.
Шундый җылы, аяз кичләрдә
Проломныйга чыгып китә идек
Такташ белән... «Һава иснәргә»...

Урам исә — кызыгын да сиңа,
Бозыгын да тәкъдим кылгалый.
Икешәр юл шигырь әйтәсең дә,
Килә-чыга — уртак робагый.

II

... Алып китте шулай
Безне урам,
Баеп барган кояш ягына.
Шаулап торган Проломныйны үтеп,
Килеп чыктык
Кремль ярына.
Хәтерләптер, бәлки, Казанына
Килен булып килгән көннәрен,
Басып тора ярда
Сөембикә...
Күзәткәндәй нугай далаларын,
Ерактагы туган илләрен,
Басып тора ярда...

## III

... Уйга калып, бераз карап торгач,
Кулын куеп минем җилкәгә:
— Башла әйдә, Брамат,— диде Такташ,—
Берәр сүз әйт Сөембикәгә...

Мин башладым:
— Сезнең йөзгә, Сөембикә ханым,
Җил-давыллар азмы кагылган...
Такташ тәмамлады:
— Кагылса да... бар бит, сау бит әле
Әдәбият «ханы» — Әмирхан...

## IV

... Көтелмәгәнчәрәк булды ла бу —
Уйнап кына әйткән робагый.
(«Кыек атып туры тидерүләр»
Булгалый шул кайчак... булгалый.)

Уйнап кына «тиеп»
Тетрәп куйдык:
— Ул, чынлап та, бар бит, сау бит әй! —
Классиканың рухи әмир-ханы —
Аяклары бәйле Прометей,
Сау бит әй...

Без — керәбез генә әле Дауга,
Тарихыбыз Давылларына.
Ә ул инде
Чыгып килә аннан,
Чыгып килә... ахыр ягына...

## V

... Безнең әле
Үтә яраткан төс
Бары зәңгәр, бары ал иде.
Безнең инде анын «төсенә» дә
Тел тидергән чаклар бар иде,
Бар иде...

Нигилизм аны — «Искермеш»не
Күмдермәкче иде тереләй:
Ул, янәсе, — аристократ әдип,
Без, янәсе,— люмпен, плебей!..
Шелтәләдек шунда үзебезне,
Шелтәләдек шактый, аямый:
— Бармы аның хәлен белгәнебез?
— Яшь буыннан сәлам! — дигәнебез?
— Бармы?
— Юк...
Ярамый бит болай, ярамый...

Без — керәбез генә эле Дауга,
Ил язмышы давылларына...
Барыйктыр без,
Барыйк бүген аңа,
Хәерле юл алып калырга.

## VI

... Урамнарда — көзнең гамьсез киче...
Менә шундый — ямьсез кичтә без,
Дәшми генә, моңсу гына атлап,
Дәү абыйга сәлам илтәбез...

Килдек.
Аякларны салдык, чишендек тә,
Гөнаһлылар кебек, иелдек тә
Кердек аның
Изге өенә...
Хәл белүдән битәр
Легендарның,
«Могикан»ның үзен күрергә.

## VII

...Гаепле дә аның каршында без,
Гөнаһлы да бераз, гомумән...
Олы җанлы кеше буларак ул,
Каршы алып ачык йөз белән
Урын бирде безгә түреннән.

Тартыныпмы,
Әллә олыларга
Хөрмәт дигән гадәт беләнме,
Тартуга да — «тәүфикъ керде» безнең,
Иләслек тә — әдәплеләнде.

Шәмен түгел, җанын ягып гүя,
Яктыртты да безнең күңелне,
Бер карауда күреп алды бугай,
Ниятебез яман түгелне.

## VIII

... Сүз бераздан
Шигырьләргә күчте.
Ул — сорады, ә без — укыдык...
Шактый сәер, «яңа» шигырьне дә
Тыңлый кебек иде йотылып.

Тыңлый... ләкин күңел күзе аның
«Әльислах»ка барып килә күк [1],
Яшьлек чорын аннан, шаулы чорын,
Тукай чорын алып килә күк...

---

[1] «Әльислах» газетасының мәгъләвн җитәкчесе булган чорына.

## IX

...Ялгыз йолдыз кебек якты, биек,
Ялан кырлар кебек киң җаны
Ача безгә:
Чаршау артындагы —
Үткәндәге серле дөньяны.

Ача безгә:
Гасыр башларының
Кара-усал, кыркү елларын,
Столыпин держимордаларын,
Ильминский «культурник»ларын...

Без ишеткән идек инде аның,
Инкыйлапны — Бөек Октябрьны
Ничек сөенеп көтеп алганын,
Ат җиктереп арба-трибунага
Авылларга китеп барганын,
Аны яклап аваз салганын
Белә идек инде.

Безнең шуңа, шушы мөһим хәлгә
Ымлаганны тойды, тойды ул,
Гаҗәпләнеп, бераз кискенләнеп,
Дулкынланып
Әйтеп куйды ул:

— Кем соң, кем соң,
Барлык вөҗүдемнең,
Йөрәгемнең асыл дуслары? —
Татарымның кулы сөяллесе,
Татарымның йөздән туксаны!

## X

... И сөйләштек шунда, и киңәштек,
Кичне, төнне, соңны белмичә:
Имтиханы бугай шигырьләрнең,
Сыналуы иде бу кичә.

Коеп куйган әдип кенә түгел,
Бу агай да тирән дипломат:
Тукаена күчереп әйтә фикерен,
Мисал итеп аны тик фәкать.

Безне шулай
Өнди бугай агай
Сөйләп бары — бүтән турында.
«Коеп куйган шагыйрь генә» түгел,
Тоеп туган шагыйрь булырга!

## XI

... Уйланабыз...
Заман бүтән инде,
Еллар безгә
Чикләр куймастыр.
Тояр өчен туган йөрәкләрне
Тыя торган көчләр булмастыр,
Еллар юлга киртә куймастыр...
Әгәр шагыйрь ил иманы аша
Тоя алса реаль дөньяны,
Эгоистик «идеал» тәңрәсенә
Төртендерә ала кем аны,
Кем!?

## XII

Шәмен түгел, җанын ягып гүя,
Яктыртты да безнең йөзләрне,
Бер карауда күреп алды бугай
Бездә туган изге хисләрне.

Ялгыз йолдыз кебек якты, биек,
Ялан кырлар кебек киң җаны
Ачты безгә
Реаль вакыйгалы,
Романтика тулы дөньяны.

Ничә кабат эндәшсә дә сәгать
Ишарәләп цифрларына,
Игътибар да итмәгәнбез ласа,
Бичараның шыңгырдавына.

Нәкъ уяныл киткән кебек булдык
Төн уртасы килеп җиткәндә...
Тирән уйга талып, әйтеп куйды,
Саубуллашып кулын биргәндә:
— «Сез чәчәкләр китердегез миңа,
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, энеләр...»
Чәчкә идемени әле алар —
Без китергән шигъри бөреләр? —
Чәчкә идемени?..

Урамнарда — көзнең сары төне.
Безнең әле — яшькелт мәлебез.
Безнең бу кич поэмадыр бит дип
Уйламый да,
Уйламый да идек әле без.

# Әй!!.

Бөтен юллар Римга илтә иде
Цицероннар исән чакларда —
Илләр хәзер сәфәр итә инде
Ленинныбыз дәшкән якларга.

Кырыс сафлар жыя яңа Спартак.
Теге Спартак ауган җирләрдә.
Юк, бу юлы аны, икенче кат
Мөмкин түгел инде җиңәргә.

Коллык чорын, феодаллык чорын,
Колонияләр чорын уздырып,
Пентагонның «ярдәм» коймаларын,
«Азат дөнья»ларын туздырып,

Туганнарым килә барлык юлдан
Кырыс, гадел, гуман туганнар,
Сине, магнат, гильотиналарга
Һәм дарларга сөйри торганнар.

Бәлки алтын синең таянычтыр?
Бәлки атом синең яклыдыр?
Бәлки синең солдат ышанычлы,
Бульдог сыман эрсез сакчыдыр?!

Сары шайтан булып, сине алтын
Һәлакәткә этәрмимени?
Кешелекнең кин нәфрәтен атом
Сиңа каршы күтәрмимени?

Дөнья көтә үзенең түбәсенә
Байракчысы менәсе көнне.
Менәр, әләр
Берлин гөмбәзенә
Ал байраклар элгән шикелле.

Әй мамонтлар, мостодонтлар сыман
Җирдә токымы бетәчәк нәсел! —
Коммунизм алмый кала торган
Континентың бармыни хәзер?!

## Ник

Көньяк Африка республикасында һәм Синцьзянда геноцид (төп халыкны юк итү) политикасы кулланалар.

*Газеталардан.*

Гаугадан, илләр давыннан
Туептыр бәлки тәмам,
Аккошта, каен төбендә
Уйланып ята Заман.

Сөйләнеп ята Замана
Тавышсыз, өнсез генә:
— «Кем җиңә — Җирдә бары
тик
Шул токым өстен игә?!

Ник адәм,
Дарвин буенча
«Җайлый» да мәсьәләне,
Шым гына эшкә ашыра
Геноцид «фәлсәфә»не?»

Гаугадан, илләр давыннан
Туйгандыр бәлки тәмам,
Урманда, кышкы аланда
Уйланып ята Заман:
«Ник бары җиңә алучы
Яшәргә хаклы һаман!?
Ник, ник»?

## Алар өчен дә

Истәлекләр генә калганмыни
Сиратларны кичкән хисләрдә? —
Әманәте калды ирәннәрнең,[1]
Васыяте калды исәндә,
Сиратларны кичкән хисләрдә.

Вакламый да, ватмыйча да ышан,
Тавыштан ук таны, танысаң.
Әгәр дә син — безнең варис булсаң,
Әгәр дә син — безнең кан булсаң,
Вакламый да, ватмыйча да ышан.

Факел кебек, чыраг кебек затлар
Яна-яна авып калдылар.
Соңгы сулышта да сезне алар —
Киләчәкне искә алдылар,
Яна-яна авып калдылар.

---

[1] Ирән — халык өчен яшәүче.

Ауганнарның
Соңгы, ахыр сүзе
Истә һаман, истә, исемдә.
Үзем өчен генә түгел минем,
Торасым бар алар өчен дә,
Алар өчен дә.

●

Хисләр утын түгел дә бит,
Кайбер «салкын» кичләрдә
Үкерә-үкерә янды мичтә,
Терелэй янды... хисләр дә.

Сөю дә матдә түгел дә,
Ул да янды кайчакта...
Рифә! Рифәм!
Синең «гүрең» —
Көлең кайсы учакта?!

## Робагыйлар

Җирдәге Кешең, атом,
Нинди яшь, бөек җисем.
Кемнәрең юктыр тагын
Мәңгедән бирле синең?!

●

Ачарсың — атом серен,
Белерсең барысын да син:
Нинди яшь әле, Кеше,
Мәңгелек каршында син!

●

Бетәсең килмиме һич?
Нидән бу, ничек, нигә?
Матдә ул — мәңгелек ич,
Артмый да, кимеми дә!

●

Фәнгә юл ача-ача,
Алга юл ера-ера
Синмени? —
Синең аша
Атомнар нида кыла...

•

Син, атом, саннар сыман,
Чиге юк, серле әсәр.
Мәңгелек синең юлың,
Мәңгелек синең сәфәр...

•

Мәңгелек сезнең гомер,
Мәңгелек атомнарым...
Нигә соң шундый түгел
Атомнан туган җаным!?

•

Кадерең бел, Җир, өстеңдәгеләрнең:
Син дә бит бер
Ай кебек үк шып-шыр калырсың.
Мәңгелекнең төпсез тынлыгында,
Галәм чүлләрендә каңгырганда
Кемгә кычкырырсың? —
Кемгә шунда аваз салырсың?..
Кешеләреңнең кадерен бел, Җир, кадерен...

•

Һәр инкарьне
Инкарь итеп үтәсең син,
Саннарыңнан сыйфатларга күчәсең син.
Бу мәңгелек, бу чиге юк тәҗрибәңнең
Әйтерсең лә, нәтиҗәсен көтәсең син...

Барлас Камалов

# КҮРШЕЛӘР[1]

ПОВЕСТЬ

## 1



Йокысы туеп җитмәсә дә, Габделбәр кояш чыгарчыкмас ук торып басты. Киерелде-сузылды, авызын зур ачып иснәп алды. Аннары олы як стенасы буендагы караватта яткан хатынына эндәште:

— Сәяра!

Тегесе йоклый иде бугай. Габделбәр кычкырыбрак әйтте:

— Сиңа әйтәләр, Сәяра!

Хатыны уянды.

— Әү димен... Ни бар? — Аның тавышы тонык кына булып ишетелде.

— Хәлең ничек?

— Әйбәткәрәк бара төсле. Кичәге кебек үк тинтерәтми. Уколның файдасы тиде, ахры... Елизавета Кузьминичнаның кулы җиңел аның.

Сәяраның хәле арурак булып та урыныннан тормавы, җитмәсә ашыгыч ярдәм машинасы белән килеп, укол кадап киткән врач хатын турында сафсата сөйләп ятуы Габделбәрнең ачуын чыгарды. Хатынының йөрәк өянәге соңгы елда ешаеп китүгә йорт башының гомумән кәефе кырыла иде. Чөнки өйдәге бөтен эш үз иңенә төшә. Ә мәшәкатьнең исәбе-чуты юк. Төзү материаллары складына эшкә бармыйча, кенетөне йорт тирәсендә тулганса да таманга киләсе. Төп хезмәткә бармый ярамый да ярамый...

Мондый көннәрне ул үзалдына мыгырданып, эченнән сүгенеп йөри. Кырык биштән узар-узмас ук йөрәген капшап, ах-ух килеп, күз асларында капчыклар кабартып яткан хатынына җене чыга, эти-әнисенә айга бер хат язып кына эшен беттегә санаган улы Әгъдәскә рәнҗи, егерме яше дә тулар-тулмас кияүгә чыгып киткән кызы Әлфияне тозлап-борычлап сүгә.

Дөрес, Сәярасы аякка басып, хуҗалыктагы эшләрнең һәммәсен кырып-себереп башкара башлагач, Габделбәрнең ачуы сүрелә, мыгырданмас була, орды-бәрде килеп йөрми. Андый чакта хатыны да сөйкем-

[1] Кыскартып басыла.

лерәк күренә, Улын искә алып, кәефләнеп куя. «Молодец, Әгъдәс! — ди ул.— Булдырдың! Текәтау поселогында гына түгел, Казанның үзендә дә художество академиясен тәмамлаган художниклар бик мыжгып тормый әле. Бас әйдә дөньяның стартерына, улым! Газуй! Ленинград-ның атаклы рәссамнарыннан уздырып җибәр. Лауреат булырга кирәк. Медален тагарга, акчасын күрәп алырга! Тик минә теге латыш кызына өйләнүең генә... Хәер, төкеримсәнә сезнең эшегезгә. Җаны теләгән, җылан ите ашаган...»

Кызына килгәндә, Габделбәр аның кияү сайлавын яхшы дип таба. Ни әйтсәң дә, ире — район прокурорының ярдәмчесе, ил-көн алдында дәрәҗәле, нәсел-ыру каршында абруйлы кеше. Әлфия үзе дә акылсыз түгел. Урта мәктәпне бетереп чыккач ук, институтка китәм, дип апты-ратмады, район судына секретарь-машинистка булып урнашты. Бала-сына дүрт-биш яшь тулгач, читтән торып укый башлады. Ярамаган-мыни хатын-кызга. Укуы бер бетмәсә бер бетәр. Юридик факультет дипломын кулына алгач, машинистка булып, бөкерәеп-чекерәеп утыр-мас, ким дигәндә бер нотариус булып урнашыр. Җаен белгән кешегә галәмәт тә кулай һөнәр ул...

Габделбәрнең шулай юанган-сөенгән чаклары да еш була, әмма бүген сөмсере коелган иде аның. Ул дырыс-дырыс басып чоланга чыкты, газ баллонының кранын борды, аннары кухня якка кереп, камфоркаларның берсенә ут элдерде. Плитә өстендә көнбагыш чәчәк-ләредәй ялкын телләре биешә башлагач, йорт башы зур яшел чәйнек белән җылытырга су куйды. Беренче эш итеп кырынып алырга ният-ләде.

Ул терәкле зур гына көзгене олы яктагы залның өстәленә китереп куйды, сабын күбеге ясады һәм помазогы белән сакал-мыек тирәләрен, яңак буйларын шау күбеккә күмде. Гөбердәп торган сабын күбеге аның бөтен битен йомшартып җибәрде. Габделбәр, хәвефсез пәкесен алып, чигә буеннан кырына башлады.

Ләззәтләнеп, тәм табып кырынды. Аның шомарып, чип-чиста булып калган йөзендә алсулык арта төште, зур кара күзләре тагын да киңрәк ачылгандай булып китте.

Габделбәр көзгедәге шәүләсенә күз кысып куйды. Булдырдык, янәсе. Яшәрдек бер ун елга. Зур эшмени? Аның өчен кенкүреш комби-натына барып, парикмахерскаяда чират торсынмыни? Куллары калты-равык адәм имгәгеме әллә ул кырынган саен егерме биш-утыз тиенен сибеп йөрергә?! Чәчтараш ханым тиеннәр белән генә кала дисеңме? Гомердә юк. «Одеколон сибикме? Шипр сибәбездер. Чәчәк одеколоны малмыни? Аның исе мәет яткан ызбаны хәтерләтә» дип, башыны-битеңне кыйммәтле одеколон белән чылата. Алай гына күңеле булмый әле аның. «Компресс ясыйбыздыр ич, Габдулбар Гафурич?» дигән була да, син эһ дигәнче, кайнар суга манып сыккан ак тастымалын яңак-ларыңа китереп чәпи. Булдымы дип, урыныңнан калкынырга итсәң, юк икән әле, чәч остасы массаж ясыйм дип бәйләнә. Ясый да. Нечкә нәфис бармаклары белән иякләреңне, бит алмаларын, борын яңакларын сыйпап-сылый, җыерчыкларыңны язгандай итә. Аннары да канәгать булмый парикмахер түти. «Пудра кирәкме, Габдулбар Гафурич?» дип әрсезләнә.

Бу тиклесе чамадан тышка китә инде. Хатын-кыз кавымыннан түгел ич Габделбәр. «Юк, юк, пудра кирәкми. Рәхмәт!» дия-дия кузгалмак була. Купмый гына тор икән әле! Апаң, үткен кайчысын чак-чок ките-реп, каш тирәңә үрелә. «Шундый куе, килешле кара кашны болай туз-гытып йөрү шәп түгел», ди һәм арпа кылчыкларыдай төрлесе төрле якка тырпаешканнарын кисеп ташлый. Габделбәрне өф-төф итеп әйлән-дерү-тулгандыру кызыл иренле апаңның «С Вас рубль десять» дигән сүзләре белән тәмамлана.

Бер сум ун тиен! Җилгә очкан акча лабаса. Аңа бит бер ел кырынырга җитәрлек дүрт пачка лезвие алып була.

Менә ич әле, ун минут вакыт узмагандыр, Габделбәрнең йөзе-бите ялт итеп калды. Савытын-помазогын юасы, корытасы бар барын. Тик ансына да кесәңнән чыгарып түлисе түгел лә!

Габделбәр юынды да залдагы заграничный трюмо каршысына килеп басты. Бармак очлары белән яңакларын капшаштыргалады, кашларын сыпырып куйды, пижамасының күкрәк кесәсеннән тарагын алып, кырау төшә башлаган кара чәчен тарады.

— Егет җилле, яше илле,— диде ул эченнән.— Кырынып кына яшәреп китәр заманнарың үтеп бара түгелме соң, иптәш Гафуров? Да-а, брат, кызлар сайлар чагың түгел шул инде. Сугыш дигәнең дә кучтәнәчен биреп калдырды: уң аягың тездән бөгелмәс булды. Аякмыни? Таяк! Өстерәп йөрисе...

Әмма ул шул минутта ук кукраеп та куйды. «Илле өч тулу әллә ни түгел ул, иптәш Гафуров. Дөньяның койрыгын кулдан ычкындырырга ярамый әле. Ярамый!»

Габделбәр көзгедәге сурәтенә текәлде. Озын, таза гәүдә. Киң җилкәләр. Иңнәрдә куәт җитәрлек. Күзләр дә очкынланып яна. Дөрес, очланып торган калын борын төбеннән авызга таба ике яклап җыерчыклар сузылган сузылуын. Маңгай буразналарын да массаж-мазар белән генә яшереп булмый. Ләкин, ничек кенә димә, фани дөньяның артына тибеп яшәрлек дәрте дә, дәрманы да бар әле. Акылы, тәҗрибәсе дә җитәрлек.

Өстенә телогрейкасын, аягына иске күн итеген киеп, башына уңып беткән эшләпәсен эләктереп ишек алдына чыкканда, кояш казык буе күтәрелергә өлгергән иде инде. Аңа иң беренче сәлам биргән җан иясе оясы янына чыгып баскан овчаркасы Пират булды. Бу җанвар бик нык, рөхсәтсез килеп кергән кешене күз ачып йомганчы бугазлап ыргытырлык. Пират, йортны әйләндереп алган тимер чыбыкка тагылган чылбырын шылдыратып, хуҗасы каршына йөгереп килде һәм алдына сузылып ятты. Йорт сакчысы күзләрен мөлдерәтеп Габделбәргә карады, ялагайланып, юан койрыгы белән такыр итеп себерелгән җирне шап-шоп кыйный башлады. Хуҗасы иелеп Пиратның башыннан сыйпады, колак артларын кашыгандай итте. Хуҗаның кәефе ярыйсы икәнен чамалап алган эт, яткан җиреннән торып, ал аяклары белән Габделбәрнең күкрәгенә сикерде, бер алдына, бер артына чыкты, чинап-чинап алды.

— Сабыр, Пират, сабыр гына...— диде Габделбәр, түземсез кылан-ган этне читкәрәк куып.— Пшул ояңа, пшул димен... Ай-һай да тәкатьсез булырсың икән. Карасана син аны, атна буе ач тотканнар диярсең. Хәзер димен, хәзер бирәм ашарыңа...

Габделбәр калын-калын нарат бүрәнәләрне урталай ярып салган зур сарай ишегендәге бияләй кадәрле йозакка үрелде. Зур ишекне каерып ачты һәм сарайдагы зур калай табактан ит кисәкләре алып, Пират тагарагына илтеп салды. Кичә, гадәтенчә, тимер юл станциясе артындагы сугым йортына кереп, бу итләрне этенә дип алып кайткан иде.

Пиратның комсызланып ашавына күз салып торган арада тирә-юнена ак кар яугандай булды. Габделбәрне егермеләп ап-ак тавык сырып алган иде. Аларның уң канатларына алсу буяу тидерелгән. Күрше-күләң тавыклары белән бутамаска яхшы була. Кош-корт дигәннәрең, куначадан төштеләрме, уңны белмиләр, сулны белмиләр, тамак дип тәмугка керергә торалар. Әнә йөнтәс тәпиле ак әтәч, батыраеп китеп, Пират алдындагы итне чукымакчы. Тик тегесе әдәп саклап маташмады, юеш кара күн төсле борынын җыереп, күзләрен алартты да, әтәчкә таба ыргылып:

— Һа-ам! — итеп куйды.

Габделбәр башта Пиратка янап алды. Чамалабрак, янәсе. Аннары әтәчне тагарак яныннан куып җибәрде.

Хуҗа янә сарайга юнәлде.

— Ти-ти, ти-ти, ти-ти, әйдәгез, ходаның мәхлуклары, үзегезгә җим бирәм. Әйдәгез, әйдә, ти-ти,— дип такмаклый-такмаклый тавыкларны ишек алдының икенче башына чакырды.

Гәрәбәдәй бодай сипте ул аларга. Тегеләре шундук җиргә төртеләләр, ләкин, озак та үтмәде, берәм-берәм су савыты ягына йөгерделәр. Бодай орлыклары яртылаш кына кимеде. «Симерүләре җитте,— дип уйлады Габделбәр,— первый сорт бодайга да исләре китми, ә?»

Чират казларга җитте. Лапасны ачуга, иң әүвәле гайрәтле кыйгылдап ала ата каз чыкты. Шуннан, егерме-утыз бәбкә ияртеп, ике ана каз ишек алдына атлады. Уңа башлаган сары йоннан чорнаган йомгаклар кебек бәбкәләр «пи-бип, пи-бип» дия-дия үз телләрендә нидер серләшә башладылар. Бармак буынтыгыдай гына муеннарын сузып, көн дә туклана торган зур китек таба янына ашыктылар. Габделбәр абзалары аларга кичтән үк хәстәрләп куйган сыйларын бирде.

Ишек алдындагы кош-корт тавышын абайлап, абзардагы сарыклар бәэелди башлады, сыер мөгерәп куйды, «каты борын» мыркылдарга тотынды. Өлгер генә!

Койма баганасына кадакланган юынгычта кулларын югач, Габделбәр сыер саварга кузгалды. Сыерның алдына тас белән силос куйды (көздән бер баз хәстәрләп куйган иде). Тирә-юньгә әчкелтем ис таралды. Силос исе генә түгел иде бу, сыек яшел боткага кушкан нашатырь спиртының исе дә борынны ярып керә иде.

Исенә чыдарга була. Аның каравы азыкка нашатырь спирты катнаштырдыңмы, сыерның сөте арта. Спирттагы аммиак азыктан аксымны мул бүлеп чыгара икән. Габделбәр бу хакта ниндидер журналдан укыган иде. Иң беренче башлап моны Венгрия галимнәре сынап караганнар ди. Габделбәр моның дөреслегенә үз сыеры мисалында ышанды. Дөньяда күзле сукыр гына була. Мал-табыш үзе кулыңа төшәм дип тора ул. Бәс шулай икән, форсатны ычкындырма инде. Бер ычкындырдыңмы — бетте. Аннары аяктан калганчы, күзең чекерәйгәнче эзләсәң дә таба алмассың. Бабайлар да бер дә юкка гына «тормышың — кыдырмышың» димәгәннәрдер. Барын да калдырмыйча күреп-белеп, эзләгәнең, татып йөргәнең, тапканың хәерле. Суга керсәң, чишенеп кер, тормышка керсәң — сызганып!

Сыерны, сарыкларны тиз-тиз көтүгә кугач, Габделбәр дуңгызны туендырды. Койрыгын алкаландырып, савыттагы әче апарага кискәләп салган икмәк кисәкләрен чап-чоп китереп ашаган дуңгыз баласына карап, аның күңеле күтәрелеп китте. «Бүрек кадәр нәмәрсәкәй иде. Тернәкләнә бит, әй! Үсәм дип тора, симерәм дип әрсезләнә. Шулай кирәк, шулай яхшы...»

Габделбәр үзе дә, хатыны Сәяра да чучка ите ашамыйлар. Ашказанына авырга килә, диләр. Сыер, сарык итенең дә урта кул тирәсен генә алалар. Тавыкны хуп күрәләр. Аның ите — җиңел ризык. Диэтический... Шәһәрдәге зирәк бәндәләр тикмәгә генә колхоз базарында тавык эзләп йөртмиләр ич! Ә дуңгыз Гафуровның мая туплый торган бер янчыгы ул. Сигез-тугыз потлы булып симергәч, беренче кар төшү белән мәктәп-интернаткамы (завхозы белеш кеше), тимер юл станциясендәге ашханәгәме (мөдире әшнә) озата ул аны. Озата да тиярен санап ала...

Нәүбәт сепаратка килеп терәлде, иртән сауган сөтне аертасы бар иде. Габделбәр кичтән юып, сөртеп калдырган сепарат тимерләрен урыннарына утыртты да эшкә керешге. Бер якка сөт ага, икенче якка саран гына булып каймак саркып тамып тора. Сепарат, җылы мич

башында йокыга талган карт мәче тавышы чыгарып, җай гына мырлап әйләнә бирә.

Йорт башы каймакны кар базына — нәүрәпкә төшерде. Атом бомбасы да зыян-зәүрәт сала алмаслык итеп, тимер-бетонлап ясаган кар базына төшкәч, ул һичнәрсә күрә алмый торды. Картлар әйткәндәй, күзе тышта калган иде. Беравыктан иялəште. Иртәнге чәй янына дип, бер мичкәдән чылатылган ике-өч алма, икенчесеннән — тозлы помидор, өченчесеннән тозлы кыяр алды. Шуларга хирес ул үзе. Сәяраның исә моңа бер дә исе китми. Таныш-белеш килеп чыкканда, түр башында кирәкле кеше яисә кадерле кунак утырганда бик кыйммәт инде бу нигъмәтләр. Габделбәрнең мондый закускаларын килгән-киткән агай-эненең татары гына түгел, аралашкан русы, чувашы да мактап туялмый.

— Ну, Гафурич, синдә эчсәң дә җирендә. Бу закуска белән агу чөмерсәң дә харап булмаслык! — дип җибәрәләр.

Әлбәттә, Габделбәр кунакларның болай ук ябырылуларына куанып тормый, шулай да теләсә кемдә елның теләсә кайсы вакытында булалмаган нигъмәтнең аның өстәлендә тулып торуы күңеленә хуш килә. Аның тел очында балачакта хәтеренә сеңгән такмак әйләнә:

Ачы торма, төче торма,
Чөгендер дә кишер,
Ходай бирсә килешер!

Ләкин, билгеле инде, моны ул килгән кешегә әйтми. Киресенчә, «алмасыннан авыз ит, Фәлән Фәләневич!». «Помидорына кагылмадың да. Үзебезчә бик әйбәт итеп саклаган идек. Кабып кара булмаса», диебрәк кыстый бирә. Шуннан соң әйтер сүзен әйтә, йомышын юллый...

Чәй өлгерде. Кухня якка гына өстәл әзерләнде. Габделбәр хатынын иртәнге чәйгә бик кыстаса да, Сәяра тормады, бер генә дә нәфсем юк, ярма йотарлык та... Ачыгу сизсәм, үзем торып капкалармын әле, диде.

Габделбәр өстәл янында иркенләп, озак итеп утырды. Ашык-пошык кына ашаучыларны җене сөйми аның. Кафеларда аягүрә ашап-эчеп йөрүче шәһәр кешеләрен бөтенләй аңламый. Шартына китереп, азык тәмен таңга сеңдереп, борчак-борчак тирләр атылып чыкканчы ризыкланмагач та, ни дип яшәргә?! Каударлана белмәгәнгә күрә, төш вакытында аңа бер сәгать кенә җитенкерәми. Аз дигәндә сәгать ярым торып килә ул. Иртә килергә, соң китәргә риза-бәхил, әмма төш вакытында ашыктырып, тәмле ашына ямьсез таракан гына булмасыннар...

Чәйләп туйганда да сәгать алты гына иде әле. Габделбәр, радиоалгыч янына утырып, шырпы кисәге белән тешләрен казый-казый, Мәскәүдән соңгы хәбәрләр тыңлады. Аннан соң өе каршындагы кечкенә бакчага чыкты. Кулында моннан ике-өч көн элек үк үткенләп, кайрап куйган балтасы иде.

Өй түрендәге бакчада биек өйнең тәрәзәләрен яртылаш томалардай булып сирень куаклары үсеп утыра. Алар, май уртасы җиткәнгә, кояшның мәрхәмәтле нурларыннан көч алып, җетә яшел яфрак ярганнар, чәчәк бөреләре бүртеп тулган. Атна-ун көннән шау чәчәккә күмелерләр. Елның елында шулай. Тәрәзәләрне ачтың исә, болай да пыялаларга орынып торган ак-шәмәхә чәчәк тәлгәшләре эчкә үреләләр. Иртәләрен чәчкәләр чык бөртекләрендә коена. Талгын гына җил исеп куйдымы, энҗедәй чык тамчылары шыбырдап җиргә коела, тәрәзә пыялаларында бормалы-сырмалы тоныл эз калдыралар. Бүлмәгә хуш ис бөркелә. Мондый һава канны уйната кебек, хыялны җилкендерә төсле. Аны күкрәк киереп сулагач, кеше җиңеләеп, сафланып калгандай була.

Әүвәл елларны Габделбәр дә шулайрак уйлый, шулайрак тоя иде. Үзеннән дә битәр Әгъдәс гашыйк иде бу сиреньнәргә. Художество училищесында укыган елларында (ул Текәтаудан йөреп укыды. Поезд

белән Казанга булыр-булмас ярты сәгать ара, асфальт юлда автобусы да йөзелми), чәчәк аенда шулар янынннан китмәс иде. Ул киндергә күчермәгән бер генә ботак калдымы икән?!

Хәзер Әгъдәс юк. Ике ел рәттән Текәтауга бөтенләй кайтмады. Өченче ел, диплом яклыйсым бар, диде. Яклагач, бик арыдым, бик йончыдым, Ригага, дингез буена ялга барам, диде. (Кәләшенең ата-аналарына күренүе булгандыр, күрәсең.) Былтыр җәен тагын бер сәбәбе табылды, юбилей күргәзмәсенә «Беренчеләр» дигән картинамны, галәм батырлары тормышына багышланган хезмәтемне, тәгаллисем бар, дип хат язды. Юбилей да узды, аннан соң да күпме гомер үтеп китте, һаман күренми. Быел да кайтмавы бик мөмкин. Латышкасының да тәртәсе бик кыска булып чыкты бугай ла. Үзе болай бер дә сер сынатмый: «Зәна, минем шикелле үк, гади эшче семьяда үскән, тормышны күргән, әйбәт холыклы...» дип яза. Хәер, Әгъдәсе үзенә охшаган аның. Авызы тулы кан булса да, кеше алдында төкерәсе юк...

Төкерүен, дөрес, төкерми, тик Ригада үскән кызыйдан да Габделбәр ният иткән нәрсә барып чыкмады. Килененә Ригадан, безнең якларда талашып алып бетерә торган галантерея товарларын, трикотаж әйберләрен чемодан-чемодан ташытып булыр дип өметләнеп хат язган иде ул. Килен үзе яманатлы булырга теләмәде, малайга гына кушты бугай. Әгъдәс, арыш сохарие кебек коп-коры җавап хаты язып, сатыш-алыш белән шөгыльләнмәячәкләрен белдерде. Ул гына да түгел, туган әткәсен мал корты кергән кеше диебрәк атарга да тартынмаган иде. Хәзерге яшьләр шулайрак ул. Югыйсә улына бер нәрсәсен дә кызганмый үстергән иде бит. Апасы — кыз кеше, кеше кешесе булачак, малайда бар терәк дип исәпләгән иде. Тот капчыгыңны! Үзең дөнья җимертеп мал тапмасаң, юләр, ун елга бер курортка барырлык акча да арттырмаслар...

Бакча артларыннан гына уза торган тимер юлдан ыжгырып килгән тепловозның өнеңне алырлык итеп кычкыртып җибәрүе Габделбәрне сискәндереп куйды. Әгъдәс турындагы уйларыннан аерып, басып торган җиренә, түр бакчасына кайтарды. Башта ул урамга карады. Узгынчылар күренми иде. Аннары балтасының ялтырап торган йөзен бармак бите белән капшап алды һәм сиреньнәргә текәлде. Шуннан соң, кем алдындадыр акланырга, кемнедер ышандырырга теләгән кебек, авыз эченнән генә сөйләнә башлады.

— Матурлык туйда кирәк. Минем туем узган, туным тузып бара. Әлфиянең туе үткәнгә дә тугыз елдан артты. Әгъдәс бездән башка гына туйлады. Студент чакта аңа ни?! Ашарга дигәндә көн дә кирәк. Заяга җир биләмәсен әле бу куаклар. Урынына ике-өч рәт помидор утыртам мин аларның. Питомниктан Сергей Никанорович бик шәп рассадалар бирәм диде. Күпме җаның тели, рәхим ит, ди. Шулай булгач... Чәчәк иснәп туенган кеше юк әле бу дөньяда...

Тик бу дәлилләре генә җитәрлек түгелен шундук тойды ул. Шунлыктандыр, бичарадан ни чара дигән кебек, сөйләнә бирде.

— Җир әрәменнән генә дә түгел инде түгелен. Чирек сутый җир каян килмәгән дә кая китмәгән. Тәрәзәләрне томалап торалар бит. Түр якка көн яктысы төшә алмый. Аннары тагын, әз генә җил чыктымы — төне буена яфраклары лепер дә лепер, кыштыр да мыштыр килеп, гайбәтче хатыннар төсле, гел кыштырдашып торалар. Бик тә әрсез булсалар, тамырдан тагы чыгарлар. Тәвәккәлләдем!..

Габделбәр таза-сау аягына ныгытып басты, тез буыныннан бөгелмәс булган уң аягын читкәрәк тырпайтты һәм бар көченә балта белән бер куакның төбенә чапты. Куак төбендә аксыл-сары яра эзе хасил булды, чишмә суы тамчыларыдай саф сүл бәреп чыкты. Әмма төбе шактый юанайган куак аварга уйламады. Габделбәр балтасын тагын шул эзгә үк төшерде. Куак очындагы ботаклар түр як тәрәзәгә сугылдылар.

Тәрәзәгә куак ботаклары килеп бәрелү Сәяраны сискәндереп җибәрде. Башта ул «колагыма гына киләме соң бу тавыш?» дип икеләнгән иде, кабат ишетелгәч, хуҗа хатын торып утырды. Аннары чыдамады, залга чыкты, тәрәзә буена килеп басты. Тышта Габделбәр, балтасын күтәреп, тагын ипләбрәк сугарга ниятләп тора иде.

Сәяра бер мизгелгә телсез калды. Йөзеннән кан качты. Башы әйләнгән төсле булды. Күз алды караңгыланып алды. Тәрәзә буенда торган китап этажеркасына ябышты һәм йодрыгы белән тәрәзә рамына төя башлады.

— Нишлисең, Габделбәр?! Габделбәр димен, нишлисең, тукта хәзер үк!

Ул кычкыргандай итә, тик тавышы үзенә дә чак кына ишетелә. Тавышсыз кинодагы кебек, авызы гына ачылып ябыла, иреннәре генә кыймылдаша төсле иде.

Бер йодрык белән какканны гына ишетмәгәч, Сәяра ике куллап дөбердәтә башлады. Ниһаять, бу тавышны Габделбәр колагына алды һәм ялт итеп карады. Ни күрсен: әчке яктан хатыны тәрәзәгә ябышкан, нәрсәдер сөйләнә, ә күзләреннән мөлдерәп яшь ага.

Сәяра, өйгә кер, дип кул изәде дә диванга барып утырды. Габделбәр керде.

— Акылыңдамы син, әткәләре? Сирень куакларын чабасың түгелме соң? Гөрләп чәчәктә утырыр көннәр җиткәндә... Тирә-күрше ни әйтер?..

Ире, бик сабыр булырга тырышып, үзенең бу эшендә аз гына да сәерсенерлек урын тапмаган кыяфәт белән аңлатырга кереште.

— Тәрәзәләрне караңгылап торалар бит, әнкәләре. Кояш бик аз төшә. Караңгыда ятарга кабергә куйгач та өлгерербез. Шунысы да бар: ул куаклар рәшәткә буена утырткан чәчәкләрне дә үстермиләр. Бөтен дымны, җимне суырып тик утыралар,— диде.

Сәяраның бәгыре әрни иде.

— Тия күрмә, зинһар. Үсеннәр! Менә Әгъдәсләр кайтыр. Шып-шыр бакчаңны күрсә, өзгәләнер улкаем. Канәфер чәчәкләре дип үлеп тора иде бит балакаем...

Габделбәрнең ачуы килде.

— Чәчәкләр дигәндә сиңа охшаган инде. Анысы йөз процентка дөрес. Тик менә чәчәк иснәп кенә берәүнең дә тамагы тук, өсте бөтен булганы юк әле.

— Аның каравы кеше күңеленә шатлык бирә ул чәчәкләр, ямь өсти...— Сәяраның тавышы бик зәгыйфь, хәлсез иде. Габделбәр исә, морҗадан кычкырган кебек, көр, калын тавыш белән үзенекен тезде.

— Кешегә шатлык өләшергә сиңа әйт. Куш учлап таратыр иден. Күршең бәби тапса да чәчәк күтәреп керәсең, егет-җилән белән кыз-кыркын култыклашып узсалар да чәчәк сузып каласың. Аннан ни мәгънә? Чәчәксез тору тәгамсез тору булып тоела икән, арт бакчага чыгарсың. Утыз төп алмагач акка төренеп утырыр, чиясе дә җитәрлек. Музыкасы да заказать ителгән, бал кортларының концертын тыңларсың...

Сәяра террасага уза торган ян ишек буендагы урындыкка киерелеп утырган иренә кадалып карады.

— Мәгънәне кем нәрсәдән таба бит, Габделбәр,— диде ул, иренең йөзеннән күзләрен алмыйча,— Мин менә, ни хәл итим, чәчәкләр яратам. Минем хакка, Әгъдәс хакына тимә син аларга. Тимә, яме? — Иренә ул шундый итеп ялварды, гүя бу аның үз гомерендә иң зур гозере иде.— Әллә бар гомер, әллә юк. Корымасыннар әле шул куаклар...

Габделбәр дә уйга калды, мәгәр бердән мәлҗерәп төшәргә, бирешергә җыенмый иде. Әйттем исә кайттым гадәтле ир түгел ул. Арты белән аркан ишәр, үз дигәненә ябышып ятыр. Шулай да җәнҗал күтәрәсе килмәде. Я тагын каты сүз хатынының йөрәгенә барып ябышыр,

янә ашыгыч ярдәм машинасын чакырырга туры килер. Тик йорт башы сүзсез дә кала алмый иде. Аптыраганнан гына:

— Гомер бармы дигәләп, тузга язмаганнарны күрәзәлек итеп утырма әле син. Кемнең күпме яшисен кем әйтә ала? Әҗәл дигәнең кешенең яшенә дә, тешенә дә карап алмый ул,— дигән булды һәм тагын бакчага чыгып китте.

Сирень куагы авып ук төшмәгән, шулай да чак-чак кына эләгеп тора иде. Эшләр болайга киткәч, бәйләп куяргамы соң әллә, дип фикерләп торган арада рәшәткә буена каршы күршесе, отставкадагы майор, поселок Советы депутаты Хәнәфи абзый Сәлмәнев килеп туктады.

— Хәерле иртәләр булсын, Габделбәр күрше! Ниләр майтарып ятасың?

Габделбәр, кеше келәтеннән әйбер урлап тотылган угры сыман, Хәнәфи тавышыннан сискәнеп китте һәм, үзе дә сизмәстән, балтасын куак төбенә ыргытты да, гәүдәсе белән бая гына чабып маташкан куакны томалады.

— Исәнлекме, Хәнәфи агай. Кая кузгалдың болай? — дигән булды ул.

-- Пекарняның икмәгеннән зар күп. Шунда барып килергә дип, комиссиягә кергәннәр иде...

— Изге юлда йөрисең инде син гомер-гомергә.— Габделбәр елмайган булды. Әмма күршесе текәлебрәк караса, мөгаен, бу көлемсерәүнең теш сызлаганда чырай сытуга охшавын чамалар иде.— Кешеләргә әйбәт булсын, дисең. Дөрес, зрә дә дөрес. Сыйфат өчен якаларыннан алырга кирәк. Көн тудымы, икмәксез булмый...

Габделбәр рәшәткәгә тотынып сөйләшкәләп торучы Сәлмәневнең тизрәк юлында булуын теләде, ә күңеленнән үзен эт итеп сүгә иде: «Үз бакчамда, үз өем каршында басып торам ләбаса мин. Нәрсә дип тизәген яшерә алмый азапланган мәче сыман калтырап төштем әле?!.»

— Чәчәк атарга итәләрме? Куакларны әйтәм,— дип сораштыра бирде Хәнәфи. Нәкъ юри сорагандай, үч иткәндәй.— Урам башы ямьләнә инде....

— Көннәр чын-чынлап жылытып җибәрдеме, ата инде, ата,— диде бакча хуҗасы. Бу минутта аның тозлап-борычлап сүгенәсе килә иде.

Хәнәфи киткәч, Габделбәр черт итеп җиргә төкерде һәм отставкадагы майорның кемендер телгә алып мыгырдап куйды.

— Йөрисең арбага бишенче көпчәк булып. Былтыр яуган карны эзләп. Фәрештә кияве. Тол буйдак. Аша да ят инде пенсияңне. Дөньяның бөкресен син генә төзәтерсең... Җилгә җиллəп, бозга бозаулап гомерең үтәр...

Очрашканда бик тәмләп сәлам бирсә дә, хәл-әхвәлен сорашмый калмаса да, Гафуров Хәнәфине һич өнәми иде. Аның карашынча, Хәнәфи — кеше ашына катык катучы. Торганы шул: теләсә кайда кыбырдый да йөри. Кыбырсынган тик тормас, артына сукмый утырмас дип белми әйтмәгәннәрдер.

— Савап җыеп йөри, җилкуар! Тик савап капчыгы тишек, туласы юк,— дип сөйләнә бирде Габделбәр.

Хәнәфинең буынсыз җиргә пычак салганын Габделбәрнең үз җилкәсендә татыганы бар. Әле былтыр гына складка финский дип аталган җыелма өйләр кайткач, бер тол карчыкны чираттан сыздыртып калдыргансың, аның өен җиләк-җимеш питомнигы директорына биргәнсең, дип кайларга гына барып җитмәде. Теге карчык кереп алтын биргәндер дип уйларсың, биллаһи. Хәер, мал кадерен белә торган бәндәмени ул Хәнәфи! Өстендәге кителе, аягындагы итеге — шулар белән гомере узган инде. Үз йорты да юк бит, туганнан туган тиешле бер карчыкта торалар...

Хәнәфинең күзгә карап турысын әйтү очраклары хәтерендә яңарса,

менә әле дә ике йодрыгы тиң йомарлана. Соңгы елларда булып узган тәмсезләнүләр бүгенге сәгатьләрдә дә әле аның канына тоз сала...

Габделбәр сарайда яткан иске-москы арасыннан чүпрәкләр табып чыкты. Аларны чылатып сирень төбенә кат-кат урады, өстән изолента белән бер-ике рәт чорнап, ныгытып куйды. Куак төбенә чүгәләп, балта белән чапканда тирә-юньгә чәчрәгән йомычка, каеры кисәкләрен җыйды. Гәүдәсен турайтып, эшләпәсен күтәрде дә маңгай тирләрен сөртеп алды. Җирдәге балтасына үрелгән генә иде, бакча буендагы сукмактан үтеп баручы Лиза Варгинаның яңгыравык тавыш белән исәнләшүе сынын шундук турайтырга мәҗбүр итте.

— Здравствуйте, Габдулбар Гафурович! — диде яшь хатын, һәрвакыттагыча ягымлы һәм матур итеп.— Утренняя зарядка, да?

— Исәнмесез,— диде Габделбәр дә русча.— Хәерле иртә, Лиза. Еракка юл тотасызмы? Иртәләгәнсез.

— Җиде дә егермедәге поездга килүем. Казанга барып кайтырга исәп,— диде Лиза һәм җанга рәхәт өстәрлек итеп елмайды.— Аның энҗедәй ак һәм тигез тешләре ялтырап китте, уң бит уртасында нәни бармак очы белән төрткәндәй генә чокырчык хасыйл булды.

— Сәгать ничә соң әле? — Габделбәрнең үз сәгате дә кулында югыйсә, җиде туларга биш кенә минут калганын да яхшы белеп тора. Бер тиенлек бу хәйләсеннән максат — пешкән кура җиләгедәй яшь хатынны тагын азрак кына булса да каршысында тоту.

Кара син аңа! Үлгән ир-атың сикереп торыр мондый зат янәшә елмаеп торганда. Адәм баласының түгел, фәрештәнең авыз сулары корыр тегеләй. Биргәнгә бирә бит хода... Күзләре язгы күк зәңгәрлеген үзләренә җыйган сихри күлләр диярсең. Чәчләре операдагы Алтынчәчнекеннән ким түгел. Төсе белән инде, әйе, төсе белән. Лиза толым йөретми, кискән чәчле. Ул күкрәк-түш тирәләре дигәндә дә хак тәгалә бер генә дә рәнҗетмәгән. Биле нинди! Хатын-кызның бер ишесе, нечкә билле булыйм дип, лап-лоп чаңгы сөйрәп чаба, иртәләрен тимер-томыр белән җенләнеп бетә. Тамагы өзелеп ачыкса да, ашамый интегә. Кием тегүчеләр белән ачылышлы булуларының чуты-саны юк. Тик барыбер, ит бүкәнеме — ит бүкәне. Лизаның бу тарафтан җаны тыныч. Матурлык менә шушылай була ул дип яраткан аны табигать. Егерме биш яшь бу хур кызына! Кияүгә дә иртә чыккан иде, мондыйлар озак утырмый. Тик ире өченче ел, өйләнешеп озак та үтмәде, Иделдә өермәгә эләгеп, батып үлде. Хәер, изге күңел буш түгелдер лә инде. Хак булса, бу фәрештәнең күңеле теге сантый Хәнәфинең ташчы малаена, Алнурга, алгысыган, диләр. Булыр да. Теге егет этисе кебек дөньядан бизәр түгел ул. Берсен дә ычкындырмас. Бер уйласаң, бу хатынга ымсынса яхшы да. Югыйсә, аны былтыр ук Корбан баҗайның Зәмирәсе тирәсендә чуала дигәннәр иде. Тузга язмаган эш булып, шул Хәнәфине нәсел-нәсәбеңә якын китерерсеңме?..

Узган декабрьда гына Габделбәр ак мунча бурасы сатты. «Үземә дип бураган идем дә сезгә җәл түгел. Ала бир»,— диде ул Лизага. Прицебын тагып машина килеп житкәч, Габделбәр уенын-чынын бергә укмаштырып, Лизага: «Арт бакчагызга кайтарып салгач, пар башларга мине чакыр, арканы юып озатыр булсаң, бәясен дә киметер идек инде, Лизочка»,— дигәләп баккан иде. Лиза көләргә дә, ачуланырга да белми аптырап калган иде. Аның бу халәтен Габделбәр тора-бара моның кылын янә дә тарткалап карарга мөмкиндер дип юраган иде. Шуңа күрә: «Сәгать ничә соң әле?» дигән булып, күзләрен майландырды ич.

— Без пяти минут семь,— диде Лиза һәм китәргә кузгалды, тик ике-өч адым да узмады, тукталды.

— Сорарга онытa язганмын. Сәяра апаның исәнлеге ничек? Кичә йөрәге бик начарланган дип әйткәннәр иде,— диде.

— Бүген ярыйсы гына. Әмма беләсең инде авыру кешене... Түгелгән тулы буламыни, Лизочка?! Бездә «кардәшнең бае яхшы, хатынның савы яхшы» диләр. Хак инде, шулай ул...

Габделбәрнең тел төбен Лиза аңламады бугай. Саубуллашып, вокзалга китеп барды.

— Хәзергә хуш, Лизочка, хуш! — диде Гафуров. Үзе күзләре белән Лизаның чәч дулкыннарына, аркасына һәм сокландыргыч балтырларына ябышты.— Салкын энәдән бармагына суык тидерүчеләрдән түгел бу, ә?!.

Габделбәр өйгә кергәндә Сәярасы торып өстәл янына килгән, чынаяк-чәшкә сөртеп азаплана иде.

— Чәй яңартыймммы? — диде ул Габделбәргә.

— Берәрне эчсәң ярар шул,— дип җавап кайтарды ире.— Көн бүген кыздырырга охшап тора. Иртәдән үк җылы...

Мөдир складка эшкә барганда, (бу складны русы, татары бер сүз белән генә «лесоторговый» дип йөртәләр) иртән сәламләшкән кешеләр белән сөйләшү тәэсире астында атлады. Лиза Варгинаны күз алдына бастырганда аның битенә талгын җил иркәләп, назлап кагылгандай булды. Теләсә-теләмәсә дә, шикәре-балы белән тыгызланып тулышкан җимештәй Лизаны әледән-әле йөрәгеннән зар елап, атна саен булмаса да һәр тумыш айда диярлек урынга аварга мәҗбүр булган Сәярасы белән чагыштырып карады. Хәтер саегамы, тормыш тәэсирләрен еллар тузаны томалый төшәме, Габделбәр Сәяраның яшьнәп-күкрәп торган чагын чак кына итеп исенә дә төшерә алмый кебек. Чибәр генә иде, билгеле, буй-сыны да ярыйсы гына иде. Тез астына җиткән толымнарына сокланмаган хатын-кыз булдымы икән? Тарап үрергә дип чәчләрен туздырса, иңнәренә ефәк шәл бөркәнгән шикелле була иде. Һәрхәлдә, «карасана бу арысландай егетне, кемгә өйләнгән бит! Әрәм булган бөркет» диярлек түгел иде. Сабыр булды Сәяра, акылсызлык күрсәтмәде. Менә диган кызны буйга җиткереп башлы-күзле итте, художник ул үстерде. Дәрт сүрелмәгән, гайрәт кимемәгән шикелле булса да, Габделбәр дә хатыны белән утыз елга якын гомер итте шул инде. Уза бит гомер дигәнең, искән җилдәй уза да тора. Кайчан гына егет белән кыз иделәр. Кайчан гына аларны олылар таныштырган иде. Әйе, әйе, таныштырганнар иде...

## 2

...Казан — Арча поезды кузгалырга тора. Нибары биш-алты минут вакыт калган. Шәһәр яны вокзалында алма төшәргә дә урын юк. Култык таякларына таянган кешегә ырып-ерып узу үзе бер мәшәкать. Соңгы айларын Казан госпитальләренең берсендә, Татарстан урамындагы дүрт катлы мәктәп бинасында дәваланган Габделбәр Гафуров, егерме дүрт яшьлек сөлектәй егет, гарип аяклы килеш туган туфрагына — Текәтау поселогына кайтып бара.

Өйдә әти-әнисе зарыгып көтәләр инде аны. Бүген булмаса иртәгә, иртәгә насыйп түгел икән, аның аргысына кайтып керәчәген беләләр. Белеп көтү тагын да газаплырак.

Казан госпиталенә күчергәч, әткәсе Гафур абзый улы янына өч-дүрт килеп китте. Һәр атнаны килгән булыр иде, госпиталь җитәкчеләренең талканнары бик коры. Тәртип. Хәрби заман законнары. Таштан юкә суалмыйсың. Арча — Текәтау якларында үткенлеге, маһирлыгы, энә күзеннән үтә белүе, теле-теше һәм чаялыгы белән телгә кергән тиреярычы Гафур да хәрби врачлар алдында чарасыз калды... Үткән эшкә салават, Габделбәр балачагы, егет еллары узган поселогына кайта.

Шәһәр яны вокзалының перронына чыга торган баскычлардан көчхәл күтәрелгәч тә, Габделбәр тимер капка турысында ук торган вагонга таба титаклады.

Вагон шыгрым тулы. Карт-коры, хатын-кызлар, бала-чагалар. Тамбурларда тәмәке пыскыталар.

Габделбәр тирә-юненә карангалады, ниһаять, бөтен вагонны күзләре белән капшап чыкты, барып теркәлердәй сынар урын да күренмәде. Әмма шундук аны бу чор өчен бик ыспай һәм житеш киенгән, тулган айдай түгәрәк йөзле, кысык күзле бер агай абайлап алды да үз янына чакырды.

— Яралы иптәш, бире килегез. Сыешырбыз...

Танышырга да өлгермәделәр, поезд кузгалып китте. Көпчәкләрнең хәрәкәткә килүен генә көтеп торганнар диярсең, вагон ишегеннән кулына унике телле гармун тоткан бер карт килеп керде. Аңа сигез-тугыз яшьлек бер малай ияргән.

Карт: «Әссәләмәгаләйкем, юлдашлар!» дип сәлам бирде дә «Алмагачлар»ны сыздырып җибәрде. Аннары карлыгып беткән тавыш белән җырларга кереште:

Сау бул, жаныем, китәм инде,
Чакыртты военкомат.
Военкомат не виноват,
Гитлер суккин виноват.

Карт һәр көнне шунда бутала булса кирәк. Казан белән Арча арасында еш йөрүчеләрнең аңа бер дә исләре китмәде. Катык сатарга килгән хатыннарның берсе, җене чыгып, әйтә дә куйды:

— Бугаз киереп акча теләнә дә Арчага баргач, исереп егыла. Аңа биргәнче мескен бер карчыкка бирсәң ичмаса...

Аңа кемдер каршы төште.

— Әй, туган, иректе көннәндер дисеңме? Сугыш шулай итә, сугыш...

Катыкчы хатын һаман ярсына бирде.

— Сугыш ди, пычагым. Агач спирты эчеп сукырайган ул...

Карт мондый сүзләрне исенә дә алмый, уйный бирә, җырлый бирә.

Минем иркәм армиядә
Атлар эчерәм, дигән.
Әйдә гуляй, вакыты шулай,
Кайткач кичерәм, дигән...

Аннары ул гармунын җилкәсенә асты, каешланып беткән бүреген ике куллап алга сузды да вагон буйлап үтте.

— Кайсыгыз күпме ярдәм итә ала, якташлар, мәрхәмәтегездән ташламагыз... Сукыр бәндәнең хәленә керсәгезсәнә, туганнар!

Ул күрше вагонга чыгып киткәч, монда тагын бер гөрләшеп алдылар. Кемнәрдер сукыр хәерчене сүкте, икенче берәүләр тирән көрсенделәр.

Габделбәр тирән итеп сулап куйды. Күңелендә көзге болыт сыман кара, кургаштай авыр уйлар чарпалашты. Гариплекнең кешене ни тикле түбәнсетүе, бичара ясавы турында фикер йөртте ул. Ләкин андый уйлардан тиз арынды. «Минем хәлем бу сукыр карт хәле түгел ләбаса. Аяк, быел булмаса, яренгә иҗкә килер. Кайтып төшәргә әтисенең нык нигезе бар. Өйдә, сандык төбендә, педагогия училищесын тәмамлау турындагы дипломы. Сентябрьдән эшли дә ала теләсә. Укытучылар ызгып тормый бит әле. Сәламәтлекләре чамалырак дип калдырып торган ир-атны да чүпли баралар. «Хафаланма, Габделбәр!» диде ул үз-үзенә.

Аның карашы янәшәсендә газета караштыргалап утыручы агай күзләре белән очрашты.

— Кай тирәгәрәк кайтыш, энекәй? — дип кызыксынды ыспай киенгән кеше. — Арчагамы?

— Текәтауга кайтам, абый.

— Кайда яраланган идең, күптәнме?

— Мәскәү тирәсендә. Былтыр декабрьда.

Бермәл сүзсез генә бардылар. Шуннан соң теге агай янә сораштыра башлады.

— Текәтауда кемнәрең бар?

— Әткәй белән әнкәй исәннәр,— диде Габделбәр. Бу ир-атның соравы бетәсе түгел иде, яудырып кына торды.

— Кем ул әткәң? Мин белмим микән аны?

Инде Габделбәр сорап куйды.

— Сез Текәтауныкымыни? Танымыйм.

— Мин анда күптән түгел генә эшлим әле.— Агай бик канәгать кыяфәт белән, бәясен белеп кенә сөйләшә иде.— Райбашкармада. Сәүдә бүлегендә. Мөдир. Фамилиям — Сагындыков. Корбан абыең булам. Әтиең кем дисең?

— Гафур. Динмөхәммәтов. Бәлки беләсездер дә... Тире-яры җыеп, кыты-мыты килеп ята шунда. Картая инде...

Корбан Сагындыковның йөзенә шундый елмаю чыкты, авызына бал белән май каптырдылар диярсең. Аның болай да җәлпәк йөзе тагын да киңәеп киткән төсле булды.

— Гафур абзыйны белмәскә! Беләм, бик беләм... Хәләл җефетем белән дә чәйдә булганым бар үзегездә. Әткәң дә минем өйгә сугылгалап тора. Белмәгән кая! Бик булдыклы абзый ул. Фани дөнья кешесе. Тәк-тәк, син — укытучы егет инде алайса... Әткәңнең ничәмә-ничә сөйләгәне бар. Исемең кем әле, энекәш?

— Габделбәр.

— Ә-ә, әйе шул, Габделбәр бит әле, Габделбәр.

Станциядән район Советы бинасына кадәр ике атлап, бер сикерәсе булса да, Корбан Сагындыковны каршыларга юртак җигеп килгәннәр иде. Габделбәргә бик ярап куйды бу. Талчыбыктан үргән тарантаска менеп утыруы алай ук ансат булмаса да, култык таякларына таянып атлау түгел!

Әти-әнисенең куанычы сурәтләп бетергесез булды. Гафур абзый күгәрчендәй гөлдерәп кенә торды. Әнисе Сажидә апаның күңеле кояшлы яңгырга охшап калды. Әле җан җылысы белән елмаеп килеп Габделбәрнең иңнәреннән кага, чәчләреннән сыйпый, әле бер читкәрәк тайпылып, мөлдер-мөлдер елый башлый һәм туздырып бәйләгән яулык чите белән күзләрен сөртә.

— Ходага шөкер, мең шөкер. Исән кайттың бит, балакай гынам... Аягың да төзәлер, боерган булса, төзәлер, балакай гынам,— дип торып-торып такмаклый.

Гафур абзый, күрешү хакына ярар инде дип, башта тәрпәләнми торган иде, бара-тора түземе төкәнде.

— Сиңа әйтәм, дөньяларыңны оныттың. Ашны-чәйне кем хәстәрләр? — Бу аның соравы түгел, әмере иде.

Корбан Сагындыков чәйләп тормаска ниятләгән төсле иде дә, Гафур абзый ике сөйләштермәде.

— Кучерыңа әйт, китсен. Үзең аштан олы булма. Начальство дисәң дә ризыктан зураерга правaң юк, Корбан энекәш.

Бу елларда бик-бик күпләрнең төшенә дә керми башлаган майлы ит белән пешкән токмач өстәлгә килде, ак күмәч тә, арыш икмәге дә туралды, тозлы кыяр белән кәбестә дә куелды. Мәгълүм инде, бу тикле зур куаныч хакына (сәүдә бүлеге мөдире дә түрендә утыргач) Гафур ак башны да китереп утыртты.

Беравыктан өч ир-ат, өстәл буенда берсен-берсе бүлдерә-туктата, гәп сата башладылар. Сажидә апа аш-су ягына чыга торган ишек бусагасы буенда, кулларын алъяпкычы астына тыккан хәлдә, аларны күзәтеп торды. Юк, аның райбашкарма кешесендә эше юк иде, шул минутта гына Гафур абзый да гамендә түгел иде. Ана күзләрен Габ-

делбәреннән, сугыш зилзиләләрен кичеп, башы сау кайткан баласыннан алалмый торды.

Күптәннән, бик күптәннән аракы затын авыз итмәгәнгәдер, тиз арада Габделбәрнең башына китеп барды, бит урталары алсуланып чыкты, хәтта теле дә көрмәкләнгәнрәк шикелле булды.

«Тагын өстәмәсә генә ярар иде балакаем. Исереп алып, яралы аягын авырттыруы бар. Әй, ходаем, сабырлык бир, акыл бир. Тәүфыйксыз олан түгел иде, килер көннәрдә дә итагатьле ит, раббем», дип, Сәҗидә апа эченнән теләк теләп торды.

Ирләрнең бар сөйләгәннәре сугыш хакында булды, телләреннән Сталинград дигән сүз төшмәде.

— Хәлләр анда киеренкенең аръягында,— диде Сагындыков.— Бик авыр. Ну күңел сизә: озакламый немец аннан табан ялтыратачак. Не может быть, чтобы иптәш Сталин фашистка Иделдә йөзәргә юл куйсын...

Сәҗидә апа да:

— Амин инде, шулай гына була күрсен,— дип сүзгә кушылганын тоймый калды. Аның өйдәлеген бөтенләй хәтерләреннән үк чыгарган ирләр, командага буйсынгандай, һәммәсе берьюлы күтәрелеп карадылар.

— Шулай булачак, Сәҗидә апа,— диде Корбан, чамадан тыш белдекле кыяфәт белән.— Мин фин сугышында яраланып кайткан кеше буларак әйтәм моны. Ак финнәр минем дә сул кул бармакларын өзеп калдылар, ләгънәтләр... Хәзер фин кампаниясе дип җиңел генә әйтеп җибәрсәк тә, анда да үлүчесе дә булды, миндәй гарипләнгәннәре дә байтак җыелды...

Тагын байтак утыргач, Корбан кайтырга кузгалды.

— Рәхмәт сезгә, хуҗалар. Үзегез килегез. Ә сиңа, Габделбәр энекәш, особый чакыру. Рәхим ит. Минем балдыз да — педагог кеше. Сөйләшергә сүз табылыр. Кил, ямс,— диде ул. Аның ихлас күңелдән чакыруына шикләнмәскә мөмкин иде.

Август үтеп китте, сентябрь яртылары якынлашты. Габделбәр эшкә урнашу дип авыз ачып караган иде, Гафур абзый белән Сәҗидә апа ашыгырга ирек бирмәделәр.

Яңа, 1943 елны каршыларга дип, Габделбәрне Сагындыковлар үзләренә чакырдылар. Корбан үзе килеп өндәп китте. Бармый мөмкин түгел иде.

Сәүдә бүлеге мөдиренең өендә бай җиһаз, мул ризык, бишектә яшь бала иде... Хатыны да тутырган тавык кебек.

Кремль курантлары чыңлый башлагач, яңа ел тосты күтәргәндә, йорт башының да, Габделбәрнең дә кәефләре әйбәт кенә иде инде.

— Син басма, Габделбәр энекәш. Утырган килеш кенә,— диде Корбан, стаканын егет рюмкасына китереп.— Яңа бәхет өчен! Фашистның муены сынсын да кызыл туйлар гөрләсен өчен!

Җизнәсе шундый сүз ычкындырып ташлагангамы, Габделбәр янәшәсенә утырган Сәяраның битләре янып чыкты. Ул маңгаенда тир тамчылары сикерешкәнен тойгандай булды. Егет Сәяра белән чәкешергә үрелгәндә, балдыз кеше карашын каядыр аска, күзгедәй ялтыратып буяган идән тактасындагы нindидер ноктага төбәгән иде.

Озак та үтмәде, Корбанның хатыны Хафаза ханым, кухняга чыгып, шөгыль тапты. Корбан тәмәке көйрәтергә дип чоланга юнәлде. Яшьләр үзләре генә калдылар.

Алар бу кичтә мәхәббәт сүзләре сөйләштеләр дип уйлау артык беркатлылык булыр һәм гыйшык дигән утны санга сукмауга әверелер иде. Юк, ул хакта ләм-мим сүз чыкмады. Әмма алар бер-берсен күрделәр һәм байтак мәсьәләдә уртак караш, уртак тел таптылар. Таныштылар.

Сәгать икеләр булгандыр, Сагындыков райбашкармада дежурлык

итүчегә шалтыратып, Габделбәрне озату өчен ат соратты. Шуннан соң «юл аягы» тәкъдим итте дә:

— Әйдә инде, хәзер киңәшеп алыйк,— диде...— Бер киңәшем бар минем сиңа. Кәеф ничегрәк? Аяк савыгамы?

— Алга таба бара инде, Корбан абый. Алай ук тинтерәтми.

Сагындыков артлы-култыксалы киң урындыгын Габделбәр янәшәсенәрәк күчереп утырды. Аларның нидер серләшергә хәстәрләнүен күреп, Сәяра да аш-су ягына, апасы янына узды. Корбан балдызкаеның мәнбелүеннән бик канәгать иде.

— Менә нәрсә, Габделбәр энекәш, Гафур абзый белән дә сүз булган иде, сиңа зрә дә кулай эш бар. Сузмый-тартмый гына керешергә кирәк шуңа.

— Нинди рәк эш икән соң ул?

— Замечательный эш! — Корбан Габделбәрнең ботына сугып куйды.— Сәүдә системасында. Райсоюз складына зав. кирәк. Бүгенге көн күзлеген киеп карыйсыңмы, иртәгенекенме — аңардан да шәбрәк вариант таба алмаячаксың.

Габделбәр көтмәгәндә генә тирән чокыр алдына килеп туктаган сыман булды. Сикерсәң, йөгереп килә-килешкә җилкенергә кирәк. Кырыенда таптана калсаң, теге якка чыгармын димә.

Юк шул, Габделбәр ыргый алмады.

— Минем кулдан килә торган эш түгел лә ул, Корбан абый. Алдарлар да башың төрмәдә черер... Укытучы бит мин.

Корбан көлемсерәп куйды.

— Яшьлегенә була сөйлисең әле син, энекәш. Хәлфәлек кайчан да качмый ул. Яшәп калырга кирәк. Бүгенгенең иртәгәсе бар. Син тормыш корасы кеше, гаилә башы булыр чагың җиткән. Көн итәр җирдән кем китәр, диганнәр. Уйла. Мин барында — алдарлар дип күз алдыңа да китермә. Кагылып карасыннар...

Ат килде. Габделбәрне өчәүләп озата чыктылар.

...Озак та үтмәде, Габделбәр склад мөдире хезмәтенең нечкәлекләренә төшенеп алды. Яңа елны каршылаган төндә кыюсызланып утыруыннан үзенең үк көләсе килә иде.

Дуслары ишәйде, таныш-белешләре артты. Элек үзе сәлам биргәч тә теләр-теләмәс кенә ияк кагып үтүчеләр хәзер ерактан ук кул сузып килүчән булып киттеләр.

Май бәйрәме көннәрендә Сәяра белән Габделбәрнең туйлары да узгач (Гафур карт, кешегә сиздерми генә, никах укытырга да онытмады), ягъни склад мөдире райбашкарма әһеленең баҗасы булып алгач, Гафуровның Текәтаудагы абруе тагын күтәрелеп китте.

Ул көннәрдән бирле чирек гасырдан артык гомер үтте. Егерме сигез язны җәй алмаштырды, егерме сигез көз кышка ялганды. Гафур абзый дөнья куйганга ун елдан артты, Саҗидә апаның гүр иясе булуына да биш-алты ел. Атадан калган йорт урынына Габделбәр хәзер яшь торган гүрнәчәсен бастырып куйды. Әйткәнебезчә, хәзер аның йорт-җир бөтен Текәтауда атаклы, кош та очып керә алмас.

Хатынынна уңды Габделбәр. Сәяра телле-тешле түгел. Берәүгә дә зарланмас, кеше алдында сыкрап-сыктап йөрмәс. Иренең чабуына ябышып йөрү гадәте юк та юк. Барысын да үз эченә җыя. Кату чыкса чыга, мәгәр каядыр барып, ире өстеннән әләкләшеп йөрүне уена да китерми. Белә чөнки, ничә ел бергә гомер ителгән, балалар үскән. Ни әйтсәң дә, шул ир белән яшисе ич.

Хәер, Сәяраның да кызган тимергә әйләнеп караган көннәре булды. Бу кадәресе — укытучылык хезмәтеннән китеп, өйдә генә яшь башларга кушкач булып алды.

Габделбәр табигатенең үзенчәлекле янә бер ягы бар: көнче күбәләк ул. Әмма ул үзен «ир көнләсә — ил төзәр» дигән сүз белән аклый иде. Сәяраның кайнарлыгын да тиз сүреллерде.

— Сыйпаганда да аяк очын гына сыйпарлык акчаңа калмадык бит әле. Шөкер!— диде ул, кырт кисеп.— Кызык килеп чыга: ир белән дә, мир белән дә булырга телисең син. Алай итәм дип ымсынма син, Сәяра. Ярамый, барып чыкмый...

Хатыны да акрынлап өйдә генә торуга ияләште. Тора-бара тәмам күнекте. Мәктәптә дә, өйдә дә эшләү мөмкин түгелдер кебек күренә башлады аңа. Язмыш дигәнең шулай, күрәсең; берәүләрне, сукырны житәкләгән малай шикелле, кая кирәк шунда тартып йөртә, икенче берәүләр аның җиленә, давылына каршы үзләре юл ярып барырга тырышалар. Сәяра, күңеле бик изгедә булса да, юл ярыр ук хәлдә түгел иде шул.

Ә Габделбәрнең тәнендә Гафур җаны, тамырларында Гафур каны. Динмөхәммәт нәселендә хатынын үзенә каршы әрепләштереп торган кеше юк. Гомер-гомергә «ачсам — учымда, йомсам — йодрыгымда» дип яшәгәннәр алар.

Хатыныннан гына димәк, бәҗадан да унды Габделбәр. Корбан абыйсы аның компасы да, калканы да, арка таянычы да булды. Әйтик, сугыштан соңгы беренче елларда, белмәс баштан, пәрәвезгә каба язганда Сагындыков аны бик чиста гына итеп йолып калды һәм гадәтенчә акыл өйрәтте. «Давыл басылгач, ике-өч ай эшлисең дә, бәҗәй, райпотребсоюздан китәсең. Хәзер синең кулыңнан уза торган нәмәкәйләр елның-елында күбәя бара. Аларга кытлык кими, тора-бара бөтенләй бетәчәк. Килер елларда, бәҗәй, халык нәрсәгә дисең бигрәк тә мохтаҗ булачак? Төзү материалларына. Агачка, кирпечкә. Чөнки йортҗир, каралты-кура искерде. Сугыш елында төзим дигән кеше күп булдымыни?! Лесоторговый складка күчсәң, ак сакаллы карт буласың. Аннан да отышлы вариантны эзлисе дә юк. Белгән кешеләрем бар, үзем көйлим»,— дип җилкендерде ул Габделбәрне.

Гафуров, малның җаен — тапкан белер, атның җаен — яккан белер дигәндәй, шуңа риза булды. Сагындыков исә моның шундый нәтиҗә бирәчәгенә тырнак очы кадәр дә шикләнми иде. Шикләнми дию генә дә Корбанның исәп-ниятләрен чагылдырып бетерми, әлбәттә. Сагындыков коммуналь йортта яшәүдән туйган, кул астында Габделбәрдәй булышчысы биеп торганда, үзенә йорт коруны планлаштыра иде. Теләгән колач белән, һәр яклап җиренә җиткезеп... Габделбәр «именнесе» дә бер читтә торырлык итеп...

Шул рәвешчә, Габделбәр Гафуров илле беренче елдан бирле лесоторговый складта.

Кеше дигәнең кызык бит ул. Әүвәле өч-дүрт тәрәзәле генә булса да йорт әмәлләп керәсе иде, баш өстендә түбә булыр иде, дип өтәләнә. Беравык вакыт үткәч, өйне алты почмаклы итәсе иде дип кытыклана башлый. Аннары инде ак мунчасы да кирәгә, сыер абзарын да шыңгырдап торган бүрәнәдән итмәк була. Шунлыктан корылыш кирәк-ярагына кытлык беркайчан да бетеп тормаячак. Менә шуңа күрә дә Габделбәрнең почеты зур.

Дөрес, хәзер Корбан бәҗәсы райбашкармада түгел. Аннан киткәненә байтак гомер үтте. Хәзер поссовет председателе ул. Шуның өстенә Габделбәрнең үз буыннары да тәмам ныгып җиткән инде!

...Бүген иртән эшкә килгәндә, ул әнә шуларны күңеленнән уздырды. Кабинеты ишегеннән атлаганда кылт итеп бернәрсә исенә төште: иртәгә аның янына әтисенең энесенең улы Ханзафар киләчәк. Бәлки, бәләкәй абыйсы үзе дә килер. Онытылып китмәсен. Сөйләшәсе сүз бик мөһим. Иртәгә эштә булалмыйм дип конторадагыларга да әйтеп кайтырга истән чыкмасын!

Календарьның бүгенге битенә ул зур итеп Ханзафар дип язып куйды.

### 3

Шимбәдә Сәярага иртәдән үк тыгызга килде, көндәлек мәшәкатьләре өстенә кунак сые хәстәрләү кадәресе дә килеп кушылды.

Бер исәпләсәң, кунак килә дип кыбырсып төшәсе дә түгел инде. Килүчеләр үз кешеләр: Габделбәр этисенең бер туган энесе Әһлиулла абзый белән аның улы Ханзафар. Шулай да йорт башының әмере нык булып кала.

— Ашың-суың ни житте булмасын. Калган ягын мин үземчә җитештерермен,— диде Габделбәр кичтән үк.— Кемгә килгәннәрен, кайда утыруларын чамаларлык итәргә кирәк. Шул чагында сүз дә башкачарак сөйләнә...

Габделбәр туйга баргандагы сыман ыспай киенеп алды, чәчен-башын кат-кат сыпырды, башта болдырга, бераздан капка төбенә үк чыгып керде. Аннары да сәгать чамасы вакыт узгач кына капка келәсе чалтырап күтәрелде һәм бәйдәге Пират буыла-буыла өрә башлады. Сыңар куллы, протез аяклы Әһлиулла абзый Габделбәр йортына онытылганда бер генә сугылгалап чыга торган кеше булганга, овчарка аны һич белми иде. Ханзафар капкадан кереп, эткә исеме белән эндәшкәләгәч кенә, тегесе һай-һаулавыннан туктады. Шул чак, чолан ишеген каерып ачып, Габделбәр үзе каршы чыкты һәм мал-мөлкәт сакчысына «тик тор!» дип кычкырып куйды. Пират тынып калды, күзләрен мөлдерәтеп хуҗасына карады һәм юан койрыгы белән такыр җирне, гадәтенчә, шап-шоп кыйный башлады. «Ярар, ярар,— ди иде кебек ул,— өрмәскә була, хуҗам. Тик үзең бит юаш булып торганны бер дә өнәмисең. Усалны яратасың».

— Көттердегез сез, агай-энеләр, зарыктырдыгыз! — диде Габделбәр, Пираттан шыгаебрак атлаган кунакларга кул сузып.— Исәнме, бәләкәй абый? Сау гына йөрисеңме? Бер поселокта яшәсәк тә айгаелга бер күрешәбез, әй! Саумы, Ханзафар. Әйдәгез, әйдүк!

Әһлиулла абзый сул кулын сузды. Уң җиңе буш, шунлыктан атлап барган шәпкә артка таба каерылыбрак килә иде.

— Имин-аман гына яшисеңме, Габделбәр туган? Килен сау-сәламәтме? Әгъдәсләрдән хәбәр-хәтер бармы? Күңелләр көр, җаннар тынычмы? — Әһлиулла, гадәтенчә, бик тәмләп, җиренә җиткереп сораштыра башлады. Ә Габделбәр:

— Шөкер хәзергә,— дип ике сүз белән генә җавапны түгәрәкләп куйды. Аннары болдыр алдындагы аяк кыргыч янында ук туфлиларын салырга ниятләгән Әһлиулланы эчкә әйдәде.

— Аяк киемен анда саласы түгел. Узыгыз, уз. Син, Ханзафар, ни дип читкә китеп бастың. Әйдәгез, хода бәндәләре, керегез. Аш-су көтә...

Өстәл мул хәстәрләнгән иде. Габделбәр чиста спирт тулы графинны шап иттереп чыгарып утыртты.

— Кемгә ничек, мин бу антигрустин дигән нәрсәне сыеклап мәшәкатьләнмәгәнне хәерлерәк күрәм,— диде ул.— Сиңа ни формырак кирәк, бәләкәй абый? Сиңа, Ханзафар? Синнән сорап тормасам да була ясь кеше әле син. Каның-сүлен, җегәрең-җенең эчендә...

Әһлиулла абзый түбәтәен әле бер, әле икенче якка шуыта торгач, кыюсызланып кына әйтә куйды.

— Мин, Габделбәр наный, су кушмый сметь итә алмыйм. Чама чамалы. Тынга килеп кабуы бар, бигайбә. Су кушып кына...

Габделбәр көлеп куйды һәм хатынына эндәште:

— Сәяра! Холодильниктан ситро шешәләрен алып кил әле. Әйдә, үзең дә утыр, көттермә! — диде. Шуннан соң, кунакларына карап, су-

зен дәвам итте: — Сыеклау дигәндә ансат ул, бәләкәй абый. Куерт дия күрмә. Анысы читен... Ягез, күтәрдек!..

Ирләр эчеп куйдылар. Әһлиулла җилкәсеннән арыш тулы капчык ыргыттымыни — авыр сулап, кырхылдап алды һәм тозлы кыярга үрелде. Ханзафар да учына йөткергәләп бакты да закуска ягын чамалады. Габделбәр генә тегеләргә, «һәй, пешмәгәннәр!» дигән төслерәк итеп, күз кырые беләнрәк карап алды һәм бер-ике йотым салкын ситро эчеп кую белән канәгатьләнде. Аннары итле бәрәңге шулпасы салган тәлинкәне алдына тартып куйды, борычын-тозын үзенә кирәкчә сибеп тәмләде һәм батырып ашарга кереште.

Кунакларны Сәяра кыстый торды. Әһлиулла аңа каршы:

— Алга куйган, кыстыйсы юк, килен. Аннан соң бит без солдат булган кешеләр, назланып торырга өйрәнмәгән дә,— дип җавап кайтарды.

Ханзафар әтисенә күтәрелеп карады. «Ярты стакан аракы башына китеп тә өлгердемени соң әле?!» — ди иде аның күзе-йөзе. Әткәсенең барлык гадәтләрен сынап, белеп бетергән иде инде ул. Азрак эчеп алдымы, «без солдат булган кешеләр...» ди башлый ул. Күбрәккә китсә, уң аяк урынындагы протез белән идәнгә тык-тык баскалап куя, бию дәрте кузгалгандай итә, күрәсең. Биеп булмасына тагын бер кат иман китергәч, дөньясыннан үчне җырлап алмак була. Моңы ташка үлчим диярлек, әмма ярыйсы ук көчле тавыш белән җырлап та җибәргәли...

Стаканнар тагын күтәрелде. Әһлиулла абзыйның табак битенә алсулык йөгерде, кызарыбрак торган тукмак борыны өстенә тир бөртекләре бәреп чыкты, зур соры күзләре мут елтыраган кебек булды.

Габделбәр, бәләкәй абыйсының да, Ханзафарның да кәефләнүен күреп, фани дөнья хәлләренә якынрак килергә вакыт икәнлекне хәтерләде. Маңгайга туп-туры бәрмичә, ләкин әллә ни урау юллар да эзләп тормастан, сүз башлады.

— Көздән бирле димәсәң, безгә килеп чыкмаганына да байтак булды бит, бәләкәй абый,— диде хуҗа.— Ярый, рәхмәт, Ханзафар оныткып бетерми. Шуна күрә хатынга да әйттем, бәләкәй абыйны чакыртып җибәрдем әле, мәйтәм. «Бөртек чәем — төртеп эчерәем» түгел, туганнар ич без. Такта чәй, якты чырай... Бер сөйләшеп утыруы үзе бер гомер, дим...

Каты бәгырьле энесенең җанга якын сүзләре Әһлиулланы эретеп җибәрде.

— Сүзең хак, Габделбәр,— дип тезеп китте ул. Аның кәефе килә барды, гүя алдына алтын тәңкәләр сиптеләр.— Рас әйтәсең. Бер күрешү— бер гомер... Тик менә гел-гел чыгып йөреп тә булмый. Ханзафарның гвардиннары чабуга ябышкан. Икәү бит, икәү. Кечесе дә тәпиләп киткәч, мәшәкать ишәйде. Җитмәгән җире, кагылмаган әйбере юк. Килен эштә, Ханзафар эштә. Маташам шул ике гвардин белән. Әбиләре булса, аның белән чүкердәшеп ятырлар иде дә соң, мәрхүмә дөньяны иртәрәк куйды...

— Яслегә, детсадка урнаштырып булмыймыни соң аларны, Ханзафар энекәш? — Габделбәр энесенә текәлде.— Чыннан да, җиденче дистәне вакларга керешкән картка артыгын күтәртмисезме? Я булмаса, малайлар баш-күз алгалаганчы хатының эшләмирәк торса? Ә? Детсадка дисәгез, иртәгә үк язуын алып бирәм, пажалысты...

Шулай диде дә хуҗа күз чите белән генә Әһлиуллага карап алды. Нечкә кылыныны чирттем бит, янәсе. Әмма картның моңа исе китмәде.

— Анысын да әйтмә инде, Габделбәр энем. Ничарадан бичара ул детсадларың. Сабый баланы түшәгеннән иртәнге биштә-алтыда каерып торгыз әле син. Унга тикле җәелеп-җәйрәп йокларга тиеш ләбаса ул җан иясе... Аннары халык нирбалы, дибез, кабынып китәргә генә тора, дибез. Яшь чәчәкне кырау тиз алучан. Балаларны да мәктәпкә кадәр

ук тинтерәтә башлыйбыз. Миңа ни... алар белән көн үткәнен искәрмидә калам.
Әһлиулла, дөресен әйтәм бит дигәндәй, Сәяра белән Ханзафарга карап алды.
— Ул кадәресе дә бар инде, бар,— Сәяра кунак абзыйның сүзен җуплап куйды. Әһлиулла исә өй башының сүзләренә җавап бирeп бетермәгән иде әле, дәвам итте:
— Киленнән эшләми торуы дигәндә, Габделбәр энем, түже рәте бар аның. Шушы яшьтән өй тавыгы булмаса да бик әйбәт. Эшләсен, кеше арасында булсын. Аннары шул: тормыш бабай дигәнең очына нужа кылы таккан чыбыркысын чөйгә элмәгән бит әле. Кулында тота, адәм балаларының сырт буйларын чамалап кына тора. Теш күрсәткәнгә чуртымны да бирмиләр, эш күрсәт, диләр. Үзең беләсең, акчасын контора̀нда санап алдың, өйлек бүрәнә, түбәлегә, идәнлегә күпмегә төште. Кирәк, ансыз да булмый. Гомергә баракта ысланырга димәгән. Яшьләрнең дә заманча көн итәселәре килә. Йоклавы да сәндерә-сәкедә булмасын, урындык-өстәле дә ялт итеп торсын. Кием шкафы да кирәк, анда әләргә кием-салымы да кирәк, значитсы... Вәт менә шулайрак, эшләми узмый...
Картның сүзе үзе ук йорт салуга китереп терәве Габделбәр өчен бик җайлы килеп чыкты.
— Авызымнан алып дигәндәй әйттең әле, бәләкәй абый.— Габделбәр, урындыгын шудырып, Әһлиуллагарак елышты.— Бер уңайдан йортны бурап күтәрү турында да сөйләшербез дигән идем. Мин бит...
Карт, борынына чирткән сыман, елт итеп башын күтәрде һәм, озын сары керфекләрен челт-челт йомгалап, Габделбәргә карады.
— Нәрсә син? — диде ул, хафаланып.— Әллә кире уйладыңмы, Габделбәр энем?
— Ю-у-ук! — дип хуҗа кулын селтәде.— Әйткән сүз — каккан казык. Өегезне минем планга күтәрәсез. Алла биргән ике сутый сезгә! Тыкрык буена азрак кинәйсәгез дә була. Анысы үз эшегез. «Икеләтәдән дә артык бит ул Гафуровның планы» дип йөрүчеләрнең авызы тыгылыр. Күршемдә агай-энем булыр. Әйткәннәр бит, атың начар булса, сатып котылырсың, күршең начар булса, ничек котылырсың, дигәннәр. Җиде яттан берәрсенә план кисеп бирмәсеннәр тагын... Ә урын наять, бәләкәй абый, наять. Бәрәңге бакчасына нарат урманы авып тора, суы кул сузымында...
— Анысын әйткән дә юк инде, энем. Комлык ягында урын иркен дә соң, ни мәгънә. Сезнең монда бигрәк фани дөнья җәннәте бит, уйлап карасаң...
Габделбәр Ханзафар да кызып сүзгә керешеп китәр дип көткән иде. Алай булмады. Ун сүзеңә бер сүз белән котылучан кешене әңгәмәгә тарту мөмкин түгел шул. Әтисе белән абыйсы сөйләшкәнне тыңлап тик утырды. Әйтерсең, сүз бөтенләй ул салып керәсе өй хакында түгел иде.
— Минем шарт бер генә, бәләкәй абый. Ханзафар аңлаткандыр. Ул тресттан җиләк-җимеш бакчасына дип бирә торган участокны ала. Дүрт сутыйдан ким итмәс дип уйлыйм. Коймасына, су кертергә, каравылчысына, фәләненә-фәсмәтәненә дигән акчасын бирәм, такта өйне салып куябыз. Быелга яшелчә-мазар гына утыртабыз. Көздән алмагачларга чират. Телен теш артында гына тотып, бакчаны полный законный үз исемендә йөртә. Вакыты җиткәч, күз күрер...
«Антигрустин» тәэсиредер инде, Әһлиулла бу мәҗлескә кирәге булмаганрак сорау да биреп куйды. Урынлы ук түгелен үзе дә абайлап алды бугай да, сүз чыпчык түгел, әйттең — кире кайтарып булмый.
— Үз җилкәңә үзең артык җәфа аласың ләбаса, Габделбәр энем. Арт бакчаң алпавытныкыдай. Алмасы, чиясе, умартасы... Нимә кирәксендең шул Зәймиш станцасы буеннан җирне? — диде ул.

Габделбәр көлемсерәп җавап кайтарды.

— Булган нәрсә ашарга сорамый ул, бәләкәй абый. Эчне тишми. Аннан соң минем Әгъдәс тә бар бит әле. Гомере буе чит калада яшәмәс, Казанга кайтыр, туган җир тартмый булмас. Инде сезнең йортны күтәрү кадәресе... Үзем булыша алмыйм. Бәрәңгеләрне чәчүгә, курортка очам. Гаграга! Ханзафар чамалар. Поссовет белән сөйләшкән, кәгазьләре рәтләнгән. Ян койманы алып торабыз да бүрәнәләрне ташый башлыйсыз. Нигезгә таш табышырмын, агай-эне хакына цементын да юнәтешергә була...

— Анысын да булыша күр инде, абый. Үземә генә калса, аяк табанымнан ут чыгар...— Ханзафар, ниһаять, сүзгә кушылды.— Машинаны үзебезнең СМУ дан табам. Нигез коярга егетләр киләбез, диделәр. Өмә ясап бурарбыз да дип торабыз...

— Иншалла ырып-ерып чыгарбыз,— дип өстәде Әһлиулла абый.— Рәхмәт, Габделбәр энем. Үз үтерми, ят ярлыкамый, дигәннәр. Бергәбергә гөрләтеп яшәрбез, сау булсак, насыйп итсә...

Габделбәр, сүз эндәшми генә, уйланып куйды: «Синең рәхмәтең белән тун тышлыйсым юк ла анысы. Бердән, минем җирем куплекне күрә алмый йөрүчеләрнең теле тешләнсен. Икенчедән, үзең, чатан чәүкәдәй, җәһәннәмгә дә барасың юк, өйдә утырасың. Яллап каравылчы тотар хәл юк. Сине хода үзе китереп утырткан булачак. Аннары Ханзафарың үгез кебек, басса бакыр өзә торган. Әпәт-теки, йорт эшенә кеше яллап булмас инде, закон сыйдырмый, ә Ханзафар — энекәш кеше. Абыйсына булыша икән, кемнең ни пычагым эше бар? Җир дигәндә, икене биреп, дүрт сутый алам ич мин. Так что, таслап-таслап уйланган һәммәсе дә... Син рәхмәт дисең. Нәрсә ул коры рәхмәт?!»

Килешү, сүз беркетү шәрәфенә янә стаканнар чыңлап алды. Сәяра самоварын гөжләтеп җибәрде, чәй яңартты.

Һәрвакыт шулай димәсәң, әүвәлрәк күтәргәннәрнең гайрәте азрак тоела, соңгы рюмка һәммәсеннән дә кодрәтлерәк булып чыга. Әһлиулла да тагын түнтәреп куйгач, бермә-бер дәртләнеп китте. Биеп булмасын күңеленә күптән киртләгәнлектән, җырлап карарга ымсынды.

— Синең баян бар иде кебек, Габделбәр энем. Бир әле шул Миңлебаяныңны Ханзафар-дәшмәс кулына. Сыздырсын әле бер...

Улы эткәсенең бу ниятен хуплап ук бетермәде.

— Таптың инде, эткәй, син дә эш...— дип сөйләнеп куйды.

— Алай димә син, улым. Димә алай.— Әһлиулла, урындыгыннан күтәрелә төшеп, сыңар кулы белән Ханзафарның җилкәсеннән кагып куйды.— Аракыны корсак тулсынга гына чөмермиләр аны, кәеф килсенгә эчеп куялар. Бергә-бергә утырганда музыка да булмагач, нигә ярагән мәҗелес ул, ә? Үлене дә аркистырлап күмәләр хәзер. Без тере кешеләр ләбаса. Эш кешеләре. Эшләп тә, газиз туфракны саклап, сугышып та күрсәткән кешеләр! Тамак тук, мең шөкер , өс бөтен, җан тынычлыгы да бар. Ил-көн имин тора...

Ханзафар этисе белән бәхәсләшергә ниятләми иде, алай да төрттереп әйтми калмады:

— Тагын берәр рюмка кабып куйсаң, коммунизмны тәмам төзеп житкергәндәй сөйли башлыйсың инде син, эткәй...

Әһлиулла имән бармагы белән улына дустанә янап алды.

— Юк әле, Ханзафар улым, бүген-иртәгә генә төзеп житкереп булмас аны. Күп тырышырга кирәк әле аның өчен. Ну, мин сиңа әйтәм, әйтәм мин сиңа: иң шәп тормышны төзүче кешеләрнең музыка тыңларга да, җырларга да хакы бар. Бар хакы!

Сәяра картның күңелен күреп, сүзләрен хуплап торды:

— Дөрес, бәләкәй абый, бик дөрес әйтәсең. Габделбәр, алып бир баянны Ханзафарга. Тыңлыйк әле бер...

Йортта юк нәрсә булмасын дип алынган музыка коралы, әнә шул

рәвешле, онытылганда бер гамәленә ярап куя тагын! Хужа кеше зур ләззәт, эчке канәгатьләнү белән баянны, футлярыннан алып, Ханзафарга тоттырды. Энесе баштарак төймәләрне барлаган төсле ыңгыр-шыңгыр китергәләп торды да беравыктан «Ике аккош» көен өздереп уйнап жибәрде.

Габделбәр үз уйларына уралып тын калды, Әһлиулла абзый, монысы минем моң түгел әле дигән кебек, бер читкәрәк карап утырды. Сәяра исә бик бирелеп, бик әсәрләнеп тыңлады. Хәтта күңеле тулышты.

Карт озак чыдамады, «улым, тегене уйна әле, уйна тегене» дип заказ бирә башлады. «Теге» дигәне «Баламишкин» иде. Ханзафарның көйне табып алуы Әһлиулла өчен күңелендәге алтын, көмеш, жиз тәнкәләр чыңын бер жепкә тезеп бирүгә тиң булды, карт шул чыңга кушылды:

Уйнат, улым, гармуныңны
Баламишкин көенә.
Шул Баламишкин көенә
Күңелләрем сөенә.

Монысы әле аның сүз кереше генә иде. Баянчы эзенә төшкәч, жырлаучы үз юлын абайлап алгач, мәжлесләрдә Әһлиулла абзый әйттергәли торган жыр худка китте:

...Сибелә чәчем давылга;
Сибелә чәчләрем давылга,
Яшьтин хәсрәт авырга.

Габделбәр нидер әйтмәкче идеме, әллә болай гына кулын хәрәкәтләндереп куйдымы, карт моны күрсә дә күрмәде. Жырлау дәрте аны тәмам биләп алган иде инде, ул тукталыш ясар тәкатен жуеп бара иде. Шуңа күрә, гадәткә кереп киткән, һәр очракта тел очында йөргән жырын башлады.

Ал да буласыларым,
Гөл дә буласыларым.
Төшләремә дә кермәде
Болай буласыларым.

Азакны ике юлны Әһлиулла абзый кабат жырлаганда үзгәртеп куйды.

Төшләремә керә килде
Шулай буласыларым.

Габделбәр, Ханзафарның кечкенә бер тыныш ясавыннан файдаланып, бәләкәй абыйсын шаяртып аласы итте.

— Һәй, бәләкәй абый, әле кайчан гына иң шәп тормыш төзүче кешеләр шат булырга тиешләр дип, бүрек сугып раслап утырдың, үзең әллә нинди моңсу жырларга кереп киттең,— диде.

Әһлиулланың жавабы әзер иде. Кичә кичтән ятлап куйган диярсең.

— Уйланырсың, кодагый, дип әйткән ди берәү, Габделбәр энем. Яман да уларсың, моңсуланырсың да. Дөнья хәлләре агач башыннан йөрмәде бит, безнең баштан йөрде. Күр син мине...— Карт, уң кулының төбен селкетеп, протезлы аягы белән идәнгә шык итеп басып куйды.

— Ярты адәм бит...

Габделбәр йөзеннән уен-көлке качты. Агайны юкка рәнжеттем, тиктәскә кыерсыттым бугай ла, дип уйлады ул. Шулай да житди итеп әйтәсе сүзләре күңеленә төзелгән иде инде, аларны әйтми булдыра алмады.

— Тәкъдирдер, күрәсең, бәләкәй абый, алай да әйтим: үзең дә артык бер катлы бит син, артык патриот...

Әһлиулланың аракы томанын жил очырып алып киткәндәй булды. Ул Габделбәргә үтә сәерсенеп карады, аның тонык яшькелт күзләре «нигә дип мондый рәнжетүле сүз сөйлисең?» дип зар итәләр кебек иде.

— Ниткән гаеп ул минем үземдә? — Әһлиулланың тавышы гайре табигый һәм каты чыкты шикелле, өй башы да имәнеп киткәндәй булды. Ләкин Габделбәр бәләкәй абыйсы ишеләр белән генә сөйләшүне эшкә чутлаган кешеләрдән түгел, үз фикерен шәп-шәрә килеш әйтте дә салды.

— Сугыш хәтле сугыштан да ике аякта кайттың бит син. Уң кулсыз гына идең. Ә тып-тыныч елда сыңар аяклы булып калдың. Кем хакына, нәрсә хакына?!

Сөйләшүнең ниндидер кискен төс алуына Сәяра да, Ханзафар да җайсызландылар.

— Ямьле утыруның ямен качырырга җыенмагыз әле,— диде Сәяра.— Ашагыз, әчегез!

Әһлиулланың күңеле купкан иде шул инде, юаткач басылырдай гына түгел иде.

— Ничек «кем хакына?» — дип тупас кына сорап куйды ул.— Кешеләр хакына!

Аның күз алдына моннан җиде-сигез ел элек булган фаҗигале вакыйга килеп басты.

...Фронттан уң кулын өздереп кайткач, Әһлиулла тракторга утыруны уйламады да. Сугышка чаклы районның атаклы механизаторы булуын, корыч айгырны үзенә буйсындыру ләззәтеннән күңеле канатлануларны хәтерләп бәгыре әрнесә дә, трактордан ваз кичәргә мәҗбүр булды. Елларның авыр чагында тракторчыга гарантияләп түләгән ашлык күз алларыннан очты. Әмма бер ни кылыр хәл дә юк иде. Әһлиулла тимер юлга стрелочник булып урнашты. Айлар узды, еллар үтте, яңа һөнәренә дә күнегеп китте, гомер-гомергә чуен юл кешесе булгандыр кебек тоелды аңа.

Кыш иде. Буранлы көн иде. Сменасын тәмамлап кайтып барган Әһлиулла тимер юлны аркылы чыккан җирдә минераль ашлама төялгән килбәтсез зур чана таккан тракторның туктап калганын шәйләп алды. Чананың арты рельс өстендә! Семафор ачык ләбаса! Бәла бит бу, катастрофа булачак! Менә-менә тиз йөрешле пассажир поезды килеп чыгарга тиеш!

Әһлиулла абына-сөртенә трактор янына ташланды. Кабинадагы егет шабыр тиргә баткан, тик машинасын кабыза алмый иза чигә иде. «Төш әле! Үзем кабызып карыйм!» — дип кычкырганын Әһлиулла тоймый да калды. Акылын җуйган егет урыныннан сикереп төште, стрелочник тракторны кабызмак булып җан ата башлады. Озак үтмәде, өнсез калган «корыч бахбай»га җан кергәндәй булды, әмма ул ике-өч мәртәбә пошкырынды-төчкеренде дә тагын тынды. Эшнең рәтсезлегенә ышанган Әһлиулла кабинадан атылып чыкты да тамагы карлыкканчы кычкырып чанадагыларга да, тракторчы егеткә дә катгый әмер бирде.

— Чананы бушатырга!

Чанадагы өч ир-ат, тракторчы егет үзе һәм Әһлиулла калын кәгазь капчыкларны кар өстенә ташларга керештеләр. Бәхеткәдер, авылларына кайтырга дип трактор чанасына өметләнеп торган егетләр килеп чыкты һәм ярдәмгә ташландылар.

Күпме вакыт узганын Әһлиулла чамалый алмады, йөк бушауга егетләрнең һәммәсен артка чакырды. Көчәнә-көчәнә чананы тартып борырга керештеләр. Өлгерделәр дә, ләкин язмышны бер мизгел хәл итте. Ыжгырып килгән тепловоз рельстан чыгып өлгерә алмаган стрелочникның аягын кистереп узды. Әһлиулланы больницага озаттылар.

Бу вакыйга Текәтауда күп сүзгә сәбәп булды. Күләгәне шүрәле итеп сөйләргә телләре кычытып торучылар: «Кырыклыны кәгеп алган булгандыр ул. Үзе чуен юлда эшли, поезд киләсен белә торып күрәләтә шунда торыр идемени?!» дип чеңгелдәделәр. Илнен-көннең аек акыллы кешеләре исә: «Ярый әле Әһлиулла килеп очраган, үзе гомерлеккә

гариплэнсэ дэ, йөзлэгэн кеше гомерен саклап калды. Адэм канынан күл булыр иде лэбаса», диделэр.
Юл эшлэре министрының приказы белэн рэхмэт белдерелде, бүлэк бирелде. Поселок кешелэренең больницага килүе өзелеп тормады. Ул һэлакэттэн коткарышкан поезд пассажирларыннан туганнарча рэхмэт эйтеп язган ничэмэ-ничэ хат килде аңа. Күп тэ үтмэде, Эһлиулланы «Батырлык өчен» медале белэн бүлэклэделэр...
Габделбэр эле дэ булса «кем хакына? нэрсэ хакына?» дип канга тоз салып утыра. «Кешелэр хакына!» дигэч тэ сэер генэ елмайды да:
— Һэй, бэлэкэй абый, купшы да сөйлэп куясың вакыт-вакыт,— дип каршы төште.— Кешелэр алар, белэсең килсэ, булышканда — эссэлам, эше беткэч — юк сэлам.
Ирене кырт кисеп каршы төшү гадэте булмаса да, сүз болайга киткэч, Сэяра да уендагысын эйтми кала алмады:
— Алай диярга ярамый, Габделбэр. Күпме кеше була поездда! Кемнең газиз баласы, кемнең атасы, анасы... Бэлэкэй абыйлар ул чакта күпме семьяны фажигадэн йолып алдылар. Кешелэр өстенэ ябырылган афэтне булдырмый калу — гомерең буена горурланырлык эш...
Ханзафар Сэяра фикерен куэтлэде.
— Эткэй урынында кем булса да шулай итэр иде, абый. Шулай эшлэргэ бурычлы хэтта!
Габделбэргэ Ханзафарның «бурычлы» дигэне ошамады, ул чыраен сытып, борынын жыерып куйды. Кызыл сүз сөйлисең, янэсе. Ханзафар моны бик тиз аңлады һэм тагын да катгыйрак итеп:
— Эйе, эйе, бурычлы! — дип кабатлады.— Күплэргэ килгэн бэланы бераү, бераүгэ килгэнне күплэр үз күкрэге белэн капларга бурычлы, абый.
Габделбэр өстэл янынная торды, ике кулын чалбар кесэлэренэ тыккан килеш, Ханзафарга якынрак килеп басты.
— Мораль кодексны минем дэ эллэ ничэ рэт укыганым бар. Такташ абзыйның бу хактагы шэп шигырен яттан белэ идем шикелле. Ничек эле? — Хужа, уң кулын түр тэрэзэлэргэ таба сузып, хэтердэн укый башлады:

> ...Ах, син, илем,
> Ничек үлэрсең соң,
> Сагыныр кешелэр синдэ булганда,
> Ничек үлим,
> Берлэр миннэр өчен —
> Меңнэр берлэр өчен торганда!..

Шулаймы?
Ханзафар-дәшмэснең дэ каны уйнаклый башлады булса кирэк, «шулай һэм бик дөрес эйтелгэн» дип жавап бирде.
— Сүздэн бишмэт тегеп булмый, энем. Бигрэк бэлэкэй абзыйга охшагансың. Сэеррэк фикер йөртэсең,— диде дэ Габделбэр янэ урынына китеп утырды.— Кешелэр хакына, имеш!
Ханзафар да үз фикерен якларга дигэндэ хирыслана белэ икэн.
— Алайса революция ясаган кешелэр, граждавнар сугышы геройлары, Испания азатлыгын якларга баручылар, Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин, Бари Шэвэлиев тэ сэер фикерлэгэннэрме? — Ханзафар Габделбэргэ текэлде.
— Ул бит сугыш... революция... Хэер, нигэ дип чүбек чэйнибез эле без. Кешелэр һэммэсе фэрештэме эллэ? Шул поездда бугазына басып соңгы тиенение алырга торучылар да аз булмагандыр... Ярарсана, кысыр кайгы белэн баш катырабыз. Ягез эле, күтэреп жибэрик.
Эһлиулла улының кире каккысыз сүзлэр табуына, Габделбэрне читэнгэ терэвенэ эченнэн куанган иде. Шуңадыр, стаканын кулына алгач,

«әйдәле, улым!» дип, иң әүвәле Ханзафар белән чәкеште. Аның тулы түгәрәк йөзенә канәгатьләнү билгесе бәреп чыкты.

Шул чак шыгырдап капка ачылды, чылбырын чәйнәп өзәрдәй булып Пират өрә башлады. Тәрәзәгә күз салдылар. Капкадан Корбан Сагындыков белән хатыны Хафаза ханым кереп киләләр иде.

— Бажай килә, поселок башлыгы! — дип, Габделбәр ишеккә юнәлде.

Сәяра да, җизнәсе белән апасын каршыларга дип, урыныннан күтәрелде.

Әһлиулла уенын-чынын бергә кушып әйтә куйды:

— Кунак кунакны сөймәс, хуҗасы берсен дә сөймәс, дигәннәр. Кузгалабызмы соң әллә, улым?..

## 4

Май азагы җитсә дә, дәррәү җылытып җибәрмәде. Көннәр һаман эленке-салынкы торды. Бер карыйсың, кояш елмая, җанга рәхәт булып китә, икенче әйләнеп баксаң, күзге айдагы сыман баш түбәнә мамык юрган кебек болытлар агылып килә.

— Май салкын икән, көзе ризыкка бай,— диештеләр картлар.— Игеннәр хут ала, боерган булса. Корт-мазар төшәргә, чир-чыру килергә җай калмый.

Алай да Әһлиулла абзый көннәрнең нygытып утырып китүен теләде.

— Дәү эшкә башлаганда кояш караган хәерле,— ди иде ул. Бу фикер аңа әллә әтисеннән, әллә бабасыннан ук сеңеп калган.

Картның күңелен күрим дигән төсле, табигать тә чырай сытуыннан туктады. Ханзафар үзе эшли торган бригада егетләре — Гадел Туктаров, Николай Святов һәм Алнур белән бергәләп Габделбәр бакчасы буендагы өйлек бүрәнәләр янына килеп баскан иртәдә, шимбә көнне, ялтырап кояш чыкты. Әһлиулла моны бик изгегә, хәерлегә юрады. Кәефе күтәренке иде аның. Өй бурашу өмәсенә килгән егетләрне мактап туймады.

— Сезне күргәч, оланнар, туп-турысын әйтим, күңелем тулышып куйды, билләһи. Егетләрнең асыллары, мин әйтәм. Ярдәмнәреннән ташламыйлар... Рәхмәтләр генә яусын үзегезгә! Хәзер Степан дәдә килеп житә. Көтик, оланнар...

Степан Семеныч, чыннан да, озак көттермәде. Йөзендә кояш нурлары уйнап торган балтасын биленә кыстырып килеп тә җитте. Ул таза гәүдәле, зур битле, чылгый мыек җибәргән, әмма сакалын тап-такыр кырып йөрүче мәзәгрәк кеше иде. Быел алтмышны тутырды. Пенсиягә чыкканына кичәле-бүгенле генә диярлек. Текәтауның атаклы кешесе, житмеш бер һөнәр иясе. Кырык елдан артык заводта эшләгән, тимерче. Гомерен Текәтауда үткәргән кеше. Һәр бирмеш көнендә шәһәргә хезмәткә йөргән эшче.

«Поездда йөреп мин үткән юлның чутына чыгасы бухгалтер тумаган әле!» — дип шаярта ул.

Төп һөнәре тимер эше булса да, Степан дәдәне тирә-юньдә әйбәт столяр һәм балта остасы буларак та мактап туймыйлар. Текәтаудагы йортларның байтагы бүрәнәсенә аның балтасы тими калмаган. Әле моннан берничә көн элек кенә раймагта Әһлиулланы күргәч тә үзе сүз башлаган иде.

— Кайчан тәвәккәллисең, Агли? Өмәгә мине обязательно чакыр! — дигән иде.— Иначе дуслыкны бозасың, старина...

Бүген дә менә, егетләр янына килеп җитүгә, гөлдерәвек тавыш белән сәлам бирде һәм шаяртырга кереште.

— Бура кайда, егетләр? Капкадан чыктым да карыйм, юк кына! Күзләрнең рәте китте микәнни, дим. Чынлап, кыл да кыймылдатмагансыз ләбаса...

— Сине көттек, сине, Симуныч... Синең кул җиңел дип атаулы бит,— диде Әһлиулла аңа каршы.— Әйдә, башлап җибәрик, хәерле сәгатьтә!..

— Көтсәгез, килдем менә. Күршелек хакы кырык өйгәчә дигәннәр бит, килми ярамый... Саулармы сез, егетләр!

Һәммәсе белән кул биреп күрешеп чыккач, Степан Семеныч билендәге балтасын сагызы бөрчек-бөрчек саркып торган юан нарат бүрәнә башына каптырып куйды һәм, ямьшәйгән кепкасын астына салып, бүрәнәгә барып утырды. Аннары учы белән маңгайдан түбәгә таба уйдыкланып кергән пләшен сыпырды, чигә буйларындагы чаларган чәчләрен төзәткәләгәндәй итте дә кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарды.

— Безнең урыста эшнең башы итеп махра көйрәтеп алу гадәте бар,— диде ул, көлемсерәп. Семеныч, тимерче әтисенә ияреп, малай чактан ук татар авылларын гизгән кеше булганга, безнең телне шәп белә. Шунлыктан бик әйбәт татарча сөйләшә иде.— Тәмәке төтене уйларны чиратка тезә диләр ич...

Шул арада егетләрнең хәл-әхвәлен сорашып алды. «Кырык тартмачылар инде сез, ә?» дигән булды. «Үзегез ташчылар, үзегез балта осталары. Кирәксә штукатурлар да, ә? Комплекслы бригадада шундыйлар кадерле, знамо. Кул тотынса, эш карышмый. Шулай кирәк, егетләр!»

Эшкә керешкәч, сүз тынды. Һәркемнең күзе балтасында һәм бүрәнәдә булды. Тирә-юньгә нарат исе таралды. Җиздәй тышлы ап-ак йомычкалар очты. Балта тавышлары урман буена ук китеп яңгырады. Беравык эшләүгә егетләрнең күлмәкләре артыкка әйләнде, тагын бераздан майкалар да кирәкмәс булды.

Степан Семеныч бер дә кабаланмады, бүрәнәне җай белән генә юнды. Балтасы аның шул тикле тынлаулы иде, агачны шулкадәр тигез итеп каезлап барды, бүрәнәнең өске ягы көзгедәй булып кала килде. Бил язарга турайган арада Семеныч яшьләргә дә күз сирпеп куйгалады һәм мыек чылгыйлары астыннан хәйләкәр генә елмайгалап алды. Алнур белән Николайның тирләп-пешүләрен бик тиз искәрде ул: көч бар егетләрдә, беләкләр нык, тик маһирлык чамалырак. Шуңа тирләп чыктылар, шуңа пар бөркиләр.

Карап торды-торды да, түзмәде Степан дәдә, Николай янына килде. «Ну-ка, Коля-Николай,— диде ул,— балтанны бир әле. Менә болайрак ал син аны... җайлабрак... Ул кадәр үк кизәнмә дә, көчәнмә дә. Корал-да болай да кырык кешенең көче бар. Син дә кара, Алнур... Ханзафар белән әнә теге егет... кем әле... исемен онытгым...

— Гадел...— диде Алнур.

— Әйе, Гадел... Аларның төтен турырак йөри. Кабаланып төшмиләр.

Степан Семеныч, шулай сөйләнә-сөйләнә, егетләргә эшнең җаен өйрәтте.

— Ашыкмагыз,— диде ул, бик җитди итеп.— Ашыгып ашка пешүгез бар. Бозау арканларга казык юну түгел, өй бурау. Гомерлек чатыр.

Гадел дә, эшеннән туктап, беләге белән маңгаен сыпырып җибәрде һәм, шаярып, Степан дәдәнең сүзен бүләргә исәпләде.

— Һей, Степан Семеныч,— диде ул, картның чын-чынлап сөйләп торуына аз гына да илтифат итмәгән кыяфәткә керергә тырышып,— гомерлек чатыр дисең син. Ул хәтле нәрсәсе бар инде аның?! Бабай әйтә иде: «Кубыз тартсаң көй була, бүрәнә тартсаң өй була», ди торган иде. Шулай түгелмени?..

Семеныч, фикере белән, уен-муеннан читкә киткән иде. Гаделгә кырыс караш ташлады да җавап бирде:

— Дөньяның бер зур эшенә җиңел караган бәндә сүзе ул. Өй, егеткәем, мәңге-мәңгедән кеше гомеренең йөзек кашы саналган. Өе барның

иле бар, иле барның көне бар, дип шунлыктан әйтелгән. Ә өй дигәнең җир жилкәсендә тормый, ир жилкәсендә тора...

— Шулай да ашыгырга да кирәк, Семеныч,— дип сүзен бирмәскә маташты Гадел.— Июньнең егермесендә Ханзафарга егерме биш тула. Җир йөзендә чирек гасыр яшәүне яңа өй туе белән бергә билгеләп үтәргә тиеш ул.

— Ашыгу — шайтан фигыле.— Әһлиулла абзый сүзгә кушылды.— Сабыр иткән — морадына житкән. Насыйп булса, Гадел энем, аннан алдарак та бастырып куярбыз...

Янә һәммәсе дә балталарына ябыштылар. Әһлиулла абзый эшнең гөрләп баруына куанып бетә алмады. Осталарның балта тавышы бу көнне аңа бернинди музыкага да алыштыргысыз иде.

Хыялы белән алты почмаклы өйнең түрендә иде инде ул. Менә, боерган булса, урам башын ямьләндереп аларның якты, иркен өе күтәрелер. Мич ягып, тәтене-сөреме, көле-күмере белән иза чигәсе юк, пар казаны көйләрләр. Күмер ягасыңмы, торфмы — үз эшең. Габделбәрләр ягыннан суны да өйгә кертәсе. Киленнең дә мәшәкате бермә-бер кимер. Онықларны да чатыр-чотыр янган мич тирәсендә сагалап утырасы булмас. Веранда да эшләп, аның буена, өй каршына чәчәкләр дә үстереп җибәрсән... Һәй, үрмә гөл күләгәсендә чәйләп утырасы гына...

Күңеле уйнаклаганга, Әһлиулла абзый бер генә урында тыныч тора алмады. Әле Ханзафар янына килеп нидер киңәшкәләп китте, әле Алнур белән Гаделгә сүз кушты, аннары Николай янында гәпләшеп торды. Семеныч белән дә нәрсә хакындадыр сөйләшеп алгач, үзенә бер шөгыль тапты. Сазан балыклары кебек җәйрәп яткан зур-зур йомычкаларны бер тирәгә җыярга кереште. Бу эш белән дә әйтерлек мавыга алмады, юыртып Сәяра килене янына, өйгә кереп китте. Аның хәлләрен белеште. Төшке аш ни чамадарак, янәсе, өлгерәме? Аш алдыннан йөриселәрен барлады, закускаларын әзерләште. Габделбәр өйдә чак булса, осталарга сый-хөрмәт ничегрәк әзерләнер иде әле, кем белсен. Аның курортта чагы булгач, Сәяра иркенләп йөри, эш кешеләрен кулыннан килгәнчә туклыклы да, тәмле дә итеп сыйларга дип тырыша.

Бер карасаң бик кызык: әллә кайларга, диңгез буйларына ялга бармаса да, ялгызы гына калдымы, Сәяра җанланып, тернәкләнеп китә. Ирен читләренә елмаю куна, күзләрендә нур ишәя, гәүдәсе дә тураеп, калкып куйган кебек була, сүзгә дә остара, жорлана шикелле. Әйтерсең лә, зәгыйфьләнеп, аксыл булып борынлаган яшь үлән кыягы өстеннән таш-туфракны алып ыргыталар... Югыйсә, Габделбәр өйдә көннәрдә дә тамагы ач, өсте ялангач түгел. Ашаган ризыгын бизмәнгә салучы юк. Әмма кеше дигән җан иясенә икмәк белән ит, чәй белән шикәр генә җим түгел, күрәсең. Майда коендырсаң да, чын ефәккә төрсәң дә, бил-беләзегенә һәм муенына асылташлар таксаң да кешенең канәгать булмавы бик мөмкин икән лабаса. Аңа рухи иркенлек зарур, ул шуңа сусый икән. Җанын бәйләп, богаулап торган путалардан, эреле-ваклы чылбыр һәм җепләрдән арынасы килә аның. Габделбәрнең күз карашы салкын кургаш булып башына бәрелмәвен, ире авызыннан чыккан һәр сүзнең катгый кисәтүче әмер төсле бәгырен көйдермәвен тели ул. Аның җаны елмаюга каршы елмаю көтеп зарыккан, киңәш-уңаш итүне өметләнеп тилмергән, ир буларак кына түгел, гомер юлдашы, фикердәш, балаларның атасы буларак та наз көтеп коргаксыган. Өметләнгән, зарыккан, тик ул кадәресе аңа насыйп булмаган. Габделбәрнең холкы болыт арасыннан елмайган кояш сымаграк. Сирәк жылыта, сирәк назлый.

Шуңадыр, ахрысы, кеше белән аралашуны гомер-гомергә күңеленә бәйрәм итеп күргән Сәяра Әһлиулланың осталарына аш-суны ләззәт һәм тәм табып хәстәрләде. Хәер, Габделбәр үзе дә ялга китәр көннәз «Бәләкәй абзыйларга булыш инде син»,— дигән иде.

Табында гөр килеп утырдылар. Эш кешеләренә хас булганча, кашык-чәнечкеләр дә уйнап торды, чәшкә-чынаяк та тиз бушады. Николай гына бер яктан бүтәннәргә иш була алмады.

— Эчмим! — диде ул, аш алдыннан тәкъдим иткән рюмкасын читкәрәк алып куеп.— Рәхмәт, кыстамагыз...

Гадел белән Алнур да аның сүзен куәтләделәр: «Николай ул яктан фәрештә ул безнең. Эчми, тартмый, сүгенми, тиргәшми. Фамилиясе үзенә тач туры килгән — Святов!»

Өстәл янынннан кузгалып, йортка чыккач, тәмәкесен көйрәтә-көйрәтә, Семеныч аш янында башланган сүзне дәвам итте.

— Эчмәсәң, тартмасаң, знамо, бик шәп!

Семеныч шушы арада гына Мәскәү газеталарының берсеннән зур галим язган «Ирләрне саклагыз!» дигән мәкаләне укыган икән. Степан дәдә, ара-тирә мыек чылгыйларын сыпыргалап, укыганының эчтәлеген сөйләп китте.

Малайлар күбрәк тусалар да, үсә-үсә, яши-яши ирләр кимеп калалар икән. Бу хәлгә беренче сәбәп, гомумән, хатын-кыз организмының яшәү сәләте зуррак булудан килсә, «шайтан суы»ның һәм тәмәке төтененең тискәре йогынтысы да галәмәт зур икән. Ул галим әйтә ди, безнең илдә хатын-кыз гомеренең уртача озынлыгы 74 ел, ирләрнең — 66 ел гына. Әгәр без шул аерманы сигез елдан дүрткә генә калдыра алсак та, халкыбыз тормышы өчен бик зур эш башкарган булыр идек, ди икән. Шундый сүзләре дә бар ди: бөтен ир-егетнең гомерен сакласак, кызларның һәммәсе дә үзләренә тормыш юлдашы табар иде, ә егетләрнең бер ишесенә кәләш житеп тә бетмәс иде...

— Йомыкыйрак егетләр буйдак булып каласылар икән, ә? — Әһлиулла абзый кеткелдәп көлеп алды.— Менә тере Симунич нияр сөйли, Николай.

Карт ни өчендер Николайга төбәп эндәште. Яратып әйтүе иде бугай, чөнки тулы түгәрәк йөзе балкый иде. Святов та тел тешләп тормады.

— Кемгә ничек булыр иде әле анысы... Семеныч кебегрәк үткеннәре икешәр кәләш алырга да өлгерерләр иде,— дип куйды. Әйтүен әйтте, тик саксызрак булды шикелле. Степан дәдәнең шаяруы өреп очырган төсле юкка чыкты. Дулап торган куе кашлары тоташып калды. Ул, Николайны шул мизгелдә тәүге тапкыр күргән кебек, егеткә чекерәеп карады. Аннары коры һәм шактый җилле итеп җавап кайтарды.

— Семья мәсьәләсендә минем үз бухгалтериям, Николаша. Бу хатынымның икенче булуын, ике хатыннан тугыз балам барын Текәтауда белмәгән кеше юктыр. Беренчесенең семья тартәсенә сыймаганын яхшы беләләр, шуңа битәрләмиләр. Значит, шулай кирәк... Син бик яшь әле. Мине алдан, арттан, яннан, чаттан кара, ну семья бухгалтериясенә үрмәләмә... Кертмәм...

Семенычның үпкәләве барысына да күңелсез тәэсир итте. Николайның: «Гафу ит, Степан Семеныч. Шаярган гына идем», дию дә күләгәне куып җибәрә алмады. Бары тик балталарны кулга алгач, бүрәнәләр тирәсенә йомычкалар чәчрәп төшә башлагач кына күңелләрдәге төеннәр чишелеп, кәефләр аязып китте.

Бер кавым эшләп, сулу алырга туктаганда Степан дәдәнең йөзендә дә, сүзендә дә үпкә һәм рәнҗү сизелми иде инде.

Күз тимәсен диярлек эшләделәр. Арысалар арыдылар, ләкин башкарган хезмәтләренең шаһите булып бураның аскы өлеше күз алдына басты. Иртәгесен иртәрәк керешергә дип таралыштылар. Яшьләр, сыннары катса да сер сынатмаска әзер халык, Текәтауның җәйге паркына чыгарга киңәштеләр.

Кич тын иде. Кояш урман артына китеп баеган. Аның соңгы нурлары гына күк читен алсуга манып тора. Әйләнә-тирәдәге үзәннәрдән үлән һәм чәчәк исләре аңкый. Урман да тынып калган. Бар табигать,

көнозын кояшта кызынып, арып, танда тешәсе чык тамчылары сискән дереп уятканга кадәр татлы йокыга талган иде.

## 5

Габделбәр иртәнге якта кайтып керде. Юл мәшәкатенең ни икәнен белергә өлгермәде дә. Гаградан Адлерга килде, андагы танышы Казанга тикле дип самолетка билет алып куйган иде. Аэропорттан Текәтауга такси яллап кайтты. Асфальттан җиңел машина җилдерә генә!

Киң кара тасмадай юлга, каршыга очраган һәм выжылдашып үтеп торган машиналарга карап кайта-кайта күзе талгач, Гафуров кояш томалагыч кара пыялага текәлеп, уйга чумды. Дөресрәге, курортта булган көннәрен, дус-ишләрен, диңгез табигатен янә бер тапкыр фикер иләгеннән үткәзде.

— Шәп соң Кара диңгез буйлары! — дип куйды ул эченнән.— Шәп, шайтан алгыры!.. Яши белеп яшәгән кешегә аяк басар, колач җәер җай бар инде. Хикмәт диңгез матурлыгында гына түгел, әлбәттә. Шул диңгез буена ымсынып килүчеләрне кырып-кыркып калырлык итеп хуҗалык көйләп җибәрүдә... Дөрес, табигать гүзәллеге дә оҗмахына торышлы...

Таксиның Текәтауга килеп кергәнен Габделбәр абайламый да калды диярлек. Райком һәм райбашкарма бинасын күргәч кенә уйларыннан арынды һәм шоферга урман башына таба барырга кушты.

Юл хакын түләп, таксичыны озатып җибәргәч, Габделбәр, бер мизгелгә йорт каршысына басып, һәммәсен күздән кичерде. Сиреньнәр җәелеп утыра, тик чабылган куак кына корыган икән. Алмагачлар да сөбханалла диярлек күренә. Бал кортларына көннәр ничегрәк булды икән? Ә монысы... монысы...— Гафуровның карашы шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салып куйган яңа, зур һәм биек өйгә тукталды.— Маладис, Ханзафар, булдыргансың! Бәләкәй абый тынгы бирми ашыктыргандыр. Көйгәләк булу да ярап куя шул дөньяда. Маладислар! Инде тәрәзә яңакларын, рамнарын куйсалар, җылыту әмәлен күрсәләр, идәнне, түбәне буятып җибәрсәләр, иһи-һи, хан сарае була бит бу! Мине кыстылар бераз кысуын да, хәерлегә булсын. Идел буенда киңәю хакына болай итәргә бик ярый. Анда бакчаның шундыен үстереп җибәрмен, янсын дошманның йөрәге! Гомерендә үз йорт-җире булмаган, буласы да юк отставной Сәлмәнов ишеләр тик корышып ятсыннар! Дөнья бу шуның өчен.

Габделбәр капка келәсенә килеп кагылуга, оясында шым гына яткан Пират ыргып чыкты һәм чылбырларын чылтыратып капкага ташланды. Тик шунда ук йорт башын танып алды һәм куанычыннан чиный-чиный аңа сарылмакчы итте. Хуҗа, кулындагы чемоданын бер читкә куеп, этнең башыннан сыйпады, муенсасы кысмаганмы дип караштырды.

— Ябыккансың, Пират... Ярамый болай, ярамый. Кабыргаларың санарлык булып бара бит, әкәмәт,— дип сөйләнде Габделбәр.

Капка тавышын һәм этнең ыргып-ярсып алуын ишеткән Сәяра да болдырга чыгып җитте.

— Бәрәкәт, әткәләре кайтып җиткән икән ич! Капкада кем бар дисәм... Исән-сау кайттыңмы?

Габделбәр болдырдан күтәрелде, Сәяраны кочагына алып күреште.

— Кайттым, әнкәләре. Ял итү җитәр, яхшы нәрсә күп булмый ул, кайтып эшкә җигел,— диделәр. Үзең нихәл яшәдең? Синнән ни бары бер хат алдым. Кайтыр алдыннан гына Әлфия белән кияү дә язганнар иде. Йөрәк нишли, бик җәфаламыймы? Я, әйдә, өйгә керик...

Чәй янында сүз Габделбәрнең ялы турында һәм Текәтаудагы хәл-әхвәл хакында булды. Әгъдәсләр язган хатны уку да хуҗаның күңеленә хуш килде. Улы зур шатлыгын уртаклашкан, соңгы күргәзмәләрнең берсендә күрсәтелгән картинасының икенче дәрәҗә диплом алуын

язган. Хатынын азагында: «Көтелмәгән үзгәрешләр булмаса, август урталарында Текәтауга кайтып килергә ниятләп торабыз. Сабан туена туры китереп кайта алмабызмы дип талпынып караган идек тә, барып чыкмады, бушамадык. Зинага үзебезнең бәйрәмне, сабан туен күрсәтермен дигән идем», дигән.

— Күрсәтербез, улым, күрсәтербез,— диде Габделбәр, эчке бер горурлык белән.— Исән-сау булыйк та, җан тыныч булсын, дөньясы гына дингез булып болганып китмәсен... Күрсәтербез... кайтыгыз гына. Үз өемдә ясармын мин сезгә сабан туеның әттәгенәсен!

Ни хикмәттер, олыгаю галәмәтеме, әллә бүтән бер сәбәбе бармы, соңгы елларда Габделбәр киләчәк көннәрдә эшлисеrange һәр адымда өйнең илнең иминлегенә бәйләп фикерләргә гадәтләнде. Биш вакыт намаз карты диярсең, «насыйп булса»ны ике сүзнең берендә кыстыра. Гәпләшеп утырган чакларында Корбан баҗасының аңа: «Син, Габделбәр, карап-карап торам да тагын бер карап куям, «алла теләсә, хатын, ишек ач» дигән татарга әйләнгәнсең»,— дип әйткәне дә бар. «Сүз җиләме генә лә ул!» дип кул селтәгән иде Гафуров.

Кеше алдында кул селтәү, ике тиен бер акча дигәндәй, бик ансат. Тик Габделбәр эч пошудан, ниндидер шомланудан, икеләнүдән чипчиста булып арына, сафлана алмый. Кешегә авыз ачып икърар итмәсә дә, хәтта күз кабагы, кашы тартудан, күз кычытудан да тик томалга пошынып, укра тешләгән сыер кебек, җанын-тәнен кая куярга белми гаҗиз булып йөргән чаклары байтак аның. Ничек дип исемләр хәл дә юк ул халәтне, тик менә ниндидер афәт сагалап торгандай тоела. Кыскасы, «уф дисәм, утлар кабына тәнемнән күлмәгемә» диярдәй вакытлары бар Габделбәрнең... Әллә шул байлыгы тынгы бирмиме аңа?! Үзе әйткәндәй, дөньяның стартерына бик көчәнеп басу бимазалыймы? Атым юк урамда, кайгым юк буранда, диебрәк яшәгәннәр күңеллерәк көн итә түгелме соң? Бәлки, шулайдыр да. Бәлки, бәлки... Әмма Габделбәр бу якты дөньяга сантый булып яшәргә килмәгән.

Дәртле-дәрманлы Габделбәр белән шик-шөбһәгә уралып калган Габделбәр бәхәскә кергән чакта ул, үзен тынычландырыр өчен, «антигрустин»га да сыенгалап карый. Бүген дә шулай итте.

— Тегендә, әнкәләре,— диде ул шаярып,— шәрабның алы да бар, гөле дә. Тик менә мондыен күзгә тамызырлык та юллап булмый... Тансыкка авыз итик әле, ә?! — Бераз спирт күтәреп куйгач, ул күп итеп су йотты.— Авыз итик дигәннән, әнкәләре, бу юлы баруда, беләсеңме, ни белән сыйладылар? Акула ите белән! Аксымга бай икән ул әкәмәт. Егерме процент аксым бар икән аңарда. Дингез ерткычы гына димәсең, аңардан ничәмә төрле аш хәстәрлиләр ди. Йөзгеч куыгыннан аш та пешерәләр икән!..

Чәйдән соң ул урын җәйдерде. Төн йокысы туйганчы әләкмәсә, буынны-сынны ватучан бит...

Йокысы йокы булмады барыбер. Бер уянганда тирләп-пешкән иде. Янында Сәярасы юклыкны шәйләгәч, аны чакырып, сәгать ничәлеген сорады. Тегесенең камыры кабарган, мич үрләткән, шуңа торып китүе булган икән, сәгатьнең унбер тулып кына үзганын әйтте. Габделбәр икенче якка әйләнеп ятты да янә йоклап китте. Алай да сәгать беренче китүгә тагын уянды. Килбәтсез төш бүлде йокысын. Имеш, Сәяра аның пинжәк кесәсендәге куен дәфтәрләрен, кәгазьләрен актарган икән дә бер блокнот арасыннан фоторәсем табып алган. Кулында әйләндерептулгандырып озак кына торган, имеш тә, Габделбәрдән сорый, төпченә башлаган. «Кем бу, янәсе, нинди хатын-кыз? Иллегә җиткән башың белән, бер тамчы да оялмыйча, ни йөзең белән моның белән фотога төштең?» Габделбәр бер фоторәсемгә, бер Сәярага карый, имеш, һәм ничә ел гомер итеп бер тапкыр да мондый гауга чыгармаган хатынының телдәрләнеп китүенә гаҗәпләнеп туймый, имеш. Шуннан, җавап-

мазар биреп тормастан, фоторәсемне Сәяра кулыннан тартып ала да, ирләгән итеп, акырып сала, имеш:

— Бүтән хәсрәтең булмаса, бар, юлыңда бул. Әнә табадагы ризыкларың кояш. Марш моннан!

Уянуы үз тавышыннан булды. Исенә килгәч, озак ятмады. Аннанмоннан гына киенде дә эшек алдына чыкты. Куен кесәсендәге блокнот арасыннан фоторәсем алды, аны, вак-вак кисәкләргә турап, кәгазьгә төрде һәм бәдрәфкә ташлады. «Бер дә кагылганга охшамый. Акчалар да, юл кайткан билетлар да үз урынында. Хәер, Сәяраның шымчылаилп, капшанып йөрү гадәте юк ла аның», дип үз-үзен тәмам тынычландырды.

Аннары Габделбәр арт бакчага чыкты. Кара кучкыл яшел булып тигелгән, хәтсез үк буй сузган бәрәңгеләрне карады. Әллә чәчәккә бөреләнергә дәртләнгәннәре дә бар инде? Әйе шул, әйе. Иртә өлгерә торган сорт бит монда. Кешең булса, иренмәсәң, июльнең унбиш-егермеләрендә Казанның колхоз базарына яңа бәрәңге илтергә бик мөмкин. Бер капчык кына озатсаң да, көзге мәлне ун капчык үлчәп сатканга тора лабаса!

Алмагачларга күз төшер! Иhи-hи-и! Быел уңыш былтыргы ише генә булмаячак. Алма куакларына хет хәзердән терәү куя башла. Терәве — үз кулында, райпотребсоюз белән дә, тимер юл ОРСы белән дә сөйләшеп куярга кирәк. Сәяраның исәнлеге чаклы-чоклы, аңа ышанып бар хәзинәңне черетерсең. Ә Габделбәр үзе килолап алма сатып тормас ич. Центнеры, тоннасы белән илаhи-уптым бер очтан төяп илтсәң дә акчасын кесәгә салып куясың...

Яле, помидорлар ни хәлдә? Быел үзе утырта алмады, рәте бармы икән? Ярыйсы, ярыйсы, болай учарланып киткәч, каhәрләп ташларлык түгел... Кыярлар да үрмәләнеп маташалар. Суны гына мулрак сибәргә кирәк...

Аннары умарта кортлары ояларының берсе буенда берничә минут басып торды. Җир йөзенең иң тырыш җан ияләре үз «дәүләтләре»нең чик капкалары төбендә мәж киләләр иде. «Сакчылар» татлы җим җыеп кайткан өйдәшләренең һәркайсын тикшереп, барлап кертә торалар. Бушаган кортлар кабат сәяхәткә юнәлә.

«Ел җилле быел, ел җилле...— Габделбәр үз алдына шулай сөйләнеп куйды.— Кортларның канатын талдыра, канатын кисә, бик тиз хәлсезләндерә. Былтыргы чамасы бал җыя алсалар, ни әйттең иде дә. Балның почеты зур, халыкта акча бар, ябырылып алалар...»

Аның бакчадан әйләнеп керүен генә көткәннәрмени, урам яктан капка төбенә казлар кайтып җитте. Габделбәр капканы каерып ачты һәм сорылана төшеп ямьсезләнгән, ләкин үсеп-ныгып киткән, яртылаш каз булган бәбкәләрне санап кертә башлады. «Берәү, икәү, өчәү... биш... тугыз... унөч, ундүрт... унсигез... егерме ике, егерме өч... Чү! Егерме өч кенә бәбкә түгелме соң?» Гафуров урамга чыгып карады. Аксаптуксап, канаты каерылып артта калганнары юкмы? Күренмәде. Шуннан Габделбәр хатынын чакырып чыгарды.

— Мин егерме өч кенә бәбкә санадым, Сәяра. Ялгыштыммы әллә...

Сәяра, ялгыш эш кылган нарасый кебек, уңайсызланып китте, битенә кызыллык йөгерде.

— Дөрес санагансың, эткәләре. Берсе үзең киткәндә үк чирләп калган иде, иртәгесен үк үлде...

Габделбәрнең йөрәк эчкәресендәге әллә кайсы җепселе киерелеп тартылгандай булды. Шунда ул:

— Ә тагын берсе? — дип чамасыз дорфа соравын искәрми дә калды.

Сәяраның чынын әйтми җае юк иде.

— Анысын бер атна чамасы элек Пират бугазлап ташлаган...

Гафуровның яңагына чалтыраттылармыни! Үзе кыегаеп китте һәм ул:

— Ә син нәрсә карап тордың? — дип җикеренде. Синең күзләрең кайда иде? Үзем өйдән аяк атлап чыгасы булгач, эт каравылларга кеше ялладыммы инде? Каз булды дигәндә бит, каз булды дигәндә!..

Гафуров кара коелды, эндәшмәс булды. Ләкин бу аның чын-чынлап котырынуы түгел иде әле. Анысы Ханзафар белән Әһлиулла абыйсы килгәч башланды.

Габделбәр аларны ачык йөз белән каршылады. Каз бәбкәләре хакында бөтенләй онытканн иде диярсең, көлеп, шаярып сөйләште. Сәярага чәй өлгертергә кушып, өчәү яңа өйне карарга чыктылар.

Озак юандылар алар анда. Мондый чакта ир-атның да сүзе бетмәүчән була. Самовар кайнап чыккач, Сәяра тәрәзәдән дә үрелеп карады, болдырга чыгып та күз салды, тегеләр һаман өй эчендә мыгыр-мыгыр нидер сөйләшәләр иде әле.

Нәрсә килеп чыккандыр, Сәяра инде әйләнеп керерләр дип торганда кинәт тавыш-гауга күтәрелде. Кычкырыша-кычкырыша өйгә керделәр. Утыр дию че дә, урын бирүче дә булмады. Әһлиулла белән Ханзафар ишек төбендә басып каттылар, Габделбәр исә ярсуына, гарьлегенә тәкать таба алмыйча, ачуыннан буылып, ишекле-түрле йөренде.

— Үзеңә җир бирмәсләрен белгәч, нигә дип минем планга йорт күтәрдең? Әйт шуны миңа! — Габделбәр Ханзафар каршына очып килде. Буш җиңен җилфердәтеп, аксый-туксый, Әһлиулла аларның арасына кереп басты һәм хәсрәтеннән миңгерәгән бер тавыш белән хәлне аңлатырга тырыша башлады.

— Ханзафарга бакчалык җир бирмәсләрен белгәндә, Габделбәр энем, цементлап нигезен катырган идек, стенасын күтәрә башлаган идек бит инде...

Бүген генә тетрәнүдән түгел, ике атнадан артык шул көенечне кичереп йөргәнгә, Ханзафар йончып, ябыгып калган иде. Болай да сүзсез кеше дачалык участоктан коры калгач, тәмам мие түнде. Хәсрәте эченә кату булып чыкты. Бүтәнчә ничек булсын ди? Габделбәр абыйсының холкын биш бармактай белә ич ул.

— Текәтаудан участок алып йорт корасың икән, сиңа бакчалык җир бирә алмыйбыз, диделәр бит, абый. Кырт кисеп әйттеләр. Законы шул, тәртибе шундый, диделәр...— Ханзафар болай сөйләвенең Габделбәргә тырнак очы кадәр дә тәэсир итмәсен белә торып әйтте. Батканда саламга ябышу иде бу.

Габделбәр, уң кулының яны белән өстәлгә суга-суга, һәр сүзен аермачык булә-бүлә:

— Законны мин сездән яхшырак беләм,— диде.— Вәгъдә — иман, дигәннәр. Сүзегездә тора алмагансыз икән, бигайбә! Миңа үпкәләмәгез. Бер атна срок сезгә: өегезне теләсә кая күчереп салыгыз! Минем сүзем бетте!

Тегеләрнең берсе дә урыныннан кымшанмады. Әһлиулла белән Ханзафарның иңнәренә тегермән ташы салганнан ким түгел иде. Башларын түбән иеп, телсез калдылар. Соңгы тиеннәренә кадәр кырып-себереп, алай гына да түгел, шушы Габделбәрнең үзеннән үк мең сумга якын әҗәткә алып, нигез җиткердем дигәндә шушы хәлләргә төш әле...

Шомлы тынлыкны Сәяра бозды. Ничек кыюлык иткәндер, әмма әйтте:

— Буласы эш булган бит инде, әткәләре. Хәзер нишләмәк кирәк? Нишләсеннәр алар?

Габделбәр хатынына шундый итеп карады, гүя аны җиргә сеңдерергә тели иде.

— Нишләсеннәр, имеш! Миңа димәгәе, тире җыеп күн эшләсеннәр. Ник чәнчелеп китмиләр! Габделбәр Гафуров мин, теләсә кемнән

алдатырга яралмаган. Ә сиңа иң шәбе: тыгыласы булма минем эшкә! Сытылырсың...

Сәяраның чыдамы шуннан арыга җитмәде. Күзләрен кулъяулыгы белән басып, ул түр якка кереп китте.

Әһлиулла, протезын шыгырдатып, Габделбәр каршына килде. Аның кыяфәте мескен, кызганыч иде. Бусага буенда басып торган Ханзафар эткәсе өчен әрнеде. Әгәр өй кадәр өй белән бәйләнешле булмаса, ул шушы минутта Габделбәргә төкерер иде дә этисен култыклап чыгып кына китәр иде. Шул тикле ким-хур булырлык кешемени аның этисе?! Ниһаять, Ханзафар үзе кемнән ким? Ачуы да килмәгәе, ярты гектарга якын җирне биләп бер үзе утыра ич бу Габделбәр. Мондый участок, ай-һай, тагын кемдә генә бардыр Текәтауда.

— Адәм рисвае булмыйк, Габделбәр энем. Туганнар бит без. Җан уртак булмаса да каныбыз уртак.— Әһлиулла энесенең күзләренә ялварулы карады. Габделбәр исә мондый үгет-нәсихәтне, ялыну-инәлүне гаменә дә алмады.

— Кан уртак булса да мал уртак түгел! Белдеңме, мал уртак була алмый! — дип агасының авызын томалады.

Әһлиулла аның саен тилмереп эндәште:

— Гомернең азагына чыкмадык бит әле, Габделбәр энем,— диде.— Бурычлы булып калмабыз. Ничек итсәк тә бәхилләтергә тырышырбыз. Бер өеп тә бер сүтеп йөрергә чегән чатыры гына түгел лабаса...

Габделбәр бөтенләй чыгырыннан чыгып кычкырды:

— Синең хәер-садакаңа калмаган мин. Белеп тор. Әйткән икән, чапкан да өзгән — бер атна срок сезгә!

Мондый янауны ике сүзнең берендә кабатлау Ханзафарның да канын кыздырды.

— Ялынма, эткәй,— диде ул, сабыр булырга тырышып. Әмма аның бөтен гәүдәсе, эче дерелди иде инде.— Кыланам дигәч тә колга буе сикермәсен. Без крепостнойлар түгел, ул алпавыт түгел. Совет заманасы башланганга илле елдан артты. Китәр алдыннан үз теле белән әйтте бит: документлар эшләнде, диде. Без закон нигезендә, аның тиешеннән артык җирендә күтәрдек йортны. Тибешеп тәртә сындыра алмас!

Габделбәрнең тамагына кылчык кадалган кебек булды. Әле генә гөбедән чыккандай көр, тупас тавышы киселеп калды. Ханзафарның кыю сүзләре буды аны. Шул хәлендә ысылдап-пышылдап Ханзафар каршына чекерәеп килде дә:

— Хокук эзлисеңмени, селәгәй?! — диде ул, ажгырып.— Эзләп кара, шәт табарсың. Төшереп калдырганнар, ди. Колагыңа киртләп куй: бармакка чорнарлык кәгазь дә язылмаган! Язылмас та. Судка түгел, аръягына барсаң да, сиңа — минә! — Габделбәр Ханзафарның борын төбендә тимәк уйнатты.

Үзләренең тозакка дучар булуларын бөтен шәрәлеге белән әле генә аңлашып җиткән Ханзафар, ачу белән, Габделбәрнең кулын бәреп җибәрде.

— Законны син эзләрсең, яме. Мин өйне җиткереп, бала-чагам белән кереп утырыйм әле. Инвалид эткәйне түр башына менгерим. Болайга киткәч, эткәйнең ул туфракка да, урман һавасына да синекенә караганда хакы күбрәк. Кемнән сорасак, шул әйтер. Текәтау халкы сукыр түгел.

— Ах, әле син шулаймы?! — Габделбәр сын төсле катып калды. Аннары, эре-эре атлап, ишек алдына чыкты. Гипнозлаган шикелле, Әһлиулла белән Ханзафар да аңа иярделәр. Өйдә тавыш басылуга хәйран булып, Сәяра да тышка атлады.

Йорт башы сарай ишеген ачып җибәрде, аннан моторлы пычкы алды. Аның ярсынуы шул дәрәҗәгә җиткән иде, күзләренең карасы

югалган шикелле булды, битенә тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыкты, авыз читләренә тәкерек юшкыны җыелды. Ул, гарип аягы белән җирне ертып баргандай, яңа өйгә таба китте. Төсе бозыкның эче бозык шул, күзенә ак-кара күрсәтмәде, илерә бирде:

— Бүген үк бүрәнәләрегезне тураклап ыргытам, утын букәннәре итәм мин сезнең...

Сәяра иренең юлына аркылы төшеп туктатты. Шул арада Әһлиулла кулына балта алып өлгергән иде, Ханзафар аңа ташланды.

— Әткәй, акылсызланма! Куй балтаңны! — дип кычкырды.

Сәяра такмаклый-такмаклый еларга кереште.

— Алла хакы өчен дип әйтәм, котырма! Дүрт-биш сутый җирдән бөлмәссең әле...

— Югалыгыз барыгыз да күземнән! Югалыгыз!..

Габделбәр шундый итеп акырынды, янындагылар таралышмау гына түгел, тирә-күрше һәм узган-барган кешеләр дә туктап калдылар. Гайре табигый хәлне сизеп, ят кешеләрне өнәмичә, Пират үрсәләнеп өрә башлады. Биш минут үтмәгәндер, Габделбәр Гафуровның капка алды янгын чыккан йорт тирәсенә охшап калды. Каршыдан Ханифәттәй юыртып чыкты. Ханәфи Сәлмәнов күренде. Алнур янына килүе булган икән, Зәмирә Сагындыкова да җизнәсе йортына йөгерде. Алнур, чыннан да, янгын-мазар бардыр, дип килеп житте. Беравыктан Степан Семеныч та монда иде инде, каядыр юл тоткан Лиза Варгина да шау-шу тирәсеннән ваемсыз гына үтеп китә алмады, тукталды. Олысы-кечесе мәйханә килеп, сөйләшә-сораша башладылар.

Габделбәрнең сүзе шул булды:

— Үзем отпускыда чакта, баскыннар кебек, минем утарга өй күтәргәннәр. Сорап-ялварып йөргәч, уйланып карарбыз дигән идем. Бары тик шул сүз чыкты авызымнан, алар йорт корганнар. Көпә-көндез, халык алдында күрәләтә талыйлар...

Әһлиулла белән Ханзафар эшнең чынын сөйләделәр. Степан Семеныч тыңлап торды-торды да Габделбәрнең йөзенә туп-туры бәреп әйтте:

— Борғаланасың бит, Габделбәр Гафурич. Ярамаган юлдан барасың. Ир-атка ике төрле сөйләшү килешкән эш түгел.

Гафуров оялып чыраен яшерә торганнарданмы соң? Исе дә китмичә, үзенекен сөйли бирде.

— Минем җирем, минем ихтыярым, Семеныч!

Тагын гөрләшеп алдылар. Шул чак Ханәфи Сәлмәнов барысын да тынычланырга өндәде.

— Берәм-берәм генә сөйләгез әле, күршеләр. Күреп торасыз, илгәкөнгә рисвай эш кузгалып ята. Мәсьәлә ачык. Габделбәр Гафуров агай-энесен бу килеш кенә тынгылыкта калдырмаячак. Поселок Советына мөрәҗәгать итик, тикшерик. Күршеләрнең әйткәннәрен теркәп бирик. Кем яза?

Степан Семеныч язар кешесен шундук тапты.

— Алнурың институт бетерә бит, Ханәфи! Писарь эзләп йөрисемени? Яз, Алнур, барыбыз да монда чакта. Бу дикарь белән — тимерче карт Габделбәр ягына баш кагып куйды — халык телендә сөйләшмәсәң, аңламас ул. Барыбыз да кул куябыз, яз. Халык белән хаклыкка каршы киртә җимерә алмас!

Алнур әтисенә карады, аннары Зәмирәгә күз ташлады. Кыз нихәл итәргә белмичә, ни әйтергә дә юл табалмыйча тора иде. Аның Алнуры җизнәсе өстеннән башлап эш кузгатучы буламыни инде?!

Габделбәр тыштан һичкемгә сер бирергә исәбе юк шикелле күренергә тырышса да, эчтән кайсыдыр кылы бушый башлаганын тойды. Әмма тешләрен шытырдатып кысты, үзен шундук ныгытып кулга

алырга тырышты. Бер мизелгә генә чайкала язып калуын сиздермәс өчен, урап алган кешеләргә кычкырды.

— Нәрсә дип ябырылдыгыз әле сез? Кайсыгызга булса да бер тәңкә бирәсем бармы әллә? Таралыгыз капка төбеннән, тормагыз козгын көтүедәй! Бәгырегез бик әрнесә, Ханзафарның ызбасын үз планыгызга күчереп салыгыз...

Шулай диде дә, кешеләрне ырып-ерып, өенә таба атлады.

Бу көн Габделбәр өчен хәерсез булды. Күрше-колан алдына чыгып, туганнары белән кан дошманнарыдай якалашу да соңгы күңелсезлек түгел икән әле.

Капка төбеннән халык таралгач та байтак гомер тынычлана алмады ул. Күзенә ак-кара күренмәде. Башы түнеп, йөрәге кагып, кече бүлмәгә кереп яткан Сәярасына да ачуын күпертте, ләкин хатынына каты эндәшүдән тыелып калды.

Корбан баҗасы янына барып эч серен бушатып кайтыргамы әллә, дип тә уйлап карады. Ул вариантны бик тиз кире какты. «Гөнаһым барлыгы факт», дигән кебек нишләп йөрим әле? — диде ул үз-үзенә.— Эш зурга китә икән, Сагындыков янына иртәгә дә, берсекөнгә дә барып була. Әлегә берсенә дә баш имәскә кирәк. Чамаңның бүрек салыр дәрәҗәгә килеп терәлгәнен сизсәләр, югарыдан карап сайрый башлыйлар...»

Исәпли-үлчи, Әлфияләргә китте. Кызы өйдә иде. Сагынып көткән икән, әткәсен ай-кояштай каршылады.

— Прокурорның уң кулы өйдә юкмыни, кызым? — Габделбәр киявен шулай дип йөртә иде.— Онытым урамда уйныймы?

— Киявең Казанда шул, әткәй. Киңәшмәгә чакырдылар. Берәр йомышың бар идемени соң? — диде Әлфия. Әткәсенең күңелендә мәчеләр тырнашканын бусагадан атлап кергәндә үк сизенгән иде ул.

Гафуров кызына берсен дә яшермичә сөйләп бирде, тик шулкадәр ачылып китүенә үкенеп бетә алмады, чөнки Әлфиядән үз файдасына сыңар җылы сүз дә насыйп булмады. Киресенчә, әтисе йортында купкан зилзиләне ишетеп, кызы бик күңелсезләнде, коелып төште.

— Әй, әткәй, бигрәк кыргыйланасың инде. Ханзафар абый болай да аз интекмәде ич. Әһлиулла абыйны әйткән дә юк. Барысы да шул табылмаган мал өчен. Тәрәзәңдә, әткәй, бер генә йолдыз синең — тәңкә... Ачулансаң да әйтми булмый.

— Сезнең барыгызны да тәңкәсез генә үстердем шул мин,— диде Габделбәр, кызына карамый гына.— Саф һава сулап кына үстегезме? Һе, ничек сайрый, тыңлап туймассың...

— Күңелеңә авыр алсаң да әйтәм, әткәй, миһербансыз син. Рәхимсез. Бөтен кешегә аяусыз. Туганнарыңа да, әнкәйгә дә, балаларыңа да... Менә бит әле, Ханзафар абыйларны утка салдың да, өстәвенә киявеңне дә шул эшкә бутап, аны карачкы ясап, гөнаһсызга кеше өркеттермәкче буласың. Зиннәтне һаман белмисең шул әле син. Андый эшкә күңеле бара торган түбән кеше түгел ул.

Габделбәр, шул сүзләрне ишетү белән, капылт торып басты. Чыраен сытып, нидер әйтмәкче иде, авызы ачылды, сүз чыкмады. Аннары ул бу йорттан актык өметен өзгән кыяфәт белән кулын селтәде дә абынасөртенә чыгып китте. Юлда очрап сәлам бирүчеләрне дә искәрмәде, берәүне дә күрмәде, ишетмәде.

Көтү кергән иде. Сыеры, сарыклары кайткан, казлар да капка төбендә. Ачып керткәнне көтәләр. Мал-туарны керткәч, Габделбәр болдырга барып утырды. Башы чуендай иде. Ачу һәм үчләнү, таяныр талым дигән баласыннан да ярага кислота булырлык сүзләр ишетү гарьлеге, тирә-күршенең йөзгә чәпәп әйткәннәренең әчесе — барысы, барысы Гафуровны чыгырыннан чыгара, шашындыра иде.

Кинәт ерактан, күе томан эченнән килгән кебек, үлем авазы белән

кычкырган каз тавышы ишетелде. Габделбәр күтәрелеп караса, ни күрсен: Пират ана казларның берсен бугазлап алган. Көтүләренә килгән афәттән котлары очып, бәбкәләр төрлесе-төрле якка сибелгәннәр, атаказ, эт өстенә ташланырга итеп, канатларын җилпи, ләкин кыюлыгы җитмичә, бер урында таптана иде.

Габделбәр йөрәк яргыч тавыш белән акырып куйды.

— Пират! Җибәр, хәшәрәт! Пират!

Тамырларында ерткыч каны уйнаклый башлаган минутлар иде, Пират хуҗасының кычкыруын колагына да элмәде, ярсынып, котырынып, казның бугазын чәйни бирде.

Үз күз алдында кош-кортка зыян салган, хәзинәсен үчерергә керешкән овчаркага зәһәре тулып ташты Габделбәрнең. Ул, ямьсез сүгенеп, болдырдан сикерде һәм, исәп-хисап биреп тормастан, абзарга сөяп куйган сәнәкне алып, Пиратка ташланды...

Сәнәк ябе йөрәккә барып тигән иде. Эт күп чинамады, озак азапланмады төсле. Һәрхәлдә, Габделбәргә шулай тоелды. Этнең пыялаланып калган ачык күзләренә карамас өчен, ул арт бакчага чыгып утырды.

Җилләп, яшенләп яңгыр килә иде. Габделбәр исә күк гөмбәзен телгәләгән яшен чыбыркысын күрмәде, күк күкрәүгә дикъкать итмәде. Кургаш ядрәләр сыман эре яңгыр тамчылары тама башлагач та сын шикелле утыра бирде әле. Уйлары үткән көннәргә, Пиратны сатып алган чакка китеп барган иде. Ни сәбәпледер, иң элек аның күз алдына бу бүре каны катышкан овчарка баласы өчен шытырдап торган унлыкларны санап биргән минутлары килде.

Йортка алып кайткач, эт ике-өч көн буена ятсынды, боек торды. Гомерендә беренче тапкыр муенчак кию җанын кысрыклады аның, Чылбырга да бәйләгәч, бөтенләй өметсезләнде. Алдына куйган азыкны ашау түгел, иснәп тә карамады. Болай булса, ачтан кәкрәергә дә күп кирәкмәсе ачык иде. Карын үзенеке итте, Пират сый-хөрмәтне ялтыратып куя торган булып китте. Ул тазарды, аяклары ныгыды, күкрәге киңәйде, өсте елкылдап торучан булды.

Өч ай узгач микән, Габделбәр абзасы аны чылбырыннан җибәрде. Салкын тимерне кимереп, чәйнәп азапланууларның, җирне тырнап шыңшуларның кирәге калмады. Эт үзен азат итеп, тулысынча ирекә итеп тойды һәм шунда, яшьлек дуамаллыгы белән, әллә качаргамы, дигән уйга бирелде. Әмма сикерергә дә, качарга да өлгерә алмады. Күпне күргән хуҗа абзасы, аның ниятен бик тиз чамалап, янадан бәйгә куйды. Янә муенчак кысты, янә чылбыр чыңы шомландырды. Аны акча түләп алып кайткан агай шаярырга уйламый иде. Пиратка үз язмышы белән килешүдән, Гафуров абзасының йорт-җирен, мал-мөлкәтен һәм тынычлыгын уяу каравыллаудан бүтән чара калмады.

Хуҗасы күндәмлекне ярата, үз сүзенә карышмаганны, аркылы төшмәгәнне хуп күрә иде. Пират гадел хезмәт итте. Тик менә тагын, күпмедер вакыт узгач, Габделбәр аның хыянәте турында ишетте. Ә бүген, бүген аның үз бавырын кисеп алдылармыни?.. Андый тамашага Габделбәр Гафуровның түземе көн кебек ачык иде. Мәгәр Пиратны чәнчеп үтерү йорт башының йөрәк януын бастырмады. Киресенчә, әллә ни чаклы үкенеч, сагыш өстәде, исәп арттырды. Исәпләрлек тә шул: санап биргән унлыклар өстенә санамый гына ашатканы да күпмегә төшкәндер... Юньсезлеген әйтми-нитми генә берәрсенә сатып олактырса да (аны дүрт куллап аласылар иде!), күргән зыян хакы чыгачак иде лә...

6

Сүз җиңел сөйләнә, эш авыр эшләнә. Күршеләр чын ихлас белән күпме генә җилкенеп, талпынып бакмасыннар, нәтиҗә Габделбәр Гафуров уенча килеп чыкты.

Поссовет башкарма комитеты Ханзафар һәм Әһлиулла Динмөхәммәтовлар ялгышканнар дигән фикергә килде. Хаталары шуннан гыйбарәт иде: Габделбәр участогыннан бер почмакны бүлеп алу хакында бернинди документ та юк. Поссоветта берәү дә бу мәсьәләне белми булып чыкты. Әһлиулла абзый очына-очына сөйләп бакты, Сәяра килен шаһит ләбаса, аның гомеренә ялган сөйләгәне юк, аңардан сорагыз, дип күрсәтте.

Хәлләр болайга әйләнгәч, Сәяра да бик томанлы, бик тонык кына җавап бирде. «Ирләр эшенә тыгылып, авызларына керbegin сүз тыңлап тора торган гадәтем юк. Әһлиулла абзый хакына дип өй бураганда һәм күтәргәндә булышканмын икән, олы кешенең Габделбәр белән килештек диюенә ышанудан иде»,— диде.

Чыннан да, склад мөдирен бер җайдан да гаепләрлек түгел иде.

Алнур, этисе белән киңәшләшкәч, янә бер чәчәләнеп бакты.

— Сез беләсезме соң, хөрмәтле поссовет иптәшләр,— диде ул,— Габделбәр абыйның баш-баштаклыгы нилектән килеп чыкты? Күбегез, мөгаен, белмисездер. Ул бит Ханзафарның безнең тезү трестыннан бакча өчен, дачага дип җир алуын таләп итте. Ул дачаны үзенә алу бәрабәренә Әһлиулла абзыйга табигатьнең ямьле урыныннан өй утыртырлык җир кисеп бирмәкче иде. Ә Ханзафар Текәтауда йорт саласы булгач, дача участогы бирмәделәр. Һәм дөрес эшләделәр. Мин үзем дә, постройком члены буларак, шул карарны якладым.

Ә Габделбәр абый Ханзафарлар өе биләгән мәйданга шул тикле мохтаҗмы? Һич ул көнгә калганы юк аның. Хәзер йорт коручыларга бирелә торган кадәр өч-дүрт мәйдан биләп яши бит ул. Уйлагыз әле, иптәшләр! Ирләрчә сүзгә ышанып, яңа өй өлгерткән кешебез Габделбәр абыйдан кимме әллә? Бөтен поселок әйтер, хөрмәтле кеше ич ул. Дөрес, Габделбәр көчлерәк күренә, ләкин аның куәте бит намуссызлыкка корылган...

Склад мөдирен формаль яктан хаклы санадылар шул. Поселок Советы мәсьәләне Әһлиулла абзый ягына хәл кыла алмады.

Утырыштан чыкканда Габделбәр Алнурны туктатып әйтте: «Әтиеңнең җәмәгать дуңгызы көтүчесе икәне дөньяга мәгълүм. Ә сиңа, яшь кешегә, ахмакланып йөрү нигә кирәк? Кем өчен диген әле! Чебен дулап тәрәзә вата алмый, беләңме?»

— Бүгенге карар белән канәгать булмаячакбыз. Сез дә белеп торыгыз! — диде егет, ярсуын чак тыеп.— Судка бирәбез!

— Аръягына бирегез! — диде дә Габделбәр кырт борылып китте.

— Аръягы да, бире ягы да юк. Район халык судына бирәбез. Совет судына, Гафурич! — дип калды аның артыннан Степан Семенович.

Болай дию Габделбәрнең ук алмас тиресенә дә барып кадалды бугай. Пырлап китеп барган җиреннән Степан картның каршысына кире борылып килде. Куллары йодрыкланды, аяк тамырларына кадәр тартышкандай булды. Секундның да бик аз өлешендә аның башында коточкыч уй яшьнәп узды: «Әллә бу картны бугазлап ташлыйммы?» Ләкин бик тиз бу уен авызлыклап, кулларын акылга буйсындырып өлгерде: «Ярамый, Габделбәр, ярамый. Кулыңны тыймавың тезәтмәслек хатага китерәчәк. Поселокның гына түгел, хәтта бөтен Казанның атаклы карт мастеровоена кул күтәрсәң, бөтен эшнәләрең бергә дә йолып кала алмаслар. Ярамый, Габделбәр!»

Әмма сүзсез калырга да ярамый иде. Ул, картның колагына үрелеп:

— Бөгәрбез дигән буласың бит, картлач. Мин бит бакыр чыбык түгел! — дип пышылдады.

Степан Семенович исә үз бәясен бик белеп кенә, тирә-юньдәгеләргә ишетелерлек итеп, җавап кайтарды:

— Ә мин, Гафурич, гомерем буена тимерне дә, корычны да үземә кирәгенчә бөктем. Корычтан чәчәк букеты ясаганым бар. Бүгенгегә

килсә инде, әйтим: ялгызым түгел бит мин. Халык безнең якта! Ил-көн каршында син кандала...

Габделбәр инде пышылдамады, үкерә башлады.

— Намусыма кагылдырмам мин сиңе, карт исәр!

Степан Семенович көлемсерәде генә.

— Юк бит ул синең. Кабергә алып китәргә дигән байлыгың гына бар. Эт ашыйсы малың... Һәй, ни дип синең белән тел талдырам?! Әйдәгез, җәмәгать, безнең үз юлыбыз такыр ич!

Әһлиулла абзый, Хаҗзафар, Алнур һәм Ханәфи Сәлманов аның белән бергә кайтып киттеләр.

* * *

Август өмет итмәгәнчә чибәр килде. Июльнең сытык чырайлы булуы өчен дә юмартланам дигән төсле, кояш ныклап кыздыра башлады. Пыскып яуган яңгырлардан, болытлы суык көннәрдән өркеп нык киенгән кешеләр яңадан җиңелчә киемнән йөри башладылар. Алмалар иннек-кершән ягынды. Җәйнең шул вакыты җитеп тә яшел уенташ кына булып торган помидорлар, бармак буыныдай хәлдә йомшаруга йөз тоткан кыярлар терпәкләнеп китте. Ә чәчәкләр дөньясы күзгә күренеп яшәрде.

Габделбәрнең генә күңеле боз базыдай суык, дары базыдай юкка-барга да шартларга тора иде. Соңгы атналарда ул үзенең иннәрендә бинибая зур кургаш герләр бар дип хис итте. Кәефе яман, яшәүнең кызыгын тапмый иде. Картаеп, бетәшеп калды. Тик, ничарадан бичара, хезмәтенә дә бармый ярамый, йортта да кыймылдамый хәле юк иде.

Якшәмбе кичендә ул арт бакчага чыкты. Соңгы көннәрдә өйдә гел бер шөгыль — коелган алмаларны җыеп озату һәм алмагачларга терәү өстәү. Югыйсә көт тә тор, җимешләр ботакларын каерып төшәчәкләр.

Беравык юангач, Габделбәр беседкага барып утырды, кесәсеннән ике хат чыгарды. Ашыкмый гына беренче конвертны ертты, аннан дүрткә бөкләп салган дәфтәр битен алды. Хәрефләргә күз салу белән, мыскыллы елмайды: «Нужаң төштемени, хөрмәтленең хөрмәтлесе Давид Самойлович,— дип уйлады ул.— Бер умарта оясы кирәк иде дисең, ә? Сүзен дә таба белә бит! Чит күздән тел яшереп кенә шулай язуы түгел каһәрнең. Әйберен алдан ук кечерәйтеп куюы. Фәлән дус-каемның дачасына җәйлек-кышлык итеп өй саласы иде дими бит, хәйлә базы! Умарта оясы, имеш. Бабаң утырмага килсен, әбиеңә сәлам әйт. Кош теледәй кәгазь белән генә минем авыздан вәгъдә ала алмассың, агай! Персональный машинаңда үзең кил әле син, галиҗәнап Давид Самойлович, яме. Кил дә, эшләпәңне салып, сәлам бир. Бу юлы синең елмаюлы сәламыңа каршы мин инде «саламыңа — печән...» диярмен. Мин гозерләп килгәндә кырык хәйлә таптың, иблис! Верховный судта белешләрең юк идемени синең, ә?! Кыл да кыймылдатмадың. Менә тот инде хәзер «умарта оясын!»

Икенче хатны ул шундук ертып ыргытты. Кыр ягыннан бераү язган. Өйне яңартасы иде, йөрәктә дәрт, беләктә куәт бар чагында авылда бер итеп күтәрәсе иде, дигән. Кайдадыр бергә булганнар иде. Шуңа кармак салып каравыдыр. Тапкансың беркатлы бәндә! Синең белән түгел, пичәтләре салмаклыраклар белән дә сафсата сатыр җай юк әле...

«Әһлиулла белән Алнур Айга чөй кактык дип йөрсәләр дә, Габделбәрнең җегәре чыкмаган әле,— дип күңеленнән күкрәк какты ул.— Һәммәгезгә берәм-берәм каршыма тез чүгәргә туры килмәгәе... Туасы көннәрдә зирәгрәк булырга гына кирәк. Бары шул. Суга туп-туры керергә ярап бетми икән хәзер...»

Уй агышы шулай барганда, ни хикмәттәндер, малай чагындагы бер хәл — тай өйрәтү исенә төште аның.

...Кыш иде. Язын сабанга керәсе өч яшьлек тайларны өйрәтер чак

җитте. Әткәсе мәрхүм, аю биетергә җыенгандай, бу эшне олы бер шөгыль итеп, ике-өч көн алдан сөйләде. Күне җиткәч, яуга барасы кеше кебек, хәстәрен күрде.

Елкылдап торган сабырсыз туры айгыр, абзарыннан алып чыгу белән, колакларын уйнатты, пошкырынды. Тәртә арасына кертәсен сизгәч, шундый җилләнеп бер читкә ыргылды — ул чагында әле аю сытардай Гафур аягында чак басып калды. Күрше Гыйззәт белән көчкә җиктеләр.

— Дөнья шулай ул, малкай! Сине түгел, адәм баласын да тәртәләп куялар! — дип сөйләнде әтисе. Капканы ачканчы яшь айгырның башына үзе ябышып торды ул. Габделбәр чанага сузылып яткан һәм үрәчәгә чытырдап береккән иде. Капканы ачып җибәрү булды, туры айгыр, күккә ашам дигән төсле, ургып-бәргеп урамга чыгып китте. Чана җирдән түгел, һавадан очып бара төсле тоелды Габделбәргә.

Ярсу айгыр пырдымсызлана алган тикле пырдымсызланып карады, әмма Гафур дилбегәне кулына алып, яшь турыны басу ягына алып китте. Япан кырда да байтак иза чиктеләр. Аннары әтисе айгырны, юлдан чыгарып, кар өстенә алып керде. Монда бахбайның тәртәсе кыскарды. Дулап караса да әллә кая китә алмады. Ниһаять, шып туктады. Ул шабыр тиргә баткан, арт ботлары буйлап ак күбек ага. Йодрык сыярлык булып зурайган борын тишекләреннән бүрек-бүрек пар бөркеп тора иде. Бу — туры айгырның адәм кулына гомерлек хезмәткә күнүе булды...

Габделбәрнең үзен дә шулай иттеләр түгелме соң?..

Алай ук та булмас иде, Сәярасына хәтле каршыга китте бит. Судта ул да: «Сөйләшеп эшләнгән эш иде бу. Үзем шаһит. Интектермәгез гөнаһсыз кешене»,— дип әйтте. Өйләренә кайткач, аулакта Габделбәр, гадәтенчә, бик ныгытып, тозлап-борычлап сөйләшмәкче иде, бусы да барып чыкмады. Егерме сигез ел гомер иткән хатыны бервакытта алай булмаганча җавап бирде.

— Акайма да, акырма да, Габделбәр. Чирек гасыр чыдадым. Авызым тулы кан булганда да төкермәдем. Инде түземем төкәнде. Тагын да бәгырь итемне кимерергә ниятләсәң, бел: я Әлфия белән кияү янына китеп яшим, я булмаса Әгъдәсләргә үк китәм. Туган аналарыннан берсе дә йөз чөермәсләр. Бала карап та тамак туйдыралар,— диде.

Көмеш туй сые көткәндә тормыш Габделбәргә менә нилар хәстәрләгән булып чыкты.

Сәяраның китүе бер хәл иде. Габделбәр, хатынга байтак нәрсә мәгълүм, болайга киткәч, сайрап ыргытудан да тайчанмас, дип өркеде. Шул рәвешле, элек хатынын дер селкетеп торган кеше үзе Сәярадан бик нык сагая башлады, чын-чынлап шүрләде.

Корбан баҗасы да, поселокның байтак кешесе телләнә башлагач, койрыкны сырт яккарак салу ягын карады. Баҗаның барлыгы — кәҗәнең маллыгы булды да куйды.

Үзеңнекеләр үз итмәгәч, җиде яттан ни көтәсең?! Җитмәсә суд утырышчысының берсе булып Лиза Варгина әләкте. Судта биргән сораулары берсеннән-берсе шырпылы. Кеше шулай бит: бар булсаң — күрәлмый, юк булсаң — бирәлмый. «Гадел хезмәт хакына яшисеңме?» димәкче була. Тел төбе шуңа бара. Һай замана! Үзгәрсәң дә үзгәрерсең икән. Көпә-көндез туктатып, кесәңдәге акчаңны санарлар, әкәмәт. Артык сумың табылса, төбенә тоз коеп җаныңны алырлар. Әле бит ике агай-эне арасындагы эшне мәхшәр иттеләр. Ирләрнең җир өчен давы хатыннарның ир өчен шавы гына түгел икән...

Степан картны әйткән дә юк. Җәмәгать гаепләүчесе булып алган бит! Ничек ди: «Мал кортлары, сумга фанатикларча табынган адәмчекләр — тормышта зур бәла ул. Бар яраксыз эш шул иске бозыктан башлана. Шуңа каршы бөтен дәүләтебез, бөтен халкыбыз күтәрелер көн якынлаша. Бу инде иң олы хөкем булачак» диме? Дипломатлар

кубәйде дөньяда, юристлар күбәйде. Контролерлар бихисап, акыл өйрәтүчеләрне әйткән дә юк. Үтәли күрәләр, диярсең, тьфу! Тын кыса, сулыш тарая шулар мыжгып торганда!

Алар карашынча, сарык та исән, бүре дә тук: Әһлиулланың йорты салган җирендә кала. Өстәвенә әле ул гражданинга каралты-куралык мәйдан да кисеп бирергә. Гражданин Габделбәрнең каралты яңы участогы шуннан соң да бик таман кала, дигән карарга килделәр.

Габделбәрнең Габделбәрлеге югалуын кем, кайдан һәм кайчан кире табып бирә? Суд карарында бу хакта ләм-мим әйтелми бит. Гафуровны исә, барыннан да бигрәк, шунысы газаплый...

Кояш әйбәт баеды. Иртәгә дә көн аяз булачак. Һавалар явымсыз торганда шунысы шәп: бакчаны әйбәтләп саклыйсың.

Габделбәр урыныннан күтәрелде. Кереп кичке чәйне эчәсе дә бакча каравылларга чыгасы. Чү! Аргы коймадан берәү алма өзәргә үреләтүгелме соң? Күзенә генә шулай күренәме? Койма аръягында берәр терлек-мазар узып китүе булдымы әллә? Юк, кеше үрмәли, кеше! Кайсы башсызы булыр бу? Ах, анасының арт сөяге сынасы җан! Мыскыл итүеме? Караңгы төшеп җитмәс борын бакча таларга уйлаган? Стоп!

Тирә-якны яңгыратып мылтык шартлады. Аның тавышын урман элеп алды һәм тәкърарлап торды.

Койма артында җиде-сигез яшьләрдәге бер малай җиргә капланды. Ул, чамасыз куркудан, йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде. Ләкин аның авазын урман ишетмәде. Малай кулындагы алмалар читкә тәгәрәде. Сабыйлык нәфесенә булышып, чәнечкеле тимерчыбык тартылган койма аша кырый алмагачка үрелгән бала Габделбәрнең оныгы, Әлфия малае Иршат булып чыкты.

Капкадан килеп керсә дә, бабасы аңа үзе теләгән алманы, мөгаен, өзеп биргән булыр иде бит. Хәер, кем белә? Иршатның күзе кызып, авыз сулары килгән чаклар аз булдымыни? Бабасы аңа һәрчак корт ашаган, җиргә коелып, бөрешә башлаган алмалар гына бирә килде. Әнкәсенең шуңа рәнҗеп: «Артыгын еткә дә ташлыйлар. Бердәнбер оныгына матуррак алма тоттырса, бөлер идемени соң?!» — дип әрнегәнен дә Иршат бер генә ишетмәгән иде инде. Әбисе, дөрес, итәк астыннан гына, бабасыннан яшереп, күз явын алырдайларын да биргәли иде. Ә Иршатка тегеләй дә әйбәт түгел, болай да. Нәни йөрәгенең әллә кай җире белән сизенеп, әбисен кызгана иде ул, ә бабасына ачуы килә.

Күршеләр җыелды. Малайны ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага, ә Габделбәрне милиция бүлегенә алып киттеләр.

Шуннан соң бер-ике сәгать чамасы вакыт үткәч, төнлә, Әлфия больницадагы баласы янында шактый утырганнан соң, этисе йортына килде. Вакыйганың ничек булганын бөтен нечкәлекләре белән белә иде инде ул. Комсызлыгы чиктән ашкан этисе хәтта шундый кыргыйлык та эшли алса алыр икән?! Очраклы туры килеп, бүген үз оныгына тидерә язган бит. Кемгә атса да барыбер түгелмени? Кешегә ата ич! Ике алма өчен! Ерткыч!

Юк, этисе белән әрләшергә дип тә, аңа ташланырга дип тә килмәде ул. Габделбәрнең сүз аңлаудан узганлыгын байтактан абайлап яши иде. Шушы йөрәк өзгеч хәлләр әнисенең исәнлегенә ни дәрәҗәдә тәэсир ясаганын чамалап килде ул. Шуңа күрә этисен сорашмады да, исемен дә телгә алмады, турыдан-туры әнисенең караваты торган бүлмәгә үтте. Ә Сәяра, йөрәген тотып, янә урынга ауган, врач чакырткannар.

Поселоктан читкә чыкмаска имза биреп кайткан Габделбәр исә түр якта сүзсез-телсез утыра иде. Ул әнкәсе белән сөйләшкән Әлфиянең: «бик каты курыккан» диюен ишетте. Шул сүзләр гүя аңа әмер булды, ул капылт сикереп торды һәм өйдән чыкты. Нияте — кар базының куш стенасы арасына шәпләп төреп салган акчаларын барлау иде һәм, шул акчаларның исәбен алгач, хәзерге кыен хәленнән котылу юлларын эзләп карау иде.

## Әнгам Атнабаев

# ШАТЛЫКЛАРЫМ, КАЙГЫЛАРЫМ

## Ике сорау

1

Син — кешесең,
ифрат бәләкәйсең.
Нәрсә килә синең кулыңнан?
Көчен җитми
үзең зурлык ташны
Алып ташлар өчен юлыңнан.

Океаннарда син йомычка сыман,
Тау янында бары бер нокта,
Кара урман, адаштыргыч буран,
Җансыз дала сине куркыта;
Һәм өркетә сине җил-давыллар,
Күк күкрәтеп килгән болытлар.
Янган утлар, аккан шарлавыклар,
Күзгә күренмәгән микроблар...
Бәп-бәләкәй генә җисеме син
Җир исемле олы корабның.
И табигать,
нигә кешеләрне
Бәп-бәләкәй итеп яраттың?

2

Син — кешесең,
ифрат бәләкәйсең,
Тик бар нәрсә килә кулыңнан,
Көчең җитә:
аккан елгаларны
Борып куяласың юлыңнан;

Океаннарны үтеп чыгаласың,
Этеп егаласың тауларны,
Җансыз далаларга җан өрәсең,
Терелтәсең үлеп барганны.

Син — тудыручы һәм... үтерүче —
Каберлекләр ята юлында...
Син төзүче һәм... җимерүче —
Хәрабәләр ята юлында...
Атомнарны җиккән бомбаларның
Дилбегәсе синең кулында.

Бар язмышы синең ихтыярда
Җир исемле олы корабның...
И табигать,
нигә кешеләрне
Шундый көчле итеп яраттың?

## Теләк

Бир син миңа, язмыш,
барысын да бир:
Көндез — кояш, төнлә аен бир,
Борма-борма барыр юлымны бир,
Юл читенә ап-ак каен бир;

Кайгырырга кара кайгымны бир,
Шатланырга якты шатлык бир,
Иң яраткан авыр эшемне бир
Һәм эшемә карап кашык бир;

Җылы язлар, усал кышлар бир,
Кышлардан да усал дуслар бир,
Дусларымның кадерен белер өчен
Дусларымнан күбрәк дошман бир.

Гомер буе янып-көяр өчен
Мәхәббәт бир...
бүген бирмәсәң
Иртәгә бир — «көт» диген.
Тик берсен дә ярым-ярты бирмә,
Бөтенләйгә бир син — бөтенен!

●

Бер көн килеп, тау менгәндә,
Ялгыш атлап, таеп китсәм,
Ташка бәреп, я кулымны,
Я аякны каймыктырсам,—
Син җәлләмә
Һәм кызганма,
Тик ташлама.

Бер көн килеп, рухым төшеп,
Кайгылардан башым исәм,
«Булмый миннән — көчем җитми,
Барысын да ташлыйм» дисәм,—
Син җәлләмә
Һәм кызганма,
Тик ташлама.

Бер көн килеп, син дә шулай
Минем кебек хәлдә калсаң,
Шул вакытта әгәр сине
Жәлләмәсәм, кызганмасам,
Жәлләп торма
Һәм кызганма,
Ташла мине!

●

— Ул бәхетсез булды —
бу дөньяга
Соңга калып туды, дисеннәр,
Соңлап тәпи басты...
Кызларга да
Соңлап гашыйк булды, дисеннәр.

— Соңлап акыл керде —
без белгәнне.
Соңга калып белде, дисеннәр,
Ул тәртипсез иде —
жыелышларга
Соңга калып килде, дисеннәр...

— Соңга калып үлде, димәсеннәр,
Их, иртәрәк үлде, дисеннәр.

## Өйрәттеләр

*Р. И.*

Гомер буе мине өйрәттеләр,
Өйрәттеләр бары яхшыга:
Башта шуышырга,
аннан атларга...
Ата-бабаларның гадәтләрен
Үземчәләтеп кабатларга.

Өйрәттеләр әниемә «әннә»,
Әтиемә «әттә» дияргә,
Ашап беткәч,
тамак туймаса да,
Битне сыйпап «әпәр» дияргә.

Вакыт житкәч,
Өйрәттеләр хәреф танырга
Һәм икедән берне алырга...
Вакыт житмәс борын өйрәттеләр
Тырма тырматырга,
ягъни иртән
Кузне ертып эшкә барырга.

Тукмап өйрәттеләр еламаска,
Кеше елаганда көлмәскә,
Авыз тулы кара кан булса да
Дошман алдында түкермәскә...

Өйрәттеләр бугай «төшермәскә»,
Ә төшергән чакта
туры басып өйгә кайтырга.
Хәтта өйрәттеләр
тәмәке юкта
Мунча мүген төреп тартырга...

Ә яратырга?
Сине яратырга
Беркем өйрәтмәде —
Качып-посып үзем өйрәндем.

●

*Н.гә*

Сине уйлап кояш бата,
Сине уйлап ата таң.
Син дә мине яратасың,
Мин дә сине яратам.

Бер-беребезне яратабыз,
Ләкин кеше аңламый:
Янәсе дә, сиңа мине,
Янәсе дә, миңа сине
Яратырга ярамый.

Тегесе әйтә: ярамый!
Монысы әйтә: ярамый!
Закон әйтә: ярамый!
Хатын әйтә: ярамый!
Ә мәхәббәт дәвам итә
«Ярамый»га карамый.

**Нәби Дәүли**

# АТУ

*Моннан берничә ай элек, язучы һәм шагыйрь Н. Дәүлинең I нче том шигырьләр китабы басылып чыкты. Бу китапка авторның иң яхшы әсәрләре сайлап алынган.*

*Киләсе елда Н. Дәүлинең II нче томы дөнья күрәчәк. Ул проз әсәрләрен берләштергән китап була. Анда «Яшәү белән үлем ара-сында» һәм «Җимерелгән бастион» дигән әсәрләр тупланган.*

*Укучыларның киңәшләрен искә алып, автор «Җимерелгән бас-тион» китабына шактый зур төзәтүләр һәм яңадан язылган бүлекләр кертте. Журналыбызның бу санында шул яңа өзекләрнең берсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

Василий әкрен генә торып ишек янына килде.

— Һер вахтман,— дип эндәште.

— Вас ис лус? [1] — диде тышкы яктан солдат.

— Ишекне ачыгыз әле, минем сезгә сүзем бар...

Вахтман җавап бирмәде. Ул барак стенасына эленгән телефон трубкасын алды да комендатура белән сөйләшә башлады. Бик тиз арада барак янында мотоцикл тырылдаган тавыш ишетелде, кинәт ишек төбенә җитеп тынып калды.

Ишек ачылды. Василий чыгарга да өлгермәде, аның йөзенә фонарь яктысы төште.

— Һа, һер полицай, Герасимуф, — дип көлде Пауль. — Сез ничек биредә? Бездә полицайлар өчен аерым бина бар...

— Мин иптәшләремне эшкә үгетли-үгетли, вакытында бaрактан чыгып өлгерә алмадым, һер оберлейтенант...

— Гут, гут,— диде комендант. Һәм үзе белән ияртеп килгән солдатка Герасимовны полицайлар йортына алып барырга кушты.

Аерылышканда аңа полицай:

— Гутен нах [2],— дип әйтергә дә онытмады. Ләкин инде төн сыегаеп килә иде. Офык буйлары алланган, тиздән таң атар. Саф урман һавасы Герасимовның йокысын ачып җибәрде. «Менә хәзер балыкка барасы иде,— дип уйлады ул.— Енисей ярларында хәзер нинди матур таң туып киләдер... Юк, ул якларда әле бу сәгатьтә караңгы була. Хәер, үз туган якларында караңгы төне дә рәхәт. Күк йөзендәге йолдызлар ни тора! Тынлык һәм шул тынлыкта яр буендагы камышлар сиңа нәрсәдер сөйлиләр кебек тоела. О, туган яклар... Еракта, еракта...»

---

[1] Нәрсә булды?

[2] Хәерле төн

Комендатура белән янәшә, лагерь эчендә, бер жыйнак кына бина бар иде. Герасимов ишек төбенә килеп тә житте. Их, ераграк юл булсачы. Барасы иде таң йөзенә карап, барасы иде, барасы иде...

Герасимов бүлмәгә килеп керде. Караса — Шмарь. Ул инде өс-башына киенеп өлгергән иде.

Яна полицай иске полицайга сәлам биреп маташмады.

— Бик иртә торгансың, әллә берәр жиргә барасың бармы? — диде.

Шмарь тиз генә жавап бирмәде. Төн буе йокысыз арып шешенеп беткән күзләрен Герасимовка усал итеп текәде дә:

— Китәм! — диде.— Генерал Власов армиясенә. Мин бит үзем дә анда оберлейтенанттан ким булмам. Бу базда сасып ятканчы... Монда син яшә, ә вакыт житкәч сине Гроссман үзе, маңгаеңа пистолет төзәп, атып үтерер. Котеп тор, ком-мунист!

— Ә мин коммунист түгел, беләсең килсә, сиңа бу юлы чын дөресен әйтә алам. Әмма синең кебек этләр белән очрашканда үземне коммунист дип саныйм...

Бу Шмарь өчен гажәп иде. Аның кеше йөрәгендәге мондый нечкәлекләрне төшенә алырлык акылы да, хисләре дә юк иде.

— Ә син ни өчен үзеңне коммунист дидең Гроссманга?..

— Чөнки немецлар коммунистларны ярата төшәләр. Аларга синең кебекләр белән сөйләшергә дә кызыклы түгел,— дип көлде Василий.— Күрдең ич, оберлейтенант ничек синең борыныңа китереп салды. Инде шуннан соң да бер нәрсә дә аңламагач, сине кем дип атарга соң, Шмарь? Түбән жан син!

Шмарьның ачуы килде. Ул Герасимов белән бик каты итеп сөйләшергә дип кенә торганда, бүлмәгә вахтман килеп керде.

— Ком,— диде ул Шмарьга.

Шмарь кулына чемоданын алды. Вахтманга карап елмайды. Әмма солдатның йөзе житди иде. Ул:

— Ком-ком, шнель,— дип кабатлады.

Шмарь агарынып китте. Куллары калтырый башлады. Бу нигә болай дорфа кылана әле, дип вахтманга нәрсәдер әйтергә жыенган иде дә, солдат инде ишекне аягы белән тибеп ачты.

— Ком, ком! — диде ул, каты кычкырып.

Шмарь Герасимовка тагы бер ачулы карап алды да:

— Очрашырбыз әле, әмма инде ул чакта соңгысы булыр,— дип әйтә-әйтә, вахтман артыннан атлады.

Герасимов таныш булмаган бүлмәдә бер ялгызы калды. Стенага күз ташлады. Бер якка ниндидер рәсем эленгән. Василий аңа игътибар бирмәде. Ул бик нык арган иде. Караваттагы матрацны кире ягы белән әйләндереп салды да, инде яртылаш йокыга киткән килеш, урын өстенә ауды. Бер-ике генә сәгать булса да йоклап алырга кирәк иде.

Капка янында Шмарьны туктаттылар. Чемоданын тартып алып, бер читкә куйдылар. Ганс килеп чыкты. Чемоданны каядыр алып китәргә кушты. Вахтманның мылтыгын тикшерде, затворын тартып, чакырып карады. Аннан соң:

— Фортиг! — диде.

Бу — барысы да әзер, алып кит үзен, дигән сүз иде.

Әле кичә генә гайрәтен кая куярга белми йөргән Шмарь кинәт телен йоткан кебек тынып калды. Нәрсәдер әйтергә иде дә, иреннәре көеп китте. Ул аларны теле белән ялап чылатырга маташты. Әмма теле дә корыч игәү кебек каткан иде...

О, Шмарь, син бит немец лейтенанты формасын киеп, пистолет асып, ялтыравыклы итекләр киеп, шалт-шолт басып, бер көнне Василий алдына килеп басмакчы идең.

«Я, егет, син мине таныйсыңмы?» — димәкче иден. «Инде сөйләшеп карыйк»,— димәкче идең. Ә хәзер синең «мине кая озатасыз?» дип сорарга да көчең җитмәде. О, егет, егет...

Капка ачылды. Алдан Шмарь, арттан вахтман чыкты. Гадәттә, кемне кая гына алып китсәләр дә, ябык машинага утырталар иде. Ә бу юлы бер генә машина да күзгә чалынмады. Шмарь сагайды. Күңеле нәрсәдер сизенде. Шулай да ул үзен тынычландырырга тырышты: якын тирәдәге станциягә генә барабыздыр, дип уйлады.

Алар юлга чыктылар. Инде таң сызылып килә. Агач башларына кояшның беренче нурлары кунган. Гүя алар канга манчылган. Ниндидер кош сайрый. Аның тавышы моңлы җырга охшый, ләкин нинди җырга? Шмарь исенә төшерә алмый.

Шмарь бер иркен сулыш алды. Язгы саф һава тәмле ширбәт шикелле күңелне күтәреп җибәрә. Тирә-як куе урман. Кая гына карасаң да, аллы-гөлле чәчәкләр. Шмарьга әллә нәрсә булды. Ул мондый язны гомерендә беренче кабат күрә шикелле. Ә бит мондый чәчәкле язлар күпме узган инде. Нигә соң Шмарь ул язларны әлегә кадәр сизми, күрми калды?

Уйлары йомгак кебек сүтелеп китте. Ул шул арада үзенең туган якларын исенә төшерде. Кайда калды соң әле ул еллар?

Кинәт вахтман:

— Һабст ду муттер ?[1] – дип, Шмарьны үзенең ачы тавышы белән сискәндереп сорады.

Шмарь җавап бирмәде. Ул, кулларын артына куйган килеш, һаман бара бирде. Барган саен үзенең узган гомеренә таба атлый кебек иде. Шмарьга әле яңа гына утыз яшь тулып килә. Утыз яшь күп тә түгел, әмма инде аз да түгел. Күп кешеләр бу гомердә инде югары белем алып, яки берәр һөнәрче, яки дипломлы инженер булып, тормышта үз урыннарын табып, инде баш-күзле булып, бала-чагалар белән яши башлыйлар. Ә Шмарьның беркеме дә юк иде. Аның әле бер генә кызны да янып-көеп, төннәрен йокламыйча, көндезләрен ут йотып сөйгәне булмады. Хатын-кызлар белән очрашты очрашуын... Ләкин нәрсә алар... Бүген бар, иртәгә юк.

Шмарьның авылда бердәнбер әнисе бар. Ләкин инде бик күп еллардан бирле ул аны күргәне дә юк, хатлар да язганы булмады. Ә менә хәзер шул карт ана улының күз алдына килеп басты. «Улым, сине кая алып баралар?» дип сорады шикелле ул, баш яулыгы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә. Шмарь үзе дә сизмәстән:

— Әнием, әнием минем! — дип кычкырып куйды.

— Вас? — диде вахтман, Шмарьның бу сүзләрен ишетеп.

Шмарь бу юлы да җавап бирмәде. Ул борылып карады. Вахтман ни өчендер арттарак калып килә, Шмарь, искәрмәгәндә генә, мылтыгын тартып алмасын дип курка торгандыр, мөгаен.

Шмарь юл читеннән генә бер сары чәчәк өзеп алды. Иснәде. Бик хуш исле иде бу чәчәк. Шундый чәчәкләрне кайчандыр ул болыннардан кочак-кочак җыеп кайта торган иде. Бозау аларны бик яратып ашый иде. Ул менә хәзер дә менә шушы юл буйлап, шул чәчәкле болыннарга кайтырга теләде. Тик юл ул якларга таба бармый иде шул. Юл каядыр билгесез якка таба китә. Ә артта гомер кала, истәлекләр кала. Ул хатирәләр кайсы көйдерә, кайсы сагындыра, кайгыга сабыштыра. Ә кайсысы җанны өзгәләп сагышландыра. Әйе, сагышландыра. Шмарьның бит әле сагышның нәрсә икәнен дә белгәне юк. Кайгырган чаклары булды, шатланган чаклары да булды, әмма сагыш... юк, Шмарь аны белми. Нәрсә соң ул сагыш? Шмарь кулындагы сары чәчәккә карады.

---

[1] Әниең бар идеме?

Әйт, чәчәк, син беләсеңме? дигән кебек җавап көтте. Һәм җавап та алды шикелле. Менә хәзер ул бу чәчәкне юлга ташлап калдырыр. Чәчәк шиңәр, аның инде беркемгә дә кирәге булмас. Шмарьның да язмышы шундый түгелме? Шмарьның да гомере шушы чәчәк кебек өзелеп калмыймы? Нигә соң ул тормышын башкалар шикелле матур итеп төзи алмады? Кем гаепле иде? Нигә ул укымады, һөнәр алмады? Нигә кызлар сөймәде? Нигә ул үзе теләп әсирлеккә төште, дошман станына килде? Ни өчен полицай булды? Ни өчен үз илдәшләрен җәберләде? Алар бит аны мәңге-мәңге каргарлар...

Шмарь бармагы белән чигәләрен тотты. Чигә тамырында дөп-дөп итеп кан тибешен сизде. Кемдер Шмарьның баш эчендә чүкеч белән дан-дан иттереп суга иде кебек.

Их, яңадан туасы иде дә яңадан тормыш башлыйсы иде. Юк, Шмарь ул чакта болай яшәмәс иде... Бәлки шул уйларны кешеләр сагыш дип атыйлардыр.

Кинәт юл ике якка аерылды. Берсе урман эченә, берсе тау буйлап түбән таба сузыла. Шмарь белә: бусы шәһәргә таба. Ул шул якка борылырга теләп атлый гына башлаган иде, вахтман:

— Линкс! — дип кычкырды. Шмарь тукталып калды. Солдат та тукталды.

— Сулга! — дип кабатлады ул.

Шмарь «Нигә?» дип сорамады. Ул бу юлның кая илтәчәген сизә иде. Ләкин ышанасы килмәде. Бәлки анда башка берәр лагерь бардыр. Шунда алып бармыйлармы икән, дип өметләнә иде ул. О, ул өметләр, өметләр...

Шмарь сул якка таба атлады. Барган саен урман караңгылана, салкыная иде. Шмарь кинәт сискәнеп китте. Тәне чемердәде. Тешләре тешкә бәрелә башлады. Ул тагын туган анасын күз алдында күрде. Менә ул үзенең улы белән янәшә бара кебек. «Улым, сине болай кая алып баралар соң? Бу кара урманда бик куркыныч бит» дип сөйләнә шикелле.

— Әнием, әнием! — диде Шмарь. Ләкин үз тавышын үзе дә танымады. Тавыш түгел, ниндидер пышылдау булып кына ишетелде. Шмарь үз-үзеннән куркып китте. Аякларының көче бетте, тәне камыр кебек ләпшерәйде. Адымнары әкренәйде. Ә вахтман ашыктыра, шнель, шнель дип кычкыра тора. Шмарь моны ишетми дә кебек. Ул һаман әнисенең йөзенә сокланып карый. Анасы, улым, улым, бәгырем минем, ди сыман. Шмарьның күзләре яшьләнде. Кинәт әнисе юл читенә чыгып басты да: «Хуш улым, мин калам инде»,— дип, күздән югалды.

Шмарь инде барысын да аңлады. Аны бу кара киемле солдат атарга алып бара. Бу сукмактан күпләр узган. Әнә анда җир өемнәре күренә, әнә әзер базлар. Алар шахмат тактасындагы кебек итеп кара-каршы казылганнар. Берсе аша сикерсәң, икенчесенә мәтәлеп төшәсең. Әле моннан өч көнә көн элек ике поляк әсирен алып киткәннәр иде. Алар ракетага куелачак радиоаппаратларны бозганнар дип сөйләделәр. Саботаж ясаучылар. Ә Шмарь кемгә, нинди зыян китерде соң? Киресенчә, җаны-тәне белән бирелеп эшләде? Ә Гроссманга ошамады. Ни өчен?

Шмарь үзе дә сизмәстән:

— О, беләм, беләм! — дип кычкырып куйды.— Болар бит шулай яңа корал серен яшерергә телиләр. Алай дисәң, Шмарь яңа корал турында нәрсә белә соң? Аннан соң ул кичә генә комендатурада булган хәлне исенә төшерде. Гроссман өч качкынны «атып үтерелделәр» дип актка язып, яшереп куйды. Ә Шмарь, юләр, яхшы булыйм дип, «алар качтылар» дип дөресен әйткән булып маташты. Менә хәзер инде Шмарь үзе дә дүртенче кеше булып шул актка языльп куелыр... Гросс-

ман өч качкын турындагы хәбәрне беркем дә ишетмәслек итеп, Шмарь белән бергә җир астына күмә. Кабер — ышанычлы урын.

Шмарь барды, барды да туктап калды. Инде теге базлар шактый якын иде. Ул кесәләрен актарып карады. Алар буш иде. Аннары ул күкрәгенә асылган калай номерны өзеп алды, учына кысып тотты.

Аның бу илдә бердәнбер һәм иң соңгы документы — шул калай кисәге иде. Менә шушы минутта әле Шмарьның җирдә яшәвенә шул калай кисәге шаһит иде. Шул калайда исеме дә, фамилиясе дә һәм уэганы да. Тик анда кешенең киләчәге генә юк иде.

Шмарь иреннәрен кысып, күзләрен чекерәйтеп урманга карап алды. Ә урман, мин сине йотам дигән кебек, үзенең корбанын тып-тынын кына көтеп тора иде.

— Мә,— диде Шмарь һәм үзенең номерын бөтен көче белән атып җибәрде.— Мин яшәмәдем, мин дөньяда юк идем...

Уйланды: минем урында Герасимов булса, нишләр иде мондый чакта? Качар идеме? Юк, качмас иде. Хәтта башын да имәс иде Герасимов. Шмарь ни өчендер көнләште. Шул минутта аңа каяндыр, ниндидер көч килеп кердө сыман. Ул кинәт кенә башын күтәреп борылды да вахтманга карады. Вахтман шактый еракта, инде мылтыгын Шмарьга төзәгән иде. Шмарь урманны яңгыратып, ниндидер авыр, тоныкк тавыш белән көлеп җибәрде. Аннан соң эре-эре адымнар белән вахтманга туп-туры карап атлый башлады. Бер атлады, ике атлады. Өченче адымда ул мылтык көпшәсеннән гөлт итеп чыккан зәңгәр төтенне күрде. Шмарьның кулыннан чәчәк төшеп китте. Ул чәчәк аңа кып-кызыл булып күренде. Шмарь тезләнде, әмма кулы чәчәккә җитә алмады. Ул яңадан торып аягүрә басты. Алга карады. Анда вахтман инде мылтыгын түбән төшереп Шмарьга карап тора иде. Шмарь тагын алга атларга теләде. Аяклар бармады. Алар җиргә ябышып калганнар кебек иде. Вахтман яңадан мылтыгын күтәреп Шмарьга төзәде. Шмарь бар көчен җыеп:

— Минем әнием бар иде, бар иде! — дип кычкырды.

Мылтыктан утлы төтен бөркелде. Шмарь авып китте.

Ренат Харисов

# СИНЕҢ ЙӨРӘК ТӘ ТИПСЕН!

*1969 елның январь аенда татар җәмәгатьчелеге патриот-шагыйрь Фатих Кәримнең 60 еллыгын зур итеп билгеләп үткән иде. Күңелле юбилей артыннан мена инде авыры да килеп җитте — быелгы февраль аеның 19 ында шагыйребезнең фашист илбасарларга каршы көрәштә батырларча һәлак булуына 25 ел тулды.*

*Миңа былтыр Балтик диңгезе буйларына, Фатих Кәримнең әле каны да кибеп җитмәгән шинеле, посылка ящигына салынып, коточкыч авыр хәбәргә әверелеп, Казанга җибәрелгән җирләргә барырга туры килде. Калининградта ук инде мин Фатих Кәримгә багышлап шигырьләр яза башлаган идем. Ләкин шагыйрь мәңгегә ятып калган үр итәген күрү, аның кабере кәсенә үз кулларым белән кагылу, Калининград тирәсенә йөзләп сибелгән туганнар каберлегендә булу тагы да нык тәэсир ясады, ул тәэсир Казанда шигырьләргә әйләнде. Шуларның кайберләрен сезгә тәкъдим итәм.*

●

Фатих Кәрим,
Менә бүген
Син күмелгән жирдә мин.
Дөресен әйтим,
Ничек үләргә кирәген
Өйрәнергә килмәдем.

Муса үлде...
Син.
Галимжан...
Үлде Шамил Усманов...
Беләм, беләм —
Үлеп була
Үлемнән өстен калып!

Миңа житкән, йөрәк тойса
Шул үлемнәр зурлыгын...
Шәт, татымам
Ил хакына
Яши белмәү хурлыгын.

Безнен чынлап яши белү
Илнс бәхетле итсен...
Кер, шагыйрь, минем йөрәккә,
Синен йөрәк тә типсен!

## Өченче ядрә

Соңгы атака вакытында Фатих Кәрим
өч мәртәбә яралана.

Үз тәнендә яра ярамени?..
Сызлаулары бары үзенә.
Кеше ярасыннан гомер буе
Сызланырга ничек түзәргә?

...Яраланып бер егыла —
Тора.
Йөгерә һәм тагын егыла...
Шагыйрь Кәрим,
Ике яраң кысып,
Тормый торсаң шунда ни була?..
Юк,
Ул тора,
Тормый кала алмый
Илен сөйгән кеше бу чакта...
Өченче ядрә... Фатих ятып кала
Ят җирләрнең карын кочаклап.

Өченче ядрә
Фатих йөрәгендә
Чарпаланып миллион ярчыкка,
Барып тия һәр сабыйга, яшькә,
Һәр агайга, картка, карчыкка...
Һәм сызлана әнә барлык кеше.
Менә яра! Шуңа түз генә...
Шагыйрь йөрәгендәге шул яраны
Оныкларга илтәм үземдә.

●

Юл буенда дотлар кала
Комсыз авызын ачып...
Авызларда сары балчык...
Үләннәр киткән качып.

Ни җан, ни аң...
Хәтта үлән
Үлемнән курка һаман...
Ә шагыйрь ничек шуышты
Икән дотларга табан?..

Ни җан, ни аң —
Ә тормышны
Сөя, бәһасен белә...
Шагыйрьгә акыл үлемнән
Курыкмаска бирелгән.

Юл буенда дотлар кала,
Авызы тулы балчык.
Җир ул үлән генә түгел,
Хәтта кеше генә түгел —

Аның карары ачык,
Аның нияте ачык:
Үлемнең үзенә үлем!

●

Төкерәм мин бу дотларга —
Балчык чәйнәп ятсыннар.
Күңлем минем бар дотларны
Таптап узар ат сыман...
Кулда кылыч булмаса, мин —
Һәр җирдә кунак җайдак!
Ашатырлар,
Эчертерләр,
Урын түшәрләр җайлап.
Төкерәм мин бу дотларга —
Балчык чәйнәп ятсыннар...
Ә кылыч айкап килсәләр,
Мин ят доттан ятсынмам —
Дошманнан калган дип тормам,
Керермен дә ятырмын,
Дошман дотыннан дошманга
Дошман булып атырмын!

## Кипарислар

Кипарислар...
Гадэттэгедэн тэбэнэклэр алар.
Әйтерсең лә нидер, үч белән,
Кипарислар башына басып тора уч белән.

Фашистлардан калган бу агачлар
Башын бәрә авыр һавага.
Һава нигә авыр?
Сора әнә теге
Башын игән анадан,
Я бу ханымнан,
Ул этисе — шагыйрьне
Зыярат кылырга
Килгән Казан ягыннан..

Монда күз яшьләре, яңгыр булып,
Күздән күккә явалар...

Фашистлардан калган кипарислар
Башын бәрә шушы авыр,
Шушы үчле,
Үче белән көчле һавага...

Шулай тосла...
Бәлки минем тойгым
Чынбарлыктан шактый ерактыр...
Я нишлим соң — сугыш кайтавазы
Йөрәгемне минем елатты.

## Фортлар[1] өстендә

*Кемгә сөйлим серләремне?*
*Ф. Кәрим*

Кемгә сөйлим соң серемне?..
Кемнең йөрәге чыдам:
Кояш монда бездәгечә —
Йөзен чытмыйча чыга,
Яктырта да, җылыта да —
Фортлар өстендә йөри.
Ә фортларга берни
булмый —
Алар күмердәй көйри.
Дөньяга ут кабар кебек
Җилләр көчле иссәләр...
Шуның өстендә чәчәкләр
Рәхәтләнеп үсәләр.

Яшерергә тырышалар
Фортның чын кыяфәтен.
Гөл дә,
Кояш та белми шул
Капонирлар[2] афәтен.
Сөеклемә мин чәчәкләр
Бирүемне кызганам,
Кояшны дустым диюгә
Минем күңел сызлана:
Кемгә сөйлим соң серемне—
Анларсызмы икән сез?
Монда җир дә, монда гөл дә
Монда кояш та гамьсез!..

---

[1] Форт — кечкенә крепость. Калининград тирәсендә илбасарлардан калган андый фортлар 15 әү.
[2] Капонир — крепость тирәсен әйләндереп алган тирән канауны буеннан буена ут астында тоту өчен җайланма.

## Ике шагыйрь

Исәнләшеп китим димен
Шиллер белән.
Яңгырдан ябалдашлар астына поса-поса,
Бөек немец һәйкәле янына киләм.
Гадәт буенча
Сәлам әйтәм исәннәрдән,
Сәлам җибәргәннәрдән,
Җибәрергә теләгәннәрдән.

Иңрәгемдә бүген минем Фатих Кәрим.
Әйтим микән сәлам аңардан?
Әйтим!
Бәлки ул,
Чын татарча ике кулын сузып,
Ничәмә окопларны,
Дотларны таптап узып,
Мин янгырдан поскан кебек,
Ядрәләрдән поса-поса,
Үзе дә ашкынгандыр Шиллер янына?..
Юк, кулындагы мылтыгы түгел
Кавыша алмау сәбәбе...
Очрашкач та
Мылтыгын ул кадаган булыр иде җиргә,
Гадәт буенча сәлам әйткән булыр иде
Исәннәрдән —
Сәлам җибәргәннәрдән,
Җибәрергә теләгәннәрдән...

Яңгыр коя.
Минем уемда
Ике кавыша алмаган шагыйрь...
Кавыша алмаулары өчен
Икесе дә гаепсез...
Янгыр коя.
Мин Шиллерга сәламемне әйтәм,
Күз яшемне яңгыр юа...

●

...Тисен ди ядрә йөрәккә —
Шуннан ни була ди, ә?—
Ядрәдән яраланмый ич
Кешелекле идея!

Керсен ди мина йөрәккә,
Шартласын тәнне телеп —
Минадан теткәләнми ич
Кешелекле зур өмет!

Суксын ди атом йөрәккә —
Мин җаным белән таям,
Барыбер җимеш китерәчәк
Кешелекле зур хыял!

Бетон маңгайлы фортларның
Әйтәм күзенә терәп:
Бернидән дә һәлак булмый
Кешелекле зур теләк!

## Фатих Кәрим кабере янында

Кабер күңелне йомшартты...
Күз яшемне чык йотты...
Кабер илсөяр рухымны
Зур итте һәм ныгытты.
Зыярат кылуларның мин
Ышандым кирәгенә...

Тик шулай керә аласың
Үзең үз йөрәгенә.
Ә анда үзең белмәгән
Чишмәләр бар, кыялар...
Шуны күрмәгән бәндәләр
Илен ансат җуялар...

●

Калининград — Татарстан...
Ике мең чакрым ара.
Фатих Кәрим кабере кәсен
Күтәреп кайтып барам.

Минут саен ерагая
Кәс яткан кабер өсте.
Ара ерагайган саен
Кәс авырая төсле.

Аны җире кире тарта,
Тарта җиренең дымы...
Шаулап торган үләннәре
Калдылар никтер тынып,

Үләннәр сизделәр кебек
Ят җирләрнең көз-кышын...
Аларга да
Кабатлау авыр
Фатих Кәрим язмышын.

Кайчак аска чүгеп ала
Көчле канатлы ТУ да...
Туфрак авыр...
Арды куллар,
Самолет канаты да...

●

Татарстанның күпме улы
Туфрак булды илдән ерак...

Һәр кабердән бер уч туфрак,
Һәр кабердән бер уч туфрак
Безнең яшәү тамырына.
Һәр
кабердән
бер уч
туфрак!..

1969.

## Марсель Зарипов

# СОҢГЫ ВАХТА

хикәя

Черенковны топчанга кертеп салдылар. Камалов аңа елышып ук утырды да бораулаучының сары тут йөгергән киң маңгаена, вак-вак тир бөртекләре кунган кылыч борынына текәлеп, күңелсез уйларга чумды: «Иң коточкыч нәрсә булган үлем дигәнең менә шулай гади генә килә микәнни? Менә бит ничек: син әле бүген генә эшләп йөргән буласың, дөнья куасың, нәрсәгәдер омтыласың, ә иртәгә болар барысы да инде әйләнеп кайтмас нәрсәләр булып калалар».

Камалов Черенков турында белгәннәреннән барысын да исенә төшерергә тырышып карады, ләкин хәтердә анкета мәгълүматларыннан гайре берни дә калмаган иде. Югыйсә, бригададагыларның барысын да яхшы белә кебек бит ул. Менә, әйтик, Донгарян разведкага әти-әнисенә үч итеп килеп эләккән. Тегеләре җае чыккан саен: трай тибүдән бүтәнгә ярамыйсың, рәт чыкмас синнән, дип аны битәрли килгәннәр, ә ул түзмәгән — тоткан да, «романтика эзләргә» дип, өен ташлап чыгып киткән. Демидов, киресенчә, нефть эзләүчеләр бригадасына умырып акча алып булмасмы дип килгән. Ул монда бераз кесә кабартып туган якларына кайтырга һәм үзенә йорт салып, башка чыгарга исәпли. Тик Черенков кына шушы көнгә кадәр нигәдер аның өчен аңлавы кыен бер «ак тап» була килде...

Черенков, тун астыннан кулын чыгарып, Камаловның учын капшап тапты да зәгыйфь кенә кысып кандай итте.

— Менә ничек килеп чыкты. Гафу ит, туган!

— Таптың сүз! — диде Камалов, бораулаучының сәяләнеп беткән кулын кысып.— Ниткән гафу инде ул?

— Минем аркада сиңа да көн бирмәсләр инде: мастер ни караган, фәлән-төгән...

— Сөйләмә юкны, Сема! — диде Камалов, аңа, шулай якын итеп, «Сема» дип беренче тапкыр эндәшүен үзе дә сизмәстән. Аннары топчаннан асылынып төшкән тун итәген күтәреп куйды.— Менә терелерсең, без әле бергәләп әллә нәрсәләр майтарырбыз. Врачлар хәзер чаларып беткән башыңны кисеп кире тегеп куярга да күп алмыйлар. Инде башкасын әйткән дә юк. Килеп тә җитәрләр инде, вертолетлары үз кулларында бит...

— Юкка чакырдың син аларны. Мәшәкатьләнеп килеп йөрүләре генә булыр. Алар миңа ярдәм итә алмый хәзер...— Черенков тун астында яткан килеш бөтен гәүдәсе белән кинәт калтыранып куйды һәм кысык иреннәре аша өзеп-өзеп:

— Егетләрне чакыр. Тизрәк! — диде.

Камалов будка ишеген ачты. Вахта егетләре вышка янындагы күперчеккә җайлап тезеп куелган трубалар өстендә утыралар иде. Камалов учларын авызы турысына китерде дә:

— Демидов! Донгарян! Килегез әле монда! — дип кычкырды.

Күптән кырынмаган, пычракка баткан бораулаучылар, итекләрен тимер баскычта каккаладылар да, будка эченә кереп, дәшми-тынмый, топчан янына килеп бастылар. Алар үзләре исән-имин эшләп йөргән бер вакытта иптәшләренең урыныннан кузгала алмый ятуына уңайсызланалар сыман иде.

Черенков терсәкләренә таянды, Камалов өстендәге брезент курткасын җәһәт кенә салып, аның аркасы астына кыстырды. Черенков иптәшләренең кайгылы йөзләренә озак кына карап торды, нәрсәдер әйтергә теләде, ләкин кинәт ачуы чыгып, ярсып пышылдады:

— Нәрсә кайгыгызны күтәреп килдегез миңа? Ягез әле, сыптырыгыз! — һәм янәдан урынына ауды.

Демидов белән Донгарян чыгып киттеләр. Камалов, бораулаучының сакал-мыек баскан соргылт йөзеннән күзен алмыйча, бергә эшләгән вакытта бу кеше турында хәтеренә сеңеп калган хәлләрне күңеленнән уздырды.

Искитмәле сәер бер кеше булып чыкты ул Черенков. Бригадага эшкә дә бит ул кешечә түгел, измә балчык төялгән самосвалга утырып килде. Шофер, кабина ишеген ачып, алып килгән пассажирын чыгарды да Камаловка:

— Әй-й, эшче көче алып килдем сиңа. Путевкага дип конторага кергән идем, кадрлар бүлеге бәйләнде генә бит: «Алыр бар». Ә миңа нәрсә — утырттым да алып килдем,— диде.

Черенков, башын күккә чөеп, озаклап, вышкага карап торды. Үзе җилкәгә әллә ни киң түгел, яшел сырмасы өстенә таман гына, аякларында нык керза итек, бите сөякчел, маңгай уртасы өчпочмакланып эчкә батып тора. Зур гына күн сумкасын, алып китмәгәйләре дип курыккандай, һич кулыннан ычкындырмый. Сумкасына корымланып, каралып беткән зур гына җиз чәйнек тагылган.

Черенков вышкага, аның тирәсендә кайнашучы кешеләргә карап туйды булса кирәк, кепкасының ямьшәеп беткән козырегын сыпырасыпыра, мастер янына килде.

— Эшләп буламы? Җир-ананы бораулыйбызмы?

— Тишәбез әкренләп,— диде Камалов.

— Бораулаучылар белән эш ничегрәк сездә? Андыйлар кирәк түгелме, диюем. Мине алырсыз микән?

— Нисең калган синең бездә? — дип дорфа гына сорады Камалов.— Пенсиягә стажың җитмиме, әллә сәмән кирәк булдымы?

— Минем нәрсә калдырып, нәрсә югалтуымда синең эшең булмасын, белдеңме? Аласың икән — ал, кирәкмәсә — хуш, сау бул! Күрче син аны, ялчылыкка аламыни!

Камаловка аның менә шулай кыю-үҗәт сөйләшүе, үзен иркен һәм бәйсез тотуы ошады: димәк, ул я үз бәясен яхшы белә торган горур кеше, яисә чиктән ашкан бер эрсез бәндә.

— Я, ярый,— диде ул, Черенковны эштә сынап карарга булып.— Бас тормоз янына. Үзеңне күрсәтә алсаң — каласың.

Һәм ул, күңелен биләп алган көнчелек тойгысыннан арынырга тырышып, Черенковның эшләвен, күзен дә ала алмыйча, ярты сәгать буе күзәтеп торды. Черенковның элеваторны миллиметрга тикле төгәл-

лек белән, бәрми-сукмый, нәкъ роторның өстенә китереп туктатуыннан, сүс канатны кәтүккә житез генә өч катлап чорнап, өч алым белән «шәмнәрне» жайлап кына бер-берсенә борып тоташтыруыннан, Донгарян белән Демидовка ни эшләргә икәнен нәкъ вакытында һәм урынлы әйтеп торуыннан ул тормоз янына үз эшенең чын остасы басканлыгын аңлап алды. Һәм үзе дә сизмәстән кычкырып жибәрде:

— Өлгер эшлисең, молодец! Кая гаризаң? Яздыңмы?

Черенков жавап бирмәде. Ул урманга, болытларга караган да тагын үз уйларына чумган иде.

Камалов аның терсәгеннән тотып, күзләренә карады. Черенковның күзләре яшь белән тулган иде. Керфек очыннан таммый торучы, үзенә бер төрле тавышсыз-өнсез күз яшьләре иде алар. «Башына тай типкәнрәк нәрсәдер лә бу. Чәнчелеп китсен, әллә эшкә алып тормаскамы үзен?» — дип уйлап алды ул. Аннары тегеңә тагын бераз карап горды да: «Вәгъдә биргәч, алмый ярамый инде, хәерле булсын,— дигән карарга килде.— Түзмәс, үзе үк качып китәр әле. Көзге пычракларга кадәр яисә тәүге кар төшкәнче торыр да үкчәсен ялтыратыр...»

Көз дә узып китте, иләмсез озын булып тоелган кышны яз да алмаштырды, жәй дә үтте, ә Черенковның һаман разведкадан китәр исәбе күренми иде.

Чыннан да бик сәер кеше булып чыкты ул. Үзенә тиешле ике атнасын эшли дә, больницага кереп ята. Ә буровойга барыр көн житү белән иске бер тиен төсле кайтып житә. Әллә аңа тиешле акча бүтәннәргә эләкмәгәе дип курка инде? Алай дисән, әллә ни комсызлыгы да юк. Әжәткә сорап торучы булса, бер сүзсез бирә. Икенче бер сәер ягы: әлеге теге жиз чәйнегеннән һич аерылмый. Кая гына бармасын — чәйнек үзе белән: өстәл янына ансыз утырмый. Башта аңа ваклап такта чәй сала, аннары кайнар су салып, бер мәл тагын ут өстендә тота да эчәргә тотына. Нәкъ төркмәннәр төсле, билләһи. Аларны да чәйсез торә алмыйлар икән, эсседән саклану өчен аны кайнап торган килеш эчәләр икән, дип сөйлиләр бит. Черенков та әллә инде шул куе кайнар чәйдән бер ләззәт таба, әллә шуның бер шифасын күрә? Кружкасын тутырып берне эчә дә, тәненә жиләсрәк булсын өчен, күлмәк жиңен кайтарып куя, тагын берне эчә — тагын кайтара... Чәйнеге бушаганчы, жиңе тәмам кайтарылып беткәнче шулай эчүен белә.

Бер вакыт Камалов аны шелтәләп тә карады:

— Курорт жене кагылган хатыннар төсле син, больницадан больницага йөрисең. Авыру икәнсең — ныклап торып дәваланырга кирәк.

— Ә мин дәваланам!— Һич исе китмәгәндәй, чая гына жавабын бирде Черенков һәм, чәйнегенә ымлап, дәвам итте:— Чифирь белән...

— Нәрсә, нәрсә?..

— Чифирь белән дим. Теләсәң сине дә өйрәтәм.

Ул шунда ук бер такта чәйне ваклап бетерде дә чәйнегенә салды, аннары аны кайнаган су белән тутырып, ут өстенә куйды. Кайнап чыккач, чәйне сөзеп, кружкасына салды.

— Мә, эчеп кара әле! Нишләп эчмисең? Юкка баш тартасың. Беләсең килсә, бөтенләй яңа кеше итә ул сине, тәңгә сихәт бирә.— Һәм ул, күзен дә йоммыйча, кружкадагы чәйне эчеп бетерде.

Бу соңгы вахтага да Черенков турыдан-туры больницадан килде. Аннан алдагы кичне Камалов үзенең кечкенә генә бүлмәсендә Гүзәлгә хат язып утырды. Ул вахтада маташкан ике атна эчендә кыздан жавап та килеп житәчәк иде. Бар шатлыгы шул хәзер Рамилнең — хат язу һәм хат алу. Тәмам туйдырды инде мондый тормыш. Ә аның очы-кырые һаман күренми. Китәргә кирәк! Житәр, институт бетергәч үзенә тиешле өч елын тутырды инде. Әллә аның башкалардан ким жире бармы? Әнә Гүзәл институтка кече фәнни сотрудник булып урнашкан бит әле. Ә башта бергәләп барырга сүз куешканнар иде. Ул шул сүз буенча

Татарстанга кайтты, ә Гүзәл — шалт! — тотты да институтта калды. Һәм дөрес эшләде. Әллә аның янына китәргәме?..

Камалов үзе яза, үзе кәгазь битенә төшкән сүзләреннән, өстән бурыч төшерү өчен генә язылган сүзләрдәй, ничектер тәэсирсез, ятышсыз килеп чыгуларын сизеп утыра. Йөрәгендә элекке назлылык та, ләззәтле бер дулкынлану да юк. Камалов бу хәлне соңгы еллардагы тормышының кырыслыгы нәтиҗәсе дип карый.

Шулай дип язды да: әгәр мин кинәт кайтып төшсәм, институтта моңа ничек карарлар икән, диде. Ул нефтьне бу якларда аңа кадәр дә күпме кеше эзләгән, менә ул да инде өч ел буена бер файдасызга аяк киеме туздыра. Өметсез эш белән йөрү — үзе бер тинтәклек. Өстәвенә аларга инде башлы-күзле булырга да вакыт түгел микән, сабакташлары күптән өйләнешеп беттеләр ләбаса...

Камалов хатын язып бетерә алмады. Кинәт ишек ачылып, бүлмәгә шакымый-нитми, разведка врачы Серафима Гавриловна килеп керде.

— Ярый әле үзеңне туры китердем,— диде ул, исәнләшмичә генә.— Ул кешегез мине авыру итәргә йөри инде сезнең. Я хода, акылдан шашармын, ахрысы, мин!

— Нинди кешебез?

— Кем булсын? Шул Черенков инде. Врач буларак мин аның вахтага чыгуына кул-аягым белән каршы. Мин начальникның үзе белән дә, бурком белән дә сөйләшә алган булыр идем, ләкин ул мастер сүзенә күбрәк колак салачак. Сөйләшеп карагыз әле, Рамил. Күндерегез әле шуны операциягә.

— Ярар! — диде Камалов, башлаган эшен бүлдерүләренә ачуы чыгып.— Сөйләшермен.

— Зинһар, Рамил, үтенеп сорыйм. Юкса әллә нинди кеше ул, эшен калдырудан курка.

Серафима Гавриловна киткәч, Камалов хатын язып бетерергә утырды, ләкин башындагы элеккеге уйлары каядыр очып беткән иде инде. Форточка ярыгыннан бүлмәгә көзге дымсу җил өрә, урамда кемдер бик тырышып гармун суза, ә карлыккан тавышлы икенче берәү гармунга кушылып җырлый иде:

Ты только одна-а-а, ты одна виновата-а-а...

— Минем шайтаннар! — дип уйлады Камалов, Демидовның тавышын танып. Ул, урындыкка басып, форточкадан башын чыгарды һәм:

— Әй, нәрсә акырасыз анда? — дип кычкырды.

— Ә-э, Рамил,— диделәр тыштагылар.— Начальствога салют. Без сине алмага киләбез, әйдә!

Тәрәзә янында аерылгысыз дуслар — Демидов белән Донгарян басып торалар иде.

— Ну-ка, марш йокларга! Иртәгә эшкә соңгармассызмы!

Камалов тагын хат язарга тотынган иде, ләкин күңелендә фикерләрен тупларга комачаулап, әле генә ишеткән җыр буталды: «Ты только одна...» Сүзләре инде туйдырып бетергән булсалар да, җырның көе алай эч пошыргыч түгел, анда үзенә бертөрле шаянлык, җорлык бар иде. «Фу, тәмам сеңде бит мигә... Суырып алыр хәл юк...»

Ул, әле һаман тәмамланмаган хаты өстенә иелгән хәлдә, бу шаян көйне каян белүен хәтерләргә тырышты. Һәм моннан ел ярым чамасы элек разведкага артистлар килүен исенә төшерде. Аяк баскысыз пычрак иде. Кунаклар утырган автобусны идән такталарыннан ашык-пошык әмәлләнгән клуб янына трактор белән тарттырып китерделәр. Һәм менә шунда көтелмәгән бер тоткарлык килеп чыкты: артистларның аягында үтә модалы очлы, нәзек башлы туфлялар иде. Бәхеткә каршы, вахтадан бушаган барлык разведчиклар клуб тирәсендә иде. Артистларны автобустан сәхнәгә шулар күтәреп илтте. Автобус ишеге янына

хәтта какча гәүдәле Донгарян да килгән иде. Ләкин аның каршына, гәүдәсе белән бөтен ишекне тутырып, алыптай юан бер ханым килеп басты. Автобус селкенеп куйды, ун якка таба янтая төште. Донгарян ничектер куырылып калгандай булды, ни әйтергә белми, як-ягына каранды. Әле ярый гәүдәгә таза Демидов шунда гына тора икән. Ул Донгарянны бер читкәрәк этәрде дә ишеккә аркасы белән борылды:

— Рәхим итегез! Курыкмагыз, ышанычлы җилкә бу!..

Артистлар киткәнгә инде күпме вакыт үткән, ә менә алар башкарган көй һаман истә, егетләр ул җырны үз сүзләре белән җырлыйлар. Хәер, бүтән нәрсә җырласыннар соң? Менә бүген акча алган көн, күңелләре күтәренке, ә иртәгә ике атнага вахтага китәләр. Чит кешене елына бер генә күрәләр бит алар. Юк, таярга кирәк моннан! Тизрәк таярга! Әллә Черенков янына барып килергәме? Нәрсә ул башын җүләргә салып йөри?

Черенков тулай торакта сумкасына әйберләр тутырып маташа иде. Өстәл өстендә төрле төргәкләр, банкалар, икмәк ята, бер шешә «Армения» коньягы тора.

Бу коньякны Черенков кая барса да үзе белән йөртә. Ул шешәне беренче тапкыр күргәндә Демидов шатлыгыннан сүзен әйтә алмый торды:

— Менә сиңа мә-ә-ә! Закускага нәрсә, кыздырган кадак?

Донгарян исә, Черенковны кочаклап, аның колагына пышылдарга тотынды:

исә, Черенковны кочаклап, анын колагына пышылдарга тотынды:

— Дюша мой! «Армения» эчмәгәнемә бер гасыр булгандыр инде, исен дә онытып бетергәнмен. Я, сал тизрәк! — Һәм ул шешәне бөкесеннән үпте дә этикеткасын сыпыргалый башлады.

Черенков шешәне тартып алып, топчан астына яшерде, ягымлы дип һич әйтеп булмый торган бер тавыш белән:

— Кеше малына күзенне ялтыратма! Һәр нәрсәнең үз вакыты була, аңладыңмы? — диде.

Камалов бүлмәгә килеп кергәндә Черенков әнә шул шешәсен сумкасына салырга дип кәгазьгә төреп маташа иде.

— Кая җыенасың болай, Черенков? — дип сорады Камалов.

— Ничек инде кая? Иртәгә смена алышына бит, вахтага — безнең чират.

— Алмашынса, бу сиңа кагылмый. Син операциягә ятарга тиеш. Юк, сине ала алмыйм.

Черенков урындыкка чүгеп утырды, өстәл өстендәге сумкасын идәнгә алып куйды. Аннары пышылдап кына:

— Ал инде, мастер! Соңгы тапкыр? — диде.

Менә бит тинтәк бәндә! Аңа ап-ачык әйтеп торасың, ала алмыйм, дисең, ә аның үз туксаны туксан: «Ал да ал!» Камалов, бөтен сабырлыгын туплап, чир белән уйнарга ярамаганлыгын, Черенковның больницадан юкка чыгуын, операциягә риза булса үзе өчен дә яхшырак булачагын, вахтаның бер кая да китмәячәген аңлатырга тотынды. Ләкин Черенков һаман бер сүзне кабатлады: «Ала күр!»

Ниһаять, Камаловның түземлеге бетте: ниемә дип ул аны сабый бала төсле үгетләп утыра әле?

Шул уй белән ул чыгып китәргә дип ишеккә борылган иде дә, Черенков, ишекне гәүдәсе белән каплап, тотлыга-тотлыга:

— Чыгармыйм. Валлаһи дип әйтәм, вахтадан кайту белән үзем барам, киссеннәр — бер сүзем юк. Тик бу юлы ала күр? — диде.

— Я, артистланма,— диде Камалов, коры гына.— Театрда түгел бит син.— Һәм Черенковны ишек яныннан этеп җибәрде дә чыгып китте.

Иртән Камалов вахтага баручылар җыела торган диспетчерскийга көндәгедән иртәрәк килде. Черенков бораулау трубаларыннан ясалган

зур трактор чанасына урнаштырылган будка эчендә «буржуйка» мичен ягып утыра иде инде. Әйтерсең, кичәге сөйләшү бөтенләй булмаган.

Камалов аңа ачуланмады. Кул селтәде дә:

— Я, ярый, чәнчелеп кит! Ләкин шуны бел: вахта бету белән хирург кулына үзем илтеп тапшырам! — дип кенә куйды.

Аннары тракторлар аларны буровойга таба алып китте. Барыр юл озын, ерак, ялыктыргыч иде. Чокыр-чакырларны үткәндә чананы әле бер якка, әле икенче якка ыргыта, аның табаннары астында бер туктаусыз пычрак чупырдый, будканы иләмсез калтырата, селкетә иде. Бораулаучылар, «буржуйка» тирәсенә тезелеп утырып, вакыт үткәрү өчен анекдотлар сөйлиләр, баштан үткәннәрне искә төшереп баралар.

Ярты юлда, урман эчендә аларга пошый очрады. Мәһабәт гәүдәле, көчле, матур бу җанвар, салкыннан шәрәләнеп калган агач ботакларын мөгезе белән як-якка аерып, кыймылдап та карамыйча кешеләргә карап тора иде. Ә алар, пошыйдан күзләрен ала алмыйча:

— Эх, атып егарга!

— Ите уникеп поттан да ким булмас моның... Бөтен вахтаны туйдырырга җитәрлек.

— Күр, ничек карап тора, падиша бу диярсең! — диештеләр.

Күренеп тора: пошый әле бер тапкыр да өркетелмәгән, кешеләрне әнә ничек тыныч караш белән озатып калды.

Билгеләнгән урынга нәкъ вакытында килеп җитеп, вахтаны кабул иттеләр. Аннары тракторлар эштән бушаган кешеләрне поселокка алып кайтып китте. Гадәти эш көннәре башланды. Биш-алты сәгать ял итәсең дә — вахтага басасың, сигез сәгатеңне эшлисең дә — тагын ял. Әмма иң кыены бу түгел, иң кыены — кешеләрнең өметсезлеккә бирелүендә: менә бу скважинаны да бораулап бетерерләр, сынап карарлар, ә ул моңа кадәр бораулаган уннарча бүтән скважиналар төсле «кысыр» булып чыгар. Бер файдасызга күпме казынырга мөмкин?

Камалов эш арасында Черенковны күздән ычкындырмаска тырышты: ул-бу булмагае! Юк, хәзергә хәвефләнер нәрсә күренми шикелле. Черенков бүтәннәр белән бергә вахтада тора, шлангтан агып торган суда тиз-тиз битен-кулын юып, туйганчы чәен эчә дә топчанына барып ята.

Смена алмашынырга бер атна калган иде. Ул көнне бораулаучыларга трубалар белән озак маташырга туры килде. Труба ташучы машина, вышка янына килеп җитә алмыйча, йөген бер чакрым чамасы җирдә чәчеп калдырган иде. Шунлыктан трубаларны күтәреп ташырга мәҗбүр булдылар. Егерме метр озынлыгындагы «шәмне» җыйнаулашып катоклар өстенә салырга, аннары буровой күперчегенә кадәр шудырып китерергә һәм, ломнар белән әләктереп алып, өскә күтәрергә туры килде. Трубалар күтәрелергә теләмичә теңкәгә тияләр, менә булды дигәндә генә кире шуып төшәләр, ләкин барыбер кешеләрнең ихтыярына гына буйсынып, дөбердәп-шатырдап булса да, күперчек өстенә меңәләр иде.

Соңгы трубаны менгезә башлаганда инде смена тәгәлләнеп килә иде. Анысын да, барысы дәррәү тотынып, күперчектән өскә таба шуыштырдылар, менә ул инде җирдә басып торган кешеләрнең күкрәкләре белән тигезләште, бораулаучыларның кайберләре кирәге калмаган ломнарын читкә ыргыттылар, чөнки «шәм» менеп җитә язган иде инде.

Кинәт Черенков: «Рамил!» — дип кычкырып җибәрде һәм бөтен гәүдәсе белән чүгә башлады. Труба дөбердәп аска таба тәгәрәде. Камалов, йөгереп килеп, аны җилкәсе белән тоткарлады һәм умрау сөягенең ничектер чытырдап куюын, бик нык авыртуын сизгән хәлдә трубаны кире күперчек өстенә китереп салды. Черенков исә пычрак уртасында утырып калды.

— Сиңа ни булды? — диде Камалов аның янына йөгереп килеп.— Хәлең беттеме әллә?

Черенков сүзсез генә тезләнде, торып басмакчы булды, ләкин шунда ук ике кулы белән эченә ябышты һәм, аягында тора алмыйча, күп тапталудан боткаланып беткән пычрак эченә башы белән килеп төште.

...Камалов, Черенковның соргылт йөзенә караган килеш, әнә шул алла да, шайтан да оныткан буровойны, үткесез юлларны, көзге пычракны һәм врачларны каргап утырды: бригадада каты авыру бар дип хәбәр иткәненә ике сәгать булды, ә аларның үзләре дә, сүзләре дә юк. Монда сәламәт кешең дә авыруга сабышыр!

— Син молодец егет, Рамил,— дип куйды Черенков, күзен ачмыйча гына.— Минем хәлгә керә белдең. Әгәр мин үземне кистерергә риза булсам, барысы да шунда ук беткән иде бит: кулга инвалид кәгазе тоттырып пенсиягә җибәрәләр иде. Бакчә үстереп, редиска белән сату итәргә генә кала иде... Бик күп кистеләр инде мине, эчтә кисәр нәрсә дә калмады. Син ничәдә?

— Ничек «ничәдә?»

— Ничә яшьтә?

— Егерме алтыда.

— Бәхетле син. Разведкада эшли башлаганда мин яшьрәк идем. Менә хәзерге төсле тегендә барып бораулыйсың, монда киләсең, өметсезләнә башлыйсың. Менә шунда кинәт — фонтан! Шатлыкның чиге юк, премиясе-фәләне килеп төшә, тормышка ямь кереп китә. Ул да булмый, синең фонтан төбенә төзүчеләр килеп житә, күз ачып-йомган арада йортлар, мәктәпләр салып куялар. Гел җан иясе юк җирдә каяндыр кешеләре дә табыла. Ә мине болары кызыктырмый. Нишләмәк кирәк — характер шундый! Яңа фонтаннар эзләп тагын китәм. Менә шулай егерме ел инде разведкадан разведкага йөрим...

— Син тик кенә ят, Черенков, сөйләшергә ярамый сиңа.

— Тукта әле, бүлдермә. Үтенечем бар сезгә. Үтәрсезме?

Камалов, ризалык белдереп, башын иде.

— Рязань тирәсендә, авылда әнием бар минем. Картайган инде, шулай да бик ягымлы карчык үзе. Гел зарлана, кайт дип чакыра. Тәки кайтып булмады шул. Тагын бер фонтан табасы килгән иде. Соңгы тапкыр. Аннары үзем дә шунда урнашып калырга, әнине алдырырга иде исәп... Нефть тапсагыз, бер шешәгә тутырып җибәрегез әле шуңа. Адресы чемоданда. Ничек-ничек булганын әйтеп хат языгыз. Коньякны сезгә калдырам. Мин аны шул фонтанны юарга дип саклап йөрткән идем. Бар борчылганым шул булды — вахтадан калырмын да мин югында фонтан бәрә башлар дип курыктым! Әллә син тапмабыз дисеңме? Сез табарсыз! Күрерсез, шушы урында шәһәр үсеп чыгар әле.

— Ташла, Сема, тик ят!

— Тукта, бетерим. Шәһәр салынгач сез мине дә шунда пропискага кертегез, ямә? Шунда яшәүче төсле итеп...

— Кертербез. Ул гына түгел, берәр урамга синең исемне дә бирербез әле. Ул урамнарның берсе Донгарянныкы булыр, берсе синеке... Без бер көтү булып шул урамнардан йөрербез.

— Хыялый кеше син,— диде Черенков, елмаеп.— Минем фамилия урам исеменә яраклы түгел. Черенков, черенок... Янгырамый. Пропискага кертсәгез — шул җиткән.

— Я, Сема, ташла әле, зинһар! Ташла! Менә күрерсең, дөньясын җимертербез әле!

Камалов үзен ахмакларча тотуын да, бу урында бөтенләй икенче сүзләр әйтергә кирәклеген дә аңлый иде. Шуңа күрә еракта мотор гүләвен ишеткәч, сүзне бүлер өчен форсат табылуга шатланып куйды.

— Ишетәсеңме, Сема? Киләләр! Әйттем бит мин сиңа!

Камалов, бүреген дә киеп тормыйча, йөгереп чыкты. Нәкъ вышка өстендә туктап калган вертолет туп-турылап җиргә төшеп килә. Ә буровой янындагы бораулаучылар бүрекләрен күккә чөяләр иде.

Камалов, Серафима Гавриловнаны һәм тагын бер хирургны ияртеп будкага әйләнеп кергәч, Черенков кымшанмады да.

— Син нәрсә, Семен? — Камалов топчан янына йөгереп килде һәм Черенковны селкетергә тотынды. Авыруның башы бер якка янтайды, туны идәнгә шуып төште. Аның маңгаенда тир бөртекләре җемелди иде. Камалов каушап калды.

— Су бирегез! Тизрәк! — диде хирург.

Бөтен бригада, баскыч төбенә җыелып, бер сәгать буена врачларның сүзен көтте. Камалов, тузгак чәчле башын ике кулы белән тотып, буровой өстендәге соры болытларга караган килеш: «Черенковка ни булыр икән?» — дип уйланды.

Ниһаять, будка ишеге ачылды да ят бер тавыш:

— Файдасыз. Ашказаны шеше. Тишелгән...— диде.

— Эх, Рамил! Әйттем бит мин сиңа... Кайда күмәсез инде,— дип елый-елый сөйләнде Серафима Гавриловна.

— Барыбер түгелмени? — дип ачулы мыгырданды Демидов.— Аңа хәзер кайда да ярый...

— Юк, аның өчен барыбер түгел,— диде Камалов, коры гына.— Монда күмәбез.

Әнисенә җибәрелгән телеграммага өч көн җавап көттеләр дә, хәбәр булмагач, Черенковны буровой янында җирләделәр. Камалов белән Демидов кабер өстенә яшел нарат ботаклары алып килеп җәйде. Донгарян тимер кисәкләреннән нефть вышкасы макетын эшләп куйды.

Бер төн уртасында Камалов тагын кабер янына чыкты. Суыткан. Салмак кына тәүге кар ява. Салкынча кар бөртекләре тавышсыз-тынсыз гына, җайлап кына буровой өстенә, кабер өстенә куналар. Алардан төн дә йомшаграк, ягымлырак булып тоела иде.

— Берсекөнгә тракторлар киләчәк,— дип куйды Камалов.— Смена алышыначак. Аннары база. Менә шунда башланыр инде. Кеше үтерден, дип директорга, профкомга йөртә башларлар, куркынычсызлык техникасы инженеры йөдәтеп бетерер. Ә карт әнисенә нәрсә дип язарга?

Ул кабер янында озак басып торды, уйланды, Рязань тирәсендәге авылда яшәүче кечкенә гәүдәле ягымлы карчыкка әйтер өчен ниндидер ятышлы сүзләр эзләде, таба алмады.

Ә нәрсә соң ул хат? Конвертка салынган коры сүзләр! Күп нәрсә әйтеп буламыни хатта? Әллә ял алырга да үзенә шунда барып, бәйнә-бәйнә сөйләп бирергәме?..

## Булат Сөләйманов

### Синең моңнарың

Казан! Себер тикле Себерләргә
Ишетелде якын моңнарың.
Искән җилләр алып килде аны,
Бураннарда бәүләп [1] тыңладым.

Көйләделәр Иртеш дулкыннары,
Юа-юа комлы ярларын,
Кая барсам җырлап озаттылар
Иксез-чиксез ап-ак карларым.

Туган җирем мине ир булырга,
Чигенмәскә юлда өйрәтсә,
Шушы моңнар миңа куәт бирде,
Җыр уятты кыргый йөрәктә.

Сунардаш кук дус та була белде
Тайгаларда ауда йөргәндә.
Шушы моңны көйләп тост күтәрдем
Кунакларга шәрап биргәндә.

Шушы моңнар мине алып килде
Бишегенә татар халкының.
Нинди генә җилләр кагылмады,
Сүрелмәде ләкин ялкыным.

Күңелемдә эретеп салкыннарын,
Ярсуларын алып давылның,
Моңнарыма салдым җырлар итеп
Сагышларын туган ягымның.

И Казаным, туган анам булып
Кочагыңа ал син гомергә,
Ярсып чапкан минем чал Иртешем
Кушылып аксын синең Иделгә.

●

Ак таңнарым өлгермәде
Җәяргә ал канатын,
Очкан уктай, томаннарга
Ыргылды хыял атым.

Эһ дигәнче ул юк булды.
Китмә, китмә, Акбүзем,
Сагышларым белән торып
Калдым мин тик бер үзем.

Сөт сыман ап-ак томаннар...
Гүя җирнең сагышы.
Калды йөрәгем күк ярсып
Типкән тояк тавышы.

Акбүз атым сине эзләп
Ил гиздем еракларда,
Кешнәвеңне ишетмәдем,
Әйтче, син кай якларда?!

[1] Бәүләп — тирбәлеп, калгып.

●

Әгәр егет кылса җинаять —
Халык
Бер булмаса бер кичерер, юк, дошман димәс аны.

Әгәр егет итсә хыянәт —
Халык
Ата-бабалары яткан зиратка күммәс аны.

●

Буровойдан кайтып киләм көйләр көйләп,
Кара ташкын тишеп чыкты катламнарны.
Баскан саен карлары да җырлап бара,
Җир күтәрер микән минем шатланганны!

Аккош йоны кебек йомшак карга батып
Ятыйм әле, карашларым күккә атып.
И марсиан, бәлки хәзер арып-талып,
Син дә миңа карыйсыңдыр чалкан ятып.

●

Тәрәзәдән узган гомер карый,
Көзге урамга уйлар текәлгән.
Бала-чага футбол уйнап йөри.

«Мин ул чакта бәйга көтү көттем».

Урамнарга коеп яңгыр сипте,
Яңгыр сипте тәрәзәне чиртеп.
Чыр-чу килеп яшьләр үтеп китте.

«Минем өскә ул чак кургаш яуды».

Нәкъ бабайның йөзе кебек сары,
Таш юлларга коела шып та шып
Агачларның соңгы яфраклары...

●

Аучымы,
Аучынымы нидер аулады...
Кара урман шомлы шаулады.

«Озак йөрмәм дигән иде бит».

Авылдашлар тирги давылны,
Күмеп киткән өчен авылны.

У-у-у...
Җилләр түгел, улый бүреләр.

Йокламады авыл төн буе,
Һәркемнең дә иде бер уе:

«Менә-менә кайтып керер ул».

Төн үтте...
Төн артыннан тагын көн үтте.

Аучы өенә кире кайтмады...
Авыл өстен болыт каплады.

## Көзге урманда

Уйга талып басып торам бер ялгызым,
Көзге урман охшап калган каберлеккә.
Минем күңелем сыман моңсу агачлар да,
Алар шулай калыр төсле гомерлеккә.

Кошлар да бит ташлап киткән бу урманны,
Болытларга кереп поскан якты нурлар,
Рәхим-шәфкать сораган күк аллалардан,
Тырпаешып тора бары шәрә куллар.

Үткән гомер безгә кире килмәгән күк,
Язлар кабат кайтмас төсле бу урманга.
Агачларның җирдә ята йөрәкләре,
Күпме яфрак үлгән кайгы саргайтканга.

Ләкин язлар тагын килер, килми калмас!
Табигатьнең үзенең бар кануннары.
Күңелемдә истәлекләр генә минем,
Ә урманда мәңге яшьлек тамырлары.

Ян Винецкий

# ПУШКИН ҺӘМ МӘРЬЯМ

ПОВЕСТЬ

## I

Кышкы салкын томан һәм зәңгәрсу кичке эңгер, тирә-як тауларга һәм үзәнлекләргә җәелеп, урманга килеп тоташкан. Кисентедәге кояшлы алан да, алтын сыман саргылт комлы урман юлы да күренми. Тын гына ага торган зәңгәр сулы Сороть елгасы да боз һәм кар астында калган.

Александр, боз бизәкләре белән капланган тәрәзәгә карап, Северный Пальмира турында уйланып тора иде. Анда, мөгаен, шау-шулы мәҗлесләр, әдәби бәхәсләр үткәреләдер, өрсәң очып китәрдәй җиңел чаналарга җигелгән юртаклар, Невский буйлап, кыңгырауларын чылтыратып, тыз да быз чабып йөри торганнардыр.

Александрның шул фикерен раслагандай, кинәт кыңгырау тавышы ишетелеп китте һәм эт өрергә тотынды.

— Ходай кемне алып килә икән тагы? — дип, гаҗәпләнеп, Арина Родионовна өялдына чыгып китте.

Александр тиз генә кәнәфидән торды да кайнар маңгаен тәрәзәгә терәде һәм килүченең озын буйлы таныш кеше икәнлеген абайлап, кара бөдрә чәчләрен җилбердәтеп, сюртюгын да киеп тормастан, күлмәкчән генә йортка чыгып китте.

— Я, рабби! Саша!

— Исәнме, Иван! Әйдә, рәхим ит!

Үбешеп алдылар. Ул арада Арина Родионовна зур бүре толып тотып урамга йөгереп чыкты да аны тегеләр өстенә каплады:

— Безнең гарәп суыкны уйлап та бирми! Ә салкын шаяруны яратмый. Әйдәгез, балакайлар, өйгә керегез тизрәк!

Көлешә-көлешә толып эченнән чыккач, Александр белән Иван өйгә керделәр. Арина Родионовна шәмдәлләргә янып торган шәмнәр китереп куйды да бер шешә кавказ шәрабы алып килде. Аннары мичкә

ягып җибәрде һәм, дусларның әңгәмәсенә кушылып, кызыл ялкын дәрләп янып-дөрли башлады.

Иван Иванович Пущин сизелерлек дәрәҗәдә олыгаеп киткән. Кыяфәте җитди һәм аның кискен карашыннан күңелендә ниндидер яшерен уй бар икәнлеге сизелеп тора. Александр моны шундук тоеп алды, ләкин Иванның үзенә әйтергә ничектер уңайсызланды. Ул бары тик соргылт-кара күзләрен елтыратып елмаеп кына куйды да:

— Синең маңгаеңа яңа җыерчык өстәлгән бит,— диде.

Пущин көлеп җибәрде.

— Син, Александр, хатын-кызлар кебегрәк: бөтен вак-төякне күреп аласың.

— Яраткан кешеңә шулай сизгер буласың ул... Карале, Иван, зарыктырма, сөйлә әле, Петербургта ниләр бар? Лицейда бергә укыган иптәшләрдән кемнәрне күргәлисең? Гусарларның һәм гвардия офицерларының тынгысыз башларында нинди уйлар кайный?

— Әй, Саша! Бу кадәр дә кызыксынучан булырсың икән. Петербург үз көенә яши, ләкин һәркем анда үзенә ни кирәк — шуның белән мәшгуль.

— Ә син нәрсә күрергә телисең? — диде Александр.

— Мин шунда яшим,— диде Пущин, дустының очкынланып торган күзләренә карап.— Ниндидер тынгысызлык, борчу... мин Рус дәүләтенең авыру, нервлы тавышын ишетәм.

— Әллә ничек син, Иван. Олыгайган саен фикерең томалана бара,— диде Александр, ризасызлык белдереп.

— Күптән түгел генә Жуковскийны тыңладым. Карамзин карт аның өендә кичә уздырган иде. Жуковскийның шигырьләрен бик яратты. Ә минем ачуым чыкты. Минемчә, Жуковскийның шигырьләре артык нечкә хисле, хатын-кыз кебегрәк дип әйтимме шунда... Поэзия андый түгел хәзер.

— Ә нинди соң ул? — диде Александр, елмаеп.

— Авыру, ачулы, гаугалы! Менә ничек!

Александр акрын гына сызгырып куйды.

— Күрәм, каның кызган синең дә.

Пущин бокалларга шәраб салды. Сүзсез генә чәкешеп, икесе дә эчтеләр.

— Әле күптән түгел генә без, хушлашуга багышлап язылган лицей җырында Дельвиг әйткәнчә, рәхәт тынычлык кочагында яши идек,— диде Иван, сүзен дәвам итеп.— Син беләсең бит, безнең барыбызны да Ватан сугышы уяткан иде. Бөтен дөнья каршында әкият баһадирдай булып калыккан рус халкы хәзер яңадан коллыкка дучар ителде!

Александр дәшмәде. Уйга калды. Сул кашының әледән-әле тартылып куюы аның гаять киеренке хәлдә булуын әйтеп тора иде.

— Син Жуковский шигырьләренең артык нечкәлеге турында әйттең миңа,— диде ул, байтак уйланып торганнан ары телгә килеп.— Үзара гына әйткәндә, Соловецки монастырена сөргенгә җибәрелүдән мине ул, Жуковский, коткарып калды бит! Һәм шул чакта патша каршында үзен чын ирләрчә тотты. Менә шулай!

— Әйе, Александр, мин ул турыда бераз ишеткән идем,— диде Пущин.— Ләкин мин ул хакта синең үз авызыңнан ишетергә телим.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның! — диде Александр, көрсенеп.— Барысы да минем Аракчеевка һәм Александр патшага язган эпиграммаларым аркасында булды. Аннары «Ирек» одасы... Шулар өчен мине көньякка сөрделәр.

— Анысын яхшы хәтерлим,— диде Пущин, җанланып китеп.— Егерменче елның маенда булса кирәк, без Дельвиг белән синең янга Фонтанкага килгән идек. Син, өстеңә кызыл күлмәк, башыңа эшләпә киеп, коляскада утыра идең. Кузлада ат тоты͏͏п, илчың Никита да утыра иде.

Шунда без саубуллаштык. Хәтерендәме, мин сиңа: «Менә синең беренче сөргенең, Саша»,— дидем. Ә Дельвиг куркып китте һәм ачуланып: «Нәрсә сөйлисең син? Авызыннан җил алсын!» — диде. Мин аңа: «Сөрген шагыйрь кешегә файдалы ул. Һәм гомумән... күңел җәрәхәтләре файдалы!» дигән идем. Хәтерендәме, Саша?

— Син дөрес әйткәнсең, Иван... Екатеринославта авырып киттем мин ул чакта. Начар гына өйдә, бернинди ярдәмсез бер үзем яттым... Кинәт, син бүген көтмәгәндә килеп кергән кебек, яныма генерал Раевский килеп керде. Семьясы белән Екатеринослав аша Кавказга үтеп барышы икән. Раевский генерал Инзовтан мине үзләре белән алып китәргә рөхсәт алды. Һәм без, Раевскийлар белән бергә, Феодосиягә бардык, аннары, хәрби корабка утырып, Гурзуфка киттек.

Пущин Александрның йөзенә карады: «Ябыккан, агарынып калган... Үзен дә, безне дә юаткан була булуын, әмма авыр аңа, ай-һай авыр...»

— Без юлда шулай йөргән арада,— дип дәвам итте Александр,— мин барырга тиешле сөргенчеләр идарәсе Бессарабиягә күчеп киткән иде һәм мин шунда юл тоттым. Чегәннәр таборы белән бергә күченеп йөрдем. Искиткеч кызык халык алар! Сүз уңаеннан әйтүем, мин әле яңа гына «Чегәннәр» исемле поэма язып бетердем.

— Сөрген шагыйрь өчен файдалы дип әйттем бит мин сиңа! — диде Пущин, көлеп җибәреп.— Укы әле, Александр, поэмаңны!

— Ашыкма. Кишиневта мин полковник Пестель белән таныштым. Чын мәгънәсендә әйбәт кеше ул. Соңыннан мин аның яшерен оешмада торганлыгын белдем. Аны миңа бер майор — Владимир Федосеевич Раевский әйтте. Моннан ике ел элек Пестельне кулга алганнар һәм Тирасполь крепостена озатканнар,— диде Александр. Аннары, тавышын акрынайта төшеп, дәвам итте: — Ул чакта мин генерал Инзовта хезмәт итә идем. Пестельнең кулга алыначагын аннан ишеттем һәм кулга алынуыннан ике сәгать элек тиз генә үзенә хәбәр иттердем. Раевский шул арада яшерен документларын юкка чыгарып өлгергән.

— Димәк, син яшерен җәмгыятьнең бер членын коткарып калу өчен бик әйбәт эш эшләгәнсең,— диде Пущин, шактый дулкынланып.

— Әйт әле, Иван: нигә алар мине үз җәмгыятьләренә кабул итмәделәр икән, ә? Әйт әле, минем өчен бик мөһим моны белү.

Пущин, гасабиланып, аның күзләренә карады да:

— Шуны да аңламыйсыңмыни? Алар сине саклау өчен шулай итәләр бит! — диде.

— Саклыйлар! Нинди коточкыч, кешелексез сүз!

— Син Россиягә кирәк. Син... ярар, әллә нинди ямьсез сүз әйттерерсең... Син... бөек шагыйрь бит, Александр!

— Бөек, бөек! Саклыйлар, саклыйлар! Шагыйрь өчен иң куркыныч сүзләр лабаса бу! Шуны аңла, Иван: бу сүзләре белән алар минем бөтен хисләремне, горурлыгымны, ахыр чиктә, күңел пакьлыгын кимсетәләр бит! Ни кирәк соң аларга? Ирек одалары, тираннарга каршы эпиграммалар язуым һәм шуларны язган өчен үземә бернинди дә куркыныч, зыян булмаячагын белеп торуыммы?

Пущин беркайчан да Александрның болай ачуланганын һәм борчылганын күргәне юк иде әле. Шунлыктан ул аны кызганып куйды.

— Артык хафаланма, Александр,— диде ул.— Самодержавие болай да әзәрлекли бит инде.

Александрны Кишиневтан Одессага якынрак күчертү өчен, Пущин бик нык тырышкан иде. Инде менә Александрны аннан тагын монда күчергәннәр икән.

— Әйт әле, граф Воронцов белән нәрсә килеп чыкты сезнең арада? — диде ул, Александрны яңа урынга күчерүләренең сәбәбен беләсе килеп.

— Берни дә булмады... Ул миңа коллеж секретаре дип кенә карады, ә мин, дөресен генә әйткәндә, үзем турында башкачарак уйлыйм. Әле узган җәйдә генә, башка чиновниклар белән бергә, граф мине саранча зарар китергән уездларны тикшереп кайтырга җибәрде. Шулай итеп, ул мине кимсетергә теләгән иде. Нишләмәк кирәк? Барып кайттым. Ләкин кайткан көнне үк, отставка сорап, гариза яздым.

— Шуннан?

— Шуннанмы? — Александрның күзләре янә ачудан зәңгәрләнеп китте.— Граф Воронцов минем турыда патшага нәрсә әйткәндер, анысы миңа мәгълүм түгел. Әмма бер айдан соң чит ил эшләре министры граф Воронцовка патшаның «коллеж секретаре Пушкинны хезмәттән бөтенләй азат итәргә һәм Псков губернасына озатып, җирле начальниклар күзәтүенә тапшырырга» әмер бирүен хәбәр итте. Әйе! Аннары, туп-туры билгеләнгән урынга барырга, юлда беркайда да тукталып тормаска дип, миңа кул куйдырттылар.

— Менә монысы шәп, Александр! — диде Пущин, рәхәтләнеп көлеп җибәреп.— Димәк, тираннар синнән курка алайса! Язмышыңнан юкка зарланасың син!

— Туктале,— диде Пушкин, кинәт житдиләнеп.— Син, якын дустым, нигә бер дә үзең турында сөйләмисең соң әле? Әллә лицейда җырлаган саубуллашу җырын оныттың дамы инде?

Александр шундук җырлап җибәрде:

> — Ватан күкрәп өнди безне алга:
> Кузгалыгыз, уллар, атлагыз!

Аннары Иван Васильевич та аңа кушылып җырлый башлады:

> — Без ант иттек: барысы туган илгә,
> Барысы аңа — хезмәт, каныбыз.
> Без сугышка әзер, тәвәккәлле,
> Хак хөкемгә туры барырбыз.

Пушкин бик нык дулкынланып өстәл янына килеп утырды да үз бокалына шәраб салып, йотылып эчеп куйды.

— Я, нигә дәшмисең, Иван?

Пущин беркавым икеләнеп торды да, кинәт башын күтәреп, пышылдап кына:

— Яшерен оешма члены мин, Александр,— диде.

Икесе дә бераз вакыт тып-тын утырдылар. Александр дустына сокланып, хәйран калып карап торды.

— Иван! — диде ул аннары, калтыранган тавыш белән.— Мине дә шул оешмага алдырырга тырыш әле! Дус итсәң, эшлә әле шуны!

— Мин берни дә эшләмәячәкмен!

Пущин моны шундый каты һәм кискен итеп әйтте ки, Александр бер мәлгә тәмам аптырап калды. Бары шуннан соң гына, ниһаять, телгә килеп:

— Нигә алай? — дип сорады.

— Ник икәнен әйттем бит инде.

— Миңа ышанмыйсыңмы? Тегеләр — көньяктагылар да ышанмады...

— Ышанам,— диде Пущин, шактый уйланып торганнан соң.— Ләкин мин сиңа инде әйткәннән артыгын әйтә алмыйм, Александр... Восстание башланырга... бик аз вакыт калып бара...

Александрга куркыныч булып китте. Төньякта да, көньякта да хәтәр, тәвәккәл эшкә әзерләнүче кешеләр өчен курыкты ул... «Восстаниегә бик аз вакыт калган... Бик аз вакыт!.. Мин аңлыйм, Иван миңа шуннан артыгын әйтә алмый. Бик аз вакыт! Тиздән!.. Ярабби, алар бик күп бит, серне ничек саклый алырлар икән? Әгәр аларны берәрсе сатса?.. Әгәр үз араларыннан... берәрсе сатса!..»

Александр тиз генә урыныннан купты да, Иван янына килеп, аның иненнән тотты һәм дустының йөрәк тибешен тойды. Үзенең дә йөрәге ярсып тибә башлады.

— Бир кулыңны! — диде Иван, пышылдап кына.

Шактый вакыт кул кысышып тордылар. Аннары Иван:

— Ә хәзер саубуллашу җырын, лицей җырын җырлыйк! — диде һәм алар икесе дә, тиздән аерылышачакларын күз алларына китереп, моңланып, дулкынланып, акрын гына җыр башладылар.

Пушкин үзе җырлый, ә үзе бөтенләй башка нәрсә турында уйлый иде: «Башкача мөмкин түгел микәнни соң? Россияне яңартыр өчен шулай ук кан түгәргә, газап чигәргә кирәк булыр микәнни? Хәер, мин үзем дә шигырьләремдә шулай дип язган идем бит:

Монарх хәрабәсе ташларына
Язылырлар безнең исемнәр.

Ә җыр әле һаман дәвам итә иде:

— Саубуллашыйк, дуслар, куллар кысып,
Кочаклашыйк соңгы тапкыр бер.
Мәңгелеккә безне аерырга,
Бәлки язмыш шулай язгандыр.

Моннан соң аларга очрашу насыйп булмады...

## 2

Князь Вяземскийдан кечкенә генә хат килде: «Петербургта коточкыч хәл булды. Яшерен оешма членнары Сенат мәйданына үзләренең полкларын алып чыктылар. Баш күтәрүчеләрнең колоннасы артиллерия уты белән таратылды. Кулга алынган кешеләр арасында синең лицейдагы дусларың Пущин һәм Кюхельбекер да бар...»

Шушы хатны укыгач, Александр дивандагы мендәргә капланды. Артык нык хисләнүдән күңеле тулган, күзләре яшьләнгән һәм сулышы кысылган иде аның. Ул тәмам аптырап калды. Шулай итеп, барысы да бетте микәнни соң? Барысы да җимерелде, тапталды һәм таш капчыкка тутырылды микәнни? Россия йоклый. Ялкынлы шигырьләр дә, Сенат мәйданында шартлаган туп авазлары да уята алмады аны... Россия йоклый. Шулай мәңгегә богауланган микәнни соң ул? Ул богауларны халык беркайчан да өзеп ташлый алмасмыни?..

Арина Родионовна да авырып китте ичмаса. Әнә ул башын сөлге белән бәйләп куйган да сыкранып ята. Битләре күгәреп чыккан, иреннәре зәңгәрләнгән.

Александр Михайловское авылының аргы башында яшәүче табипны алып килде. Табип авыруны караганда, ул ишек төбендә тыңлап торды. Карчык буылып-буылып йөткерә иде. «Иван белән минем өчен борчылып йөргән иде, бичара,— дип уйлады Пушкин.— Безгә толып алып чыккан иде. Ә үзе өстенә киярга оныткан. Шунда салкын тигәндер, мөгаен... Ичмаса, мин дә тиз генә күреп ала белмәдем. Һаман үземне аның янында сабый бала шикелле хис итәм әле. Сакларга кирәк иде аны, әйе, сакларга кирәк иде! Ялгыз чакларымда минем үз әнием кебек иде бит ул...»

Бик озак уйланганнан соң, шул ук көннен кичендә Александр үзен сөргеннән азат итүләрен үтенеп, яңа патшага — Николай Беренчегә прошение язды. Ул көндез диванда аптырап ятканда да Степан Разин турындагы җыр турында уйлаган иде. Менә хәзер, прошение язып утырганда да, шул җыр исенә төште:

Әй, син, рус елгасы Волга,
Әй, туган анам минем.

Идел... Гаҗәп, исеме җырларга кергән, даны еракларга таралган шул мәһабәт елганы Александрның әле һаман күргәне юк. Тагын аның күз алдына Идел өстендә йөзеп йөрүче Степан Разин каеклары килеп басты. «Ярабби, рус тарихының иң әйбәт шигъри сәхифәсе ләбаса бу Степан Разин! Менә кем турында язарга кирәк иде миңа! Әйе, мин Иделне күрергә тиешмен. Үз күзләрем белән аның дулкыннарын күрсәм, сулышын тыңласам, бик күп нәрсәне аңлый алыр идем бит...»

Әнә шул турыда уйлый-уйлый, Александр патшадан үзенә җавап көтә башлады. Шул ук вакытта шигырьләр дә язды. Бик күп язды ул. «Евгений Онегин»ның байтак бүлекләре, «Борис Годунов» трагедиясе шунда, Михайловскоеда, туды. Заман хәлләренә ишарә ясаган урыннар бик күп иде аның ул әсәрләрендә. Крепостное право да, патша баш-баштаклыгы да, халыкның изелүгә каршы ризасызлыгы да чагылдырылган иде аларда. Зур вакыйгалар белән халык җитәкчелек иткәнне рус әдәбиятында моңарчы беркем дә сурәтләп күрсәткәне юк иде әле. Аны Александр сурәтләде һәм аңлы рәвештә сурәтләде!

Ул чорда Александр халыктан аерылып бер үзе яшәргә мәҗбүр иде. Көндез атка атланып йөрүдән һәм кичләрен Арина Родионовнаның әкиятләрен тыңлаудан башка бернинди юанычы да, күңел ачар урыны да юк иде. Бары тик бәйрәм һәм ярминкә көннәрендә генә өстенә кып-кызыл күлмәк киеп, билен каеш белән буып, атка атланып Изге тау дигән тауга баргалый иде ул. Анда крестьяннар белән сөйләшеп, халык җырларын язып алып кайта торган иде.

Кайчакларда Тригорскида яшәүче Осиповалар семьясына да кагылып чыккалый иде. Бервакыт ул шунда Анна Петровна Кернны очратты. Очратты һәм, дөньясын онытып, аңа гашыйк булды. Башка вакыттагыдан йөз мәртәбә хисләнеп, әсәрләнеп, очынып йөрде. «Я помню чудное мгновенье» дип башланып китә торган шигырь нәкъ әнә шул көннәрдә язылды да инде.

Көннәр үтте дә үтте. Ләкин патшадан җавап юк иде әле. Хәбәр генә түгел, тагын бер нәрсәне көтте Александр. Төннәрен, этләр өреп тынлыкны бозган вакытларда, колакларын торгызып, кыңгырау тавышы килмәсме дип өметләнеп ята иде ул. Нигәдер нәкъ менә шулай төнлә килеп алып китәрләр төсле тоела иде аңа: «Ирек», «Хәнҗәр» исемле шигырьләре, эпиграммалары бик усал язылган һәм турыдан-туры баш күтәрергә чакырып язылган иде бит. Александр моның шулай икәнлеген бик яхшы белә. Ләкин, гаҗәп хәл, бер дә курыкмый иде ул. Алай гына да түгел, әгәр килеп кулга алып китсәләр, нигәдер тираннардан үче алынган кебек хис итәр шикелле төсле иде аңа. Азатлык тантана итәр сыман була иде.

Шуларны уйлап яткан вакытларында аның күңеленә тагын шигъри юллар килә:

> Ин беренче дустым, якын дустым!
> Язмышымнан мин бик, бик риза...

Аннары каршына Пущин килеп баскан сыман була. Александрның тагын кәефе кырыла, тагын күңеле өшеп китә...

Көтә торгач, ниһаять, тәки кыңгырау тавышын ишетте ул. Нәкъ ул көткәнчә булды: такыр башлы симез жандарм ротмистры төн уртасында шпораларын чылтыратып килеп керде дә, бик күңелле хәбәр китергән кешедәй канәгатьлелек белән:

— Рәхим итеп, минем белән Псковка, губернатор янына барырга кирәк булыр, Пушкин әфәнде,— диде.

Көз башы иде. Яңгыры булмаса да, җиле куәтле. Нарат урманының шаулавы ерактан ук ишетелеп тора иде.

Авыруыннан әле һаман терелеп житә алмаган Арина Родионовна, мәсьәләне аңлап алгач, тәмам коелып төште. Куркып, калтыранып, нишләргә дә белмичә ай-вай килеп йөргәндә, Сенат мәйданында булган вакыйгалар алдыннан гына Антон Антонович Дельвиг бүләк итеп калдырып киткән кыйммәтле вазаны ялгыш төшереп ватты.

— Аптырама, Арина Родионовна, бәхеткә ватылды ул! — диде Александр һәм күзләрен, гадәтенчә, хәйләкәр-серле итеп кысып, елмаеп куйды.

Кинәт шул чак Арина Родионовна Александрның кечкенә чагын күз алдына китерде. Бала чагында кайвакыт Александр кирәгеннән артык шаяра башлый да, шуның өчен әнисе аны нык кына орышып ала торган иде. Әнә шундый вакытларда нянясы Арина Родионовнаның борчылып торуын күргәч, Александр күзләрен, нәкъ менә хәзерге шикелле, серле, хәйләкәр итеп кысып куяр иде дә әнисенә күрсәтмичә генә елмаеп җибәрер иде... Инде менә Александрны алып китәргә килгәннәр. Ни тырышса да, түзә алмады Арина Родионовна: елап җибәрде.

— Мин анда озак тормам, тиздән әйләнеп кайтырмын,— диде Александр, карчыкның битләреннән үбеп алды. Битләре суык иде нянянын, бөтен гәүдәсе калтыранып тора иде.

— Азрак тоткарлансам, борчылма,— диде Александр.— Ни булса да, мин сиңа хәбәр итәрмен.

Шул чак Александр өстәлдә яткан хатка күз салды. Баратынскийдан килгән иде ул хат: «Бөтен илләр арасында Петр Беренче Россияне ничек югары дәрәҗәгә күтәргән булса, син дә башка халыклар арасында рус шигъриятен шундый югарылыкка күтәр!» — дип язылган иде ул хатта. «Кара син аны! — дип уйлады Пушкин.— Әллә алар анда барысы да акылдан язган инде...»

Аннары үз алдына елмаеп куйды да жандармга ияреп чыгып китте.

Псковка барып җитеп, губернатор янына кергәндә, сәгать төнге иkенче иде. Губернатор озаклап сөйләшеп тормады:

— Сезне Мәскәүдә көтәләр,— генә диде дә Александрны бер фельдъегерга ияртеп җибәрде.

Ә иртән аны, Кремль сараена алып килеп, туп-туры патшаның үз янына кертеп җибәрделәр.

Озын һәм сылу гәүдәле Николай Беренче, өстенә алтын эполетлы зәңгәр мундирын киеп, юка иреннәренә чак кына елмаю билгесе чыгарып, зур өстәл янында басып тора иде.

— Менә нинди икән ул Пушкин! — диде ул, соры күзләрен кыса төшеп һәм шактый ук гаҗәпләнеп.

Александр аңа җитәргә өч адым чамасы калгач тукталды, баш иеп исәнләште.

— Сезнең турыда бөтен Россия сөйли, сударь! — диде патша, һаман шулай гаҗәпләнгән хәлдә.

— Ә мин аларның сөйләвен генә түгел, бәлки шигырьләремне укуларын теләр идем, галиҗәнап! — диде Пушкин.

— Укыйлар да, билгеле. Шигырьләрегез болай начар түгел сезнең. Тик... вакыт-вакыт бик каты әйтәсез.

Александр бер сүз дә дәшмәде.

— Миңа әйттеләр,— диде Николай, сүзен дәвам итеп.— Асылган кешеләр арасында да, каторгага сөрелгәннәре арасында да... сезнең шигырьләрне яратучылар байтак икән.

Александр тагын дәшмәде. Әйтә башласам күңелемдәгенең барысын да әйтеп ташлармын, ә бу минем каршыда торучы тар карашлы, ләкин чикләнмәгән властька ия булган кешегә сөйләүдән барыбер мәгънә юк дип, авырлык белән булса да, үзен тыеп торды.

— Әгәр 14 декабрьда Сез Сенат мәйданында булган булсагыз — нишләр идегез? — диде Николай, текәлеп карап.

Александр сискәнеп китте һәм шундук җавап бирде:

— Дусларым белән бергә булыр идем!

Бу юлы Николай сүзсез калды һәм тагын Пушкинга текәлеп карап тора башлады. Шагыйрьнең африкалыларныкыча калын иреннәре аңа нык һәм кискен кыяфәт биреп тора. Кара-коңгырт күзләрендә үкенү дә, ялагайланырга тырышу да сизелми иде.

14 декабрь восстаниесеннән соң үткәрелгән тикшерү материаллары буенча Николай Пушкин шигырьләренең нинди революцион көчкә ия булганлыгын бик яхшы белә иде. Җандармнар башлыгы Бенкендорфның: «Галиҗәнапләре! Әгәр Пушкинның каләмен һәм сөйләгән сүзләрен үзебезнең якка борырга мөмкин булса — бик зур файда булыр иде!» дигән сүзләре әле дә колагында тора иде аның.

— Мин сезне, ихтимал, үзегезне үзегез белгәннән дә яхшырак беләмдер,— диде Николай, яңадан дустанә тонга күчеп.— Шагыйрь хисләр дөньясында яши ул. Ә кешелек дөньясы башкачарак төзелгән. Мин Сезгә озаклап акыл өйрәтергә теләмим, шагыйрьләр аны яратмыйлар...— Император кинәт үзенә хас булмаганча ягымлы итеп елмаеп куйды да дәвам итте.— Җәзаланып үтерелгән кешеләрнең барысы да... сезнең шигырьләрнең тәэсире турында әйткән. «Пушкинны укыгыз. Безнең ни эшләргә тырышканлыгыбызны шуннан соң аңларсыз!» дигәннәр. Алар сезне сатканнар, сударь!

Александрның сул кашы тартышып куйды.

— Алар бөтенләй башка нәрсәне күздә тотканнар, галиҗәнап,— диде ул.— Минем шигырьләрдә сурәтләнгән кешелек горурлыгы турында сүз алып барган алар.

— Сез хәтта мәетләрне дә фаш итәргә теләмисез,— дип мыгырданды патша.— Аңлашыла: алар сезне тикмәгә генә аллаларыдай якын итмәгәннәр икән. Ярый, бу турыда җитеп торсын! — Николайның горурлык тулы соры күзләре ялтырап китте.— Мин беркемнең дә сүзен тыңламадым. Сез рус тарихын өйрәнәсез һәм Петербургка нигез салган Петр патша шәхсе белән кызыксынасыз икән. Бик күңелле хәл бу! Рус шагыйре нәкъ менә шул юлдан барырга тиеш тә!

«Бу кеше мин уйлаганча ук гади, беркатлы түгел икән»,— дип, гаҗәпсенеп уйлап алды Александр һәм патша тагын нәрсә әйтер икән дип көтеп торды.

— Яңадан хезмәткә керсәгез ничегрәк булыр икән? — диде патша.— Ләкин чиновник булып түгел. Мин аңлыйм, сез чиновниклыкны бик үк өнәп бетермисез... Мин сезгә Рус дәүләте тарихын өйрәнү эшенә керешергә тәкъдим итмәкче булам.

«Нәрсә бу? Үзе сизенгәнме, моны әллә аңа Бенкендорф әйтте микән?» — дип уйлады Александр. Ул, чыннан да, Петр Беренче һәм Пугачев тарихларын өйрәнергә хыялланып йөри иде. Петр Беренче тормышын өйрәнү аша самодержавие шартларында реформа ясау мөмкинлеген ачыкларга, ә Пугачев тормышын өйрәнеп, крестьян восстаниеләренең серенә төшенергә, «бишмәтле патша» Пугачевның шәхесен тирәнтенрәк аңларга тели иде. Инде менә патша үзе шуна өндәп тора. Димәк, дәүләт архивларына юл ачык булачак.

Патша Александрдан җавап көтеп тора иде. «Барлык уйлары йөзенә чыга икән бу кешенең,— дип уйлады Александр.— Бигрәк беркатлы икән. Ә мин акыллырактыр дип уйлаган идем».

— Мин риза, галиҗәнап! — диде Александр.

— Алайса, булды! — диде Николай.— Бүгеннән башлап, мин үзем сезнең цензорыгыз булачакмын...

## 3

Кичен Александр Наталия Николаевна Гончарова белән Мариински театрына килде. Килеп керү белән, театрга җыелган халык, сокланып һәм гаҗәпләнеп, аларны күзәтә, үзара пышылдаша башлады. Александр башта бу кызыксыну Наталиянең матурлыгына, зифалыгына исләре китүдән дип уйлаган иде. Әмма сонрак барысы да аның үз исемен әйтүләрен һәм барысының да бинокльләре аның үзенә төбәлүен абайлап алды. Тәнәфескә чыккач та аны танышлары һәм таныш түгел кешеләр сырып алды. Залның һәр тарафында:

— Пушкин! Пушкин! — дигән авазлар ишетелә иде.

Халыкның үзен шушылай хөрмәт итүен күреп тору рәхәт иде аңар. Димәк, йокысыз төннәре заяга үтмәгән. Ләкин шул ук вакытта үзенә төбәлгән карашларны тоеп тору ничектер уңайсыз да иде аңа. «Әйтерсең, күктән төшкән, тапканнар шаккатарлык нәрсә!» — дип ачуланып куйды ул.

Аның каравы Наталия Николаевнаның куанычы йөзенә чыккан иде. Бөтен халыкның күңелен җәлеп иткән Пушкин янында ул тагын да купшырак, чибәррәк булып күренә һәм шул чибәрлеген үзе дә сизеп, һавалы гына атлап, аккош сыман, үз дәрәҗәсен бик белеп кенә йөри иде.

Икенче тапкыр тәнәфескә чыккач, Александр аңа:

— Әйдә, киттек моннан, Наталия,— диде.— Бер кеше бик текәлеп караса да көйдерергә мөмкин диләр, ә безгә йөзләрчә караш текәлгән. Янам мин!..

Алар, юртак атка утырып, Невский урамы буйлап кайтып киттеләр. Яшь кызлар көлүенә охшап чылтырап барган кыңгырау тавышы, кечкә саф һава, Наталиянең чәчләреннән аңкып торган тәмле хушбуй исенә кушылып, Александрның күңелен әллә ничек авырайтып, борчып бара башлады.

— Син бүген нигәдер бик күңелсез, Александр,— диде Наталия һәм алсу иреннәрен кыйшайтып елмайгандай итте.

— Мин бик арыдым, Наталия,— диде Александр.

Ул Наталияне бик соң гына өйләренә илтеп куйды. Аннары аның иреннәрен суырып үпте. Наталия дә аңа шундый ук дәртле һәм онытылып үбү белән җавап бирде. Александрның хәтта рәхәтлектән башлары әйләнеп китте һәм шушындый зур мәхәббәткә юлыктырган язмышына куанып бетә алмады.

Өйгә кайткач, төн инде авышып баруга да карамастан, Александрның йокысы килмәде һәм ул Васильев утравына, эчемлекләр сатыла торган йортка китте. Ул үзен бик бәхетле хис итә һәм бер танышы белән дә очрашырга теләми иде.

Кабакның тар һәм караңгы залында шешәләр һәм төрле савыт-сабалар белән тулып торган өстәлләр артында берничә кеше — киемнәренә караганда һөнәрчеләр яки мещаннар булырга тиеш — бик рәхәтләнеп, сәрхүш баштан гәп сатып утыралар иде.

Александр бер почмакка, стена буендагы өстәл артына, килеп утырды.

Инде шактый картаеп барса да, яшьләрчә житез булып кыланырга тырышып йөрүче ябык кына официант, тавышына мыскыллау билгесе чыгарып:

— Нәрсә телисез, әфәнде? — дип сорады.

— Кавказ виносы һәм колбаса белән кыздырылган йомырка тәбәсе,— диде Александр.

— Бик рәхәтләнеп! — диде официант һәм ялагай эт шикелле юыртып, буфет ягына китте.

«Бигрәк әшәке инде бу дөнья,— дип уйлады Александр.— Бөтен гадел, саф күңелле кешеләр кыен хәлдә кайгы-хәсрәт эчендә яшәгәндә, иптәшләрем каторгага озатылган һәм дарга асылган вакытта, шул гомуми язмыштан читтә калуыма үч иткәндәй, бүгенге бәхетнең килүен әйт әле син!..» Шул уй башыннан үткәч, Наталиянең матурлыгы да ничектер тоныкланып калгандай булды. Александрның күз алдына полковник Пестель килеп басты. Ул искиткеч яхшы кешенең язмышы бигрәк кызганыч булды шул!

Алар беренче тапкыр Кишиневта таныштылар. Александр бер кофеханәгә килеп кергәндә, анда берничә офицер утыра һәм алар, артык тавышланмыйча гына, үзара бәхәсләшәләр иде. Ул да шулар янәшәсендәге өстәл артына барып утырды. Офицерлар сүзләрен дәвам итсәләр дә, еш кына Александрга карап-карап ала башладылар. Аннары шуларның берсе, уртача буйлы, кырысрак кыяфәтлесе, кинәт урыныннан торды да, Александр каршына килеп басты:

— Александр Сергеевич! Пушкин!

Шагыйрь, баш иеп, үзенең чыннан да Пушкин икәнлеген раслагач, офицер:

— Полковник Пестель! — дип үзенең дә исемен атады.

— Бик шатмын,— диде Александр.— Әйдә, утырыгыз. Көнчыгыш яшерен оешма членнарыннан мин Сезнең хакта бик күп ишеткәнем бар.

Пестель күңелсез генә елмаеп куйды:

— Алай дусларга һәм танышларга сөйләп йөргәч нинди яшерен була ди инде ул! Үпкәли күрмәгез, зинһар. Сезгә ышанырга була!

— Ә нигә алай дип әйтәсез әле сез?

— Начар кеше яхшы шагыйрь була алмый. Шулай ук яхшы шагыйрь дә начар кеше була алмый! — диде Пестель һәм аның кырыс, трагик йөзенә елмаю билгесе чыкты.— Аннары сезнең шигырьләрдә без туган илнең чакыруын, теләген тоябыз. Бу сезнең үз сүзләрегез. Гафу итегез, шуннан да әйбәтрәк итеп әйтә алмадым.

Алар ул чакта шактый озак сөйләшеп утырдылар. Аерылышканда, Пестель:

— Мин беләм, сез монда сөргендә,— диде.

— Сезгә кем әйтте моны?

— Ватан сугышы герое генерал Раевский. Хафаланмагыз, Александр Сергеевич. Тиздән дөньялар үзгәрәчәк.

Ә өч ел үткәч, полковник Пестельне Петропавел крепостенда асып үтергәннәр. Аның белән бергә Рылеев, Каховский, Муравьев-Апостол һәм Бестужев-Рюминнарны да асканнар...

Александрның күз алдына асылган биш гәүдә килеп басты. Һәм шул гәүдәләр биш зур кыңгырауга әйләнеп, көн-төн тавыш биреп, халыкны чакырып торалар төсле тоела башлады.

— Дон! Дон! Дон! Дон!

Ул көннәрдә шигырь язарга утырган вакытларында да ул башта кәгазьгә дарга асылган биш кеше гәүдәсе ясый торган булды. Ә колагында һаман «дон», «дон» дигән аваз яңгырап тора иде. Ул каләмен ташлап, диванга барып авып, колакларын мендәр белән каплап та карады. Әмма кыңгырау тавышларыннан барыбер котыла алмады!..

Кинәт кабакта гадәттәгедән ныграк шаулашырга тотындылар һәм Александрның уйлары шунда бүленеп калды. Күрше өстәл артына утырган калын тавышлы, чалара башлаган мыеклы бер кеше иптәшләренә кызып-кызып нидер сөйли иде. Александр да аның сүзләренә колак салды:

— Безнең гвардия полкы дингездән кайтып килә иде. Барыбыз да шатлыктан исерек. Шулай булмый хәле дә юк! Җиңеп кайтып киләбез

бит. Наполеон һәм башка шундый сугыш чукмарлары чакырылмый килгән кунакларны Россиядә ничек кунак иткәнлекне тиз генә онытa алмаслар дип уйлыйм! Ярый, Ориенбаумга кайтып җиткәч, кораблардан төшә башладык. Ә ярдагы халыкны күрсәң! Кара болыт шикелле! Һәм менә бервакыт полиция шул халыкны куарга, кыйнарга тотынды. Гаскәрләр янына җибәрмәскә тырышалар. Нинди тамаша икән бу? Үз җиребездә нигә үзебезнең халыкны кимсетәләр икән, дип гаҗәпләндек без. Ник котырасыз дип кычкырасы бик килә, әмма... куркыныч...

«Куркыныч... коллар, коллар!» дип уйлады шунда Пушкин. Аннары «Чегәннәр» поэмасындагы шигъри юллар исенә төште:

Сөю оят, уйлау гөнаһ анда,
Ирек белән сәүдә итәләр,
Акча белән богау сорап бары да
Санәмләргә[1] сәҗдә итәләр...

Шул чак өстәл артында утыручыларның берсе:

— Тукта, Федор! — дип, сөйләүченең сүзен бүлде.

Барысы да Александрга шикле караш ташладылар. Аңа ничектер кыен булып китте. Ул тиз генә урыныннан торды да кабактан чыкты. «Менә ничек, Александр,— дип уйлады ул.— Алар синнән курка. Алар сине чит күрә, ышанычсыз дип саный...»

Ул, йөгереп дип әйтерлек, кайтыр якка ашыкты. Ә күз алдында асылган биш гәүдә, колагында биш чаң авазы яңгырый иде:

— Доң! Доң! Доң! Доң!

## 4

«Гомерем буе тынычлыкка, ялгызлыкка омтылам, әмма — юк, һич тә иркенләп яшәргә мөмкин түгел, шайтан алгыры! Әле бал, әле маскарад, әле әдәби кичәләр... Алары да кирәк, билгеле, тик болай ук еш ярамый лабаса! Шагыйрь кеше тормыш шау-шуын да күрергә тиеш, әмма, үз чиратында, шау-шу аңа зыян да итә...»

Пушкин әнә шул рәвешле борчылып, үз бүлмәсендә арлы-бирле йөри. Ә күрше бүлмәдә Наталия Николаевна акрын гына ыңгырашып ята. Ул бүген икенче баласын көтә...

Александр аяк очларына гына басып, ябылып җитмичә калган ишектән башын тыкты да хатынына күз салды. Иртәнге әңгердән зәңгәрсу төсле күренгән мендәр өстендә Наталиянең озын кара чәчләре тузгып ята, ә йөзе ап-ак булып калган иде. Александрның тыннары кысылып китте. Шундый кыен хәлдә ятканда да искиткеч матур иде аның Наталиясе! Шунда Александрның күңеленә бер шигъри юл килде. «Гүзәлләрнең гүзәл үрнәге».

— Кер әле монда, Саша! — диде хатыны.

Ул, кереп, Наталиянең юрган өстендә яткан кулына яңагын тидерде.

— Син күреп дәштеңме миңа, әллә күңелең белән сизеп кенәме? — диде Александр.

— Мин куркам,— диде хатыны, аның соравына игътибар итмичә.— Мин Машенька белән йөкле чакта: «Әгәр алла коткарып, бу юлы исәнсау котылсам, бүтән бала тапмыйм инде», дигән идем... Әмма сүземдә тора алмадым...

Ул елап җибәрде.

— Наталия, гүзәлем минем! Борчылма, барысы да әйбәт кенә булыр. Нәни Пушкин авазын ишеткәч, үзең дә көлеп җибәрерсең әле!

— Ой! — дип кычкырып җибәрде Наталия.— Акушерканы чакыр тизрәк. Ә үзең монда кермә!

---

[1] Санәм — пот, алла образы.

Александр тиз генә акушерканы дәште дә, үз бүлмәсенә кереп, тизрәк шушы мәшәкатьле, әмма барыбер матур дөньяга килергә тиешле баласының тавышын түземсезлек белән көтә башлады...

Хатыны малай табып, ул малайга Александр исеме кушканнан соң берәр атна вакыт үткәч, Пушкин Бенкендорфка прошение язды: «Котылгысыз рәвештә килеп чыккан хәлләр аркасында, мин ике-өч айга Нижегородтагы биләмәмә китәргә мәҗбүрмен. Шул уңайдан мин моңарчы үземә таныш булмаган Оренбург һәм Казан шәһәрләренә дә кагылырга теләр идем. Галиҗәнапләрегездән шул ике губерна архивлары белән танышырга рөхсәт итүне үтенәм».

Шушы прошениене тапшырганнан соң Александр җавап көтә башлады. Үзара очрашкан вакытларында Бенкендорф иренен кысып, читкә карап үтеп китә иде. Бер очрашканда, әллә нигә болай узуының сәбәбен сорашып карыймы микән, дип тә уйлаган иде ул. Ләкин шундук: «Юк, өченче отделение начальнигы белән шаярырга ярамый! Түзәргә, көтәргә кирәк»,— дип, ул фикереннән кире кайтты.

Күңеле тыныч булмагач, юньләп эшли дә алмады Александр. Әйбәт кенә фикерләре дә бар кебек, әмма каләм алып, өстәл янына утыруга, бөтен уйлары, киртәгә кунган чыпчыклар сыман, таркала да китә... Кечкенә Александр да шактый елак булып чыкты. Бигрәк төннәрен тынгысызлана. Наталиясе дә бик борчыла. Битләре озынчаланып калды инде, күз төпләре күгәреп чыкты. Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Кешеләр дөньяга барысы да бер төрле киләләр, ә киткәндә һәркайсы үзенчә китә. Бик гаҗәеп һәм уйландыра торган хәл бу. Тормыш дип атала торган дөнья бакчасында син нәрсә калдырып китәсең? Җимешле агачмы, әллә коры тигәнәк кенәме? Менә шул хакта уйланырга кирәк!..

Тагын берәр атнадан соң, Александрны Бенкендорф үз янына чакыртып китерде. Бик коры һәм гадәттән тыш тыйнак иде ул. Салынкы аксыл иреннәрендә эчтән тантана итүе сизелеп тора иде.

— Бөек галиҗәнапләре,— диде ул, өстәлендә яткан кәгазьгә карап,— Сезнең Казанга һәм Оренбургка нинди ният белән барырга җыенуыгызны белергә тели. Аннары бөек галиҗәнапләре сезнең ни өчен монда үзегезгә тапшырылган эшләрне ташлап китмәкче булуыгыз белән дә кызыксына.

Шулай диде дә шактый вакыт текәлеп карап торды. Александрның ул караштан ачуы кабарып китте, сул кашы нервланып тартышырга тотынды. Ләкин ул ачуын сиздермәскә булды һәм иплән кенә:

— Аңлатып бирергә рөхсәт итәрсез дип ышанам,— диде.

— Әйе.

— Соңгы ике ел эчендә мин гел тарихи тикшеренүләр өстендә генә эшләп утырдым. Бер генә юл да саф әдәби әйбер язмадым. Шунлыктан, галиҗәнапләре, ул тикшеренүләрдән арынып, ял итү өчен, миңа ике ай гел ялгызым гына яшәргә кирәк. Ә иң мөһиме шул: күптән башланган бер китабымны язып бетерергә телим. Шул китабымны тәмамлап, акча алырга ниятлим. Ә миңа хәзер акча бик кирәк...

— Беттеме? — диде Бенкендорф.

Александр сюртугының изүен каппап куйды. Шул чакта аның йөзек кашы ялтырап китте.

— Бәлки, патша авылда минем нинди китап язып бетерергә җыенуымны белергә телидер. Роман булачак ул. Анда Казанда һәм Оренбургта булган хәлләр сурәтләнәчәк. Менә шуңа күрә әлек шул ике губернага барырга теләгән идем мин.

— Мин галиҗәнапләренә бу хакта әйтермен.

Бенкендорф янынннан Александр бик күңелсезләнеп чыкты. «Юк,— дип уйлады ул,— мин бу кешенең йөзенә дә карый алмыйм, тавышын

ишетәсем дә килми. Ул сөйләгән чакта кемдер башымны бөгеп, жиргә төртергә тырыша төсле тоела...»

Александр тагын җавап көтә башлады. Ни тырышып та, «Капитан кызы» исемле әсәренең кереш сүзен язудан ары китә алмады. Чөнки Петербург архивында шуннан артыгын язарлык материал юк иде. «Юк, болай булмый! Материал житми. Тере кешеләр, Идел, Пугачев заманының һавасы житми. Казанга барсам бик күп мөһим нәрсәләр табылыр иде төсле!» дип көннән-көн ныграк борчылды ул.

Ә вакыт һаман үтә торды. Инде көз дә якынлашып килә. Болай булса, андый ерак юлга чыгып киту дә мөмкин булмаячак.

Әнә шулай аптырап йөри торгач, ниһаять, жиденче августта аны тагын Бенкендорф чакыртты.

— Сезгә,— диде ул, Александрның язмышын үзе хәл иткән кешедәй бик канәгать кыяфәт белән,— шатлыклы хәбәр килде. Император галиҗәнапләре, теләгегезне искә алып, дүрт айга Казанга һәм Оренбургка барып кайтырга рөхсәт итте...

Александр шул ук көнне юлга әзерләнергә кереште. Уен түгел бит: биш мең чакрым җир йөрергә тиеш ич ул. Бигрәк озын юл инде. Хәер, зыян юк! Аның каравы борынгы Казанны, мәһабәт Иделне һәм Оренбургны күреп кайтачак!

Унсигезенче августта, ямщикка утырып, Александр Мәскәүгә юл тотты. Ике көн эчендә Валдай һәм Торжок шәһәрләрен артта калдырып, дүрт йөз илле чакрым жир үтте. Әмма шуннан ары юл авырайды — көзге яңгыр коярга тотынды. Колясканы алты ат көч-хәл белән генә сөйрәп бара башладылар. Ә Мәскәүгә житкәндә коляска үзе дә тәмам эштән чыгып, ватылып бетә язды. Аны төзәтергә тагын өч көн вакыт китте.

Бары шуннан соң гына Новгородка юл тотты ул. Әле урак бетмәгән, крестьяннар арыш ура, көлтә бәйли иде. Юлда ап-ак күлмәкле каен урманнары, аланлыкларда көзге чәчәкләр, ашыкмый гына утлап йөрүче сыер-сарыклар күренеп кала һәм шул күренешләргә сокланып, хәйран калып, Александр: «Их, нинди матур син, Россия! Бу жирдә торып та шагыйрь булмыйча мөмкинме соң?» — дип уйланып бара.

Ә атлар юырта да юырта. Новгородны үтеп, йөз егерме чакрым киткәч, Чугуны дигән авылда житди каршылык килеп чыкты. Шул авылда почта атлары белән эш итүче чиновник озак итеп Александрга вәгазь укырга тотынды:

— Почта атлары кешеләрне көз көне сигез, ә кыш көне унике чакрымга гына илтергә тиеш. Бары тик курьерларны һәм фельдшерларны гына мөмкин кадәр тиз һәм үзләре ничә чакрымга теләсәләр — шул чаклы илтергә мөмкин.

— Ә мине дә шулай иттереп булмыймы соң? — диде Александр.

Чиновник Пушкинның шаян күзләренә карап, бераз гаҗәпсенеп торды да, һич тә пошынмыйча, үз сүзен дәвам итте:

— Андый нәрсә бары тик митрополитларга, тайный советникларга һәм башка шундый махсус документлары булган беренче класслы аерым кешеләргә генә рөхсәт ителә, ә икенче класслы кешеләргә һич тә рөхсәт итә алмыйм! — диде ул.

Бу мужик, мөгаен, туганда әйбәт кенә бала булгандыр, дип уйлады Пушкин. Аннары ул үскән, өйләнгән, эшли башлаган һәм ниндидер сәбәпләр аркасында менә шушындый үз сүзле, кире беткән бәндәгә әйләнгән.

Ә чиновник әле һаман сөйләнеп тора иде:

— Архимандритларны, майорларны, коллеж асессорларын һәм башка шундый түбән дәрәҗәдәге кешеләрне хәзер сигез чакрымнан ары берничек тә илттерә алмыйм.

Александр шуннан соң да сүз көрәштерүне кирәк тапмады, чиновник шартына ризалашырга туры килде.

Инде сентябрь — шагыйрьнең иң яраткан ае кергән иде. Чугуны авылындагы чиновник кәефне бик нык бозган булса да, аннан кузгалып киткәч, Александрның күңеле күтәрелде, уйлары ачыкланды. Василькурск станциясенә барып җиткәч, ул хатынына менә шушы хатны язып салды: «Кадерле Наталия! Син ничек яшисең анда? Салкын тиюдән саклан. Хәзер көз бит, ә көз усал ул. Ә мин һаман барам да барам. Юлым кайда тәмамланыр — шайтан белсен. Дүрт айның икесендә эшләп калырлык булса ярый инде. Мин юлга алган китаплар сандыкта селкенеп-ышкылып бара-бара тәмам теткәләнеп бетте инде. Шуңа күрә мин бүген ачулы. Машкага көйсезләнергә һәм нянясы белән сугышырга киңәш итмим: тукмап ташлавым бар үзен. Үзеңне үбәм. Машка белән Сашкага миннән хәер-фатиха».

Василькурск станциясеннән соң Казан губернасы башланды.

## 5

Казандагы Петропавел тыкрыгына урнашкан гостиницада хезмәтче булып эшләүче Мәрьям иртән эшкә килүче хезмәттәшләрен яңа хәбәр белән каршылады:

— Әй, кызлар! — диде ул, кап-кара күзләрен очкынландырып.— Төнлә титуляр советник килеп төште бит әле! Зур күзле, бөтеркә, куе бакенбардлы. Ревизия ясарга килгән дип сөйлиләр. Симез муенлы түрәләргә эләгә инде болай булса!

— Ә ниндирәк нәрсә соң үзе? — дип кызыксынды иптәшләре.— Бик карт кеше түгелме?

— Карт түгел. Утыз-утыз дүртләр тирәсендә генә.

Хезмәткәрләрнең өлкәне, бик рәхәтләнеп көлеп җибәрде дә:

— Ну, кызлар, алайса Казанда хәлләр булачак икән! — диде.

Башкалары да аңа кушылып көлешә башладылар...

Иртәнге сәгать тугызларда, бик нык борчылып, гостиницага полицмейстер килеп керде. Зур чиндагы барлык кешеләр кебек үк, ул бик һавалы һәм җитди итеп:

— Мине титуляр советник янына алып керегез!.. Тизрәк! — дип кычкырды.

Мәрьям, полицмейстерга сиздермичә генә, гаҗәпсенеп, йөзен чытып куйды да:

— Рәхим итегез! — дип аны Александр бүлмәсе янына алып килде һәм акрын гына ишеген шакыды.

— Кем бар анда? — дип сорады бүлмәдәге кеше, шактый кырыс һәм карлыкканрак тавыш белән.

— Сезгә полицмейстер әфәнде килгән иде! — диде Мәрьям.

Беркавым җавап булмыйча торды. Аннары бүлмәдә ниндидер авыр әйбер ауганы ишетелде. Бары шуннан соң гына бүлмә хуҗасы:

— Керегез! — диде.

Полицмейстер кереп китте, ә Мәрьям, ишеккә колагын куеп, тыңлап тора башлады.

— Исәнлек телим! — диде полицмейстер.— Ничек соң, Казанны ошаттыгызмы?

— Беләсезме... мин аны күрергә өлгерә алмадым әле. Төнлә барлык мәчеләр дә соры булып күренә, диләр бит.

— Хах-ха-ха! Бик шәп әйттегез әле сез! Бөтен мәчеләр дә... Шулай да, җөрьәт итеп әйтәм. Казан көндез матур! Идел, чиркәү гөмбәзләре, Кремль һәм тирә-якта ямь-яшел урманнар...

— Шулаймы? Бик рәхәтләнеп карармын мин Казанны.

— Әйтуләренә караганда, сез әле күптән түгел генә патшаны күргән икәнсез.
— Әйе.
— Император галиҗәнапләре Казан өчен берәр төрле яхшылык эшләргә җыенуын әйтмәдеме соң?
— Юк. Бүтән нәрсә хакында бер сүз дә булмады.
— Нинди учреждениеләргә ревизия ясалачагын белергә мөмкин булмасмы? Шаярып кына кызыксынуым түгел бу. Әгәр кирәк булса, мин сезгә яшерен күзәтүчеләрем белә торган барлык мәгълүматлар белән ярдәм итә алам.
— Гафу итегез! Мин ревизор түгел ләбаса! Мин шагыйрь Александр Пушкин мин.
— М-м... бернинди дә зур вәкаләтегез юкмыни?
— Юк.
— Алайса, чын күңелемнән гафу үтенәм!
Шулай диде дә, шпораларын чалтыратып, полицмейстер ишеккә таба килә башлады. Мәрьям тиз генә йөгереп китеп барды.
Полицмейстер чыгып киткәнгә күп тә үтмәде, Александр шактый нык кычкырып, Мәрьямне чакырды.
— Ни эшләдең син, Мәрьям? — диде ул, эче катып көләргә тотынып.— Нинди ревизор ясадың син мине? Әйт әле, синең эшең бит бу, шулаймы?
Мәрьям түгәрәк алма кебек битләрен кызартып, озын керфекле күзләрен челт-челт йомгалап, аптырап һәм сокланып беркавым карап торды да:
— Чынлап та Пушкинмы сез? — диде.— Чыннан да «Руслан һәм Людмила»ны язган Пушкинмы?
— Ха-ха-ха! Әйе, шул үзе инде! Ә полицмейстер минем ревизор түгел икәнлегемне белгәч... ха-ха-ха... шундук җан кереп китте бичарага!.. Тукта, нигә син «Руслан һәм Людмила» турында сорадың әле? Әллә аны укыганың бармы?
— Укымаган кая инде ул! Мин шул китапны укып, русча сөйләшергә өйрәндем. Кимендә мең кат укып чыкканмын инде мин аны. Хәтта күңелдән дә башыннан ахырына тикле укый алам.
Пушкин Мәрьямгә текәлеп һәм гаҗәпләнеп карап торды.
— Яттан сөйли алам диденме?
Мәрьям, күкрәгенә төшеп торган чәч толымнарын ялт итеп аркасына алып салды да, кинәт җитдиләнеп һәм рухланып сөйләргә тотынды.

— Яшел имән диңгез култыгында,
Алтын чылбыр аңа бәйләнгән,
Көне-төне галим песи шунда
Ул чылбырны сөйрәп әйләнә.

Ләкин Александр аңа озаклап сөйләргә ирек бирмәде:
— Булды! — диде ул.— Күрәм, син чыннан да, аны яттан беләсең икән! Шуны укып рус телен өйрәндем дисең алайса? Ә кем киңәше белән эшләдең моны?
— Берәү дә киңәш итмәде. Мин бер усал бай өендә асрау булып торган идем. Шуларда әз-мәз хәреф танырга өйрәндем. Аннары акрынлап «Руслан һәм Людмила»ны укырга керештем.
— Син изге җан икәнсең бит, Марютка!
— Юк ла инде...
Шул чак ишек шакыдылар һәм өстенә кара сюртук, башына эшләпә кигән бер кеше килеп керде.
— Баратынский! — дип куанып кычкырып җибәрде Пушкин.— Евгений!
Мәрьям тиз генә коридорга чыгып китте. Ә Пушкин бүлмәсендә

күрешү, үбешү, кыскасы, дуслар очрашкач була торган күнелле шау-шу, хәл-әхвәл сорашу башланды.

— Беләсеңме,— диде Пушкин, бераз тынычланып сөйләшә башлагач.— Казан полицмейстеры мине ревизор дип уйлаган бит! Әй, кызык та булды соң! Ул чыгып киткәч, эчләрем авыртканчы көлдем. Ә Нижнийда мине губернатор ревизор дип кабул иткән иде. Комедия өчен менә дигән сюжет бит бу! Петербургка кайткач, язучы Гогольгә сөйлим әле мин боларны. Ә Чугуны станицасында анакаебыз Екатерина Александровнаның генералы турында бер кызык хәл ишеткән идем. Фамилиясен Кар диделәр, ахрысы. Менә шул Кар, гаскәрләрен пугачевчылар туздыра башлагач, авыруга сабышып, сугыш кырын ташлап качкан ди. Комедиялек хәл түгелмени бу?

— Сине сау-сәламәт һәм кәефен әйбәт хәлдә очратуыма бик шатмын! — диде Баратынский.— Мин синең өчен бик курыккан идем, Александр! Син Михайловскоега сөрелү белән генә котылгансың икән. Моның өчен язмышка бик зур рәхмәт!

— Юкка куанасың,— диде аңа Пушкин,— 14 декабрьда иптәшләрем белән бер сафта була алмавыма үкенәм мин. Бу хакта патшаның үзенә дә әйттем инде.

— Юктыр ла! — Баратынский куркынып китте. Аннары пышылдап кына сорап куйды:— Ә ул... нәрсә диде?

— Хәлемне аңлады. Хәтта титуляр советник итеп тә билгеләде.

— Шаяртма, Александр!

— Шулай булуга да карамастан... Ә, әйе, онытып торам икән: хатың өчен бик зур рәхмәт, дустым! Әй кызык иткәнсең соң үзең дә: мине Петр Беренче белән тиңләгәнсең!

— Син теләсә нәрсә әйт. Әмма «Руслан белән Людмила»дан соң, «Евгений Онегин»нан соң... Хәер, нигә күп сөйләп торырга инде! Синең сигез юл шигырең дә үзе бер шедевр була бит. Менә тыңла әле...

Шулай диде дә дәртләнеп яттан укый башлады.

Сөйдем сезне: бәлки хәзер инде
Сүнгәндер ул хисләр җанымда.
Кабат тетрәтмәсен сөю сезне,
Мин борчымам сезне тагын да!

Сөйдем сезне бер өметсез көеп,
Тартынып һәм көнләп, асыл яр,
Өзелеп, назлап сөйдем, минем кебек
Сөйсен иде сезне башкалар.

— Беләсеңме, Александр,— диде аннары Баратынский, яшьле күзләрен сөртә-сөртә.— Мине бер хатын яратмый башлады бит. Минем өчен дөньяда иң кадерле кеше иде ул. Кояшым да, күгем дә, йолдызым да шул иде. Һәм менә хәзер ул миннән суынды. Аның янына соңгы мәртәбә баргач, мин аңа синең шушы илаһи шигыреңне укыдым.

— Ә ул нишләде? — диде Пушкин, балаларча кызыксынып.

— Тын да алмыйча тыңлады. Аннары, сихерләнгән кеше сыман, беркавым дәшми торды да: «Кем шигыре бу?» дип сорады. «Пушкинныкы!» дидем. «Ә сезнең аңа ни катнашыгыз бар?» диде ул. «Катнашым шул: Пушкин ул,— мин дә, син дә, барыбыз да!» дидем мин аңа.

— Файдасы тидеме соң сүзләреңнең? — диде Пушкин.

— Юк.

— Хафаланма, Евгений! Минем белән дә андый хәлнең булганы бар. Үтә ул. Андый борчулар җәйге яңгыр төсле генә алар: бер күкрәп, яшенләп аласың да тагын күңелеңдә ялт итеп кояш чыга.

— Юк, минем кояшым чыкмас инде,— диде Баратынский. Авыр уйларын кысып чыгарырга теләгәндәй, куллары белән маңгаен тотып, беркавым сүзсез торды. Аннары:

— Үз тормышын ничек соң? Петербургта ниләр бар? — дип сорады. Александр геләр-теләмәс кенә елмаеп куйды.

— Минем Петербургтагы тормышның һич тә рәте-чираты юк әле. Күңелсезләнергә вакыт тими, мәшәкать күп. Ләкин миңа язучы өчен кирәк булган ирекле тормыш җитми. Югары җәмгыять эчендә тулганам!.. Хатыным бик модада минем.

Баратынский Пушкинның ничектер кайгырып, күңелсезләнеп китүен сизенеп алды.

— Анда йөрү өчен бик күп акча кирәк,— диде Пушкин, сүзен дәвам итеп.— Акчаны мин зур хезмәт куеп кына табам, ә иркенләп эшләр өчен тынычлык, ирек кирәк.

Гостиницаның тәрәзәсеннән шәһәрнең Идел ягындагы куллар, болыннар һәм, су керергә әзерләнгән өч сылу кыздай булып, өч каен күренеп тора иде. Болытлар арасыннан күренгәләп киткән кояш нурларыннан Идел өсте ялтырап-ялтырап китә. Көтмәгәндә чагылып киткән шул яктылыкта вакытлыча гына яшеренеп торган ниндидер зур көч бардыр төсле тоела иде.

— Исегездәме, Евгений,— диде Пушкин, тәрәзәдән карап торган килеш,— 1828 елда Төркия белән сугыш игълан ителгән иде. Шул елны мин хәрәкәттәге армиягә җибәрүләрен үтендем, әмма үтенечемне кире кактылар. Шуның икенче елында мин Кавказ фронтына киттем.

— Ай-һай, үз сүзле, төзәлмәс кеше син, Александр!

— Тукта әле. Мин рус гаскәрләре белән Арзрумга кадәр бардым һәм аны яулап алуда катнаштым. Аннары грузин шагыйрьләре белән дә якыннан таныштым. Әй, шәп тә соң андагы халык җырлары!.. Егерме тугызынчы елның сентябрендә Мәскәүгә килдем. Ә октябрьда Петербургка кайттым һәм Бенкендорфтан шуның өчен каты шелтә алдым. Шайтан алсын шелтәсен! Аның каравы мин «Арзрумга сәяхәт»не яздым... Карале, тыңла әле, Евгений: Казан архивларында Пугачев турында мәгълүматлар табып булыр микән?

— Ишеткәнең юкмыни әле? — диде Баратынский.— 1815 елны Казанның бөтен иске архивлары янып бетте бит. Карл Федорович Фукс дигән искиткеч әйбәт бер профессор документларны уттан коткармакчы булып тырышкан икән дә губерна башлыклары каршы килгәннәр. Ул башлыкларның үзләрен фаш итәрдәй документлар да булган анда, шуңа яндырганнар.

— Алай булса, эшләр кыенлаша икән,— диде Пушкин, аптырашка калып.— Хәзер бөтен ышаныч Пугачев вакыйгаларын үз күзләре белән күргән кешеләрдә генә инде. Пугачев турында язмакчы идем мин. Аннары рус халкы турында тагын берничә әйбер язармын дип йөри идем. Күз алдыңа китер, Евгений: ирексез һәм караңгылыкта яшәүче кол-халык диктатор һәм үтерүче Наполеонга каршы күтәрелгән бит! Күтәрелеп кенә дә калмаган, аның гаскәрләрен һәм коры җирдә таптап үткән, һәм Днепр, Березина, Дунай һәм Сена елгаларына батырган, ә дошманны җиңеп кайтканнан соң тагын ирексезлек камытын кигән. Чыра яктысында чабата үрә, самогон куа, соңгы тиенен шәм сатып алып, Христка — коткаручы исәнлегенә дога кыла башлаган. Ул халыкның көче һәм бөеклеге нәрсәдә? Йомшак һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт? Бәлки, ул үзе гаепле дә түгелдер. Шул ук халык арасыннан калкып чыккан мәгърифәтле кешеләр, безнең ише культура әһелләре гаепле түгелме икән монда?

Пушкин боларны бик кызып, дулкынланып сөйләп бирде.

— Сизәм, Александр, син чыннан да бик зур эшкә тотынырга ниятләгәнсең икән. Россиядә синең ише кешеләр булганга ничек горурлануымны белсәң иде син! Үзеңә кирәкле материалларны кайдан җыярга уйлыйсың соң?

— Кайда мөмкин — шуннан! Архивлардан, Пугачевны күреп белгән картлардан, кабаклардан, Идел буйларыннан, Пугачев ярсуыннан кызып калган һәм әле суынырга да өлгермәгән Казан урамнарыннан җыячакмын!

Баратынский авыз ачарга да өлгермәде, Пушкин тагын сүзгә кереште:

— Истәлеккә нәрсә бүләк итим сиңа, Евгений? Көзен коелган агач яфраклары сыман, соңгы елларда минем дә дусларым югала, азая башлады. Ал менә шушы минем портретны. Рамын үзем ясадым мин аның!

— Рәхмәт, Александр. Рәхмәт, дустым!

Беркавым кочаклашып, бер-беренә карап тордылар. Алар хушлашып аерылышканда сәгать унберенче киткән иде инде.

Язмыш ул ике дусны бүтән очраштырмады. Шушы сөйләшүдән соң үнике ел үткәч, Баратынский сөргендә вафат булды. Ә Пушкинның гомере нибары өч ел да дүрт ай гына калган иде инде...

## 6

Кичә кич тау битенә урнашкан гостиница тәрәзәсеннән караганда, Пушкин еракта, болыннар артында, җәйрап яткан Иделгә сокланып һәм кызыгып торган иде. Бүген иртүк шул мәһабәт елганың янына ук барып, аны үз күзләре белән күреп кайтырга дип чыгып китте.

Әле чабылмаган болын тәмле үлән исе, чәчәкләр исе белән тулган. Һава сулап туйгысыз саф, ә күктә тургайлар җырлаша. Аяк атлаган саен Иделнең якынаюы сизелә. Акчарлаклар тавышы ишәя, һаваның дымсулыгы һаман арта бара...

Ниһаять, Идел үзе дә күренде. Яр буена килеп туктагач, Александр байтак вакыт хәйран калып торды. Менә нинди киң, иркен һәм мәһабәт икән ул! Аргы як ярында яшел агачлар белән капланган текә тау. Ул тауның бите урыны-урыны белән ниндидер җанвар тырнап алгандай булып сыдырылгаланган. Язгы ташу суларыннан шулай булгандыр, күрәсең...

Александр, сумалалары кояшта эреп, ялтырап яткан көймә янында җырлый-җырлый ятьмәсен ямап маташучы түгәрәк ак сакаллы татар картына карап тора башлады. Менә шушылай Иделнең сулышын тоеп, дулкыннарын карап тору искиткеч рәхәт иде аңа. Уйлары киеренке, күңеле көр иде. Шул чак аның уйлары үткән тарихка барып тотышты. Әйе, Пугачев Иделгә Степан Разиннан соң нәкъ йөз ел үткәч килгән. Һәм ул да шулай ук Дон казагы. Алай гына да түгел, алар икесе дә бер үк станицадан — Зимовскийдан чыккан кешеләр. «Кызык бит бу, бик кызык. Ниндидер тарихи бер хикмәт юкмы соң монда? Бар, билләһи бар. Вакыт дигән нәрсә шундый акыллы ул, аңа алла үзе дә көнләшеп карый торгандыр. Вакыт ул барысын да тикшерә, хөкем итә, киләчәк өчен шагыйрьләрне һәм геройларны сайлап ала. Әгәр чынчынлап игътибар белән тыңласаң, үткәнне генә түгел, киләчәк хакында да күп нәрсә сөйли ала ул...

Тарих безгә кайбер хәлләрне аеруча нык итеп искәртеп тора. Аның тавышын бары тик чукраклар гына ишетми. Башы чабылган Стенька Разин тавышы, икенче бер казак кыяфәтендә, йөз елдан соң янадан әйләнеп кайтты. Ничек кенә кайтты әле! Дәүләт эшендә дә, сөяркәләре белән шаяруда да гаять аек акыллы императрицаның тәхетен дер селкетте. Бәлки, пугачевчылык богау һәм чылбырлар белән уратылып алынган Россиянең яңа бер ярсуыдыр. Бәлки, мин нәкъ менә шушында һәр шагыйрьдән халык көтә торган иң мөһим сүзне әйтергә тиешмен...»

Александрның уйларын бала елаган тавыш бүлде. Тавыш килгән якка әйләнеп караса, баягы татар карты үнике яшьләр чамасындагы

бер малайны каеш белән кыйнап тора иде. Александр тиз генә ярдәмгә китте.

— Нигә баланы кыерсытасыз алай?

Карт кыйнаудан туктады да агач бүкән янында яткан ике табак калайны күрсәтте. Пушкин, якынрак килеп, калайларны күтәреп карады. Аларның икесенә дә акбур белән рәсем ясалган иде. Берсенә бик күп балык эләккән җолым тартучы ике балыкчы ясалган. Балыкчылары да таныш. Берсе — әлеге карт, икенчесе — малай үзе. Малай аларны шактый оста итеп эшләгән, тәҗрибәле рәссамнарның да күбесе алай эшли алмас иде.

Рәсемне карап торганда Александр әле күптән түгел генә Австрия вәкиле өендә үткәрелгән бер әдәби бәхәсне хәтерләде. Анда Жуковский яшь әдип Грибоедовның «Акыллылык бәласе» исемле кызыклы пьесасы турында сөйләде һәм ул әсәрдәге персонажларның тоныграк булуын искәртеп үткән иде.

— Бер чагыштыру китермәкче булам,— дигән иде шунда Александр.— Шекспир иҗат иткән кешеләр Мольерныкына һич тә охшамаган. Мольер саранны саран гына итеп сурәтли. Ә Шекспирның Шейлогы саран, астыртын, хәйләкәр һәм бик зирәк акыллы. Мольерның икейөзле кешеләре үзенә яхшылык итүче кешеләрнең хатыннары артыннан сөйрәлә — икейөзлелек, бер стакан су сорый — икейөзлелек. Шекспирның Анжелосы да икейөзле, чөнки аның кеше алдында эшләгән эшләре яшерен хисләренә каршы килә. Ләкин Анжело кеше буларак ачыграк. Грибоедов Шекспирга якынрак һәм мин аның шулай булуы бик әйбәт, дип әйтмәкче булам!

Әлеге татар малаеның рәсемендә дә Шекспир персонажларына хас чалымнар бар иде. Рәсемдәге кыяфәтендә картның бөтен характеры күренеп тора. Ә малайның йөзендә яшьлек куанычы, кызыксыну һәм өмет балкый.

Калайга ясалган икенче рәсемдә батып бара торган кояшның Идел өстендәге соңгы нурлары сурәтләнгән һәм ул, шулай ук, хәйран оста эшләнгән иде.

— Кем эше бу? — дип сорады Пушкин.

Малай, гаепле кеше сыман куркып, башын аска иде.

— Кем булсын! — диде карт, һаман әле ачуын баса алмыйча.— Менә шушы алла каһәрләгән малай эше инде! Тере җан ияләренең сурәтен ясарга ярамаганын белә торып шушыларны ясаган бит, хәерсез. Теге дөньяга баргач, бу сурәтләр җан сораячаклар бит аннан!

— Оныгыгызмы бу? — дип сорады Пушкин.

— Әйе лә...

— Кыйнамагыз сез аны, моннан ары беркайчан да кыйнамагыз. Ул...

Пушкин малай янына килде дә, иелеп, аны шашынып үбәргә керешге. Ә күңелендә: «Я рабби, никадәр күп талант бар бу Россиядә! Һәм шул талантлар ничек изелә, юкка чыгарыла»,— дигән борчулы уйлар кайный иде.

— Сез аңа тимәгез,— дип кабатлады Пушкин, малайны үбеп туктагач.— Аңа тияргә ярамый. Кешеләрне шатландырырга алла үзе кушкан оныгыгызга. Сезнең Корьәнне мин дә азрак беләм. Минемчә, сез аны тиешенчә аңлап җиткермәгәнсез...

Карт, ни дип әйтергә дә белмичә, әүле-тәүле булып торганда Пушкин кайтыр якка юнәлде һәм аның күңелен тагын Пугачев тарихы биләп алды: «Миңа нигәдер Стенька Разинны нәкъ моннан йөз ел элек җәзага алып барганнар шикелле тоела. Һәм йөз ел буена җыр ыңгырашып торгандыр кебек. Аннары менә Емельян Пугачев башы да тәгәрәп киткән. Ә җыр һаман, халыкны чакырып, ыңгырашуын дәвам итә...»

Балык рәте дип аталган урамдагы бер сыраханәдә Пушкин шау-гөр килеп сөйләшеп утыручы бер төркем кешеләрне күрде. Карап торырга инде шактый олы яшьтә булсалар да, яшьләрчә кызып һәм дәртләнеп сөйләшә иде алар. Александр да шуларның берсе — кап-кара сакаллы-мыеклы, бөдрә чәчле һәм юантык гәүдәлесе янынарак барып утырды. Ул арада теге агай, колакларны ярырлык калын тавыш белән:

— Гугниха әби исәнлегенә эчәбез! — дип иптәшләренә мөрәҗәгать итте. Аның тавышыннан хәтта утырдашлары да сискәнеп киттеләр һәм берсе, ачуланып:

— Ярар инде, Илюха, нигә халык куркытып, поп шикелле акырасың? — дип мыгырданып та алды.

Ул арада Пушкин бөдрә чәчле агайга тагын да якынрак елышты. Аннары:

— Нинди карчык ул? Кай ягы белән атаклы? — дип сорады да, ялчыны чакырып, шәраб һәм закуска китерергә кушты.

— Җаек казагы түгеллегең әллә кайдан кычкырып тора,— диде аңа әлеге калын тавыш.— Үпкәләмә, туган, бөтен кыяфәтең әйтеп тора — барин син.

— Юк. Язучы мин. Ә безнең агай-энене барин дип түгел, бәлки тоткын дип атау хәерлерәк булыр иде. Сөйлә әле, эшлә бер изгелек!

Пушкин аңа бер стакан шәраб салып бирде. Бөдрә чәч ялындырып тормады:

— Синең исәнлеккә! — дип, тиз генә стаканны каплап куйды һәм тамагын кырып алды да, закускасын бөтенләй кабып та тормастан, сүзгә керешге:

— Бу хәл элекке заманда булган. Безнең казакларның әби-бабалары Җаек буена барып урнашканнар. Башта алар җирле татарлар белән низагълашып яшәгәннәр. Ә соңыннан... Дөнья шулай ул, агай-эне, бөтенесе белән, хәтта үлем белән дә килешергә өйрәтә. Тегеләр дә тора-бара үзара килешкәннәр, ә аннары дуслашып ук киткәннәр. Казаклар татар кызларына өйләнешә башлаган. Әмма казакның шул ягы бар бит аның: ирек аңа туган анасыннан да кадерлерәк. Ә хатынлы кеше ничек ирекле була алсын ди инде. Түзә алмаган казаклар, үзара киңәшкәннәр дә, балаларын үтереп, ә хатыннарын ташлап калдырып, походка чыгып киткәннәр. Ерткыч хайваннарча кыланганнар инде, сөйләп тә торасы юк... Ләкин ни булса да — булган инде! Үткән эшне яшерүдән мәгънә юк. Шуннан ары менә мондый хәлләр булган. Бер дә бер көнне Җаек гаскәрләре атаманы Василий Гугня чиркәү янына барлык казакларны да җыярга кушкан. Казаклар җыелгач, болдырга чыгып баскан. Таза һәм мәһабәт гәүдәле, бөркетнекедәй үткен күзле булган ул. Ә кулына калкан тоткан ди. Аннары атаманның ярдәмчеләре чыккан һәм, бүрекләрен җиргә салып куеп, барысы да дога укыганнар. Шуннан соң Василий Гугня хатыны Гугниханы алып чыгарга кушкан. Ярдәмчеләре — есауллар — искиткеч чибәр бер татар хатынын алып чыкканнар. Колакларындагы көмеш алкаларын ялтыратып, каратут матур йөзе белән казакларга карап, бер дә шаккатмыйча гына тора ди теге хатын. Ул гәүдәсенең сылулыгын, ул билләренең тал чыбыгыдай нечкәлеген бер дә әйтеп-сөйләп кенә бетерерлек түгел ди инде! Ә янында бишәр яшьлек ике игезәк улы басып тора икән.

— Казаклар! — дип кычкырган атаман Гугня.— Сез минем ничек сугышуымны беләсез. Туп ядрәсеннән дә, кылычтан да курка торган бәндә түгел мин. Әйдәгез, курыкмыйча хакыйкатьнең күзенә карыйк! Без борынгы бабаларыбыздан калган гадәт буенча яшәдек һәм ул гадәт мәңгегә шулай калсын!.. Әмма, агач яфраклары көзен корыган кебек үк, хәзер кайбер гореф-гадәтләр дә саргая, үлә башлады. Сез ул

гадәтне беләсез. Кыргый җанварларның да күбесенә хас булмаган начар гадәт ул. Минә минем балаларым, минә хатыным. Сезнең дә хатыннарыгыз һәм балаларыгыз бар. Ә иртән походка чыгасы. Нишлибез, яшь балаларны тәвәккәллибезме, әллә хатыннарыбызны ташлыйбызмы?

Казаклар бер сүз дә дәшмәгәннәр.

— Алайса мине тыңлагыз! — дигән атаман.— Бүгеннән башлап бер казакның да үз балаларына һәм хатыннарына кулы күтәрелергә тиеш түгел! Килештекме, егетләр?

Казаклар шаулаша башлыйлар. Кайсы: «Килештек» дип, кайберләре: «Бөгештерeп торма әле, атаман», «Хатыннар итәгенә тагылырга өндәмә әле безне!» — дип кычкыралар.

Атаман шактый вакыт казакларга ачуланып карап торса да, тегеләр кычкырышудан тукталмыйлар. Менә шул чак Гугниха бер адым алга атлый һәм аның баш очында яшен ялтырап китә. Ләкин ул яшен түгел, ә атаман хатыны күтәргән кылыч икән.

— Ягез! — дип кычкыра атаман хатыны.— Кайсыгызның йөрәге җитә минем балаларыма кул салырга?

Башта казаклар көлешә башлыйлар. Әмма шундук авызларын ябарга мәҗбүр булалар. Мәче булып мәче, балаларын ала башласаң, җан-фәрман тырмаша. Ә монда атаман хатыны ачуланган. Җитмәсә кулында кылычы да бар!

Бик нык кычкырыша казаклар. Башта һич тә хатыннары, бала-чагалары янына кайтырга теләмиләр. Ләкин соңыннан атаман белән килешергә туры килә. Менә шул заманнардан алып, бүгенге көнгәчә казаклар һәрвакыт:

— Гугниха әби хөрмәтенә! — дип эчә башлыйлар...

## 8

Пугачев тарихы белән Александр 1831 елны ук кызыксына башлаган иде. Князь Вяземскийга язган бер хатында менә болай диде ул: «Син, мөгаен, Старая Русса һәм Новгородта булган хәлләрне ишеткәнсеңдер. Новгород тирәсендәге авылларда йөздән артык генерал, полковник һәм офицерларны бик кансыз рәвештә суеп ташлаганнар... Мужиклар эше булган ул. Полклар үзләренең начальникларын шулар хөкеменә тапшырганнар. Әйбәт түгел, әфәндем!»

Шул чакта Александрның күңеленә, рус халкы ачуланса — бик хәтәргә әйләнә, дигән уй килгән иде һәм ул Пугачевта Екатеринадан башлап Николай Беренчегә кадәр булган патшаларның берсе дә күрмәгән якларны күргән сыман булды. Аның күз алдына казак авыллары буйлап, нинди эш туры килсә — шуны эшләп һәм байларның, патшаларның усаллыкларын яманлап, бунт күтәрергә өндәп йөрүче бер сукбай килеп басты. Бигрәк тәвәккәл булган ул сукбай. Хәтта рождество көннәрендә, һичшиксез, бунт булачак дип, ачыктан-ачык сөйләп йөргән. Аннары аны Малыковка авылында тотып алганнар да сак астында Казанга озатканнар. Казанга килгәч, бер дә бер көнне ул, үзен ике солдат саклап йөргән хәлдә, урамга хәер сорашырга чыккан. Бер урам почмагында сакчының берсен сугып еккан, икенчесе белән бергә тройкага утырып киткән. Ә тройка аны алдан әзерләнеп, махсус көтеп торган икән. 1773 елның 19 июнендә була бу хәл. Ә теге сукбай Емельян Пугачев булып чыга.

Бунт әнә шулай башлана. Казанның хәрби коллегиясе шул ук көнне качкынны эзли башларга боерык бирә. Берникадәр вакыттан соң аны Җаек шәһәре тирәсендәге бер хуторда күрәләр, әмма тота алмый калалар. Ә шул ук елның 18 сентябрендә инде ул, өч йөз казакны ияртеп, Чаган елгасының аръягына барып чыга һәм үзен Петр Өченче дип

игълан итә. Шул көннән алып, кая гына барып чыкса да, аның сафларына казаклар, татарлар, чувашлар, башкортлар, чирмешләр һәм мордвалар да кушыла башлый. 24 сентябрьдә Пугачев Рассыпная крепостен яулап ала. Крепость коменданты майор Веловскийны, берничә офицерны һәм крепость руханиын асып үтерәләр, ә гарнизон ротасы һәм тагын йөз илле казак Пугачев отрядына кушыла.

Аннары Пугачев Нижне-Озерной крепостена юнәлә. Шул хакта ишетү белән, крепость коменданты Харлов үзенең яшь хатынын — Татищево коменданты Елагин кызын — этисе янына кайтарып җибәрә һәм оборонага әзерләнә башлый. Солдатларына крепостьны сакларга, пугачевчыларга каршы һич аяусыз ут ачарга боерык бирә. Әмма солдатлары аңа буйсынмыйлар. Пугачев бу крепостьны да бик ансат кулга төшерә һәм Фигнер, Кибалеров исемле прапорщиклары белән бергә, Харловны җәзалап үтерергә боерык бирә. Аннары писарьны һәм Бикбай атлы бер татарны да җәзалап үтерәләр.

Икенче көнне үк Пугачев Татищевоны камап ала һәм крепостька атарга тиешле тупларны калкурак урыннарга үзе урнаштырып чыга. Аннары крепость тирәсендәге салам эскертләренә ут төртәләр. Ут эскертләрдән агач корылмаларга күчә. Крепость халкы, хафага төшеп, утны сүндерергә маташкан арада Пугачев икенче яктан һөҗүмгә күчә һәм крепостька бәреп керә. Полковник Елагинны һәм барон Биловны шундук җәзалап үтерәләр. Елагинның хатынын чабып үтерәләр, ә кызын, ягъни кичә Нижне-Озернойда вафат булган Харловның хатынын Пугачевка алып киләләр. Пугачев ул хатынның матурлыгына шакката һәм аны үзенә наложник итеп ала...

«Кем соң ул Пугачев? — дигән уй килде Александрның күңеленә.— Бик зур шәхесме? Билгеле бер дәрәҗәдә — әйе, зур шәхес. Хәрби эш өлкәсендә беркадәр белеме булган аның. Аннары ул гадәттән тыш тәвәккәллек белән эш иткән. Барыннан да элек, Пугачев — очкын ул. Әмма ул очкынга гади халык арасында кайнап, җыелып килгән дәһшәт җитмәгән. Шул ук вакытта Пугачев ялгыз хакимлек тә итмәгән. Аның күп кенә эшләрен Җаек казаклары башкарган, ул бар нәрсәне дә шулар белән киңәшеп эшләгән. Казаклар аңа башка кешеләрне яратырга һич тә юл куймаганнар. Бервакыт ул асарга хөкем ителгән Кармицкий дигән сержантны кичерә дә үзенә писарь итеп ала. Җаек казаклары бу хәлгә озак түзеп тора алмыйлар: Кармицкийны буып үтерәләр дә таш бәйләп суга батыралар. Пугачев:

— Писарь кая? — дип сорагач,

— Җаек буйлап түбән таба, әнисе янына кайтып китте! — дип җавап бирәләр.

Пугачев бер сүз дә әйтми, кулын гына селки...

Надан булган Пугачев. Анысы дөрес. Ләкин бөтен кара халык аның яклы булган, аңа ияргән бит. Аның көченең сере әнә шунда! Шул җәһәттән караганда, генерал-майор Карның тарихы бик кызыклы. Аның турында Казанда шул хәлнең шаһите булган картлардан ишетте Александр. Эш менә болай булган икән. Самарадан Оренбургка таба хәрәкәт итүче Сембер коменданты полковник Чернышевка Кар мөмкин кадәр тизрәк Татищевога барып җитәргә кушып боерык җибәрә. Ноябрь башында Кар үз гаскәрләре белән шулай ук юлга чыга. Оренбургтан йөз чакрымлап киткәннән соң, ул Пугачевның яраткан кешесе Холопушаның, крестьяннарны котыртып, Оренбургка кайтып килүен ишетә һәм Холопушаның юлын кисәр өчен, секунд-майор Шишкинны алга җибәрә. Шишкин алты фетнәчегә юлыга һәм аның отрядындагы кораллы крестьяннар белән татарлар Холопуша ягына чыгалар. Аннары, Холопушага ияреп барып, Пугачев отрядына кушылалар да Кар гаскәрләрен кысрыкларга керешәләр, унсигез чакрым артларыннан куып

баралар. Ул арада Оренбургка таба баручы полковник Чернышев карамагындагы гаскәр сугышчылары да, командирларына хыянәт итеп, Пугачев ягына чыгалар. Чернышев үзе әсирлеккә төшә һәм, бүтән күп кенә офицерлар белән бергә, фетнәчеләр тарафыннан җәзалап үтерелә. Бу хәлләрдән Кар тәмам аптырап кала. Авыруга сабыша да, командалык итүен ташлап, башта Казанга, аннары Мәскәүгә сыпырта. Шуның өчен әби патша аны хәрби хезмәттән бөтенләй куып чыгара.

Менә шушы вакыйгаларны күңеленнән кичергәч, Пушкинның күңеленә бер уй килде: патша генералы белән карак һәм качкын Емельян Пугачевны икесен бергә бастырып карыйсы иде! Әгәр, чыннан да, шулай итеп булса, нигә байларның коты алынып качулары һәм ни өчен ярлы-ябагайның ирек даулап, байларны туздырырга омтылып йөрүләре ачыграк күренер һәм күп нәрсә хакында уйланырга мәҗбүр итәр иде. «Мондый коточкыч фетнәнең бөтен Европада булганы юк иде әле,— дип уйлады Пушкин.— 14 декабрьда мәйданга кемнәр чыккан иде? Бары тик дворяннар гына. Ә янадан ризасызлык туса — күпме кеше чыгар икән? Белмим... Күп булыр, мөгаен...»

Бу фикерләренең барысын да Александр «Пугачев тарихы»ның өченче главасына кертергә булды.

## 9

Акрын гына ишек шакыдылар. Кыяр-кыймас кына шакуыннан ук Пушкин аның Мәрьям икәнен сизеп алды һәм:

— Кер, акыллым, кер әйдә!

Ул үзенең юлъязмаларын тәмамлап, Казанны карарга җыенып тора иде. Оялыбрак кына бүлмәгә Мәрьям килеп керде. Ул өстенә зәңгәр ситсы күлмәк кигән, башына бизәкле яулык япкан. Озын кара толымнары биленә үк төшеп тора иде.

— Сез Пугачев турында сорашкансыз дип ишеткән идем,— диде ул, уңайсызланып кызарынып китеп,— минем бабам исән әле. Ул... аны белгән.

Александр кинәт сикереп купты.

— Ул бабаң кайда синең?

— Суконный бистәсендә.

Кылт итеп, архив документларында язылган сүзләр исенә төште: «Пугачев Казанга Суконный бистәсе аша кергән». Ә нигә нәкъ менә Суконный аша керде икән? Кызык бу, кызык!

— Бабаң ни исемле, Мәрьям? — диде Александр, беркавым уйланып торгач.

— Яхъя.

Александр, гаҗәпләнеп, кашларын сикертеп куйды: рус кызларына һич тә охшамаган бу кызый русча ничек болай оста сөйләшә соң әле?

Кыз, Пушкинның сүзсез соравын аңлап булса кирәк, бер дә тоткарланмыйча сөйләп китте:

— Мин татар кызы. Мәрьям исемле. Руслар мине Марютка дип йөриләр. Җиде яшьтән ятим калдым. Аннары бабай мине сәүдәгәргә хезмәткә бирде. Ә ундүрт яшь тулгач, мин аннан киттем. Түзә алмадым.

— Балакай,— диде Александр, яшел тышлы дәфтәрен алып.— Әйдә, тизрәк алып бар мине бабаң янына!

Мәрьям, тиз генә барып, өлкән асраудан рөхсәт алып килде дә, Пушкинга ияреп, Суконныйга китте. Чокыр-чакырлар арасындагы калкулыкларга урнашкан тәбәнәк өйләргә карап бара торгач, алар Мәрьямнең бабаларына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Пушкин тарантастан төшәргә дә өлгермәде, ут борчасыдай җитез Мәрьям ап-ак сакаллы картны җитәкләп капкадан килеп тә чыкты. Ә үзе кызып-

кызып, татарчалатып бабасына нидер сөйли иде. Александрны күргәч, карт бераз тикшереп-сынап карап торды да:

— Пугач! Пугач! — диде.— Пугач ул, әфәндем, туп белән, кылыч белән Иделдән алып Уралга тикле барып житкән. Юлында очраган байларның йортына кызыл әтәч тә калдырып барган ул. Аның ул хикмәтләрен Рәсәйдә тагын йөз ел буе сөйләрләр әле!

— Бик әйбәт һәм дөрес әйттең, бабай! — диде Пушкин, рәхәтләнеп көлеп җибәреп.— Мин Пугачев фетнәсендә катнашкан кешеләрнең истәлекләрен җыям. Сез дә үзегез күргәннәрне сөйли алмассызмы икән?

— Ә нинди ният белән җыясың син аларны? Угрыга мәчеттә дә, чиркәүдә дә дога укымыйлар бит.

Пушкин, хәйләкәр һәм риясыз итеп, картка карап торды.

— Үзегез үк тагын йөз ел сөйләрләр әле дидегез бит. Менә шуңа күрә Пугачев тарихын язмакчы булам. Сөйләгез әле, зинһар?

— Салават күпере төсле балкып, яшен тавышы кебек яңгырап торган нәрсә турында ничек сөйләмәк кирәк? «Менә сиңа халык — шагыйрь!» дип уйлап алды Пушкин.

— Күзләреңнән күреп торам, — дип дәвам итте Яхъя карт. — Син минем сүзләремә гаҗәпләнәсең. Кечкенәдән үк рус осталары белән Суконныйда эшләдем мин. Казанның Осокин мануфактурасы, мин сиңа әйтим, дары базы кебек иде. Шырпы ташласаң, бөтен Казанны шартлатырлык дәрәҗәдә кызган иде ул!

Безнең күрше урамда Горлов дигән кешенең сыраханәсе бар иде. Менә шунда ял көннәрендә мануфактура эшчеләре җыелып, эчеп, җырлашып утыра торган иде. Беренче тапкыр Пугачны әнә шул сыраханәдә очраттым. Ул Җаек казаклары кия торган бүрек һәм бишмәт кигән. Биленә яңа ай төсле ялтырап торган кылыч таккан иде.

Мин килеп кергәндә, сыраханәдәгеләр бик кычкырышып, яман сүзләр белән мануфактура хуҗаларын сүгеп утыралар иде.

— Туктагыз, Суконный агай-энеләре! — дип кычкырды шул чак Пугач.— Сез гыйбадәт кылырга килгән марҗалар түгел, ә мин поп түгел. Тиздән кылычларга эш табылачак. Әгәр Суконный кутәрелсә, аңа башкалар да иярер. Менә шул чакта Казанның хуҗалары без булырбыз, ә байларга һәм генералларга көн бетәчәк! Хәзергә хушыгыз, агай-энеләр! Патшалык итүче ана эт Екатеринадан мәрхәмәт көтеп, кул кушырып торасызмы, әллә минем Казанга әйләнеп килүемне көтеп, яхшыга — яхшылап, яманга — яманча исәп-хисап ясарга әзерләнәсезме — анысы сезнең карамакта!

Шулай диде дә Пугач сыраханәдән чыгып китте. Халык аны:

— Сине көтәбез, Пугач!

— Кунак булырсың, яхшылап сыйларбыз,— дип кычкырып озатып калды.

Шуннан ары ул Казанны камап алганга һәм үзен патша Петр Федорович дип игълан иткәнгә тикле күрмәдем мин аны. Казанны камап алгач, губернатор йомышчылары чиркәү һәм мәчет алларына барып:

— Патша түгел ул! Карак һәм качкын Емельян Пугачев ул! — дип кычкырышып йөрделәр.

— Рәхмәт, Яхъя бабай! — диде Пушкин, бик зур игътибар белән картны тыңлап торгач.

— Ә мин әле бетермәдем, әфәндем.

— Бәлки, бергәләп Пугачев булган җирләрне карап кайтырбыз.

— Була ул.

Пушкин, Яхъя карт һәм бер Бабин дигән рус агае, тарантаска утырып, китеп бардылар. Ә Мәрьям бабасы өе янында басып калды.

Воскресенски урамындагы губернатор йорты турыннан үтеп, Өченче тауга килеп чыккач, Бабин сүзгә кереште:

— Пугач башта урман эчләтеп килгән. Аннары аның гаскәрләре Арча кырына һәм шушы Өченче тауга сибелгәннәр дә Казанга бәреп кергәннәр. Шуннан ары бөтенесенең асты-өскә килә. Байлар ярлылана, ярлылар баеп китә.

— Ха-ха-ха! — Яхъя карт рәхәтләнеп кычкырып көлеп җибәрде.— Горловка сыраханәсендә нәкъ Пугач әйткәнчә булды бит эшләр! Кинәнде дә инде Суконный халкы! Көне-төне эчтеләр. Пугач отряды да Казанга иң элек шуннан бәреп керде...

Бердин бистәсендә тарантасын туктатып, Пушкин урамда утыручы карт-карчыклар белән дә шактый озак сөйләшеп, сораштырып торды. Үзе кирәк тапкан нәрсәләрне дәфтәренә дә язгалап барды. Шул карткорылар арасында Пьянов фамилияле бер Җаек казагы да бар иде. Ул башта сүзгә кушылмыйча, каш астыннан гына карап торды. Аннары, шактый кырыс итеп:

— Син ни... Кара, Пугачев дип атама аны! Сиңа Пугачев ул, ә миңа — бөек патша Петр Федорович! — диде...

Шул көнне кич, гостиницага кайткач, Пушкин дәфтәренә менә шушы сүзләрне язып куйды: «Үзем язачак заманның иң мөһим вакыйгалары булган урыннарны карадым, үле документлардагы мәгълүматларны әле исән, әмма инде бик карт шаһитлардән сөйләтеп тикшердем һәм яңадан аларның иске хәтерләрен тарихи тәнкыйть күзлегеннән кичереп чыктым».

## 10

Өч ат җигелгән җиңел арбага утырып, җиденче сентябрь көнне иртән иртүк Пушкин ялгызы гына Себер тракты буйлап, Казаннан ун чакрым ераклыктагы Троицкий тегермәненә юл тотты. Юлда ул Пугачевның Казанны ничек итеп камап алу картинасын күз алдына китерергә тырышып барды. Уникенче июльдә, таң аткан вакытта, фетнәчеләр Царицын авылыннан Арча кырына юнәлгәннәр. Алар шәһәр читендәге кирпеч сарайларын, куаклыкны һәм Кудрявцев йортын бик тиз кулга төшергәннәр һәм шунда тупларын урнаштырганнар. Юлны саклап торган отряд, фетнәчеләргә каршы тора алмыйча, чигенергә мәҗбүр булган...

Аннары Пушкин Себер тракты турында уйлана башлады. Бу юл буенча кемнәрне генә каторгага кумаганнар! Фетнәчеләр дә, дворян мундиры кигән офицерлар да сөрелгән, шушы юл буйлап куылган. Һәм алар барысы да патша өчен куркынычлы, зарарлы кешеләр булган. «Я, ходаем,— дип көрсенеп куйды Александр.— Акыллы һәм хисле кешегә Россиядә яшәү никадәр кыен! Барысы да тираннарның явыз хакимлеген искә төшереп тора бит!..»

Өченче көн гостиницада Баратынский сөйләгән сүзләр исенә төште:— «Менә шушы хәзер без утыра торган бүлмәдә моннан ярты гасыр элек Дворянское собраниегә килгән чагында Екатерина Икенче туктаган булган. Ә моннан җиде ел элек княжня Волконская куныш чыккан. Ул яшь һәм бик акыллы, инсафлы хатынны син беләсең инде. Менә шушы бүлмәнең тәрәзәсеннән күренә торган каршы як йортка балга җыелучы маскалы байбичәләрне күреп торгандыр инде ул. Ә икенче көнне ул, Себер тракты буйлап, ире артыннан үзе теләп сөргенгә киткән...»

«Менә бит нинди хатын! — дип гаҗәпләнеп куйды Александр.— Без, аның иренең дуслары, беребез дә андый батырлыкка лаек түгелбез». Аның күз алдына әкияттәгедәй матур Наталия килеп басты. Ул инде ике бала анасы, әмма һаман элеккечә сылу әле үзе. Хәтта тагын да

сылуланыбрак киткән сыман... Күрәсең, дип уйлады Пушкин, ир-ат күңелендә хатын-кызларны куркыныч хәлләрдән һәм кимсетүләрдән сакларга омтылу гомер-гомердән килә торган изге бер хистер инде. Шуңа күрә хатын-кызларның йомшаклыгы һәм көчсезлеге күңелгә бик якын тоеладыр...

Александрның уйларын чаптырып килгән ат тоягы тавышы бүлде. Ул сискәнеп китеп әйләнеп караганда җайдак инде янына ук килеп җиткән иде. Я, рабби! Мәрьям ич бу!

— Александр... Сергеич! — диде Мәрьям, килеп туктауга сүз башлап.— Мин... мин сезгә әйтергә тиеш...

Пушкин кызны ат өстеннән җиргә төшерде. Мәрьям аңа мамыктай йомшак һәм җиңел тоелды. Мәрьям Александрның кучерына шикләнебрәк карап алды да, әйтер сүзе бик мөһим икәнен аңлатып:

— Әйдәгез, тегендәрәк барыйк әле! — диде.— Мин сезгә шуны әйтмәкче идем.— Бабай кичә сезгә бөтен белгәннәрен дә сөйләмәде. Ул... курка. Пугачев билгесез сукбай булган чагында, патшага каршы сүзләр сөйләп йөргәне өчен Казан төрмәсендә утырган җиреннән теләнергә чыккан вакытта урам почмагында ат җигеп көтеп торган һәм аннары аны үз янына утыртып алып киткән кеше — минем бабай инде ул.

— Бабаң шуннан соң күргәнме аны?

— Нигә күрмәсен! — диде Мәрьям, көлеп җибәреп.— Пугачев Казанны алгач, мануфактура эшчеләре Яхъя бабайны фетнәчеләр лагерена җибәргәннәр. «Петр Федорович патшага кайдан һөҗүм итәргә кирәклеген күрсәт!» дигәннәр. Тыңлаган бабай тегеләр сүзен. Төнлә белән Пугачев лагерена киткән. Шунда барышлый ул лагерьны саклап торучы казакларга юлыккан. Тегеләр башта бабайны бик шәпләп кыйнаганнар, аннары кем син, нишләп йөрисең, дип сораша башлаганнар. Бабайның, үзен кыйнаган өчен, тегеләргә ачуы чыккан булган. Шуңа күрә бер сүз дә дәшмәгән бу. Ни тырышып та телен чиштерә алмагач, капчыкка салып бәйләгәннәр дә, ат сыртына аркылы салып, Пугачев янына алып барганнар һәм менә разведчик тоттык дип әйткәннәр. Атаман бик нык уйга чумган. Казанны штурмлый башларга бер тәүлек кенә калган булган ул чакта. Ә бабайны танымаган Пугачев. Ул танымагач, бабай да үпкәләгән, дәшми торган.

— Асыгыз! — дип боерган Пугачев.

Шуннан соң бабайны асарга алып киткәннәр. Ә бабай һаман бер сүз дә дәшми генә барган. Дар агачы янына алып килеп, муенына элмәк сала башлагач кына телгә килгән ул:

— Яхшылыгың өчен рәхмәт, Пугач! — дип кычкырып җибәргән.— Суконный халкы синең вәгъдәңне онытмаган әле!

Бабай шулай дигәч, Пугачев сискәнеп киткән дә җәзаны туктатырга һәм бабайны үзе янына алып килергә кушкан. Ике казак аны әйди башлаганнар икән дә бабай аларның икесен ике якка төртеп җибәргән һәм Пугачев каршына килеп баскан.

— Нинди вәгъдә ул тагын? — дип сораган атаман.

— Гадел хөкем турындагы вәгъдә! — дигән бабай.— Яхшылыкка — яхшылык, яманлыкка — яманлык булачак дип үзең әйткән идең түгелме соң?

Пугачев, Горилов сыраханәсендә әйткән сүзләрен исенә төшереп булса кирәк, кинәт йомшап киткән һәм:

— Ни йомыш белән килдең минем лагерьга? — дип сораган.

— Синең казакларың алып килде! — дигән бабай, ачулы итеп.

— Ә кем җибәрде?

— Мануфактура эшчеләре.

— Нигә башта ук шулай дип әйтмәдең соң?

— Синең сукбайларыңа ачуым килде. Эт урынына сугышалар.

— Кичер син аларны. Ачулары чыккан. Аннары син үзең дә алай бик юашка охшамагансың. Сөйлә.

Бабай, шул тирәдә торган казакларга ымлап:

— Куып җибәр аларны моннан! — дип әйткән.

Пугачев елмаеп куйган да:

— Минем алардан яшерен серем юк,— дигән.

— Мине сиңа шәһәргә кайдан керергә кирәк икәнлеген аңлатырга дип җибәрделәр.

— Әйдә!

Тиз генә ике ат китертеп, шуларның берсенә Пугачев үзе атланган, икенчесенә бабайны атландырган да...

Мәрьям, сөйләвеннән кинәт тукталып, Александрга карап куйды.

— Шуннан нишләгәннәр? — диде Александр, түземсезләнеп.

— Шуннан соңмы? Шуннан соң без менә алар йөргән урыннардан барабыз инде. Мин — бабай, ә Сез — Пугачев. Килештекме?

Пушкин көлеп җибәрде:

— Килештек.

Юлның сул ягында Казанка елгасы үзәнлегенең чите күренеп тора. Елга буендагы агачларның төрле төскә кереп саргая башлаган яфраклары ничектер күңелдә моңсу хис уяталар иде.

— Әнә Царицын авылы,— дип дәвам итте Мәрьям.— Минем бабай Пугачев белән шул тирәләрдә дә йөргән инде.

— Соңыннан анда Михельсон гаскәрләре белән бик каты сугышлар булган,— дип өстәде Александр.

Мәрьям гаҗәпсенеп калды.

— Сез барысын да беләсез икән бит!

— Азрак беләм.

Шулай бара торгач, алар Царицынны үтеп киттеләр. Юл кинәт сулга борылды һәм барган саен тарая башлады.

— Әнә теге авылны күрәсезме? — диде Мәрьям.— Троицкая-Нокса авылы ул.

Александр Мәрьям күрсәткән якка борылып карады.

— Әйе, күрәм.

— Пугачевның лагере шунда урнашкан булган. Әнә теге калкулыктагы тегермән янында.

Алар тегермән янына бардылар. Аннан Казан күренеп тора. Кремль манарасы гына түгел, хәтта йортлар, бакчалар, чиркәүләргә кадәр аермачык күренә иде.

— Пугачев менә шушы без басып торган җиргә 11 июньдә килгән,— диде Мәрьям.

— Ә аннан алдагы көнне полковник Николай Толстой җитәкчелегендә фетнәчеләргә каршы җибәрелгән атлы легионны туздырган булган,— дип өстәде Пушкин.

— Анысын белмим, бабай миңа ул хакта әйтмәде,— диде Мәрьям.— Ул миңа 10 июньдә кичен Пугачев белән шәһәрне күзәтеп йөргәнлеген генә сөйләде. Ә иртән Пугачев шәһәргә һөҗүм башлаган. Горлов сыраханәсе каршындагы тауга туп куелган булган. Пугачев гаскәрләре урман эчләтеп яшеренеп килгәннәр дә, Арча кырына һәм Өченче тауга сибелеп, шуннан шәһәргә ыргылганнар.

Пушкин да, Мәрьям дә беркавым дәшми тордылар. Казанка буенда ак каеннар тезелешеп утыра. Сулда, болыннар артында, Савиново, Сухая река һәм Караваево авыллары күренә иде.

— Пугачев соңыннан әнә шул авылларга таба чигенгән,— диде Пушкин, күрсәтеп.

— Менә ничек! — диде Мәрьям, хәйран калып.— Ә мин аны белми идем әле.

— Күрәсең, өлкән яшьтә булса да, яшьләрчә шат күңелле әфәнде белән йөреп кайту кайчакта файдалы икән,— диде Пушкин, шаярып.

— Сез һич тә алай ук өлкән түгел әле!

— Яхшы сүзегез өчен рәхмәт!

— Сез Казан турында язачаксызмы? — диде Мәрьям, кинәт җитдиләнеп.

— Әйе, Казан турында да, Пугачев турында язарга ниятлим.

— Минем бабам турында язарсызмы?

— Бәлки язармын.

— Ләкин минем турыда яза күрмәгез!

— Нигә алай дисең? Миңа ышанмыйсынмы әллә?

— Мин ышанам да бит... «Руслан һәм Людмила»гызны укыганнан соң мин сезне этием кебек күрә башладым. Чынлап менә!

— Алай булгач, нигә үзең турында язмаска кушасың соң?

— Ничек дип әйтим инде... Баһадирлар, тылсымчылар турында гына китапта язалар бит. Ә мин... мин нибары асрау кыз гына.

— Син нәкъ тылсымчы кыз инде менә! Шушы матурлыгың һәм акылың белән һич тә югалмассың син. Менә күрерсең, беркөнне бик әйбәт егет алып китәр әле!

— Андый көн үтте инде,— диде Мәрьям, күңелсез генә итеп.— Ләкин алып китмәделәр шул.

— Алай булмагандыр ла!

— Булды инде, булды! Беренче гильдия сәүдәгәр малае иде ул. Миңа өйләнергә теләп, атасыннан фатиха сораган иде дә атасы ишетергә дә теләмәде: «Фәкыйрь кызга, мөселман кызына өйләндерәмме соң мин сине. Нәсел пычраттырамммы сиңа? Авызыңны да ачма ул хакта. Әгәр сүземне тыңламыйсың икән — дүрт ягың кыйбла, минем йортыма аяк басасы булма!» дип, Сережаны бик каты орышкан. Сережа аптырап калган. Асылынмакчы булып, муенына элмәк салган. Ләкин аңа асылынырга ирек бирмәгәннәр. Шул хәлләрдән соң Сережаның атасы:

— Мә, бар, зинһар, күземнән генә югал,— дип миңа акча бирмәкче булды. Мин алмадым. Күзеннән дә югалмадым. Мин китмәгәч, атасы Сережаның үзен каядыр олактырды. Шуннан бирле әле һаман аны көтеп йөрим. Менә-менә кайтып төшәр төсле тоела...

Пушкин кызның моңлы яшькелт күзләренә, борчылудан кысылып киткән матур иреннәренә һәм ике алма шикелле булып төртеп торган күкрәкләренә карап, үзенең язмышы белән шушы кыз язмышы арасында нинди дер уртаклык тоеп, уйланып торды. Александрның Наталиягә булган мәхәббәтенә дә әле һаман һәртөрле киртәләр куелып килә бит. Көн саен әле анда, әле монда күңел ачу кичәләренә барырга туры килә. Бармас иден, хатынын чакыралар, аның хәтерен сакларга кирәк. Чиркәүгә гыйбадәткә бармаган өчен дә сүз ишеттереп торалар. Эш шуңа барып җитте, хәтта аның хатынына адресланган хатларны да полиция ача һәм аларны патшага укыта башлады инде. Патша аны кимсетергә һәм көлкегә калдырырга чамалый. Әмма ул җәһәннәмгә олактырсалар да баш имәячәк!..

Шул уйларны күңеленнән кичергәч, Мәрьямгә карады һәм, чыланган керфекләрен күреп, аны кызганып куйды.

— Кайгырудан мәгънә юк, Мәрьям,— диде аннары, кызның башыннан сыйпап.— Син әле яшь, бәхетең алда әле синең! Я, елмай инде, Марютка? Менә шулай! Инде әйт: нинди бүләк бирим мин сиңа?

— Берни дә кирәкми,— диде кыз һәм оялып башын иде.

— Юк, сиңа бирәр истәлек калдырмыйча барыбер китмим мин. Әйт, нәрсә теләр идең?

Кыз тагын беркавым дәшми торды. Аннары, ниһаять, батырчылык җыеп:

— Әгәр сез профессор Карл Федорович Фукстан миңа аның лекцияләренә йөрергә рөхсәт итүен үтенсәгез — иң зур теләгегез шул булыр иде.

Беренче күрүендә үк Александр Мәрьямнең кызыксынучан һәм бик житез булуына сокланып калган иде. Инде менә кызның бу үтенечен ишеткәч аның күзләре яшьләнеп китте.

— Син медицинаны өйрәнергә телисеңмени? — диде ул, иплән кенә.

— Әйе.

— Ләкин, үзең дә беләсеңдер, хатын-кызларга һәм рус динендә булмаган кешеләргә анда уку рөхсәт ителми бит.

— Ә мин укырга түгел, бары тик аның лекцияләрен тыңларга гына рөхсәт итүен үтенәм. Тыңларга да ярамый микәнни соң?

Пушкин йөзен читкә борды. Рус империясенең шундый гаделсез законнары булуы оят һәм уңайсыз иде аңар. Шул законнар аркасында мондый күңелсез хәлдә калуы бер бүген генә түгел иде инде.

— Син Карл Федоровичның лекцияләрен тыңларсың! — диде Александр, катгый итеп.— Ә хәзер, әйдә, Кремльне карарга барабыз.

Александр атларына утырып, алар Кремльгә бик тиз килеп життеләр.

— Мин синең бабаң белән таныш инде,— диде Пушкин, Кремльне карап йөри башлагач.— Хәзер мин сиңа үз бабамның бабасы турында сөйлим.

Мәрьям шаккатып калган һәм сүз әйтә алмыйча бара иде. Ә Пушкинның күз алдына янып торган Казан, кораллы крестьяннар килеп басты, колагына хәвеф барын хәбәр итеп янгыраган чиркәү чыңы авазлары ишетелгән кебек булды. Ул хәтта Пугачев гаскәрләренең Гостиный двор трактирына тупларын куеп, шуннан Кремльгә атып торганнарын үзе күреп торгандай хис итә иде.

## 11

Шул ук көнне кичен Александр Фуксларга барды. Карл Федоровичлар Мәскәү урамы белән Аркылы-Тихвин урамы чатындагы йортта торалар.

Александр килеп кергәндә Фуксларда кунаклар — Казан университеты профессоры Григорий Степанович Суровцев һәм аның хатыны утыра иде. Өлкән яшьтәге Карл Федоровичны Александр моңарчы да күргәне бар. Иске танышларча дустанә итеп күрешкәннән соң Фукс Пушкинны хатыны Александра Андреевна белән дә таныштырды. Күрер күзгә хәйран сөйкемле ул хатын Россиянең иң атаклы шагыйре үз өйләренә килеп керүенә бик куанганын әйтте. Александр, аның кулын үпте дә:

— Безгә әллә ни зурлап танышып торуның кирәге дә юк. Күрешкәнебез булмаса да, язган әйберләребез һәм, бигрәк тә, Баратынский аша күптәннән таныш инде без,— диде.

Александра Андреевнаның шигырьләр язгалавын белә иде ул. Бу сүзләрне шуңа ишарәләп әйтте.

— Әйе,— диде Александра Андреевна.— Баратынский! Бик шәп шагыйрь ул Баратынский, шулай бит?

— Евгенийны мин үзем дә яратам һәм аны иң яхшы шагыйрьләребезнең берсе дип саныйм! — диде Пушкин.

Аннары кунак булмәсенә үттеләр. Александра Андреевна Пушкинны профессор Суровцев һәм аның хатыны белән таныштырды. Аннары, Георгий Степановичка мәгънәле итеп карап алды да, Пушкинга мөрәҗәгать итеп:

— Александр Сергеевич, Баратынский поэзиясенә нинди бәя бирүегезне сезнең үз авызыгыздан ишетәсе килә иде. Мөмкин булса, җентекләбрәк сөйләгезче? Безнең өчен бик мөһим ул! — диде.

Профессор Суровцев та бик кызыксынып, Пушкинның фикерен көтеп тора иде.

— Нәрсә сөйләргә соң инде сезгә,— диде Пушкин, кинәт дәртләнеп китеп.— Ул безнең оригиналь шагыйребез, чөнки ул үзенчә фикер йөртә. Ул һәркайда оригиналь булыр иде, чөнки дөрес һәм үзенчә уйлый. Шуның өстенә бик сизгер һәм тирән хискә дә ия. Тагын нәрсә? Аның шигырьләренең камиллеге, сүзләрне төгәл һәм бик урынлы куллана белүе сәламәт акыллы һәр кешене сокландырырга тиеш.

Гадәттә салкын канлы Суровцев бу юлы бик нык рухланып һәм дулкынланып Пушкинга карап утырды. Аннары кинәт:

— Менә! — дип кычкырып урыныннан купты да, баш бармагын күрсәтеп:— «Оригиналь, чөнки үзенчә фикерли!» Фикерсез образлар сакау һәм безнең бәхәсләр, кадерле Александра Андреевна, нәкъ менә шул кучәр тирәсендә әйләнә! — диде.

— Шагыйрь хисләр теле белән сөйли, ә сез шуны аңларга теләмисез! — диде Александра Андреевна.

— Мин сезне килештерәм,— диде Пушкин, көлеп.— Тирән фикер йөртергә, хисләнергә тырышыгыз һәм шул чакта яхшы әйберләр яза алырсыз. Көн саен иҗат итегез һәм уйланыгыз. Башка сере юк иҗатның. Шаховскийны хәтерегезгә алыгыз. Талантлы шагыйрь булган ул. Ләкин шигырь сәнгатенә өйрәнергә тырышмаган һәм шуның аркасында урта кул шагыйрь генә булып калган.

Өстенә кара фрак, бармакларына ялтыравык кашлы йөзекләр кигән Пушкин мәһабәт һәм кырыс күренә. Әмма чак кына елмаю белән аның кырыслыгы юкка чыга һәм ул шундук мөлаем, ачык йөзле кешегә әйләнеп китә иде.

— Карл Федорович! — диде ул, бу юлы да шулай кинәт ачылып китеп.— Әле Петербургта чагымда ук мин Сезнең лекцияләр хакында күп ишеткән идем. Бик мактап, бик игътибарлы һәм миһербанлы кеше дип сөйлиләр иде сезне. Шул миһербанлы игътибарыгызны бер яшь кенә җан иясенә юнәлтә алмассызмы икән? Ул кыз университетта сезнең лекцияләрне тыңларга бик тели.

— Гафу итегез, Александр Сергеевич,— диде Фукс, кызыксынып.— Кем була соң инде ул кыз?

— Асрау кыз ул. Мәрьям исемле.

Профессорлар бер-беренә карашып алдылар.

— Асрау? — диде Фукс, гаҗәпләнеп,— дөресен генә әйткәндә...

Профессор ни дияргә дә белмичә тотлыгып торган арада Пушкин сүзен ялгап алып китте:

— Крестьян малае Михайло Ломоносовка да үз вакытында гаҗәпсенеп караганнар бит. Талантлы кешеләр, күрәсең, гел шулай гаҗәпләнү тудыралар булса кирәк. Бик нык үтенәм сездән...

Фукс бераз уйланып торды да, ниһаять, кискен карарга килеп:

— Пушкин үтенече минем өчен изге. Әйдә, ул кызың иртәгә минем янга килсен! — диде.

— Рәхмәт, Карл Федорович!

Алар сөйләшкәндә каядыр чыгып киткән Александра Андреевна әйләнеп керде һәм тантаналы итеп:

— Әфәнделәр! Залга яшьләр җыелган. Бер генә танцыга булса да, Александр Сергеевичның чыгуын үтенәләр,— диде.

— Бик рәхәтләнеп! — диде Пушкин һәм хуҗа хатынга ияреп чыгып та китте.

Залда өч кыз — хуҗалар кызы һәм аның ике дусты көтеп торалар иде. Уртача буйлы, өстенә кара фрак кигән, бөдрә чәчле һәм куе чигә сакаллы бу кунак әфәнденең Пушкин икәнен белгәч, алар өчесе дә авызларын ачып, шаккатып калдылар. Ул арада Пушкин, тиз генә барып, тәрәзә төбенә пистолетын куеп килде дә кызларның берсен вальска чакырды. Аннары икенчесе, аннары өченчесе белән биеде.

## 12

Таң беленгәндә Пушкинның ишеген шакый башладылар.

— Александр Сергеевич! Казан почтамтыннан ямщик килде!

Александр шундук танып алды: Мәрьям тавышы иде бу.

— Рәхмәт, Марютка! Мин әзер!

Тиз-тиз генә киенеп, Александр гостиница коридорына чыкты. Башына эшләпә, өстенә шинель кигән иде ул.

Гостиница ишеге төбендә аны Мәрьям куып җитте дә:

— Александр Сергеевич, Идел буена кадәр генә булса да озатырга мөмкинме сезне? — диде.

— Бик мөмкин!..

Идел ярына җиткәч, ямщик атларын туктатты. Әле кояш чыкмаган, әмма инде җил кузгалган һәм Идел өстендәге ак томанны ерткалый-куа башлаган иде инде. Су өстендәге шул томан ничектер Иделдән чыккан сулыш сыман булып тоела. Бигрәк гаҗәеп һәм мәһабәт икән шул Идел! Хәзер ул, әнә, тыныч кына җәйрап ята. Ә җил-давыл вакытларында чал дулкыннарын уйнатып, ачуланып алган чаклары да була бит аның. Кай заманнардан бирле туктаусыз агып тора икән инде ул? Кемнәр генә йөзмәде икән аның суында. Күпме йөк күтәргәндер ул! Яз көннәрендә, боз киткән вакытларда аеруча куәтле буладыр ул. Күрәсе иде үзен бер шул ташыган чагында! Хәер, ул хәзер дә бик зур, бик иркен һәм ару-талуны белмичә, ага да ага. Менә шушы Идел шикелле, артка әйләнеп карамыйча, үз-үзенә сокланып, тукталып тормыйча, эшләргә кирәк, эшләргә! Гел алга таба барырга кирәк!

Александр байтак вакыт бер сүз дә эндәшмичә, Иделгә карап, тын гына торды. Аннары Мәрьямгә борылды:

— Табигать белән икәүдән икәү генә калган вакытларда игътибар белән тынлап торсам, кинәт миңа тавышлар, сүзләр ишетелгәндәй, җырлар яңгырагандай тоела башлый. Сиңа шулай тоелганы бармы, Мәрьям?

— Бар, Александр Сергеевич. Бик күп мәртәбәләр шулай булганы бар!

— Димәк, дөрес икән. Җирнең үз тавышы бар шул аның! Тик аны чын күңелдән, бөтен йөрәгең белән бирелеп тынлый белергә генә кирәк. Менә Иделгә генә кара. Үз гомерендә нинди генә хәлләр күрмәгән инде ул! Халык аның моңын тынлап торган да, отып алып, җырга салган. Степан Разин турындагы җырны әйтүем! Ул җыр — Идел үзе бит инде! Моңы да, көче-куәте дә, характеры да шушы Иделнеке!

Таң җиле һаман көчәя барганлыктан, өстенә юкарак кына киенгән Мәрьям туңа башлаган иде. Пушкин йомшак кына итеп аның иңеннән тотты да:

— Хуш, Марютка! Туңа башладың, бар кайт инде. Хуш! Мин сине беркайчан да онытмам! — диде.

— Мин дә сезне онытмам, Александр Сергеевич!

— Карл Федоровичның лекцияләрен тыңла! Григорий Степановичныкына да йөр. Алар сине кимсетмәсләр. Ә хатын-кызларның язмышы тиздән үзгәрәчәк. Бөтен ил язмышы үзгәрәчәк!

Пушкин кызның битен үпте дә коляскасына менеп утырды. Аннары ямщик дилбегәсен тартты һәм, кыңгырауларын чылтыратып, атлар юыртып китте.

Салкын җил исүен дә, үзенең туңып калтырана башлавын да онытып, Мәрьям коляска тәмам күздән югалганчы карап торды.

* * *

Ул көннән соң өч ел ярым вакыт үтте.

Казан император университеты студентлары рус теле профессоры Суровцевны көтеп торалар иде. Лекцияләр башлануын белдереп, кыңгырау шалтырагач профессор аудиториягә килеп керде дә, гадәттәгедән акрынрак атлап, кафедра янына барып басты. Йөзеннән каны качкан, күзләре уйчан иде аның. Бу хәлне күреп, студентлар кинәт сагаеп калдылар.

— Әфәнделәр, басыгыз! — диде профессор.

Барысы да аягүрә бастылар.

— Поэзиябезнең кояшы батты... Пушкин юк инде хәзер,— диде Суровцев.

Кинәт бер студентка йөрәк өзгеч нечкә тавыш белән кычкырып елап җибәрде. Ул — Мәрьям иде. Студентларның барысы да тып-тын калып, аптырашып торалар иде.

Профессор дулкынлануын күрсәтмәс өчен йөзен читкә борды. Кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды. Аннары, студентларга карап, сүзен дәвам итте:

— Рус шагыйрьләренең иң зурысы табутта ята. Аның гәүдәсен Петербургтан каядыр еракка алып киткәннәр. Ихтимал, аны әле күмәргә дә өлгермәгәннәрдер...

Григорий Степанович Суровцев беркавым залда утыручыларга карап торды да, кискен итеп:

— Пушкинның табуты ябылмас борын ничек итеп рус теле турында сүз алып бармак кирәк? Бүген лекция булмый! — диде.

Русчадан **ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН**
тәрҗемә итте.

Нигъмәт Ихсанов

# БАТЫР ЭШТӘ БЕЛЕНЕР

ОЧЕРК



Кайдадыр шушы тирәдә баядан бирле самолет гүли иде. Карт очучы Аксубаев, учакка коры чыбык ташлый-ташлый, аучы иптәшенә:

— Биредә нишләп йөри ул? Самолетка бер-бер хәл булмады микән,— дип әйтеп куйды.

Озакламый чыннан да ПО-2 самолеты күренде. Ул нидер эзләгән кебек, әле өскә менеп китә, әле, урман эчендәге ниндидер җәнлекне эзәрлекләгән сыман, аска кадалып төшә иде.

— Шайтан алгырый! Самолетның бер-бер нәрсәсе ватылган булырга тиеш. Әнә бит, җиргә төшәргә ачык урын эзли,— диде карт очучы, арлы-бирле йөгергәләп...

«Зың-ң-зың-ң!» иткән металл тавышы ишетелде. Кабина тәрәзәсендә май таплары күренә башлады. «Нәрсә булыр бу?» — дип уйланды очучы, машинаның дерт-дерт итеп китүен тоеп. Штурвалны борганда, самолет теләр-теләмәс кенә буйсынган кебек. Май таплары тиз арада арта барып кабина тәрәзәсен каплый башлады. Очучы, әле бер приборга, әле икенчесенә кагылып, бу хәлнең сәбәбен эзләде. Басым һаман кими, двигатель кыза бара иде.

«Эш шәптән түгел, май килми»,— дип уйланды очучы, урман өстендә әйләнеп. Ул җиргә төшәргә ачык урын эзләгән арада, температура тагы да артты. Моннан да ары двигательне эшләтеп булмый: кыза-кыза очкын чыгып, самолетка ут кабуы мөмкин. Очучы, рычагны кисәк кенә үзенә тартып, самолетны тагы да өскәрәк күтәрде һәмерактарак күл чите күрде. Якыная башлагач, газны туктатып, кош шикелле әле бер як канатка, әле икенчесенә авыша-авыша җиргә юнәлде.

Аксубаев, түбә җиргә йөгереп менеп, кулын болгый-болгый:

— Егет тә икән үзе! Шушындый кара урман эчендә дә төшәр җир тапты бит! Исән-аман төшеп утыр, коллега! — дип кычкырды.

Самолет җиргә төште. Тигезле-тигезсез түмгәкләр өстендә каты гына сикергәләп алды.

Пилот ашыкмыйча гына кабинадан чыкты, тирә-юненә күз салгалап күл читенә килде. Иелеп, битен салкын су белән юды.

Каушамыйча, тыныч исәп белән әлеге самолетны өч чакрым биеклектән җиргә төшереп утырткан очучы — Өлфәт Мостафин иде.

Кечкенә чагында Өлфәт үзенең яшьтәшләре — Митрәй Әюп авылы малайларыннан бер ние белән дә аерылып тормагандыр. Үз авыллары яныннан борыла-сарыла тайга урманнары эченә китеп югала торган Базы елгасында көзләрен боз өстендә



тимераякта шуарга ярата ул. Җәй көне исә яшьтәшләре белән көн озын судан чыкмый. Ул, аучыларга ияреп, Чарлак буе күленә ауга бара.

Калкулыклар арасында яшел хәтфә төсле булып җәелеп яткан туган як кырлары нинди ямьле! Бакыр тау үзе генә дә дөньядагы иң зур таудыр кебек тоела Өлфәткә.

«Безнең авылдан, Базы елгасыннан да матур җир юк дөньяда»,— дип уйлый малай.

Өлфәткә кечкенәдән үк машина, техника «җене» кагыла, автомобильнең шулкадәр тиз йөрүен күреп шакката ул.

Кеше һәрвакыт эзләнә: геолог җир байлыкларын эзли, астроном ерак дөньялардан яңа сигналлар көтә, яңа йолдызлар ачарга хыяллана. Язучы үзенең яңа геройларын эзли. Эзләү, эзләнү — кешенең табигатенә хас сыйфат.

Өлфәт механикадан, һавадан, машиналар тизлегеннән үзенең киләчәген эзли.

Малай чагында ул, авыллары өстеннән самолет очып киткәндә: «Бар бәхетле кешеләр! Алар үзенә бер төрле кешеләрдер»,— дип хыялланып кала. Ә бер тапкыр әтисе белән Бөре каласына баргач, Агыйдел елгасына суга самолет төшеп утыра. Өлфәт калкавычлар өстендә чайкалып торган самолетны күрә. Ул моның матурлыгына шулкадәр соклана, машинаның тышкы рәвешен һәм төп детальләрен хәтерләп калып, өйләренә кайткач, үзе кереп утырырлык итеп фанердан зур гына самолет ясый. Моны иптәш малайларына күрсәтергә ояла. Шулай да яшьтәшләре сарай ярыгыннан самолетны күрәләр, дусты Рәүф аңардан: «Нихәл, җәяүле очучы?» — дип көлә, башкалар да: «Самолетың шәп тә, бензин сала торган җире юк икән!» — диешәләр.

Өлфәт кызарынса да, югалып калмый:

— Үземә ошады да ясадым. Сезнең кебек, ишәккә охшаган ат юнып утырмыйм,— дип җавап кайтара.

Язын карлар эреп, Бакыр тау битендә яшел чирәм шытып чыга башлагач, Өлфәт иптәш малайлары белән тау башына менә. Яшел басуларга, Базы елгасына, туган авылына карап: «Самолеттан тагы да ераграк күренәдер»,— дип хыяллана. Кич, уйнап арыгач, тау наратлары башына үрмәли-үрмәли ертылып беткән ыштаннары белән өйләренә кайтып керә. Билгеле, Өлфәткә моның өчен әнисеннән яхшы гына эләгә. Ә бервакыт, самолетның бер җиренә куярга дип, бабасыннан калган иске иярнең каешын кисеп алгач, әтисе Хөсәен абзый да малайны кыздыра:

— Бабаңның истәлеге иде бит ул. Шушы иярга атланып, күпме бүре үтерген бабаң. Ә син аны нишләткәнсең? — ди. Шулай да малайга кул якмый.

1941 елда, авыр сугыш башланыр елны, Өлфәт Мостафин сигезенче классны тәмамлый. Өлкәннәрне көн саен фронтка алып торалар, алар урынында тылда, завод-фабрикаларда, колхозларда иртә таңнан караңгы төн җиткәнче хатын-кыз, картлар эшли. Яшьләрне һөнәр мәктәпләрендә укыталар. Алар укып кына калмыйлар, фашистларны җиңү өчен, өлкәннәр шикелле, бөтен көчләрен биреп эшлиләр.

Шуларның берсе унбиш яшьлек Өлфәт була. Уфада чактагы елларын искә төшереп, Өлфәт болай дип сөйли:

«Мәктәпләрне ябып, анда фронт ягыннан күчеп кайткан семьяларны урнаштырдылар. Көненә уникешәр сәгать эшлибез, айга бер-ике генә көн ял эләгә иде. Мастер мине күгәреп беткән бер станок янына алып килде дә шуны сүтеп, детальләрен юарга

аннары яңадан җыярга кушты. Ул чакта әле минем кулыма ачкыч та тотканым юк, гайканы кайсы якка борырга кирәклеген дә белми идем. Шулай да станокны әйтелгән вакытыннан алда җыеп куйгач, мастер яныма килде дә:

— Булдыргансың, молодец! Мәнә фронтка беренче ярдәмең тиде. Бу — револьвер ясый торган станок, агай-эне! — диде.

Минем фронтка беренче ярдәмем шундый булды».

Бераз вакыттан соң Өлфәт самолет двигательләре заводында эшли башлый. Аны комсомолның цех комитеты секретаре итеп сайлыйлар. Секретарьның характеры җыелышларда гына күренеп калмый, ә җанлы хезмәт үрнәгендә дә ачыла. Башкалар аңардан үрнәк алалар.

Өлфәтнең күптәнге хыялы тормышка аша: ул аэроклубка укырга керә. Әтисе белән әнисенең моңа ризалык бирмәячәкләрен белеп, ул башта берни дә белгертми. Комиссия яраклы дип тапкач, әти-әнисе аның белән әч көн буена сөйләшми, тик дүртенче көнне генә әтисе:

— Ярар, бар, укы. Алла юлдашың булсын,— ди.

Мәнә беренче тапкыр очарга әзерләнә ул. Беренче тапкыр кулы самолет штурвалына тия. Яхшы очучы булыр өчен техниканы белү генә җитми, үзеңне, характерыңны да җитлектерергә кирәк.

Бөтен ихтыяр көчеңне туплап, һәрбер көтелмәгән хәлгә әзер булу — пилот өчен закон ул. Мотор эшләгәндәге чак ишетелерлек чит тавышларны тоя белү очучының килачәген билгели. Мәнә беренче очыш тәмам. Винт туктап кала. Өлфәт, дулкынланып, инструкторның ни әйтәсен көтә.

— Яхшы! Әйбәт очучы булырсың! — ди ул.

Инструкторның сүзе раслана. Әле кичә генә очучылар мәктәбенең курсанты булган Мостафинга кешеләр язмышын — яшь очучыларны өйрәтү эшен тапшыралар. Өлфәт үзенә хас таләпчәнлек һәм сабырлык белән яшь пилотларда батырлык, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләргә тырыша. Курсантларга ул:

— Һавада үзегезне җирдә күнегү бүлмәсендәге шикелле хис итмәсәгез, сездән очучы чыкмаячак,— ди. Очкан чакта яшь пилотның һәр кул хәрәкәтенә игътибар итеп, самолетны йөртү осталыгына өйрәтә. Курсантка теорияне берничә тапкыр укыттырырга, аны рычаг, секторлар, штурвал, педальләр белән эш итәргә кат-кат өйрәтергә мөмкин. Тик бу эштә таләпчән булу белән бергә, иптәшләрчә мөгамәлә дә кирәк. Чак кына саксызлык күрсәтеп, кешенең күңелен гомерлеккә рәнҗетүең мөмкин. Мостафинны өйрәнчекләре бер үк вакытта таләпчән дә һәм кешелекле, яхшы күңелле инструктор булганы өчен дә яраталар.

...Дөньяда төрле кешеләр бар. Шундый кешеләр була: аларга теге яки бу мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итсәң, ничектер хәтерең кала, аның өчен дә, үзең өчен дә күңелең рәнҗи. Соңыннан ул кеше белән очрашуыңа үкенәсең. Шундыйлары да була: аның кабинетыннан чыккач, үзеңне кечерәя төшкәндәй хис итәсең. Ләкин андый кешеләрне эзләмиләр. Мин дә башка төрлене эзләгән идем. Эзли торгач таптым. Бу җитәкче кеше белән сөйләшеп утырганнан соң, күңелең ничектер җылынып, яктырып, күз алдың ямьләнеп китә, бу кешенең уй сөреше, фикер ачыклыгы сине бөтенләе белән биләп ала. Аның белән очрашып сөйләшкәч, үзең дә яхшыра төшәсең, барыннан да бигрәк, үзеңне бәхетле хис итәсең.

Гражданский авиациянең зур гына бер предприятиесе җитәкчесе ул Өлфәт Хәсәенович Мостафин.

Бу кешенең биографиясе дә кызыклы. Аңа 44 яшь. Шуның 24 елы укып узган. Ике ел очучылар мәктәбендә укыган. Тугыз елга якын инструктор булып эшләгән. Читтән торып, Киевтәге Гражданский авиация институтын укып бетергән. Югары очыш мәктәбен ике тапкыр тәмамлаган. Уфада эшләгән. Анда аны коллективның партия бюросы составына, аннары КПССның Уфа шәһәре Киров райкомы пленумы составына сайлыйлар. Хәзерге вакытта ул Казан шәһәре Совет райкомының пленум члены, Казан шәһәре хезмәт ияләре депутатларының шәһәр Советына икенче тапкыр депутат булып сайланган.

Мостафин — нык характерлы кеше. Кайвакытларны арыганнан, талчыкканнан аварып та алгалый. Андый көннәрне ул өенә кәефсезрәк кайтып керә.

— Нишләптер кәефем юк әле,— ди хатынына. Шулай да кичен соң гына, яки иртән иртүк тагы эш урынында, самолет моторлары гүләвен басарга теләгәндәй, калын тавыш белән гади хезмәткәрләр белән сөйләшеп йөри. Яисә ул, экипажның ничек эшләвен тикшереп, берәр самолетта очып әйләнеп кайтырга да өлгергән була.

Коллективтагы кешеләрнең яхшы карашын яулап алу, аларга җитәкче була белү — бик зур эш ул. Моңа зур тырышлык белән, үзеңә йөкләнгән эшне яхшы белеп, гомум-дәүләт күзлегеннән, ә бу очракта көн саен самолетларда килеп-китеп торучы меңләгән пассажирлар интересыннан чыгып башкарганда гына ирешергә мөмкин.

Хезмәткәрләр аны яраталар, хөрмәт итәләр, ләкин кешелекле кеше булганы өчен генә түгел. Хәзерге вакытта экономика һәм кеше ихтыяҗы өчен эшләү омтылышы кешеләрнең психологиясе белән тыгыз бәйләнгән. Хәзер иң төп психологик үзгәреш: искедән баш тартып, яңача эшләү омтылышы туып килә.

— Яңача планлаштыру һәм экономик кызыксындыру шартларында эленке-салынкы эшләп булмый. Безнең өчен көн саен яңадан-яңа мәсьәләләр туып тора. Беребез дә тынычланып яшәргә тиеш түгел,— диган иде бервакыт Мостафин предприятие җитәкчеләре киңәшмәсендә.

1929 елда Казанда пыскы фонарь яктысында эшли башлаган кечкенә генә заправка станциясен локаторлары, самолетларны төнлә дә, томанда да җиргә төшереп утыртa торган системасы булган хәзерге аэропорт белән, ул замандагы килбәтсез ПО-2 ләрне хәзерге ТУ-124 лайнерлары белән чагыштырсаң, җир белән күк арасы кебек.

1968 елда самолет белән миллионнан артык пассажир юл йөргән — республикабызның өчтән бер кешесе диган сүз бу. Ун мең тонна йөк ташылган, колхоз һәм совхозларда алты йөз мең гектар җир эшкәртелгән. Планнан тыш йөз алтмыш дүрт мең сум табыш алынган. Казан авиаторлары Татарстан республикасының илле еллыгы кенә ярты еллык планны 100% ка үтәргә планлаштырып торалар. Коры ният кенә түгел, реаль нигезгә корылган эш бу. Партия-профсоюз коллективының тырышлыгы, омтылышы, җитәкчеләр белән бердәмлеге дә моңа зур этәргеч булачак.

Дәһшәтле авыр сугыш заманында Өлфәтнең яшьлеге бушка узмаган. Төннәр буе йокламыйча, аэроклубка ярым ач, җәяү йөреп алган белемнәре аның алдагы тормышына таяныч, нигез була. Шул елларда аның характеры, ихтыяр көче чыныга, тырышлык сыйфаты тәрбияләнә. Аэроклубны курсант булып тәмамлаганнан соң шундый ук курсантларны самолетта очу осталыгына өйрәтүче инструктор булып китү һәркемнең сәләтеннән килә торган эш түгел.

Мин һәр очучыга бирә торган соравымны Мостафинга да бирдем:

— Бик күп очу дәверегездә нинди кыенлыкларга очраганыгыз булды? — дидем.

Ул миңа карап елмайды да:

— Кыен хәлләргә очрау мәҗбүримени? Бер тапкыр сүнгән двигатель белән җиргә төшеп утыру кебек кечкенә бер очрактан башка куркыныч хәлләр булмады,— диде.

— Кечкенәмени бу? — дип каршы төштем мин.

— Гадәттә очучы самолетны җиргә төшереп, һәлакәттән коткарып калса, моны батырлык саныйлар. Аларны «ас» дип, тәҗрибәле очучы дип атыйлар. Егерме елга якын очу дәверендә миңа әнә шул «батырлык»тан башка бернинди хәтәр хәлгә очрарга туры килмәде. Бу бик нормаль хәл,— диде Өлфәт Хәсәенович, елмаеп.

Хәзер ул, үзенең иң якын хезмәттәшләре — политик эш буенча урынбасары Евгений Гаврилович Зинченко, партбюро секретаре Евгений Иванович Варфоломеев һәм профсоюз җитәкчесе Алевтина Сергеевна Чайковская белән бергәләп, партия куйган бурычны — заман таләп иткән прогрессны тормышка ашыру эшендә эшли.

Әгәр: «Кеше кайчан кеше булып формалаша?» — дип сорасалар, «Бала чагыннан, үсмер чагыннан ук»,— дияр идем мин. Ләкин кеше булып җитлегү — характер формалашуның соңгы ноктасы дип кем әйтә алыр! Казан предприятиесендә эшләү дәвере Өлфәткә җитәкче буларак өештыру осталыгы, үз сәләтеңә ышану көче китермәдемени? Аның характеры көн саен чарлана, эшкә ипләшә бармыймыни?

Минемчә, кешегә бервакытта да:

— Тукта, җитте, булды. Син барлык сыйфатка да ирештең! — дип әйтеп булмый. Юк, кеше бүген дә, иртәгә дә, гомер буена да һаман эшли, иҗат итә, камилләшә бара.



## ХӘСӘН ХӘЙРИГӘ 60 ЯШЬ

# АЛГЫ САФТА

*Утызынчы еллар башы. Илдә яңа тормыш төзү өчен каты көрәш бара, илне социализм нигезләрендә үзгәртеп кору өчен киеренке хезмәт гөрли. Шул елларда әдәбият мәйданына завод-фабрикалардан, шахталардан, зур төзелешләрдән һәм авыл кырларыннан әлеге көрәш һәм хезмәт пафосы белән рухланган бер төркем яшьләр килә. Алар арасында үзенең тормыш юлын беренче бишьеллыклар гиганты Кузнецк металлургия комбинаты төзелешендә башлаган Себер егете Хәсән Хәйруллин да була. Әдәбиятка ул хезмәт энтузиазмын чагылдырган очерк, хикәяләре һәм шигырьләре белән килеп керә. Аның 1934 елда «Зур Кузбасс өчен» һәм «Тавышлы ялкын» исемле беренче җыентыклары басылып чыга. Болардан тыш, ул «Азат Себер», «Совет Татарстаны» газеталарында һәм «Совет әдәбияты» журналында күп кенә очерклар, хикәяләр бастыра.*

*Заман белән бер адымга бару теләге соңрак аны әдәби хәрәкәтнең аерүча хәрәкәтчән һәм җаваплы тармагына — тәнкыйть өлкәсенә алып килә. Чын тәнкыйтьче булу өчен, чор, заман сулышын нык лап белүдән тыш, җитди әдәби-теоретик әзерлек тә кирәк. Шуны яхшы аңлаган Хәсән Хәйри үзенең белемен күтәрүгә күп игътибар бирә. 1950—53 елларда ул КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясендә аспирантурада укый. 1953 елда, аны уңышлы тәмамлап, «Сугыштан соңгы татар әдәбиятында социалистик реализмның үсеше өчен көрәш» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.*

*Татар совет әдәбиятына багышланган күп санлы мәкалә һәм рецензияләрендә Х. Хәйри үзен әдәби хәрәкәтне тормыш белән аерылгысыз бәйләнештә өйрәнүче, әдәбиятның өлгергән мәсьәләләрен үз вакытында һәм кыю рәвештә күтәреп чыгучы, әдәби күренешләр турында принципиаль фикер йөртүче тәнкыйтьче итеп танытты. Аның «Эзләнүләр» (1941), «Әдәбият һәм тормыш», «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1960) кебек җыентыкларында әдәбиятыбызның мөһим проблемалары яктыртыла. Ул шулай ук зур-зур монографияләр һәм дәреслекләр авторы да.*

*Хәсән Хәйри — үз-үзенә таләпчән, өзлексез эзләнә торган тынгысыз тәнкыйтьче. Әгәр ул узган иҗат юлына күз салсак, без аның вакытлы кыенлыкларны җиңә-җиңә туктаусыз алга атлавын, идея-эстетик карашларының елдан-ел тирәнәя, камилләшә баруын күрербез.*

*Әдәби тәнкыйть өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеген Хәсән Хәйри зур җәмәгать эшләре белән бәйләп алып бара. Бөек Ватан сугышы елларында ул «Совет сугышчысы» исемле фронт газетасында, аннан кайткач, 1947 елга кадәр партиянең Татарстан өлкә комитетында эшли. Озакламый Хәсән Хәйри «Совет мәктәбе» журналына җаваплы редактор итеп билгеләнә. 1953—59 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтына җитәкчелек итә, хәзерге көндә шул институтның әдәбият секторы мөдире булып эшли.*

*Үзенең хезмәт бәйрәмен Хәсән Хәйри гыйльми иҗат өлкәсендә яңа үрләр яулап, ачыграк әйткәндә, татар совет романына багышланган зур монографик хезмәт тәгаллә каршылый.*

**Ф. МУСИН.**

Хәсән Хәйри

# РОМАН ҺӘМ АНЫҢ ГЕРОЕ

Прозаның җитлегүен халык тормышын киң планда тасвирлаган зур эпик әсәрләр — роман белән повестьлар билгели. Андый әсәрләр, һичшиксез, әдәбиятның гомуми үсешенә дә җитди йогынты ясый. Моны татар әдәбияты тарихыннан да күрергә мөмкин. Сугыштан соңгы елларда безнең прозабыз чагыштыргысыз дәрәҗәдә алга китте, бигрәк тә төрле типтагы повесть, романнарга баеды. Соңгы вакытта бездә ел саен диярлек берничә роман дөньяга чыга. Бөек Ватан сугышына кадәр унсигез — егерме роман туган булса, сугыштан соң инде кырык яңа роман язылган. Дөрес, хикмәт санда гына түгел, сыйфатта да. Татар совет романы хәзер нык алга китте. Эчке төзелеш, тел-стиль ягыннан булсын, герой төрлелеге, тематикасы киңәю ягыннан булсын, ул зур үзгәреш — яңару процессы кичерә. Хәзер инде безнең романнарның бер өлеше бөтенсоюз мәйданына чыкты. К. Нәҗми, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Ә. Фәйзи, Ф. Хөсни, И. Гази, М. Әмир, А. Расих, Г. Ахунов, Н. Фәттах романнары рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителде. Эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше белән бөтенсоюз мәйданына кыю чыгарлык, күп миллионлаган укучылар каршында җитди сынау үтәрлек киң колачлы әсәрләр тудыру бурычы, әлбәттә, бүген дә көн тәртибеннән төшмәгән.

Соңгы унбиш елны повесть һәм роман чоры дип атарга мөмкин. И. Газиның «Онытылмас еллар», М. Әмирнең «Саф күңел», Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр» романнары, Г. Бәшировның «Таң беленгәч», «Туган ягым — яшел бишек», И. Туктарның «Ике егет» исемле әсәрләре, Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», Ш. Маннурның «Муса», Г. Ахуновның «Хәзинә», «Хуҗалар», А. Расихның «Ике буйдак», «Ямашев», С. Рафиковның «Беренче яз», «Авыл иртәсе» романнары һәм шулай ук Н. Фәттах, И. Салахов, Э. Касыймов, М. Хәсәнов романнары, Г. Гобәй, Ә. Еники, Г. Минский, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Б. Камал, Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов һ. б. повестьлары бүгенге прозабызның җанлы хәрәкәтен, яңа омтылышларын чагылдыралар. Хәзерге прозабызда халык тормышындагы зур тарихи вакыйгаларны, тормыштагы төп конфликтларны художник күзе белән күреп сурәтләү, алар турында уйлану, бигрәк тә кешегә, аның рухи тормышына игътибар итү тенденциясе көчәя һәм тирәнәя бара. Кыскасы, әдәбият фәнендә кабул ителгән сүз белән әйтсәк, аналитик тенденция нык тамыр җәя. Тормыш яңалыгын, тарих героен һәм заман героен, аларның үзенчәлекле психологик портретын, мораль йөзен, идеалларын ачарга тырышу бигрәк тә роман һәм повестьларда тулырак күренә. Шунысы да бик характерлы: сугыштан соңгы иң яхшы романнарыбызда эчке киеренкелек, драматизм, вакыйгаларны кеше язмышы, уй-кичерешләр белән органик рәвештә тыгыз бәйләп бирү көчәйде. Монда язучыларның чынбарлыкка актив мөнәсәбәте, темаларны мораль-әхлак планында тирәнрәк ачарга омтылышлары күренә. Шуның белән бергә лиризм да көчәйде. Бу яктан, мәсәлән, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Э. Касыймов, Ә. Еники, А. Гыйләҗев әсәрләре бик үзенчәлекле. Безнең романистикада хәзер иҗтимагый-психологик һәм тарихи-иҗтимагый романнар төп урынны алып торалар. Бу факт, һичшиксез, безнең прозаикларның тормыштагы зур иҗтимагый мәсьәләләрне, чынбарлыкның иң әһәмиятле вакыйгаларын тулырак яктыртырга теләүләре белән дә бәйләнгән. Әйткәнебезчә, И. Газиның «Онытылмас еллар», М. Әмирнең «Саф күңел», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романнарында эпик киңлек, эпик сурәт-характерлар бар. Бу әсәрләрдә татар халкының тормышында барган тарихи үзгәреш, революцион, социалистик аң үсү процессларының дөрес чагылышы, объектив эпик хикәяләү бар.

Мондый әсәрләр безнең романның социалистик реализм әдәбияты юлыннан кыю адымнар белән, новаторларча туктаусыз алга атлавын күрсәтәләр.

Прозабызның тематик диапазоны һаман киңәя баруын да уңай бер күренеш дип әйтеп үтәргә кирәк. Кайчак «әшне тема хәл итми бит» дип әйтүләр дә очрый. Асылда бит тема язучының реаль тормышка мөнәсәбәтен, чынбарлыкның кайсы ягына игътибар итүен, нәрсә белән кызыксынуын, иҗат объектын, материалын билгели торган факторлардан берсе. Моңарчы безнең әдәбиятта авыл тематикасы төп урынны алып килде (хәзер дә ул шулай), эшчеләр тормышына җитәрлек игътибар бирелмәде, ә моның соңгы чиктә әдәби-иҗат эшендә бертөрлелек, тарлык тудыруы ихтимал иде. Соңгы елларда чыккан әсәрләр бу кимчелекнең бетә баруын, әдәбиятыбызның тематикасы һәм проблематикасы сизелерлек киңәюен күрсәтәләр. Татар халкының революцион көрәше, аның үткән тарихы белән кызыксыну, татар авылында булган яңа иҗтимагый үзгәрү процессларын, социалистик тормыш нигезендә крестьяннарда революцион аң, революцион психология формалашуы процессларын сәнгатьчә тикшереп сурәтләү, совет эшчеләр сыйныфының героик хезмәте, бөек көрәшкә рухландыручан көче, яңа яшь буынның чыныгып үсүе, Татарстан нефтьчеләре тормышы һәм башка бик күп темалар, күпкырлы, катлаулы реаль чынбарлыкның төрле яклары, төрле катлаулары бүгенге әдәби иҗат үзәгендә торалар һәм бүгенге әдәбиятыбызның тематик колачын билгелиләр. Шулай да совет эшчеләр сыйныфы тормышы, җәмгыятьнең төп җитәкче көче булган эшчеләр сыйныфы көрәше, аның үсеше, рухи-психологик үзгәрешләре безнең әдәбиятта әле җитәрлек тулы чагылмавын әйтеп үтәргә кирәк.

Татар совет романында хәрби тема, Бөек Ватан сугышы темасы да күренекле урын алып тора, һәм бу гаять әһәмиятле, зур тарихи патриотик тема белән кызыксыну, һичшиксез, киләчәктә дә кимемәс. Бу өлкәдә аеруча Г. Әпсәләмовның уңышлы иҗади эшчәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Аның укучылар арасында киң таралган «Алтын йолдыз», «Газинур» һәм «Мәңгелек кешe» әсәрләре тема-проблема ягыннан гына түгел, героик образлары белән дә, эчке төзелешләре, төрләре белән дә безнең хәзерге романга яңалык өстәделәр. Ниһаять, М. Әмирнең роман-эпопеяга якын торган «Саф күңел» («Ялантау кешеләре») туды, Ш. Маннур күп еллар буена эшләгән беренче романын, совет кешеләренең бөеклеген, рухи ныклыгын чагылдырган, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең онытылмаслык образларын сурәтләгән зур күләмле «Муса» романын дөньяга чыгарды. Нәби Дәүли «Җимерелгән бастион» романы белән газаплы сугыш хәлләренең яңа якларын ачып салды.

Татар әдәбияты тарихында роман жанры төрле үсеш баскычларын, төрле этапларны үтте. Аның сугыштан соңгы чордагы үсеше, ирешелгән зур уңышлары, әлбәттә, элекке традицияләргә, тәҗрибәләргә нигезләнгән, һәм татар романының хәзерге этапы — яңа күтәрелеш, яңа үсеш этапы. Үкенечкә каршы, бу мәсьәләгә бер яклырак караш та очрый әле. Тарихи үсеш процессын, элекке этапларның үзенчәлеген исәпкә алмыйча, татар әдәбиятында чын роман бары тик сугыштан соң гына туды, дигән бәхәсле бер фикергә тукталып үтмичә булмый. Ул мәсьәлә герой образы, романда характер проблемасы белән дә бәйләнгән. Ибраһим Гази «Юл барганда» дигән мәкаләсендә, хәзерге әдәбиятыбызда күренгән уңай һәм тискәре тенденцияләргә бик мәгънәле күзәтүләр ясау белән бергә, бездә роман жанрының үсү тарихына да кагылып үтә. «Илле еллык әдәби хәрәкәт тарихында,— дип яза И. Гази,— минем күзгә ташлана торган, тәнкыйтьчеләр җитәрлек бәя бирми торган нәрсә шул: татар әдәбиятында роман барлыкка килде. Роман элек-электән бар, дип әйтүләре мөмкин. Хак сүз. Бар иде. Ләкин зур социаль вакыйгаларны эченә алган, заманга хас җанлы образлар тудырган романнар бары тик Ватан сугышыннан соң гына дөньяга килде. Элекке романнарны без роман-вакыйга дип атый алабыз. Хәзерге романнарны исә роман-образлар дип, яки образлы романнар дип атау дөрес булыр иде. Классик рус романнарының күп еллык тәҗрибәләре нигезендә туган бу романнар татар әдәбиятының соңгы егерме-егерме биш елдагы зур уңышы дип әйтсәм, ялгыш булмас» [1].

Күрәсез, И. Гази шактый кискен әйткән. Ләкин элекке романнарыбызга караган фикере тарихи чынлыкка һич тә туры килми. Әдәбият тарихыннан һәм фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, татар романы соңгы 20—25 ел белән генә чикләнми, аның үсеш тарихы шактый киң һәм формалашу юлы

[1] И. Гази. Юл барганда. «Социалистик Татарстан» газетасы. 19 сентябрь. 1968 ел.

да катлаулы. Көнбатыш һәм рус классик романнары безнең романның үсешенә гаять зур йогынты ясый, рус совет романнарының да йогынтысы зур. Әмма татар совет романының үсү, формалашуында Октябрьга кадәрге татар романнарының һәм шулай ук 20—30 еллардагы Г. Ибраһимов, Ш. Камал әсәрләренең тарихи ролен, безнең прозага булган йогынтысын күрмәү тарих фактлары белән исәпләшмәү яки әдәбиятның милли җирлеген, традицияләрен инкарь итү булыр иде. Аннары нәрсә ул «роман-вакыйга» һәм «роман-образ»? Алты-җиде ел элек күренекле совет язучысы Константин Симонов күтәреп чыккан «роман-вакыйга» һәм «роман-характер» мәсьәләсе буенча бәхәсләр бу билгеләмәләргә яхшы ук ачыклык кертте, дип уйлыйбыз [1].

«Образлар сүзенә басым» ясап, И. Гази безнең егерме-егерме биш ел элек чыккан романнарның да үзенчәлеген билгеләргә тели. «Роман-вакыйгада образлар әле ялангы хәлендә генә иделәр,— ди ул,— исеме бар, кылган гамәле бар, тик телгә кертерлек, әйдәп барырлык характерлар — образлар юк, образ, характер юк җирдә чын сәнгать тә юк». Тарих фактларына каршы килгән мондый берьяклы нәтиҗә белән, әлбәттә, килешеп булмый. Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ. б. романнары бары тик вакыйга сөйләүгә корылганмыни, аларда образ-характерлар да юкмыни? XIX йөз ахырында язылган З. Бигиев романнары өчен генә «вакыйга сөйләү», мәгърифәтчелек идеясе белән бәйле дидактизм күпмедер күләмдә характерлыдыр, бәлки. Ләкин ул әсәрләрдә үк инде Зөләйха, Хәдичә һәм Муса («Гүзәл кыз Хәдичә»), Маһруй, Якуп һәм Ибраһим («Гөнаһе кәбаир») кебек җанлы образ-характерләр сурәтләнә; романның хәзерге җитлеккән дәрәҗәсеннән карап кына ул әсәрләрне «сәнгатьтән читтә торган» дип бәяләү һич дөрес түгел.

И. Газиның татар романнарындагы яңа күтәрелешне күрергә һәм тирәнрәк аңларга теләвенә кушылмыйча булмый. Гомумән Октябрьдан соңгы әдәбиятыбыз төрле үсеш баскычларын кичерә, һәм зур әдипләребез бу үзгәрү, яңару процессын һәрвакыт сизеп торалар. 1930 елның башында ук, мәсәлән, Г. Ибраһимов мондый нәтиҗә ясый:

[1] Карагыз: Пути развития современного советского романа. Сборник статей. Рус телендә. Мәскәү. 1961 ел; М. М. Кузнецов. Советский роман. Рус телендә. Мәскәү. 1963 ел; История русского советского романа. Рус телендә. «Наука» нәшрияты. II том. 1965 ел.

«Әдәби җимешләребез эчендә совет пролетариат әдәбиятыбызның гөрләп үсеше бар. Үсеп чәчәк атышы бар. Иҗтимагый ягы белән дә, стиль, тип-характер-сурәт, композиция кебек форма ягы белән дә әдәбиятның байтак тармаклары инде классик аталган элекке әдәбиятны үтеп баралар, үтәчәкләр» [1].

Һичшиксез, дөрес фикер, әдәби хезмәтнең перспективалы үсеш, яңару процессын күз алдында тотып әйтелгән фикер. Ләкин бу элекке тәҗрибәләрне, казанышларны инкарь итү дигән сүз түгел. Элекке романнарыбызның уңай тәҗрибәләре җирлегендә үскән бүгенге романнарыбызда кеше характерын төрле яктан сурәтләү, чорның җанлы герой образын иҗат итү тенденциясе көчәйде. Хәзерге иң яхшы романнарыбызның тарихи-иҗтимагый мәйданы киңәйде, иҗтимагый тормыш белән шәхес язмышы бәйләнеше киңрәк куелып, тарихи һәм фәлсәфи тирәнлектә хәл итәргә омтылу нык сизелә. Югарыда әйткәнебезчә, хәзер бездә роман төрләре күбәйде, геройлар галереясе баеды. И. Гази, һичшиксез, менә шул процессны күз алдында тота һәм бу үзгәрешләрне дөрес сиземли, романчыларыбызның осталыгы күтәрелә баруын, үзенчәлекле иҗат йөзләре булган яңа романчылар әдәбиятка килүен дөрес күрә; социаль роман тирәнең бездә алгы сызыкта торуын билгеләве дә бик урынлы.

Безнең хәзерге әдәбиятта исә моның характерлы мисаллары итеп Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр», И. Газиның «Гади кешеләр», «Онытылмас еллар», М. Әмирнең «Саф күңел», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», «30 нчы ел», А. Расихның «Ике буйдак», «Ямашев», Г. Ахуновның «Хәзинә», Ш. Мануровның «Муса» романнарын һ. б. күрсәтергә мөмкин. Бу романнарда чынбарлыкны киң эпик планда аңларга һәм сурәтләргә, гомумиләштерүләр ясарга омтылыш бар, тарихи перспективалык бар; алар өчен халык тормышында хәлиткеч төп проблемалар җәмгыять һәм шәхес, тарих һәм кеше язмышы проблемалары, иҗтимагый тормышка сәнгатьчә анализ ясау, үз чоры геройларын күрсәтү характерлы. Андый әсәрләр чын тарихилык принцибына, иҗтимагый конфликт һәм шәхси конфликт бердәмлегенә, органик бер бөтен итеп тасвирлауга нигезләнә. Эре характерлар, зур шәхес язмышлары, әлбәттә, тарихи,

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Татиздат. 1960 ел. 217 бит.

иҗтимагый вакыйгалар, конфликтлар — бәрелешләр аркылы ачыла, һәм мондый әсәрләр «роман-вакыйга» гына булып калмыйлар, «роман-характер»ны да үзләрендә берләштерәләр. Киң колачлы роман — ул характерлар романы, социаль-психологик роман, ниһаять, роман-эпопея. Совет әдәбиятында моның классик мисаллары: М. Горькийның «Клим Самгин тормышы», М. Шолоховның «Тын Дон», А. Толстойның «Михнәт чигеп йөрү», М. Ауэзовның «Абай» роман-эпопеялары. Дөрес, бу эпопеялар рәтенә куярлык әсәрләр бездә юк әле, әмма шушы юнәлештә уңышлы эзләнүләр баруы бәхәссез. Сугышка кадәрге прозабызда моңа Г. Ибраһимов, Ш. Камал һәм М. Галәү романнарында нигез салынган булса, сугыштан соң бу тәҗрибә сизелерлек үстерелеп җибәрелде. К. Нәҗминең «Язгы җилләр»ен, Ә. Фәйзинең «Тукай» романын, И. Газиның «Онытылмас еллар», М. Әмирнең «Саф күңел» романнарын шушы юнәлештәге уңышлы һәм перспективалы тәҗрибәләр, матур үрнәкләр дип исәпләргә кирәк.

И. Гази мәкаләсендә кузгатылган «роман-вакыйга» мәсьәләсенә кайтыйк. Тәҗрибәле прозаикларыбызның берсе булган И. Газиның бу мәсьәләне бераз соңгарып булса да кузгатып җибәрүе бер дә урынсыз түгел. Сөйләргә нигез бар. Чынлап та, безнең бүгенге романнарда эре характерлар, зур язмыш, кабатланмас образ — тип иҗат итү урынына яссы описательностька бирелү, яки характерны сюжет, фабула эчендә «эретеп» җибәрү бармы? Әллә, И. Гази мәкаләсендә әйтелгәнчә, безнең элекке романнар өчен генә «вакыйга сөйләү» хас булган да, менә соңгы унбиш-егерме ел эчендә инде андый нәрсә бездә күренмиме, «кеше язмышын» сурәтләүче «образ-характер романнары» гына языламы? Әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән билгеле булганча, бернинди роман һәм аның герое «вакыйгадан», икенче төрле әйткәндә, иҗтимагый тормышның катлаулы, каршылыклы вакыйгаларыннан, кеше характеры формалашкан тарихи конкрет тирәлектән, ситуацияләрдән читтә була алмый. Һәр «вакыйга» кеше язмышына кагыла, кеше аның үзәгендә тора, иң беек хәл-әхвәлләр, үзгәрешләр дә кеше катнашы белән була. И. Газиның «Онытылмас еллар» романында сурәтләнгән Хәлим, Якуп, Шәрифҗан һәм Федюшкин образлары гына да моны раслый ала. Әдәбият үзәгендә дә, М. Горький әйткәнчә, кеше, конкрет кеше характерлары тора. Романда «вакыйга» һәм «характер» мәсьәләсен аерым карау яки каршы кую бернәрсә белән дә аклана алмый. Дөрес, кайбер романнарда «вакыйга сөйләү» белән мавыгу зур характерны сурәтләүгә осталык, тәҗрибә җитмәүдән булуы мөмкин. Ләкин бу очракта да образлылыкны инкарь итү дөрес булмас иде, чөнки аңсыз ул гомумән сәнгать әсәре була алмый. Романның төге я бу формасын өстен кую, шуны иң яхшы форма итеп канунлаштыру чикләнүчелеккә өндәү булыр иде.

Турысын әйткәндә, «вакыйга сөйләү» белән мавыгу, катлаулы зур характерлар иҗат итә белмәү безнең бүгенге романнарыбызда да нык сизелә әле. Әле дип әйтүемнең хикмәте шунда: 20—30 нчы елларда басылган беренче повесть һәм романнарыбыз (Ш. Усманов, Л. Гыйльми, бигрәк тә Г. Ильяс әсәрләре) андый кимчелектән азат түгелләр иде. Чынлап та, аларда характер, тип иҗат итү, геройның психологик портретын тирәнтен ачу кебек якларга җитәрлек игътибар бирелмәде. Бу яктан, һичшиксез, безнең хәзерге романистика чагыштыргысыз алга китте. Шулай да халыкның бүгенге тормышында барган зур иҗтимагый, культура, рухи үзгәрешләрен чагылдырган характер, герой образына, романның фәлсәфи тирәнлегенә тиешлечә игътибар биреп җиткермәү мисаллары бүген дә аз түгел. Мондый кимчелек, минемчә, соңгы вакытта дөньяга чыккан романнардан С. Рәфиковның «Авыл иртәсе», М. Хәсәновның «Саф җилләр» һәм «Юллар, юллар» романнарында нык сизелә.

Бу әсәрләр гомумән уңышсыз, аларда бернинди яңа образ юк дип әйтергә теләмибез, әлбәттә. Үсеп килгән сәләтле романчыларыбызның үз табышлары, заманы өчен хас тормыш детальләрен күрә белүләре бар. Биредә сүз романның үзәген, сәнгатьчә эчке көчен билгеләгән кеше характерын, геройның катлаулы җанлы образын тулы сурәтләүдә осталык җитеп бетмәү турында бара. С. Рәфиковның «Авыл иртәсе» романында сугыштан соңгы чорда авыл хуҗалыгындагы кыенлыкларны, авыл җитәкчеләренең инициативасызлыгы, аларның халык акылы һәм тәҗрибәсе белән исәпләшмәүләрен күрсәткән җанлы гына картиналар бирелә. Партия куйган яңа бурычлар нигезендә колхоз кешеләре арасында активлык, җаваплылык хисе көчәюе дә гәүдәләнә. Әмма боларның барысы да җанлы

кеше образы, кеше язмышы, кабатланмаслык характерлар аркылы бөтен тирәнлеге, психологик үзенчәлекләре белән ачылмавы аркасында, әсәрдә бирелгән вакыйгалар ничектер төп образларны «каплап» китәләр, шактый өлешендә публицистика, очерк стиле өстенлек итә башлый, әсәрнең гомумиләштерү көче тоныклана. Колхоз председателе Шәрифуллин да, парторг Садыйков та, райбашкарма комитеты председателе Яһудин дә, райком секретаре Хаков та шактый схематик образлар, чөнки аларны автор алдан уйланылган билгеле бер схема — әзер «тезис» буенча эшләгән, теге я бу «вакыйганың» шаһите итеп кенә сурәтләгән. Геройларның рухи дөньясы, эчке хәрәкәте йомшак, үзенә генә хас индивидуаль холкы-гамәле, газабы һәм шатлыгы аркылы ачылган эчке философик фикере бик тар, көчсез. Минә шуңа күрә дә, күрәсең, С. Рәфиковның бу романы, бик актуаль темага язылган булса да, безнең тәнкыйтьтә бик үк уңай бәя ала алмады һәм укучылар арасында да ул тиешенчә яңгырамады. Әйткәнебезчә, романда бөтенләй юк, авторның үз «мине», үзенчәлекле стиле дә нык сизелми, әсәрдәге образларга, вакыйгаларга автор мөнәсәбәте күбесенчә публицистик рухтагы юлларда ачыла, ә әдәби әсәрдә исә бу берьяклылыкка, әсәрнең эмоциональ көченә бәя биреп җиткермәүгә китерә. «Авыл иртәсе»ндә нәкъ шундый хәл килеп чыккан. Бу яктан караганда, С. Рәфиковның «Беренче яз» романы уңышлырак эшләнгән иде.

Реаль тормыш вакыйгалары эчендә төп образларны бөтен каршылыклары белән калку итеп сурәтләү урынына күбрәк вакыйга сөйләү, икенче төрле әйткәндә, иллюстрациягә бирелеп китү М. Хәсәнов романнарында да нык сизелеп килә. Аның нигездә уңышлы гына язылган «Саф җилләр»е дә моннан азат түгел. Геройның эчке үсеш логикасына, үзенә генә хас индивидуаль сыйфатларына художникларча игътибар итмәү аркасында, башта әйбәт кенә билгеләнгән образлар хис-тойгы тирәнлеге ягыннан көчсезләнә, тоныклана башлыйлар, ышандыру көчләрен югалта башлыйлар. Мәдинәләрне җитәкләп йөрүче райком секретаре Рәхимова образы көбек статик, алдан ук билгеләнгән җансыз образны әйтмим мин. Бик мәгънәле һәм җанлы итеп сурәтләнә башлаган Мәдинә һәм Борһан образларының ахырынача тигез эшләнеп чыкмавын күздә тотам. Төп конфликты әсәрнең уртасында ук хәл ителеп беткәнгә күрә, «Саф җилләр» романының соңгы кисәкләре, патетик-публицистик юллар белән тулы булуы, көчсез һәм артык ясалма килеп чыгуы турында безнең тәнкыйтьтә әйтелгән иде инде. Бигрәк тә менә шушы өлештә язучы художниклык тойгысын бөтенләй диярлек югалта һәм образлар (Мәдинә һ. б.) эчке хәрәкәттән, үсештән туктыйлар, тышкы вакыйга-фактларның күзәтүчеләре хәлендә генә биреләләр. Әсәрнең ахырында бирелгән «Эпилог»та яңа бернәрсә өстәми, киресенчә, Мәдинә һәм Борһан арасындагы конфликтның үткенлеген югалтуга, Мәдинә кебек намуслы кеше көрәшенең эчке мәгънәсен томалауга, төбендә герой характерының бөтенләеен, табигый үсешен киметүгә генә хезмәт итә.

М. Хәсәновның моннан соң басылып чыккан «Юллар, юллар» исемле романында да шундый ук йомшаклыклар нык сизелә. Язучының үз-үзенә таләпчәнлеге кимемәдеме икән? дип сорыйсы килә. «Юллар, юллар» романында юл төзүчеләрнең патриотик хезмәте турында матур гына сәхифәләр бар. Авыр язмышлы Хәйруш образы чагыштырмача уңышлы гына эшләнгән. Аның үсешен, җәмгыять өчен файдалы, кирәкле кеше булып тәрбияләнүен, каршылыклы эчке кичерешләрен күрәбез. Шулай да әсәрдә язучы «вакыйга сөйләү» белән шактый мавыгып китә, еш кына гади публицистик стиль әсәрнең эмоциональ сурәтлелек, пластик тасвир сыйфатын йомшартып җибәрә. Коры сүз булмасын өчен, яңа кеше тәрбияләү мәсьәләсенә кагылган, гаять җансыз, примитив язылган юллардан берничә мисал китерик:

«Варис киң масса арасында кайнады, халык арасында булды. Юллар төзүчеләр арасында коммунистик хезмәт мәктәпләре оештырды. Җиңел бирелмәде ул эш. Авыр, ай-һай, авыр булды.

Яңа кеше тәрбияләүнең камилләштерелгән (?) бу формасын тормыш үзе таләп итте. Техминимум курслары, производство алдынгыларының эш алымнарын үзләштерү генә эшчеләрне канәгатьләндерә алмый. Яхшы эшче булу гына җитми хәзер. Кеше алдына яңадан-яңа таләпләр, бурычлар куя тормыш. Коммунистик хезмәт мәктәпләрендә политика, мораль, этика мәсьәләләре күтәрелә, культура һәм экономик яктан тәпле белемнәр бирелә.

Юллар төзү идарәсендә коммунистик хезмәт мәктәбе программасы нигездә (?) өч төрле темага бүленде. Беренчесе аның — политик тәрбия бирү. Бу тема бе-

ләп турыдан-туры партком шөгыльләнде»[1]...

Шуннан соң тагын икенче, өченче... темалар турында сүз бара... Ниндидер «инструкция» бирелә кебек, һәм бу берничә биткә сузыла. Кайда монда сәнгать сүзе, сәнгатьчә фикерләү, хис итү? Художник буларак, язучы реаль тормышка анализ ясарга һәм аны сәнгатьчә сурәтләргә, хәтта хәзергә әле гади күзгә күренеп тормаган яңаның тууын, кеше характерының, аның караш, холык, гамәлләренең үзгәрү процессын ачарга тиеш иде — сәнгатьлелек үзе шуны таләп итә бит. М. Хәсәнов романының төп кимчелеге, йомшаклыгы да менә шуның белән бәйләнгән. Романда герой характерлары кабатланмас индивидуаль сыйфатлары белән җитәрлек ачылмыйлар, еш кына алар автор «кушуы» буенча кинәт үзгәрәләр, герой булалар. Риторик эндәшләр һәм факт теркәүче сүзләр әсәрнең идеясен, эчке пафосын, укучыны дулкынландырырлык эмоциональ көчен арттыра алмыйлар, әлбәттә.

Мин биредә сәләтле прозаик М. Хәсәновның әсәрләре бөтенләй яраксыз, дигән фикерне әйтергә теләмим. Роман кебек киң колачлы жанрда таләпчәнлекне йомшарту, аеруча геройлар образын эшләүгә тиешле игътибар бирмәү язучыны уңышсызлыкка очратуы мөмкин дигән фикерне басым ясап әйтергә телим. М. Хәсәнов, үзе дә сизмәстән, бу әсәрендә «конфликтсызлык теориясенең» дә йогынтысына бирелә кебек. Шушы уңай белән, тарихи романнарга карата әйтелгән булса да, бөек Белинскийның сүзләрен искәртеп үтәсе килә. «Тормыш фактларын» сөйләү белән, асылда гади иллюстрация белән мавыгучы, натурализм йогынтысына бирелүче романчыларга карата ул сүзләр бик туры килә: «Роман тарих фактларын сөйләп бирүдән баш тарта һәм аларны бары тик эчке мәгънәләрен ачкан аерым вакыйга белән бәйләнештә ала; ләкин шуның аркылы безнең алда тарихи фактларның эчке ягын, эчке рухын ачып сала»[2].

Күптән билгеле булганча, роман, аерым кешеләрнең язмышын сурәтләү белән бергә, иҗтимагый тормышны киң планда күрсәтә һәм тарихи-иҗтимагый үзгәреш-үсешнең үзенчәлекләрен, яңа якларын сәнгатьчә анализлап ачып сала. Роман үз эченә күп нәрсәне сыйдыра: халыклар язмышын да, аерым шәхесләр язмышын да... һәм роман жанрында, әлбәттә, эпик сурәт лирика, драматизм, публицистик «алым», стиль үзенчәлекләре берләшә ала. Әмма боларның барысы да художникның эчке сиземләвенә, сәнгать закончалыгына һәм төп иҗат максатына буйсынган булырга тиеш.

Роман тарихын өйрәнүчеләр дә, теоретиклар да романда төп мәсьәлә — ул герой мәсьәләсе, кабатланмаган яңа характер тудыру мәсьәләсе, дип исәплиләр. Ә бу исә, әлбәттә, үз заманына хас уңай герой образын бирү, заман героен әдәбиятта чагылдыру мәсьәләсе. Билгеле, әдәби әсәр, шулай ук роман да, бер бөтен организм булып туа һәм яши, аның сәнгатьчә эшләнешендә төрле компонентлар бар (тип, характер, сюжет, композиция, конфликт, тел-стиль h. б.).

Роман герое уңае белән, гомумән әдәби герой төшенчәсенә кыскача аңлатма биреп үтәргә кирәктер. Геройны төрлечә төшенү, төрлечә аңлату да бар. Гадәттә, әдәби герой төшенчәсен «персонаж», «әдәби әсәрдә катнашучы кеше образы» дип, ә кайбер очракларда «тип», «характер» мәгънәсендә дә кулланалар. Шулай ук авторның идеалын, төп пафосын чагылдыручы буларак яки героик характерны сурәтләүче итеп каралганда да, «герой» һәм еш кына «уңай герой» төшенчәсе алына. Әдәбият фәнендә кабул ителгәнчә, «тискәре тип»ка, «уңай герой» да конкрет әдәби әсәрнең герое, ягъни төп персонажы булып исәпләнә. Без дә шул караштә торабыз. Ләкин мин бу мәкаләдә, барыннан элек, романда уңай герой турында сүз алып барам.

Уңай герой мәсьәләсе — әдәбият һәм сәнгатьтә төп мәсьәләләрнең берсе. Уңай геройны, бигрәк тә заман героен иҗат итү халыкның иң бөек хыялларын, тормышчан характер көчен җанлы сурәтләр аркылы ачып салу белән аерылгысыз бәйләнгән. Әдәбият һәм сәнгатьтә уңай герой мәсьәләсе иҗат кешеләрен элек-электән кызыксындырган, классиклар өчен дә ул җиңел хәл ителә торган мәсьәләләрдән исәпләнмәгән. Бу мәсьәлә буенча төрле дәверләрдә, төрле бәхәсләр булып үткәне дә әдәбият тарихыннан билгеле. Уңай геройны иҗат итү принципларына, тәҗрибәләргә караган бәхәсләр безнең заманда да сүрелми... Илленче елларда һәм алтмышынчы еллар башында, башка әдәбиятларда булган кебек, безнең татар әдәбиятында да «кимчелексез герой» яки «идеаль герой» турында җитди генә бәхәсләр булып үткән иде. Ул

---

[1] М. Хәсәнов. Юллар, юллар... Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1966. 97 бит.

[2] В. Г. Белинский. Әсәрләр. Рус телендә. 1958—1965 еллар. 5 том. 41 бит.

бәхәснең иң югары ноктасы Татарстан язучылар союзының III һәм IV съездлары көннәрендә булды, дип әйтергә мөмкин. Төрле карашларны ачыклау, уңай герой, заман героен иҗат итүгә игътибарны көчәйтү өчен файдалы булган бу фикер алышуларның төп мәгънәсе нәрсәдә иде соң? «Кимчелексез» герой карашын яклаучы М. Әмир, асылда шуңа ук тоташкан «идеаль герой» яки «геройны пьедесталга күтәреп» сурәтләү принципын үзенчә аңлаткан Г. Әпсәләмов чыгышлары геройның вакланууына, көнкүреш белән, бер яклы шәхси кичерешләр белән чикләнгән, рухи дөньясы тар, канатсыз геройлар иҗат итү белән мавыгу күренешләренә каршы юнәлтелгән иде. Әмма аларның «идеаль герой»ны яклаулары теоретик яктан нигезсез, практик яктан үзләренә үк каршы килә иде. Шуңа күрә, Г. Бәширов, Ф. Хөсни һ. б. язучылар, шулай ук әдәби тәнкыйть моңа бердәм каршы чыктылар. «Кимчелексез герой» һәм «идеаль герой» дигән ике «вариант» та бер үк дәрәҗәдә, ахыр чиктә, тарихи чынлыкны бозуга, характерның, герой образының табигыйлегеннән, дереслектән һәм каршылыклы үсү процессын ачудан читкә алып китә, кыскасы, ясалмалыкка, әзер схемага илтә. М. Әмир, Г. Әпсәләмовларның әсәрләре үзләре үк «идеаль герой» тезисының ялгышлыгын күрсәтә. Күренекле каләм остасы. Г. Бәшировның шушы уңай белән әйткән сүзләре бүген дә әһәмиятле: «Уңай геройның кимчелекләре булырга мөмкинме, дип сорыйлар. Бирегә сүз характерның тулылыгы, индивидуаль ачыклыгы турында гына булырга мөмкин. Югарыда әйтелгәнчә, дөньяга карашы ачык булмаган кеше совет укучысы өчен үрнәк була алмый. Бу мәсьәләдә геройны лакка буяп, «тәти» итеп бирү дә, шулай ук «тормыштагыча» була дигән сылтау астында натуралистик алым белән, барлык чүп-чары белән сөйрәп кертү дә бер үк дәрәҗәдә зарарлы» [1].

Күптән шаулап алган бу бәхәсне хәзер искә төшерүнең ни кирәге бар, дип әйтерләр бераулар. Мәгънәсе һәм гыйбрәтле ягы бар аның. «Идеаль герой» турындагы төрле карашлар бүген инде әһәмиятләрен югалтырлар, дип әйтү бик үк дөрес булмас, безнеңчә. Күп кенә популяр романнарның авторы Габдрахман Әпсәләмов бер мәкаләсендә болай дип кабат язып чыкты: «Без «гомумән кеше» тарафдарлары түгел, без аңлы рәвештә уңай геройны яклыйбыз, аны романтик планда калку күрсәтәбез, кирәк икән, пьедесталга да бастырабыз» [1].

Бу сүзләрдә, һичшиксез, берникадәр дереслек тә бар. Уңай геройны яклауга һәм кирәк икән «аны романтик планда калку күрсәтүгә» кем каршы килер икән? Ләкин «романтик калку» сурәтләү Г. Әпсәләмов иҗаты өчен хас булса да, аның талант үзенчәлегенә туры килсә дә, аны бердәнбер дөрес принцип итеп карап булмый, хәтта ул «Сүнмәс утлар» яки «Мәңгелек кеше» кебек аның реалистик романнарына да бик үк туры килми.

Г. Әпсәләмов геройларының күбесенә романтик калкулык, бигрәк тә реаль тормыш шартлары нигезендә туган героик романтика характерлы. Бу — язучы иҗатына, аның талантына хас якты бер үзенчәлек. Аның ул сыйфаты безнең хәзерге прозадагы стиль төрлелеген, иҗади эзләнүләрнең киңлеген дә аңлата. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы да язучының һәм безнең хәзерге романистикабызның бер уңышы булып тора. Ләкин язучы «пьедесталга бастыру», ягъни «идеаль герой»ны ясарга омтылу тенденциясенә бирелеп китмәгән булса, романның төп геройларыннан берсе Гөлшаһидә образы җанлырак һәм тирәнрәк ачылыр иде. Пьедесталга бастыру (алдан уйланылган схемага буйсындыру) чәкъ шушы образның дереслек көченә, табигыйлегенә шактый зыян иткән. Үкенечкә каршы, язучы монда яңа ачыш дип әйтерлек көчле характер иясе, бай рухи дөньясы, катлаулы тормыш язмышына очраган гүзәл хатын-кыз образының, заман героинясының образын бөтен тулылыгы белән ачу мөмкинлегеннән киң файдалана алмаган.

«Идеаль герой» карашын тәнкыйтьләү уңае белән соңгы вакытларда әдәбиятта икенче бер чиккә ташлану, гомумән уңай герой проблемасын шик астына кую, аны уйдырма бернәрсә итеп исәпләү кебек зарарлы һәм ялгыш тенденцияләр дә күренә башлады. Кайбер иптәшләр кимчелексез герой, иң яхшы һәм иң яхшылыклы кеше тезисына каршы күптәннән билгеле булган тере кеше, ягъни әчке каршылыклы, катлаулы кеше дигән карашларны күтәреп чыктылар, һәм моңа бик сәер аңлатмалар бирделәр. Катлаулы характер, «кырыс»

---

[1] Г. Бәширов. Татар совет әдәбиятында уңай герой. «Совет әдәбияты» журналы. 1954 ел. 7 сан. 117 бит.

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы. 19 ноябрь. 1965 ел.

реализм, тормышчанлыкны алар еш кына герой характерының кимчелекләрен, йомшак, тискәре якларын, рухи гариплекләрне халку, беренче планда күрсәтү дип аңлыйлар. Шуннан инде тормышның бер генә ягын, кара ягын куертеп сурәтләү, кеше рухының, хисләрнең тәэсирләнмәслек бер «серле» нәрсә итеп бирү омтылышлары туа. Түбәндә мондый хәл әдәбиятта «геройсызлык» («дегероизация») кебек безнең өчен ят карашларга юл ача.

Совет әдәбияты беренче көннәреннән үк яңа кеше, яңа герой образын беренче планга куйды, дөньяны үзгәртеп коручы, яңа тормыш төзүче һәм революцион көрәш процессында үзе дә үзгәрүче герой образын иҗат итте. Совет әдәбиятына героик характер, героик образ хас. Социалистик революция, социализм өчен көрәш онытылмаслык геройларны тудырды. Һади Такташ сүзе белән әйтсәк:

> Без үткәннең каты җилләре
> Бүгенгенең җилен килүе —
> Көрәшендә
> Артык ашкынулы
> Хисләр уты белән янабыз:
> Без яңа җир,
> Яңа кеше өчен
> Җирдә зур дау алып барабыз...—

дигән төп мотив, төп идея пафосы безнең иң яхшы әсәрләребез өчен, аларның геройлары өчен характерлы булып тора. Әдәби иҗат эшендә бу яңалык та, новаторлык күренеше дә иде. Һәр тарихи чор үз героен тудыра икән, шул чорның чын сизгер әдибе дә аңа битараф булып кала алмый, аның бөек образын иҗат итүне үзенең төп бурычы дип аңлый. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Ш. Усманов, К. Тинчурин, К. Нәҗми, М. Җәлил, Т. Гыйззәт, А. Шамов, М. Максуд, Г. Кутуй һ. б. күп кенә язучыларыбызның әсәрләрен, халык күңелендә бүген дә яшәгән геройларын искә төшереп карагыз. Ул нәкъ шулай булган. Әдәбиятыбызның бу традициясе бүген дә уңышлы дәвам итә.

Хәзерге совет әдәбиятының герое — безнең замандаш, коммунизм төзү өчен көрәш кешесе. Ул ком сахраларын яшелләндергән, анда шәһәрләр төзегән, ятма җирләрне иген кырларына әверелдергән, гигант гидроэлектростанцияләр төзегән, фән һәм техника өлкәсендә яңа ачышлар туган чорда, кешенең галәмгә очкан елларында яши. Атом, кибернетика, космос эпохасы кешесе дип кенә әйтү бу геройны тулы ачу, аңлау дигән сүз түгел әле. Анык коммунизм төзүче совет кешесе булуын, катлаулы, бай рухи тормыш белән яшәвен, яңа сыйфатларын күрә белергә һәм аның поэтик образын ача да белергә кирәк. Укучы бүгенге һәм киләчәк турында уйлана белүче, тормыш фәлсәфәсен тирән аңлаучы зур характер иясе булган геройларны күрергә тели. Гомумән герой образы, характер-тип нигезендә Кеше концепциясе ята. Халыкның монументаль образын, реаль герой образын иҗат итү өчен, барыннан да элек, роман жанрында чиксез киң мөмкинлекләр бар. Белинский сүзе белән әйтсәк, роман — безнең заман эпосы, ул— иҗтимагый тормышка, халык тормышына, кешеләр язмышына сәнгатьчә анализ ясау.

Әйткәнебезчә, татар совет романы хәзер яңа күтәрелеш елларын кичерә, заманыбызның уңай героен иҗат итүдә дә аның уңышлары кечкенә түгел. Хәзерге романнарыбыздагы геройлар арасында төрле катлам, төрле профессия, төрле милләт, төрле язмыш кешеләре бар. Романнарның күпчелеге авыл, колхоз тормышына багышлангānлыктан, геройларыбызның да күпчелеге авыл белән бәйләнгән. Әмма менә хәзерге, бүгенге авылда, бүгенге авыл халкында барган яңа процессны, бүгенге авыл кешесенең рухи дөньясын ачкан зур, катлаулы образлар бик аз әле. Совет эшчесе, совет интеллигенциясе образларын биргән уңышлы гына романнар да күренә башлады («Хәзинә», «Ике буйдак», «Ак чәчәкләр»). Хәзерге романнарыбызда уңышлы эшләнгән уңай герой образлары итеп, мәсәлән, шундыйларны күрсәтергә мөмкин: Рәхим («Ике буйдак»), Сөләйман Уразметов («Сүнмәс утлар»), Мансуров («Гади кешеләр»), Шәрифҗан һәм Хәлим («Онытылмас еллар»), Муса («Муса» романы), Арслан һәм Кәрим («Хәзинә»), Аллаһияров («Язгы авазлар), Һарун («Бала күңеле далада»), Сәет («Күкчәтау далаларында») һ. б. Индивидуаль характер, эчке рухи тирәнлек, бөтенлек, милли үзенчәлекле булу ягыннан безнең хәзерге романнарда бигрәк тә татар хатын-кызлары образлары беренче урында тора дип әйтсәк, ялгыш булмас.

Гомумән сугыштан соңгы романнарыбызда герой образын реалистик планда төрле яктан төсмерләп, тормышчанлык көчен, характер үзенчәлеген тирәнрәк һәм тулырак ачу осталыгы шактый үсте. Күпчелек романнарыбызда турыдан-туры халык, ил тормышы белән бәйләнгән, заманның зур проблемаларын кую һәм сәнгатьчә типиклаштыру омтылышлары көчәйде. Гади эшче, колхозчыдан башлап тормыш сынавын үткән мастер, инженер һәм галим об-

разларьı романнарыбызның үзәгендә торалар. «Гади кешеләр», «Сүнмәс утлар», «Хәзинә», «Ике буйдак», «Ак чәчәкләр» һ. б. ш. кебек әсәрләрдә татар халкының, башка кардәш халыклар белән бер сафта, хезмәт һәм фән мәйданына, зур культура дөньясына актив көч булып керү, җитлегеп үсү процессы гаять мәгънәле, перспективалы итеп, тарихи дөрес һәм реаль образ, вакыйгалар аркылы гәүдәләндерелгән. Эчке структуралары, образлары һәм стильләре белән аерылып торган, һәр романчыга хас үзенчәлеге булган бу әсәрләр өчен тагын шунысы да уртак: аларда иҗтимагый һәм шәхси конфликтлар аерым каралмый, катлаулы тормыш бәйләнешләры ачыла, искелек белән яңалыкның көрәшендә яңаның үсешен куәтләү, геройларының идея-рухи үсешләрен күрү нык сизелеп тора. Ә бу исә — социалистик реализм әдәбияты өчен иң көчле, яңалыкны билгеләгән сыйфат. Һәр әдәби әсәр һәм һәр роман үзенең яңа герое белән, укучы күзенә әле бик үк ташланып тормаган тормыш яңалыкларын сәнгатьчә ача белүе белән безне сокландыра. Яңа геройны иҗат итү — яңа ачыш ясау белән бер дәрәҗәдә. Әйтик, Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы кайсы ягы белән кыйммәтле? Татарстан нефтьчеләре турында булганга гынамы? Билгеле, «Хәзинә»нең темасы да, куйган мәсьәләләре дә безнең әдәбият өчен яңа һәм бик кирәкле. Әмма әсәрнең укучыга йогынты ясаучан көче, эстетик сокландырырлык ягы, барыннан да элек, аның моңарчы кабатланмаган, шәхси үзенчәлекле образларында, геройларында. Төрле язмыш кешеләре, төрле характер ияләре итеп сурәтләнгән Арслан белән Кәрим дә, Фәйрүзә белән Мөнәвәрә дә, аеруча калку, психологик яктан нечкә эшләнгән Лотфулла белән Шәвәли агайлар да безнең истә калалар, уйландыралар. Безнең заман тудырган, үстергән, мәйданга чыгарган кешеләрнең, геройларының уй-хисләре, характерлары, эш-гамәлләре, яшәешләре чагылган аларда. Бирегә реаль тормыш «чагылышы», дип әйтү генә җитми, безнең кешеләрнең тирәлекне, чынлыкны үзгәртеп коручылар, яңаны төзүчеләр, иҗади хезмәтнең җимешен, шатлыгын белүчеләр дә булулары турындагы идея белән ямыртылуын да әйтергә кирәк. Димәк, язучы монда тормыш материалына актив мөнәсәбәттә тора.

Шуның белән бергә, безнең романчылар әле хәзергә тиешле тирәнлектә күрсәтә алмаган бер герой образы турында искәртү ясап үтәсе килә. Безнең романнарда уңышлы гына иҗат ителгән «рядовой» коммунист образлары бар. Әмма җитәкче коммунист, алгы сафта торган, массаны оештыра белгән чын тәрбияче, бай рухи тормыш иясе коммунист образы, реаль тормышта булганча, үзәк герой дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнгәне юк диярлек әле.

Әдәби әсәрләрдә партиянең җитәкчелек ролен, көрәшчә коммунист образларын, халыкның югары идеаллар героен ничек чагылдыру мәсьәләсе Г. Ибраһимов кебек зур әдипләрне дә уйландырган. Алар моны иҗади эшләренең төп бурычларыннан санаганнар [1].

Җитәкче коммунист образы безнең романнарда, еш кына, тасвирланган вакыйгаларда я эпизодик рольдә бирелә, яки һәр очракта акыл бирүче бер схемага әверелә, автор рупоры ролен генә уйный. Сюжет тукымасына органик кергән, асылда төп сызыкны билгеләгән, сюжетны оештыручы буларак тасвирланган катлаулы характер, зур язмышы белән ачылган җитәкче коммунист образлары безнең романнарда әле бик сирәк. Бигрәк тә ул бары тик эш кешесе, үгетләүче кебек кенә күренә. Моңа бик күп мисал китереп булыр иде (ул кимчелектән иң уңышлы романнарыбыз да азат түгел).

Минемчә, «Хәзинә» романында шактый иҗади кыюлык күрсәткән, ачыш ясаган Гариф Ахунов «Хуҗалар» исемле икенче романында нәкъ шушы, югарыда без кагылган мәсьәләдә уңышсызлыкка очрады. «Хәзинә»дәге яшь Арслан белән «Хуҗалар»дагы олыгайган, җитәкче дәрәҗәсенә үскән Арслан арасында сәнгатьчә эшләнеш, әдәби тәгаллек ягыннан бик зур аерма бар. Соңгысында язучы геройның «эше» зурлыгы, кирәклеге турында күп сөйләп тә, аның эчке дөньясына, рухи байлыгына, психологик портретына җитәрлек игътибар итә алмаган. Нәтиҗәдә зур белгеч, җитәкче инженер-коммунист Арслан образы еш кына тышкы фактлар аркылы гына күренә. «Хуҗалар» романы турында әйтелгән хаклы тәнкыйть сүзе дә нәкъ шушы төп герой образына караган иде.

Күренекле каләм остасы Фатих Хөсни әйткәнчә, «Хуҗалар» романының төп кимчелеге Арслан Гобәйдуллинны баштан ук бизәп күрсәтеп, укучыларны аның бик шәп кеше икәнлегенә ничек кенә булса да ышандырырга тырышуында. Гомумән бу романга бетенлек, тәгаллек, характер-

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960 ел. 225 бит.

ларны эзлекле үсештә, хәрәкәттә күрсәтү җитешми»[1].

Арслан Гобәйдуллинның бөтен эчке рухи хәрәкәте, эчке каршылыклары тирәнтен ачылмаганга күрә, бу герой күбесенчә бары тик тышкы каршылыклар белән, эш шартларында очраган кыенлыклар белән генә көрәшә кебек тоела. Әйтерсең, шәхсән ул инде бик төгәл кеше, бөтен эзәр хакыйкатьләрне үзләштереп, уй-хисләрендә билгеле бер чикләр эчендә генә яши... Ә тормыш һәм кеше шактый катлаулырак шул.

Әдәби әсәр герое, бигрәк тә роман герое бары тик сюжет функциясен үтәүче булып калмыйча, үз заманы кешесенең характерын бөтен катлаулыгы белән чагылдырырга тиеш. Реализм әдәбиятының төп таләпләреннән берсе бу. Геройга бары тик тарих объекты итеп түгел, тормышны үзгәртүгә сәләтле, аңлы актив субъект итеп карау совет әдәбиятының иң яхшы әсәрләренә хас бит. Менә шушында инде авторның да үз чоры героена карата булган концепциясе, мөнәсәбәте тулырак күренә. Без биредә, әлбәттә, «Хуҗалар» романында авторның карашы юк дип әйтергә теләмибез. Ф. Хәсни үзенең мәкаләсендә моны берникадәр шик астына куя шикелле. Юк, Г. Ахуновның төп фикере, концепциясе бик ачык, хәтта урыны-урыны белән публицистик-очерк стиленә тартым рәвештә ачык итеп язылган. Әмма сәнгатьчә эшләнеше ягыннан, тирән эстетик-художестволы фикер дәрәҗәсенә күтәрелү ягыннан ул талымсызлык күрсәткән.

Шушы уңайдан тагын бер бәхәсле фикергә кагылып үтәсе килә. «Хуҗалар» романмы, түгелме? Ф. Хәсни үзенең мәкаләсендә анда «роман юк» дип исәпли, ә автор үзе әсәрен «роман» дип атаган. Кем хаклы? Роман яки повестьта төп образлардан берәрсенең әдәби эшләнешендә кимчелекләр булса, ул тулы ачылып җитмәсә, моңа карап бу әсәр үзенең жанр үзенчәлеген югалтамы? Билгеле, андый әсәр кимчелекле була, әмма жанр (роман яки повесть) үзенчәлеге юкка чыкмый. «Хуҗалар» романына карата да шуны әйтә алабыз. Роман кебек катлаулы эпик жанрдагы әсәрнең характерын эчке мәгънәсе, идея-эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән структура-төзелеш һ. б. компонентларын да (сюжет, композиция, стиль, күләм һәм сурәтләү-хикәяләү темпы) исәпкә алмыйча билгеләп булмый. Романда зур характерлар, зур язмышлы герой яки геройлар булуы — иң мөһим шарт. Шулай да әсәр чын роман булу өчен ул гына да җитми әле. Монда тормыш материалының, тасвирланган вакыйгаларның киңлеге, колачлы булуы, сәнгатьчә анализ тирәнлеге һәм, әлбәттә, авторның эзлекле караш-идеясе зур роль уйный. Роман — халык тормышы энциклопедиясе, халык тормышы көзгесе ул (Белинский).

Ф. Хәсни дә асылда моңа каршы килми, аның мәкаләсендәге төп фикер дә шул рухта. Гомумән олы язмышлы герой образын иҗат итү осталыгын күтәрүгә чакырган бу мәкалә җитди игътибарга лаек. Ләкин «Хуҗалар» романының жанр үзенчәлегенә кагылышлы әйткән фикере, безнеңчә, тар бер сыйфат белән генә чикләнгән. Ул бу очракта роман жанры өчен хас традицион бер сыйфатка — романистик сюжетка — семья, мәхәббәт сызыгына гына басым ясап, «Хуҗалар»да «роман юк» дигән нәтиҗәгә килгән булса кирәк.

Иҗтимагый тормышта кешеләр төрле бәйләнеш, мөнәсәбәтләр эчендә яшәгән кебек, роман геройлары-персонажлары да төрле катлаулы мөнәсәбәтләр эчендә ачылалар, төрле конфликтлар эчендә бирeләләр. Беришe конфликт иҗтимагый тормыш белән бәйле һәм аның хәл ителешенә карап аерым шәхеснең язмышы яки коллективның хәле ачыла; икенче төр конфликтларның масштабы тагын да киңрәк булып, экономик, политик, идеологик эшчәнлек, әхлак сферасын үз эченә ала. Безнең хәзерге иң уңышлы социаль-психологик романнарыбызның геройлары нәкъ әнә шул киң тормыш мөнәсәбәтләре, үз чоры өчен типик шартлар, типик тирәлек эчендә сурәтләнәләр. Гариф Ахуновның романнарындагы («Хуҗалар»да да) уңай тенденцияләре, иҗади эзләнүләре дә нәкъ менә шушы юнәлештә.

Традицион бер герой романы, семья романы формаларының безнең заманда шактый үзгәртелеп, яңартылып үстерелүе, әлбәттә, иҗтимагый-политик, тарихи тормыш фактларының романда киң мәйдан алуы, катлаулана баруы белән дә аңлатыла. Шулай ук аерым шәхес язмышы, бер геройга караган психологик конфликт нигезендә язылган роман төрләре дә яши, яңара тора. Моның характерлы бер мисалы — Э. Касыймовның «Гомер икс килми» әсәре.

Безнең хәзерге прозада психологик анализга җитди игътибар бирү, шуның бе-

---

[1] Ф. Хәсни. Кайда сез, олы язмышлар? «Казан утлары» журналы. 1969 ел. 6 сан. 134 бит.

лен бәйләнгән лирик прозаны үстерүгә омтылышлар көчәя башлады. Бу, һичшиксез, стиль байлыгы, үзенчәлекле талантлар ачылуы турында сөйли. Сугыштан соңгы романнардан, барыннан элек, Г. Бәшировның «Намус»ында күренгән бу уңышлы тәҗрибә, яңа тенденция Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», «30 нчы ел» романнарында, Ә. Еники, А. Гыйләҗев повестьларында, өлешчә Г. Ахуновның «Хәзинә» романында да яхшы ук сизелеп тора. Э. Касыймов та шул ук юнәлештә эзләргә омтыла. Лирик прозаның үсеен яклаганыбыз хәлдә, бер искәрмә дә ясап үтмичә булмый. Монда хәзер тегеләй бу рәвештә бер җитди кимчелек үзен сиздерә башлады. Ул — кайбер роман һәм повестьларыбызга фикер тирәнлеге, тормыш киңлеге, каршылыкларның чагылышы җитешмәве. Бу бигрәк тә кайбер сурәтләнгән геройларның реаль тормыш белән бәйләнешләре, иҗтимагый интереслары, карашлары артык тар булуында күренә. Илдәге, дөньядагы вакыйгалардан, политик-идеологик көрәш мәсьәләләреннән, хуҗалык һәм фән яңалыкларыннан бериш геройлар ничектер мәхрүм, читтә яшиләр кебек. Мәсәлән, шул ук «Гомер ике килми» яки «Томан аша» романнары геройларының йомшаклыклары нәкъ шунда күренә дә инде. «Гомер ике килми» романы үзәгендә тасвирланган Мөнирәнең фаҗигале кичерешләре, уй-хисләре бары тик бер генә планда бирелүе аркасында хәрәкәтсезлек туган һәм артык чикле образ килеп чыккан. Кайгы-хәсрәтнең, бәхетсезлекнең авырлыгын, газабын татымаган, башыннан кичермәгән кеше бәхетнең, шатлыкның кадерен белми һәм тирән кичерешләрне аңламый, диләр. Хак сүз бу. Зур характер ияләре, көчле натуралар, тынгысыз йөрәкләр моның шулай икәнен яхшы беләләр. Хикмәт тә шунда шул — монда зур характер, зур язмышлы герой булырга тиеш.

Соңгы елларда Эдуард Касыймов иҗади активлыгын шактый көчәйтте, безнең хәзерге прозабызда үзен талантлы бер әдип итеп танытты. Элекке роман һәм повестьлары өчен бигрәк тә эчке лиризм, уйлануллар характерлы булса, хәзер инде «Томан аша» исемле яңа романында (беренче китап) без язучы каләменең икенче сыйфатын — объектив тасвир, тыныч агышлы хикәяләү стилен үстерүгә омтылышын күрәбез. Димәк, Э. Касыймов прозасының мөмкинлекләре чикле түгел, осталыгы арткан саен, аның моңарчы безгә билгеле булмаган бүтән яклары да ялтырап ачыла бара.

«Томан аша» романы нигездә химиклар тормышын күрсәтүгә багышланган. Сюжет үзәгендә завод шоферы Фуат белән лаборатория эшчесе Зөлфәнең мәхәббәте, үз бәхетләрен эзләүләре, төрле язмышлары торса да әсәрнең иң күп өлеше Бондюг (әсәрдә ул Акъбалык дип алынган) химия заводының элекке һәм хәзерге хәлен, тарихын һәм кешеләрен сурәтләүгә бирелгән. Шулай да аны тарихи яки тарихи-революцион жанр әсәре дип атап булмый, чөнки тарих материалы теге яки бу күләмдә урын алса да, ул бүгенге химия заводы коллективы, аның кыенлыклары, кешеләре турында сөйли. Романда реалистик стильдә сурәтләнгән уңышлы гына образлар бар. Олы һәм яшь буын кешеләрен Фуат, Закир абзый, Зөлфә, Гәргери кебек образларда язучының герой характерын индивидуаль үзенчәлекләре белән җанлы итеп, калку итеп гәүдәләндерү юлындагы яңа иҗади эзләнүләре сизелеп тора. Ләкин романның төп герое Фуат образы әсәрнең бу кисәгендә ачылып җитмәгән әле. Ул күбрәк икенче дәрәҗәдәге вакыйгалар, маҗаралар эчендә (караклар «эше» һ. б.) бирелә. Авыр язмышка очраган, төрмәдән кайткан Фуатның үзгәрү, яңадан «туу» процессы ничектер завод коллективыннан читтәрәк бара, аның рухи дөньясының үсеше зур иҗтимагый интереслар, идеаллар белән яктыртылмый.

Герой образын сурәтләгәндә һәр язучы, әлбәттә, төп сюжет турында да уйлана. Сюжетны тудыручы, хәрәкәткә китерүче — ул образ, герой образы. Мавыктыргыч һәм реаль тормыш нигезендәге сюжет ачкычын табу җиңел түгел. Һәр язучы монда ихтыярлы. Конкрет тормыш материалы кушканча үз «ачкычын» табарга омтылуда, характерны, образны тулырак ачучы сюжет сызыгын билгеләүдә, һичшиксез, бернинди стандарт юк. Шулай да, ничек кенә булмасын, чын художник монда сәнгатьнең эчке закончалыгы белән исәпләшмичә булдыра алмый. Ә ул — тарихи дөреслек, объектив киң караш, образның һичбер ялгансыз логик хәрәкәт-үсешен ачу, халык тормышының реаль күренешләрен тасвирлау дигән сүз. Кайчак әдәбият фәнендә сюжетка артык зур йөк салып, аңа «чынбарлык концепциясен ачучы» бер сыйфат итеп карау да бар. Дөрес бу. Әмма «чынбарлык концепциясе», «язучы концепциясе» дигәнне сюжет кына түгел, әсәр үзе бер бөтен организм буларак билгели. Чынында әсәрнең бөтен-

леге, тәгәллеге, эчке мәгънәсе аның һәрбер әдәби компонентына кагыла. Чигенешләр, ярдәмче эпизодлар, икенче-өченче дәрәҗәле персонажлар һ. б. бер бөтен булып оешалар, төп фикерне ачуга хезмәт итәләр. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романындагы Фәхри образы, аның язмышы белән бәйле сюжет «җепләре» («Фәхрине үтереп ташладылар»дан соң башланган вакыйгалар) әсәрдә бирелгән башка хәлләрдән аерым ачыла алыр идеме, авторның фикере бирелә алыр идеме? Әлбәттә, туры сызыклылык эчке мәгънәне, катлаулы хәлне тулы ача алмас иде. Яки Г. Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә образының үсешен, эчке дөньясын Хәйдәр һәм Зиннәт образларыннан башка, яки Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ындагы Хәсән Мортазин образын Сәләйман абзый образыннан башка аңлап булыр идеме? Һич мөмкин түгел. Тормыш үзе монда язучыдан катлаулы сюжетны таләп итә, герой тарихы, характер үсеше үзенә генә хас сюжет юллары булуын сорый, һәм аларда кабатланмаслык индивидуальлек тә, гомумилек тә чагылырга тиеш. Роман иҗат итүче язучы кеше язмышының «катып калган» бер моментын сурәтләү белән чикләнә алмый, тормыштагы хәрәкәт, үсеш белән, идея-эстетик идеал белән бәйле булган төп геройның эчке логикасын, үсешен һәм аның перспективасын күрергә тиеш. «Томан аша»ның төп герое Фуатка, өлешчә аның сөйгән кызы Зөлфәгә дә нәкъ менә шушы фәлсәфи тирәнлек, киңлек җитешми, аларның зур иҗтимагый идеаллар өчен көрәштә формалашкан характерлары һәм үсеш перспективалары тулы ачылып бетми кала. Ихтимал, автор романның икенче китабында киңрәк мәйданга чыгарга уйлыйдыр, һәрхәлдә, без беренче китабын азмы-күпме тәгәлләнгән бер бөтен әсәр дип исәплибез.

Роман жанрында күптән урнашкан традиция буенча килеп, без геройның җанлы, кешелекле, типик характер булуын бары тик семья, мәхәббәт тарихы рәвешендә генә күз алдыбызга китермибезме икән? Һичшиксез, романистик сюжет еш кына семья, мәхәббәт сферасы белән бәйләнгән, бу мөһим факторны беркем дә инкарь итмәс. Ләкин совет әдәбиятының, шулай ук дөнья әдәбиятының иң яхшы романнарындагы тәҗрибә моның белән чикләнми, тарихи, иҗтимагый-политик, философик идеяләр, фәнни-техник прогресс мотивлары, халыкның революцион көрәше мотивлары романда киң урын алуы аның сюжет-структурасына да йогынты ясады, романга яңа сыйфатлар өстәде. Бу безнең иң яхшы социаль-психологик һәм тарихи-революцион романнарыбызда бик ачык күренә.

К. Марксның «бөтен тарих кеше табигатен өзлексез үзгәртүдән башка нәрсә түгел» дигән карашыннан чыгып, чын реалистик роман тарихына күз салсак, монда да бөек классиклардан башлап хәзерге романчыларга кадәр — барысы да «кешенең табигате өзлексез үзгәрү», кешенең аң-хис, гамәл-фигыльләренең реаль чынбарлык астында үзгәрү процессын җанлы итеп сурәтләүләрен, үз чоры кешесе образын бөтен катлаулыгы белән ачуын күрербез. Кеше җәмгыятьтән читтә яшәми, конкрет мөхит эчендә аның уй-хисләре, гореф-гадәтләре, максат һәм идеаллары формалаша. В. И. Ленин әйткәнчә, кешенең аңы һәм үз-үзен тотуы, бөтен характеры «материаль тормышның каршылыклары»на бәйләнгән һәм ул, әлбәттә, аның «уйларында һәм тойгыларында...» чагыла торган иҗтимагый мөхит белән билгеләнә [1].

Без әдәбиятта уңай геройның әһәмияте турында сөйләгәндә, аны халыктан өстен, массадан, коллективтан читтә яшәгән «гадәттән тыш» бер шәхес дип карамыйбыз. Җәмгыятьтән үзен өстен санаган «герой»ны яклау яки «герой культы» дигән нәрсәләр социалистик реализм әдәбияты өчен ят нәрсә. Героизм, зур герой мәсьәләсе безнең әдәбиятта халык көрәше, идеаллары, социалистик гуманизм принциплары нигезендә карала. Абстракт гуманизм, җирлексез, ясалма героизм күренешләре совет әдәбияты традициясенә, иҗади практикасына каршы килә. Безнең әдәбиятта зур герой-характерны иҗат итү нигезендә художникның халык көченә ышану, аерым шәхеснең бөек идеаллар өчен батырлыклар эшләргә сәләтле булуына ышанып карау ята. Һәр язучы моны үзенчә, үз талантына, сәләте кушканча хәл итә, кырыс реализм стилендә, яки канатлы романтик, яки катлаулы психологик стильдә иҗат итә.

Гомумән безнең күпчелек романнарыбызда шәхес һәм коллектив, шәхес һәм халык проблемасы үзәк урын алып тора, дисәк тә ялгыш булмас. Матур бер традиция булып урнашкан бу тәҗрибә, һичшиксез, яңа туачак романнарыбызда тагын да тирәнрәк тамыр җәяр дип ышанырга нигез бар.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Рус телендә I том. 409 бит.

Сәнгатьтә, әдәбиятта шәхес мәсьәләсе бары тик аның индивидуаль үзенчәлеге мәсьәләсе белән генә чикләнә алмый, әлбәттә. Классик реалистик әдәбият геройларында ук инде шәхеснең катлаулы үзенчәлекләре тормыштан, тирәлектән, җәмгыятьтән аерым бер «серле» нәрсә итеп сурәтләнми. Социалистик реализм әдәбияты кеше шәхесенең тарихи үсешен, кеше интересы белән җәмгыять интереслары бердәмлеге процессында формалашкан шәхес характерын, революцион көрәш чорында яңа кеше — яңа геройның катлаулы эзләнүләрен бөтен тирәнлеге белән тасвирлап күрсәтү бурычын куя, һәм совет әдәбиятының төрле баскычларында туган иң уңышлы әсәрләр нәкъ әнә шул принцип нигезендә иҗат ителгәннәр дә.

Билгеле, роман, гомумән әдәби әсәр көндәлек тормыштагы кимчелекләрне ничек бетерү турында кулланма яки җәмгыятьтә, кеше арасында үзеңне тоту турындагы белешмә түгел. Бигрәк тә яшьләр өчен үрнәк булырлык уңай геройны иҗат итү бурычын алай примитив аңларга кирәкми. Н. Г. Чернышевский әйткәнчә, әдәбият, әдәби әсәр — ул кешеләр өчен тормыш дәреслеге, ягъни киң мәгънәдә тәрбия коралы, тормышны танып белү, рухи-әхлакый дөнья үрнәкләрен ачып бирүче. Әдәбият, шул җөмләдән роман да, барыннан да элек, үзенең көчле, батыр, изге телəкле герой образлары, характерлары белән укучыга йогынты ясый.

В. И. Ленин тормыштагы уңай фактларны күрә белүгә, гүзәллеккә сокланып карауга, уңай өлге-үрнәкләрнең тәрбияви, рухландыручан көченә аеруча игътибар бирә. Бигрәк тә социализм шартларында, ди В. И. Ленин, уңай факт, өлге-үрнәк факты — матди һәм рухи тормышта бер этәргеч көч ул[1]; социализм максатларының берсе — яңа шәхес, яңа кеше формалашып үсүе, «бөтен яктан үскән һәм бөтен яктан хәзерлекле булган кешеләрне тәрбияләү, өйрәтү һәм хәзерләү»,— ди[2].

Безнең әдәбият, безнең роман осталары алдында да әнә шул гаять зур һәм мактаулы бурыч тора.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Рус телендә. 36 том. 191 бит.
[2] Шунда ук. 41 том, 31 бит.



*ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫНА*

**Гомәр Билалов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ТАТАРСТАННЫ ИНДУСТРИЯЛӘШТЕРҮ ПРОЦЕССЫНДА ПРОЛЕТАР ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМ

Элеккеге патша Россиясенең артта калган һәм изелгән районы булган Татарстан бик кыска вакыт эчендә Советлар Союзының югары үсешкә ирешкән индустрияле республикасына әверелде. Бу милли республикаларны һәм өлкәләрне индустрияләштерү процессында ленинчыл милли политика һәм пролетар интернационализм тантанасының ачык дәлиле булып тора. Билгеле булганча, элеккеге Казан губернасы Россиянең Европа өлешендәге иң артта калган губерналарыннан санала иде. Казан губернасында җан башына промышленность продукциясе гомумән ил буенча булганнан 4 тапкыр кимрәк җитештерелә иде. 1913 елда Россия халык хуҗалыгында промышленность продукциясенең өлеше 42 процент тәшкил итсә, Казан губернасында ул 25 проценттан аз гына артык иде. Шул ук елда Россиядә шәһәр халкының саны 18 процент булса, Казан губернасында бары тик 9,2 процент кына иде.

Коммунистлар партиясенең һәм Совет дәүләтенең артта калган милли районнарны, шул исәптән Татарстан АССРны да, социалистик индустрияләштерүдә күрсәткән конкрет ярдәме түбәндәгеләрдән гыйбарәт булды: беренчедән, бу районнарны экономик яктан тизрәк үстерү максатларында аларның табигый байлыкларын һәрьяклап тикшерүне оештыру; икенчедән, аларның территорияләрендә зур промышленность предприятиеләре төзүне планлаштыру; өченчедән, промышленность һәм культура төзелеше өчен зур суммаларда финанс средстволары җибәрү; дүртенчедән, аларда төзелә торган предприятиеләр өчен илебезнең промышленносте алга киткән районнарыннан һәм чит илдән җиһазлар китертү; бишенчедән, эшче һәм инженер-техник кадрлар әзерләү, аларны төп милләт эшчеләре һәм крестьяннары арасыннан үстерүгә аеруча игътибар бирү; алтынчыдан, алдынгы промышленность районнарының тәҗрибәләрен артта калган милли районнарга таратуда илебезнең республикалары һәм өлкәләре арасында үзара ярдәмләшүне оештыру.

Партиябез һәм хөкүмәтебез Совет властеның беренче елларыннан ук милли районнарның территорияләрендә табигый байлыкларны эзләүгә һәм тикшерүгә гаять зур әһәмият бирделәр. Академик И. М. Губкин үзенең истәлекләрендә, Владимир Ильич «Геология комитеты» кебек иренчәк һәм әкрен кыймылдаучы учреждениегә һич тынгылык бирмәде, аны яшь республика өчен нефть, күмер һәм кургашын эзләргә дәртләндерде» дип язды. (И. М. Губкин, «Урал-Иделдәге нефть өлкәсе». 1940 ел, 4 бит.)

1918—1919 елларда В. И. Ленин инициативасы буенча Татарстанда, Башкортстанда һәм Идел-Урал җирләренең башка районнарында И. М. Губкин белән Ф. Ф. Сыромолотов җитәкчелегендәге зур геология экспедициясе эшләде. Бу экспедиция Сөкәй, Чистай, Сызрань, Батрас, Камышлы, Түбән Кармалка, Сарабикол һ. б. районнарда тикшерүләр үткәрде. Тикшерүләрдән соң академик Губкин, Идел белән Урал арасындагы гаҗәеп зур киңлекләрдә гаять бай нефть ятмалары бар, дигән ныклы нәтиҗәгә килде. 1919 елның 26 августында И. М. Губкин һәм Ф. Ф. Сыромолотов Чистай һәм Сөкәй ятмаларын беренче тикшерү нәтиҗәләре турында Казаннан В. И. Ленинга телеграмма җибәрәләр. Алар бу телеграммада Идел белән Урал арасында һичшиксез зур нефть ятмалары булу һәм биредә нефть эзләп тирәнгә бораулау эшләре башларга кирәклек турында хәбәр итәләр.

Ләкин илебез экономикасының һәм техникасының ул вакыттагы хәле Идел белән Урал арасындагы девон нефтенең иксез-чиксез байлыкларын ачарга һәм файдаланырга мөмкинлек бирә алмадылар. Биредәге нефть ятмаларын яңадан тикшерү 20 нче елларның ахырында, 30 нчы елларда гына башланды. «Уралнефть» берләшмәсе 1931 елда татар нефтен эзләү эшләрен яңартты. 1935 елда Чистай районында дүрт геологлар партиясе эшли иде инде. 1938 елда СССР Авыр промышленность Халык Комиссариатының баш Геология идарәсе начальнигы академик Губкин инициативасы белән Татарстанның үзенең мөстәкыйль Геология идарәсе оештырылды.

Татарстанда куәтле нефть промышленносте тудыру СССР халыкларының туганнарча ярдәмләшүен һәм социалистик интернационализмны раслаучы иң яхшы мисал булып тора. Нефть байлыкларын эшкәртүнең беренче этабында Татарстанга Бакудан һәм Башкортстаннан, Грозныйдан һәм Төркмәнстаннан, Чечен-Ингушетиядән һәм илебезнең башка районнарыннан квалификацияле меңләгән эшче-нефтьчеләр һәм инженер-техник работниклар җибәрелде. Геология һәм нефть эзләү буенча Ленинград институтының академик С. И. Миронов җитәкчелегендәге фәнни сотрудниклары Татарстан территориясенең перспектив структурасын тикшерделәр. СССР Фәннәр академиясе сотрудниклары С. Ф. Федоров, К. Р. Чепиков, В. П. Батурин, М. И. Варенцов һәм башкалар республиканың нефть районнарында җир асты катламнарының төзелешен өйрәнделәр. Хәзер Татарстанның нефть районнарында Советлар Союзында яшәүче 40 тан артык милләт вәкилләре эшли.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте, ленинчыл милли политиканы тормышка ашырып, социалистик төзелешнең барлык чорларында да илнең артта калган милли республикалары һәм өлкәләре промышленностен тизләтелгән темплар белән үстерүгә гомумсоюз фондларыннан финанс средстволары җибәрүне һаман арттыра бардылар. 1918 елның 15 августында РСФСР Халык Комиссарлары Советының В. И. Ленин кул куйган карары моның тарихи мисалы булып тора. Ул карарда Татарстанда эшчеләр поселогы төзүгә 2.030.000 сум акча җибәрү каралган иде. Ә бу бит Советлар республикасының дошманнарның утлы боҗрасы эчендә калган чагы була. [ТАССРның ҮДА, 637 фонд. 1 тасвирлама, 8 эш, 98 бит.]

Беренче бишьеллык планда РСФСР дәүләт промышленностеның төп фондларын 291,5 процентка үстерү каралган булса, Татарстан АССР буенча бу үсеш 534,5 процент тәшкил итә иде. [1930 елда Мәскәүдә басылган «СССР халык хуҗалыгы төзелешенең бишьеллык планы», III том, 554 бит; шулай ук 1929 елда Казанда басылып чыккан «Татарстан АССРның халык хуҗалыгы һәм социаль-культура төзелеше буенча бишьеллык планы», 8 бит.]. Татарстан промышленностена капитал салуның 58 процентын гомумдәүләт фондлары исәбенә булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Беренче бишьеллык план нигезендә Татарстан промышленностена 85 миллион сум капитал салу каралган иде. Ә чынбарлыкта исә бишьеллык чорында 121,9 миллион сум капитал салынды. Икенче бишьеллыкта бу сан 703 миллион сумга җитте.

Совет хөкүмәте бу средстволарны республикада яңа авыр промышленность тармакларын булдыру максатларына тоту өчен җибәрде, шул ук вакытта промышленность төзелешенең республиканың экономик үсеш профиленә һәм гомумдәүләт интересларына яраклашуына игътибар бирде. Аеруча зур предприятиеләр ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм Совет хөкүмәтенең махсус карарлары нигезендә төзелделәр. Бу исә партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең Татарстанда индустрия үсешенә зур игътибар белән каравы ту-

рында сөйли иде. Беренче ике бишьеллык дәверендә республикабызда 46 зур һәм 100 дән артык зур булмаган промышленность предприятиесе төзелде. [Татарстан 50 елда. Статистика җыентыгы. Казан. 1967 ел. 77 бит.] Беренче бишьеллыкларда төзелгән зур предприятиеләр арасында түбәндәгеләрне әйтеп китәргә була: Казан мех комбинаты (ул беренче бишьеллык ахырына ук инде Советлар Союзында җитештерелә торган барлык мех әйберләрнең 40 процентган артыгын эшләп чыгара иде), Казан синтетик каучук заводы (алар СССРда бары дүртәү генә иде), илебездәге өчаунең берсе булган Казан кинопленка фабрикасы (хәзер ул илебездә җитештерелә торган кинопленканың 45 проценты чамасын эшләп чыгара), СССРда бердәнбер булган Казан кетгут заводы, Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, берничә машиналар төзелеше заводы, Казанда төзелгән куәтле ике теплоэлектроцентраль һәм башкалар.

Татарстанда төзелә һәм реконструкцияләнә торган предприятиеләр өчен илебезнең промышленность районнарыннан машиналар, станоклар һәм башка җиһазлар агылды. Мәсәлән, Ленин исемендәге Казан җитен комбинаты тулысынча Ленинград, Брянск һәм Шуйск машина төзелеше заводларыннан алынган җиһазлар исәбенә реконструкцияләнде. Синтетик каучук заводына полимеризаторларны һәм рифайнерларны Киевтагы «Большевик» заводы, суыткыч җиһазларны Мәскәүдәге «Компрессор» заводы җибәрде. Казан кинопленка фабрикасына җиһазлар Ленинград һәм Одесса заводларыннан килде. Казан ТЭЦлары өчен югары басымлы казаннар Ленинград металлар заводыннан, турбиналар һәм генераторлар Ленинградтагы «Электросила» заводыннан алындылар. СК-4 заводы, ТЭЦ-1 өчен һәм Вахитов исемендәге комбинатны реконструкцияләү өчен кирәкле җиһазларның бер өлешен Совет хөкүмәте чит илләрдән сатып алды. Татарстанның нефть промышленносте өчен бораулау җайланмаларын «Уралмаш» заводы бирде һәм хәзер дә җибәреп тора, бораулау вышкалары Куйбышевтан алына, нефть промышленностена кирәкле күп төрле җиһазлар Мәскәү, Ленинград, Баку, Уфа предприятиеләреннән китерелә. Хәзерге вакытта Татарстан машиналарны һәм станокларны, чималны һәм материалларны Советлар Союзының 98 экономик районыннан алып тора. Бу районнар безнең республиканы кара һәм төсле металлар, тракторлар һәм комбайннар, автомобильләр һәм станоклар, цемент һәм таш күмер, мамык, минераль ашламалар һәм башка бик күп продукция белән тәэмин итеп торалар.

Илне социалистик индустрияләштерү чорында Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте милли республикаларга, шул исәптән Татарстанга да, квалификацияле эшче һәм инженер-техник кадрлар әзерләүдә гаять зур ярдәм күрсәттеләр. Беренче чиратта төп милләт хезмәт ияләре арасыннан кадрлар әзерләүгә игътибар ителде. Социалистик индустрияләштерү елларында Татарстанда эшчеләр сыйныфының саны нинди кызу темплар белән үскәнен түбәндәге мәгълүматлар бик ачык күрсәтә:

| | 1913 ел Казан губернасы | 1927—1928 ел Тат. АССР | 1932 ел Тат. АССР | 1937 ел Тат. АССР |
|---|---|---|---|---|
| Эре промышленностьтагы эшчеләр саны | 25.157 | 26.436 | 65.353 | 82.533 |
| Шулар арасындагы татар эшчеләренең проценты | 11 | 24,5 | 35,6 | 36,5 |
| Татар эшчеләренең абсолют саны | 3.000 | 5.500 | 16.400 | 28.100 |

[Татарстан АССР XX елда саннарда. Статистика җыентыгы. Казан. 1940 ел. 18, 59 битләр].

Таблицадан күренгәнчә, Татарстанның эре промышленностендагы эшчеләр саны 1937 елда 1913 елдагыга караганда 3 тапкырга арткан, ә шул ук вакытта татар эшчеләренең саны 9 тапкырдан да күбрәккә арткан. Татар эшчеләренең промышленность

квалификациясе дә үсә бара. Мәсәлән, 1937 елда югары квалификацияле эшчеләр группасында татарлар 29 процентган артыграк, урта квалификация группасында 39 процент булды. Ә революциягә кадәр югары квалификацияле татар эшчеләрен бармак белән генә санарлык иде.

Партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда да, инженер-техник кадрлар әзерләү турында кайгыртучанлыгы ул республикаларда югары һәм урта махсус белем бирүче уку йортлары ачуда, аларга укучылар алуны арттыруда, беренче чиратта, төп милләт эшчеләрен һәм крестьяннарын кабул итүдә чагылды. Мәсәлән, 1929—1937 елларда Татарстанда яңа 10 югары һәм 46 урта махсус уку йорты ачылды. Әгәр дә 1913 елда Казанның 3 югары уку йортында 3.488 студент укыган булса, 1937 елда Татарстан АССРның 13 югары уку йортында 9.300 студент, шул исәптән 2 мең чамасы татар студентлары укый иде. 1913 елда Казан губернасындагы 9 урта махсус уку йортында 1739 кеше укыса, 1937 елда Татарстандагы 55 урта махсус уку йортында 12.800 укучы, шул исәптән 6 меңнән артык (ягъни барлык укучыларның 49 процент чамасы) татар укучысы бар иде.

1928 елдан алып 1938 елга кадәр Татарстандагы югары уку йортлары һәм техникумнары 34 мең белгеч, шул исәптән 15 мең чамасы югары квалификацияле белгеч, әзерләп чыгардылар.

Татарстан халык хуҗалыгы өчен белгечләр үзендәге югары һәм урта махсус уку йортларында гына түгел, бәлки Мәскәү, Ленинград һәм илебезнең бүтән шәһәрләрендәге уку йортларында да күпләп әзерләнделәр. Мәсәлән, 1927 елда Ленинградтагы уку йортларында 149 татар студенты укыды. Аларның 85 проценты техник уку йортларында белем ала иде. («Кызыл Татарстан» газетасының 1927 ел 16 марттагы 61 нче саны.) 1932 елда Мәскәүнең югары уку йортларында Татарстаннан барган 61 аспирант, шул исәптән 49 татар аспиранты, укыган. (КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. 15 фонд. 15 тасвирлама. 481 эш. 27—28 битләр.)

1938 ел ахырында Татарстанның халык хуҗалыгында 53.742 белгеч, шул исәптән 18.433 (ягъни 34,3 проценты) татар белгече эшли иде инде. (Татарстан АССРның 20 еллыгы. Казан. 1940 ел. 185 бит).

Шулай итеп, Татарстанда күп санлы яңа совет интеллигенциясе барлыкка килде. Бу партиянең ленинчыл милли политиканы һәм пролетар интернационализм принцибын эзлекле тормышка ашыруы нәтиҗәсе иде.

Социалистик индустрияләштерү чорында пролетар интернационализмның тәҗрибә уртаклашу юлы белән үзара ярдәмләшү традицияләре барлыкка килде. Промышленносте югары дәрәҗәдә үскән үзәкләр үсешләре түбәнрәк булган милли республикалар белән социалистик ярыш, шефлык итү договорлары төзеделәр, күп санлы делегацияләр алмашу оештырдылар, алдынгы тәҗрибәне аларга да илтеп җиткерү чаралары күрделәр. Үсешләре түбән булган милли республикалар индустрияләштерү чорына югары үсешкә ирешкән административ-экономик өлкәләр составына кертелделәр. Мәсәлән, Башкортстанның промышленносте үсешенә беренче бишьеллык башында Урал-Кузнецк комбинатын (УКК) төзү һәм аның составына Башкортстан промышленностен кертү бик зур йогынты ясады. (В. Хавин. Милли республикаларны һәм өлкәләрне социалистик индустрияләштерү. Мәскәү. 1933 ел. 72 бит.) Чувашстан АССРның һәм Мари, Удмурт автономияле өлкәләренең 1929—1936 елларда югары үсешкә ирешкән промышленносте һәм идея-оештыру ягыннан нык тупланган партия оешмасы булган Нижегород (Горький) крае составында булулары да аларның экономикасын һәм культурасын тиз күтәрүдә, социалистик индустрияләштерү темпларын тизләтүдә гаять зур роль уйнады.

1930 ел башында Мәскәү өлкәсе белән Татарстан арасында социалистик ярыш договоры төзелде һәм ул 10 ел гамәлдә булды. Мәскәү өлкәсе бу елларда безнең республикага машиналар, станоклар һәм башка җиһазлар җибәреп торды, квалификацияле кадрлар белән ярдәм итте, производстводагы һәм эре промышленность предприятиеләре төзүдәге алдынгы тәҗрибәсе белән уртаклашты. Мәскәү белән Казан эшчеләре арасындагы ныклы производство элемтәләре аңардан да элегрәк җайга салынган иде. 1929 елның февралендә Казанга зур группа Мәскәү эшчеләре килде һәм 10 көн дәвамында республикадагы хуҗалык һәм культура төзелеше процессы белән җентекләп танышты. Мәскәү эшчеләре заводларда һәм фабрикаларда, ша-

һәр Советында һәм Татарстан Үзәк Башкарма Комитетында булдылар. 27 февральдә «Красная Татария» һәм «Кызыл Татарстан» газеталарында Мәскәү эшчеләр делегациясенең «Без Казанда ун көн булдык һәм без Казан эшчеләренә менә нәрсә дибез» дигән хаты басылып чыкты. Мәскәү эшчеләренең бу хатында түбәндәгеләр язылган иде: «Кадерле иптәшләр! Без Казаннан канәгатьлек һәм иптәшләрчә кайнар рәхмәт хисләре белән китәбез. Сезнең арада үткәргән ун көнебез союзыбызның хезмәт ияләре арасындагы элемтәләрнең, алар кайсы районда гына эшләсәләр дә, никадәр нык һәм тыгыз булуын тагын бер кабат раслый».

Шул көннәрдә үк Татарстан эшчеләре делегациясе Мәскәүдә булды һәм шулай ук башкаладагы промышленность предприятиеләренең, совет һәм җәмәгать оешмаларының эшләре белән җентекләп танышты. Тәҗрибә алмашуның һәм үзара ярдәмләшүнең әһәмиятенә бәя биреп, Мәскәү эшчеләре болай дип яздылар: «Тәҗрибә уртаклашу—хаталарны булдырмауда иң дөрес ысул. Мондый алмашуларны безнең көндәлек эшебезгә кертергә кирәк. Бер эшче икенче эшче белән, предприятие предприятие белән, шәһәр шәһәр белән, республика республика белән тәҗрибә уртаклашсыннар. Безнең 1929 елның февралендә вәкилләр алмашуыбыз планлы төстә тәҗрибә уртаклашуның, Советлар Союзы хезмәт ияләренең тагын да тыгызрак берләшүенең башлангычы булсын. Безнең иң яхшы предприятиеләребезнең эше белән танышу һәм аларның тәҗрибәләрен урыннарга җиткерү максатларында производство делегацияләре оештыру аеруча кирәкле эш.

Бүген Казаннан киткәндә, Татарстан хезмәт ияләренең киң күңелле һәм бердәм гаиләсеннән киткәндә, без үзебез белән тирән канәгатьлек, рәхмәт хисләре һәм үзара аралашу нигезендә ныгыган, уртак ихтыяр һәм хисләр белән янган хәлдә социалистик төзелеш юлыннан яңа җиңүләргә тагын да кыюрак барырбыз дигән ныклы ышаныч алып китәбез». («Красная Татария» газетасы. 27 февраль. 1929 ел. № 46.)

Беренче бишьеллык елларында Татарстанның эшчеләр сыйныфы белән Урал, Донбасс һәм илебезнең башка промышленность үзәкләрендәге эшчеләр арасында да тыгыз элемтәләр урнашты. Донбасс шахтерлары Татарстанның удар төзелеше булган Казан ТЭЦ ы өчен беренче эшелон күмерне үзләре алып килделәр, ә аны СССР Авыр промышленность халык комиссариатының Главэлектро командировкасы белән Казанга килгән Штерово электростанциясе кочегарлары бертуган Галиәкберовлар якты. Бу пролетар интернационализм көченең символы иде. Кочегар туганнарның берсе — Габделхак Галиәкберов беренче Казан ТЭЦында өлкән кочегар булып калды, шул урынында чирек гасырдан артык эшләде һәм хезмәттәге җиңүләре өчен ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнде.

Икенче яктан, беренче бишьеллыкта ук инде Татарстаннан киткән уннарча мең эшчеләр илебезнең зур төзелешләрендә һәм промышленность үзәкләрендә эшләделәр. Мәсәлән, илебезне индустриялəштерү башланганда бары тик Донбасста гына да 12 меңнән артык татар шахтеры эшләгән, аларның күбесе тырыш хезмәт үрнәкләре күрсәткәннәр. Әле 1926 елда ук производстводагы югары күрсәткечләре һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен танылган шахтер Шәрәфетдин Фәхретдиновка «Хезмәт Герое» дигән мактаулы исем бирелгән. («Кызыл Татарстан» газетасының 1926 ел 30 марттагы 72 нче саны.) Беренче бишьеллык елларында Донбасс шахтерлары сафына тагын 20.000 татар эшчесе баса.

Мирсәет Ардуанов җитәкчелегендәге төзүчеләр бригадасының соклангыч хезмәтләре 1927 елда Березники химия комбинаты төзелешендә башлана. Ул вакытта төзелештә эшче куллар җитешми. Мирсәет Ардуанов Татарстанга кайта, үзенең якташларыннан бердәм төзүчеләр бригадасы оештыра. Татар егетләреннән торган бу бригаданың даны тиздән бөтен илгә тарала. Березники төзүчеләренең күп тиражлы газетасы ул вакытта, Ардуанов бригадасында 4 ел эчендә бер генә дә прогул булмады һәм ул производство заданиеләрен һәрвакыт арттырып үтәп килде, дип яза. Тырыш хезмәтләре өчен бригаданың күпчелек членнары хөкүмәт бүләкләре алалар, ә бригадир Мирсәет Ардуанов Ленин ордены белән бүләкләнә, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана, Советларның VIII Бөтенсоюз съезды эшендә, СССР Конституциясен кабул итүдә катнаша. Березникида хезмәт батыры эшче-бетончы Мирсәет Ардуанов исемендәге урам бар. («Березниковский рабочий» газетасы, 1957 елның 10 мартындагы 50 (8677) сан.) 1968 елның 11 ноябрендә «Правда» газетасы

Березникида завод мәйданында эшче Мирсәет Ардуановка һәйкәл салу турында хәбәр итте.

Магнитогорск металлургия комбинатын төзүдә Апас районының татар егетләреннән торган һәм Галиуллин җитәкчелек иткән 26 кешелек бетончылар бригадасы намуслы хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр. Кыска вакыт эчендә бу бригада егетләре үз эшләренең осталарына әверелә һәм 1931 елның июнендә коксохимкомбинатының насос станциясен бетонлауда нормага караганда дүрт тапкыр артыграк югары сыйфатлы измә өлгертеп, дөнья рекорды куялар. Бригада Бөтенсоюз кучмә Кызыл Байрагын яулап ала, ә бригадир Галиуллин Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Икенче дөнья рекорды 1932 елның сентябрендә Казан шәһәренең Ленин районы төзелешендә эшләүче латыш халкы вәкиле Максим Казик тарафыннан куелган. Ул сменага 30 кубометр җир казый һәм моңа кадәр дөнья рекорды булып саналган Днепростройдагы күрсәткечне (26 кубометр) уздыра. Ул вакытта «Красная Татария» газетасы язганча, Максим Казикның дөнья рекорды кую тарихы 1917 елның Октябреннән башлана. Ул вакытта Казик кызыл гвардияче була, Петербургтагы Павлов училищесы казармаларын штурмлауда катнаша, 1918 елның сентябрендә Казанны акгвардиячеләрдән һәм чехлардан азат итүчеләр арасында була, каты яраланып, Казанда кала. Гражданнар сугышыннан соң ул бетончы һөнәрен үзләштерә, иң оста җир казучы булып китә, үзенең бөтен көчен яңа социалистик җәмгыять төзүгә бирә.

Илебезнең һәр почмагында промышленность гигантлары төзү социалистик индустрияләштерүнең характерлы якларыннан берсе иде. Бу төзелешләрдә Советлар Союзының уннарча милләт вәкилләре катнаштылар, халыклар арасында дуслык ныгыды, бердәм интернационал коллективлар барлыкка килде. Татарстанның Дәүләт музеенда Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына Днепрострой тапшырган Кызыл Байрак саклана. Бу байракның бер ягына түбәндәге сүзләр язылган: «Днепрострой — ул партия политикасы, ул — большевистик программаның практик чагылышы, ул — ЛЕНИН теләгенең, большевиклар партиясе теләгенең гәүдәләнеше». Байракның икенче ягына: «Днепрокомбинатстройның 60.000 пролетариеннан ТАССР ЦИКына, Татреспублика хезмәт ияләренең Днепрогэс төзелешендә актив катнашулары өчен»,— дип язылган.

Днепрогэс төзелешендә югары күрсәткечләргә ирешүләре өчен республикабызның күп вәкилләре дәүләт бүләкләренә лаек булалар, ә эшче-бетончы Закир Таһиров һәм инженер Гыйззәтулла Ибәтуллин Ленин орденнары белән бүләкләнәләр. Днепрогэс төзелешендә илледән артык милләт вәкилләре — руслар һәм украинлылар, татарлар һәм башкортлар, чуашлар һәм марилар, белоруслар һәм грузиннар, удмуртлар һәм башкалар катнашты. Магнитогорск металлургия комбинатын төзүдә дә 40 милләт вәкилләре эшләде. Башкортстанның һәм Татарстанның нефть промышленносен үстерүдә 50 дән артык милләт вәкилләре катнашты. Мондый мисалларны тагын бик күп китерергә мөмкин булыр иде.

Халык хуҗалыгының барлык тармакларын реконструкцияләү чорында туган стахановчылар хәрәкәтенең киң колач алуы илебез халыклары арасындагы производство элемтәләрен тагын да ныгыта төште. Мәсәлән, 1935—1936 елларда Казан һәм Ленинград язу машиналары заводлары арасында социалистик ярыш җәелде. Казан заводы эшчеләре Ленинградка бардылар һәм анда үз хезмәттәшләренең эш ысулларын җентекләп өйрәнделәр. 1936 ел башында Казан, Ленинград һәм Мәскәүнең мех фабрикалары коллективлары социалистик ярышка кушылдылар. Мондый ярышлар предприятиеләр арасында гына түгел, бәлки аерым бригадалар, хәтта аерым эшчеләр арасында да киң колач алды. Мәсәлән, Казан ОМКУЗ (сарык тиресен каракүл итеп эшкәртү) заводының Н. Хәсәнов җитәкчелегендәге бригадасы Ленинград мех фабрикасының тирене кырып чистарту бригадасы белән социалистик ярыш договоры төзеде. Ленинград бригадасы чакыруына җавап итеп, Хәсәнов бригадасы 1936 ел планын 9 айда үтәргә, дәүләт техник имтиханнарын «отлично»га бирергә һәм хезмәт җитештерүчәнлеген 250 процентка күтәрергә йөкләмә алды. («Меховщик» газетасы, 1936 елда 27 январь саны.)

Исеме бөтен илгә билгеле булган стахановчы Николай Сметанин Казанга килде һәм «Спартак» комбинатының директоры итеп куелды. Биредә ул үзенең алдынгы тәҗрибәсен производствога кертте. Татарстандагы «Красный металлист» заводы ти-

мерчесе Василий Дьячков Горький автомобиль заводында эшләүче танылган стахановчы Александр Бусыгин янында булды һәм аның эш ысулларын өйрәнде.

Үз чиратында Татарстан предприятиеләренең стахановчылары да башка шәһәр, өлкә һәм республика предприятиеләренең эшчеләре белән үзләренең тәҗрибәләрен уртаклаштылар. 1936 елның мартында Казан киез аяк киемнәре фабрикасында Ярославль киез аяк киемнәре фабрикасы («Упорный труд» фабрикасы) эшчеләре булдылар. Алар бирәдә алдынгы стахановчы эш ысуллары белән җентекләп таныштылар. Аннары эшчеләр алган тәҗрибәләрен үз фабрикаларында файдаландылар. («За ударные темпы» дигән күп тиражлы газета, 1936 елның 13 март саны.)

Әйткәннәрдән ачык күренгәнчә, социалистик индустрияләштерү процессында Советлар иленең күп милләтле халыклары арасында дуслык һәм ярдәмләшү ныгый барды.

* * *

Коммунистлар партиясенең социалистик индустрияләштерү процессында эзлекле рәвештә ленинчыл милли политика үткәрүе һәм пролетар интернационализм принципларын тормышка ашыру нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде: беренчедән, элекке артта калган милли республикаларда промышленность үсешенең темплары гомумсоюз һәм гомумроссия күләмендәгедән шактый югарырак булды. Мәсәлән, әгәр Совет властеның 50 елында РСФСР да промышленность производствосы 67 тапкыр арткан булса, Башкортстанда ул 352 тапкыр, Удмуртиядә — 312 тапкыр, Татарстанда — 258 тапкыр, Чувашстанда — 192 тапкыр, Мари АССР да — 146 тапкыр артты. («Правда» газетасы, 1967 елның 1 ноябрендагы 305 саны.) Икенчедән, социалистик индустрияләштерү нәтиҗәсендә аграр булган күпчелек милли республикалар беренче бишьеллык елларында ук индустриаль яки индустриаль-аграр республикаларга әверелделәр. Мәсәлән, Татарстанның халык хуҗалыгында промышленность продукциясенең өлеше 1928 елда 33 процент кына булса, 1932 елда ул 60 процентка, ә 1937 елда 74,8 процентка кадәр үсте. Өченчедән, социалистик индустрияләштерү чынбарлыкта Татарстанның экономик артталыгын һәм фактик тигезсезлеген бетерү проблемасын хәл итте. Әгәр Татарстанда җан башына промышленность продукциясе житештерү 1913 елда гомумроссия күләмендәгедән 4 тапкыр кимрәк булса, беренче бишьеллык башына ул инде 2,5 тапкыр гына, ә икенче бишьеллык башына 1,6 тапкыр гына кимрәк булды. 1941 елга исә Татарстанда җан башына промышленность продукциясе житештерү күләме гомумсоюз күләмендәге дәрәҗәгә якынлашты.

Республикабызда яшәүче барлык милләт эшчеләренең, колхозчыларының һәм хезмәтчел интеллигенциясенең тырышлыгы, илебездәге барлык халыкларның чын күңелдән күрсәткән туганнарча ярдәме, Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасы нәтиҗәсендә Татарстан Советлар Союзының иң алдынгы индустриаль республикаларының берсенә әверелде. Безнең республикабыз нефть чыгару, фотокинопленка, желатин, мех әйберләре, кетгут һәм кайбер башка промышленность продукциясе житештерү буенча СССРда беренче урында тора. Хәзер Татарстан илебездә эшләнә торган барлык мех әйберләренең 25 процентын, киез аяк киемнәренең 32 процентын, җылылык энергетикасы процессларын тикшерүче һәм регулярлаштыручы приборларның 35 процентын, нефтьнең 31 процентын, кул сәгатьләренең 12 процентын житештерә. Бораулау иңсәләре, олеин кислотасы, модификатор, фотожелатин һәм преципитат кебек продукцияләр илебездә бары тик Татарстан предприятиеләрендә генә житештерелә.

Хәзер Татарстан промышленностеның югары квалификацияле кадрлары белән илебезнең башка өлкәләренә һәм республикаларына үзе ярдәм күрсәтә. Безнең республикабызны бик хаклы рәвештә «нефтьчеләр университеты» дип атыйлар, чөнки нефть эзләүнең, бораулауның һәм нефть чыгаруның Татарстандагы алдынгы методлары Советлар Союзының күпчелек нефть чыгару өлкәләрендә киң кулланыла. Татарстан нефтьчеләре Себердә, Казагыстанда, Белоруссиядә һәм илебезнең башка районнарында нефть ятмалары эзләүдә турыдан-туры катнашалар. Мәсәлән, Әлмәтбурнефтьнең 36 кешедән торган Александр Травин һәм Владимир Чернозубов житәкчелегендәге бригадалары әле 1962 елның маенда ук Себердәге Марково нефть ятмасын тикшерергә һәм үзләштерергә киттеләр. Татарстан вәкилләре үзләренең себерле дуслары белән иңгә-

иң торып эшлиләр. Борауланган беренче скважиналар ук әйбәт нәтиҗәләр бирде, югары сыйфатлы кембри нефте фонтаны бәрде. Бригадалардагы 36 кешенең берсе дә хезмәт фронтыннан китмәде. 22 нче скважинаны борауларганда ирешкән югары күрсәткечләре өчен Травин бригадасы Главгеологиянең беренче премиясен һәм профсоюзлар Үзәк комитетының Кызыл Байрагын алды. Тырыш хезмәтләре һәм белемнәрен арттыру өстендә эшләүләре нәтиҗәсендә бораулаучы ярдәмчеләре Шалимов һәм Гагизуллин 6 нчы разрядлы бораулаучылар булдылар, ә бораулаучы Мөслимов белән Сәхипов бораулаучы мастер дәрәҗәсенә үстеләр. Бораулаучы мастер Александр Травин читтән торып нефть институтын тәмамлады һәм күршедәге нефть эзләү участогына өлкән инженер итеп куелды. Татарстан вәкилләре һаман да зур энтузиазм белән эшлиләр, тайгага һөҗүмне дәвам иттерәләр, Себер «кара алтын»ының иксез-чиксез байлыкларын ачалар, урындагы иптәшләренә үзләренең бай тәҗрибәләрен өйрәтәләр.

Яшь коммунист Дамир Нурисламов бригадасы үзенең җидееллык план заданиесен ел ярым срогыннан элек үтәде һәм тулы составы белән Казагыстандагы Мангышлак нефтен үзләштерергә китте. Анда ул менә берничә ел инде тырыш хезмәт үрнәкләре күрсәтеп эшли.

Социалистик Хезмәт Герое Александр Тимченко җитәкчелегендәге вышкалар монтажлау бригадасы 1965 ел башында Төмән өлкәсенә китте. 11 кешелек бу бригада анда да тизләтелгән метод белән вышкалар төзүдә Татарстанда туплаган тәҗрибәсен уңышлы куллана. Мондый мисаллар китерүне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Алар илебез халыкларының бергә эшләве нәтиҗәсендә социализмның ничек төзелүен ачык раслыйлар.

Кайчандыр патша Россиясенең артта калган хокуксыз милли районы булган бүгенге Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы үзенең промышленносте үсеше дәрәҗәсе ягыннан алга киткән күп кенә капиталистик илләрдән шактый югары тора. Татарстаннан дөньядагы 50 дән артык илгә 2.000 төрдән артык промышленность продукциясе чыгарыла. Республикабыз продукциясен алучылар арасында социалистик илләрнең барысы да, шулай ук Бөекбритания, Бельгия, Япония, Һиндстан, Бирма, Берләшкән Гарәп Республикасы, Цейлон, Сурия, Камбоджа, Пакистан, Йәмән, Сомали һәм башкалар бар.

* * *

СССР да, аннары халык демократиясе илләрендә дә социалистик төзелеш процессында пролетар интернационализм принципларының йогынты ясау сферасы гаять киңәйде, пролетар интернационализм халыкларның нык дуслыгына, аларның экономика, политика һәм культура өлкәләрендә хезмәттәшлегенә, эчкерсез туганнарча ярдәмләшүенә нигезләнгән социалистик интернационализмга әверелде. Социалистик интернационализм бөтен дөнья социалистик системасы илләрендәге барлык катлау хезмәт ияләренең — эшчеләрнең, хезмәтчел крестьяннарның һәм интеллигенциянең идеологиясенә әйләнде.

КПСС Программасында әйтелгәнчә, киң колач белән коммунизм төзү чоры СССРда милли мөнәсәбәтләрнең үсешендә яңа этап булып тора, ул милләтләрнең тагын да якынлашуы һәм аларның тулы бердәмлегенә ирешү белән характерлана. Коммунизмның материаль-техник базасын төзү совет халыкларының тагын да тыгызрак берләшүенә алып бара. (КПССның XXIII съезды. Стенографик отчет. III том, 312—313 бит).

Татарстанда һәм башка милли республикаларда социалистик индустрияләштерү чорында эчкерсез туганнарча ярдәмләшү — ул ленинчыл пролетар интернационализм идеясенең тантанасы, илебездәге социалистик һәм коммунистик төзелешкә Коммунистлар партиясенең зирәк җитәкчелеге күрсәткече. КПСС барлык социалистик илләр белән, тугандаш коммунистик һәм эшчеләр партияләре белән мөнәсәбәтләрендә бөек Ленинның пролетар интернационализм принципларына таянып эш итә. Коммунистлар партиясенең һәм Совет дәүләтенең үсеп килүче илләр белән мөнәсәбәтләре нигезендә шулай ук пролетар интернационализм принциплары — аларның экономик һәм культура үсешләренә һәрьяклап ярдәм итү, халыкара эшчеләр хәрәкәтен һәм милли азатлык өчен көрәшне яклау политикасы ята.

# МӘГЪРИФӘТ НУРЫ

«Казан утлары» журналы редакциясе кушуы буенча мин Татарстан Халык мәгарифе министры Мирза Мәхмүтов янына әңгәмә үткәрү өчен килдем. Минем максат шул: республикада 50 ел эчендә халык мәгарифе нинди казанышларга ирешкән — шуны министрның үз авызыннан ишетү.

Алдан ук әйтим: мин журналист буларак та, укучы буларак та гадәттәге әңгәмәләрне күз алдыма китерә идем инде — син сораулар бирәсең, ул җаваплар бирә. Ләкин бу әңгәмәне ничектер үзенчәлеклерәк итеп үткәрәсе килде.

Моңа очраклы бер вакыйга ярдәм итте. Ул болай булды.

Мин, алдан белдереп тә тормастан, министр бүлмәсенә үттем. Министр янында бик гади киенгән олы яшьтәге бер ханым утыра иде. Мирза Исмәгыйлович ягымлы елмаеп бик мөлаем тавыш белән аңа нәрсәдер сөйли. Ханым да бик акрын тавыш белән, бүлмәдәге тынлыкны бозарга теләмәгәндәй, җавап бирә. Ә министр аны бик игътибар белән тыңлый.

Әллә мин әйтәм, министр үзенең әнисе яки берәр туганы белән сөйләшеп утырамы! Миңа ничектер уңайсыз булып китте, секретарь чыгып чакырганчы ук ашыгып керүемә уңайсызланып куйдым.

Мәхмүтов мине каршылап урыныннан торды һәм әлеге ханымга күрсәтеп:

— Таныш булыгыз, бу минем укытучым,— диде.

Мин мөлаем чырайлы бу ханымның кулын кыскан арада, Мирза Исмәгыйлович сүзен дәвам итте:

— Менә шушы тыйнак, гади һәм гаҗәеп тырыш кешеләр — алар бездә меңнәрчә — татар яшьләренә гыйлем бирәләр, кыю рәвештә тормышка атларга ярдәм итәләр, туган илгә, республикага файдалы кеше булып үсәргә булышалар. Мондый ханымнарга һәр очраганда башыбызны иеп рәхмәт әйтеп үтәргә тиешбез.

Укытучы ханым көлеп куйды һәм кинәт кенә укучы балага мөрәҗәгать иткәндәй сорады:

— Әллә сез журналистмы!

— Әйе,— дидем мин.

— Халык мәгарифе казанышлары турында сорашырга телисездер инде!

— Әйе.

— Сезгә, әлбәттә, иң беренче, саннар кирәк: элек күпме мәктәпләр булган, хәзер никадәр. Шулаймы!

— Шулайрак.

— Ә сез менә аңардан сорагыз,— ул министрга таба ымлады,— ул ничек хәреф танырга өйрәнде, аннары ничек тракторчы булды, ә соңыннан кыю рәвештә фән дөньясына атлады.

Мирза Исмәгыйлович, игътибар итмәгез дигәндәй, кулын селтәде. Ләкин укытучы апа сүзен дәвам итте.

— Ул бик файдалы зур сүзлек төзеде, аның белән хәзер бездә генә түгел, чит илләрдә дә, Көнчыгыш илләрендә дә файдаланалар. Ул педагогия фәннәре Академиясе член-корреспонденты булып үсте, министр булды. Ә кем иде соң ул! Гади бер авыл малае. Мин аны бот буе вакытыннан беләм.



Бу мактаулардан уңайсызланган Мирза Исмәгыйлович нәрсәдер әйтергә теләгән иде, укытучы апа тагын аның сүзен бүлде.

— Безнең бөтен республика менә шундый инде,— диде ул горур тавыш белән,— нәкъ шундый. Ыштансыз йөргән авыл малайлары инженерлар булып, галимнәр булып, очучылар булып, врачлар, министрлар булып үстеләр. Боларның барсы өчен дә халкыбыз Ленинга рәхмәт укый. Менә шулар турында языгыз...

Ул беравык сүзсез торды, аннары аналарча якын итеп миңа карап куйды.

— Сез инде мине гаепләмәгез. Беләсезме, укытучы кеше өчен һәркем бала. Ана баласы белән, укытучы шәкерте белән горурлана. Бәлки мин артыграк сөйләп җибәргәнмен. Бу нәрсәгә үз балаларыңа булган мәхәббәт сәбәп... Сез мине аңлыйсыздыр...

Тиздән ул чыгып китте. Шул ук вакытта, секретарь кереп, кызлар көтеп утыруын әйтте:

— Сез ул кызларга сәгать унбергә килергә кушкан идегез,— диде ул.

— Рәхим итсеннәр, керсеннәр.

Аннары, миңа мөрәҗәгать итеп, министр әйтеп куйды:

— Алар озак тормаслар. Аларны тыңлау сезгә дә кызык булыр.

Ишек ачылды, бүлмәгә өч кыз килеп керде. Мин аларны студенткалар дип уйлаган идем, ялгышканмын икән. Бу кызлар татар мәктәпләрендә рус теле укытучылары булып чыкты. Берничә елга туган якларыннан еракка, чит илләргә җибәргәннәр: берсен Германия Демократик Республикасына, икесен хәтта ераккарак — Африка илләренә.

Министр аларның һәрберсе белән озак сөйләште. Ә саубуллашканда болай диде:

— Әгәр анда Татарстанда культура казанышлары турында сүз чыкса, бик гади мисал китерегез. «Менә без татар кызлары,— диегез,— безнең әтиләр бөтенләй укыйяза белмәгәннәр. Ә без татар телендә урта мәктәп бетердек, аннары институтта укып педагог булдык, хәзер сезнең балаларны рус теленә — Ленин сөйләшкән телгә өйрәтәбез». Мин ышанам: ГДРда да, Африка илләрендә дә бу бик ышанычлы җавап һәм Татарстан культурасы үсешен күрсәтү өчен менә дигән мисал булыр.

Мин министр белән әңгәмәгә керешкәнче, менә шундый хәлләр булды.

— Менә хәзер инде,— диде елмаеп министр,— мин сездән гадәти сораулар көтәм: «Революциягә кадәр Татарстан территориясендә мәктәпләр күпме булган, хәзер никадәр!» Дөресме!

— Дөрес әйтәсез.

— Менә бу сорауның үзендә төгәлсезлек ярылып ята. Революциягә тикле Татарстан дигән ил булмаган. Казан губернасы гына булган. Татарстан — илебез картасында 1920 елда, Владимир Ильич Ленин Татарстан Автономияле Республикасы төзү турындагы декретка кул куйганнан соң гына барлыкка килде. Татарстан — Ленинчыл милли политика нәтиҗәсе. Моны онытырга ярамый.

Менә хәзер мәктәпләр мәсьәләсенең асылына күчик. Мин үзем бер дә 1913 елгы мәктәпләр саны белән хәзерге мәктәпләр санын чагыштыруга гаҗәпләнмим. Әлбәттә, 1913 елда мәктәпләр саны бездә аз иде. Ә бүтән илләрдә алар күп идеме соң! Шулай ук аз иде. Гомумән, мәгариф хәлен, халыкның белемен, мәктәпләр, укытучылар белән генә үлчәү дөресме икән!

Әгәр дә мин соңгы елларда Татарстанда мәктәпләр саны кимүен әйтсәм, мөгаен, сез гаҗәпләнерсез. Әйе, мәктәпләр саны кимеде. Моның сәбәбе нәрсәдә соң! Әлла

балалар укудан баш тарталармы! Юк, моның сәбәбе башкада. Кечкенә, уңайсыз мәктәпләр урынына колхоз авылларында һәм совхоз поселокларында зур мәктәпләр, күп катлы, бөтен кирәк-яраклар белән җиһазландырылган яңа тип мәктәпләр салына. Менә шундый бер мәктәптә генә дә электәге 5 мәктәптә укыган кадәр бала укый. Әгәр дә бу турыда нинди дә булса буржуаз газетасы хәбәрчесе белеп алса, лаф орыр иде: имеш, Совет Татарстанында соңгы елларда халык мәгарифе күп мәртәбәләр кимеде дип, сенсацион мәкалә оештырудан бер дә тартынып тормас иде. Алар мондыйга бик оста бит.

Халык белемен күтәрүдәге үзгәрешләр, менә шулай, саннарны чагыштыруда түгел, ә тирәнрәк. Мәсәлән, гаять зур социаль үзгәрешләрдә, безнең илебездә, республикабызда, Совет власте елларында Коммунистлар партиясе, хезмәт ияләре депутатлары Советлары, комсомол тарафыннан халык мәгарифен күтәрүгә иң әһәмиятле чара итеп куйган тырышлыкларда.

Менә бер кечкенә генә, ләкин бик характерлы мисал китерәм. Революциягә кадәр безнең шәһәрләрдә һәм күп кенә авылларда дини мәктәпләр — мәдрәсәләр генә бар иде. Аларда малайлар гына укый ала иде. Шулай ук кызлар өчен дә мәдрәсәләр юк түгел иде. Ләкин алар мулла өендә остабикәдән генә дәрес алалар иде. Бу мәдрәсәләрдә балалар нинди белем ала алсын инде!!. Аз-маз хәреф танырга, язарга өйрәнгәч, мулла аларны көне-төне дини китаплар ятларга мәҗбүр иткән. Бу нәрсә, әлбәттә, чынбарлыктан, фән доньясыннан аларны ерак тоткан. Бу мәдрәсәләрдә укыган кешеләр, нигездә, томана булып калганнар, тормыш хәлләрен алар берни белмәгәннәр. Ә муллаларга, байларга шул гына кирәк тә. Бу нәрсә рус алпавытларына, сәүдәгәрләренә, завод хуҗаларына да файдалы булган.

Шуңа күрә дә патша колонизаторлары мөселман мәктәпләре эшенә катнашмаганнар. Шулай ук алар рус уку йортларына да мөселман кешеләрен кертүгә аягүрә каршы торганнар. Казандагы публичный китапханәгә татарларга керү тыелган, алар бары тик аның филиалына гына йөри алганнар, анда да әле якшәмбе көннәрдә генә — 12 дән сәгать 4 кә кадәр.

Революциягә кадәр 105 ел эчендә Казан университетында бары тик 78 татар укыган. Бу бик аз, әлбәттә...

Мәхмүтов каядыр телефоннан шалтыратты да минем хәлемне белеште — янәсе, арымадыммы! Үз-үзенә сөйләнгәндәй фикерен тагын дәвам итте:

— Ә хәзер сезнең төп соравыгызга җавап — Совет власте татар мәгарифе өлкәсендә нәрсә бирде һәм республиканың 50 еллыгы көннәрендә аның казанышлары нинди!

Бөтен нигезләрнең нигезе шунда: милли социалистик дәүләт төзү, бөек Ленин декреты белән Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы төзү — бу төп мәсьәлә. Татарстан Совет республикасы барлыкка килде, аның төп халкы теле — татар теле — бу функциональ булып калды. Татар теле турындагы фән зур үсеш алды, татар теле баеды. Татар әдәбияты баеды. Шәһәрләрдә, авылларда татар мәктәпләре эшли башлады, аларда фәннәр туган телдә укытыла.

Культура революциясенең асылы шунда да — ә бу нәрсә татар халкы өчен генә түгел, ә бәлки СССРдагы барлык милләт халыклары өчен дә. Алар шулай ук туган телләрен укыйлар, язалар.

Татарстан тулысы белән укый-яза белә торган республикага әйләнде.

Шунысын да әйтик, сез игътибар иткәнсездер, укый-яза белү генә, белем дәрәҗәсе генә кешенең югары культуралы булуы турында сөйләми әле. Белемлелек — хәзерге мәгънәсендә ул культуралылык, доньяны киң танып белү, үз-үзеңә зур таләпчәнлек.

Бөтенләй хәреф танымаган кешеләрне хәзерге мәгънәсендә белемле итү өчен күп көч түгелгәнен күз алдына китерәсездер сез!

Әйе, күп көч түгелде. Бик күп. Укый-яза белмәгән эшче һәм крестьяннарны укытуны оештыру турында 1919 елның 19 декабрендә В. И. Ленин кул куйган декретны хәтерлик. Ул елларда бөтен илдә ликбез мәктәпләре булдырылды. Миллионлаган кешеләр аң-белемгә омтылды.

Халык массалары укуга керешкәч, дәреслекләр — гади, һәркемгә аңлаешлы, шул

ук вакытта акыллы, кешедә хәзерге мәгънәдәге культура тәрбияләрлек дәреслекләр кирәк булды.

Казан университеты китапханәсендә искереп беткән татар дәреслекләре саклана. Алар — начар, арзан кәгазьләргә басылган юка гына брошюралар. Гарәп, фарсы, татар һәм төрек телләре дәреслекләре бар. Ә физика, химия, биология фәннәре буенча дәреслекләр бөтенләй юк диярлек. Милли мәктәпләр өчен рус теле дәреслеге дә юк.

Димәк, бу дәреслекләрнең барысын да Совет власте чорында булдырырга туры килде. Алар булдырылды, камилләштерелде һәм камилләштерелә.

1930 еллар тирәсендә культура революциясенең беренче этабы тәгәлләнде. Владимир Ильич васыятьләрен үтәп, Коммунистлар партиясе культура революциясенең икенче этабын башлады: 1930 елның сентябреннән башлап мәҗбүри түләүсез гомуми башлангыч белем бирү башланды. Ә дүрт елдан инде безнең илебездә мәҗбүри җидееллык белем бирү өчен көрәш җәелде.

Менә шулай, партия этаптан этапка барлык халыкның белемен күтәрү курсын алып бара. Мәктәпләр салына, дәреслекләр төзелә, педагог кадрлар әзерләү киңәя.

Сезнең белән без, безнең балаларыбыз белемле, культуралы кешеләр булсыннар өчен гаять зур, титаник көч салынды.

Менә минем алда берничә сан: хәзер Татарстан промышленностенда 20 мең инженер, 35 мең техник эшли. Соңгы елларда бездә 200 мең квалификацияле эшчеләр әзерләнде, 8 мең 400 кеше техникумнарның кичке бүлекләрен бетерде, 11 мең кеше производстводан аерылмыйча институтлар тәмамладылар.

Нинди кешеләр соң алар! Алар мәктәпләрдә яки татар телендә, яки рус телендә килечәктә кем булырга теләсәләр — инженермы, педагогмы, галимме — булырлык белем алган кешеләр. Милли мәктәпләр һәм рус теле аша татарлар, чувашлар, марилар, удмуртлар рус һәм хәзерге прогрессив дөнья культурасын үзләштерделәр. Менә һәр кешегә хәзерге совет мәктәбе нәрсә бирә!

Халык мәгарифе бигрәк тә соңгы ун ел эчендә зур казанышларга иреште. 1958 елда бөтен халкыбыз КПСС Үзәк Комитетының мәктәпләр турында тезисларын тикшерде. Соңыннан мәктәп турында һәм мәҗбүри сигезеллык белем бирү турында яңа закон кабул ителде. Яңа мәктәп биналары салу, мастерскойларны һәм лабораторияләрне җиһазландыру өчен зур средстволар бүленде.

Татарстанда соңгы ун ел эчендә тагын 300 мең укучы сыешлы яңа мәктәпләр салынды. Яңа интернатларда 24 мең 200 укучы тора. Әгәр элеккеге авылларда иң күзгә бәрелеп торган бина — мәчет яки чиркәү булса, ә бүгенге көндә иң зур, иң якты бина — мәктәп.

Олы Әтнә авылы картлары әле дә хәтерлиләр: һәр иртәдә дүрт мәчет манарасыннан мәзиннәр халыкны намазга чакыра торган булганнар. Бу иң хозур күренеш исәпләнгән. Хәзер, авылга керү белән, ике катлы ак мәктәп бинасы балкып күренә. Аның тирәсендә уку-өйрәнү бакчасы. Бу мәктәптә 54 педагог укыта. Аларның күбесе шушы ук мәктәпне бетергәннәр. Олы Әтнә мәктәбенә инде 35 яшь. Шушы чор эчендә ул 1 мең 140 кешегә урта белем биргән. Аннан 120 педагог, 80 инженер, 40 агроном һәм ветврач, 18 врач, 8 финансист, 17 Совет Армиясе офицеры чыккан. 150 кеше урта махсус белем алган. Ә җиде колхозчы баласы фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән. Хәзер Олы Әтнәнең горурлыгы әлеге мәчетләр түгел, әнә шушы кешеләр.

Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин, чөнки һәр авылда мәктәп бар, һәр мәктәп үзендә тәрбияләнеп чыккан кешеләр белән горурлана. Мәктәпләрдә тәрбияләнеп чыккан кешеләр белән генә түгел, беренче чиратта, аларны тәрбияләп чыгарган, кеше иткән укытучылар белән дә горурланырга кирәк.

Владимир Ильич Ленинның укытучының роленә нинди зур бәя бирүен хәтерлик. Коммунистлар партиясе аларга нинди зур әһәмият бирә!

Бездә, Татарстанда, белемле педагоглар кадрын 1918 елда төзелгән Казан педагогия институты әзерли. 50 ел эчендә бу институт мәктәпләргә 20 мең укытучы бирде, аларның күбесе татар мәктәпләрендә укыта. Алабуга педагогия институты да укытучы кадрларны уңышлы әзерли. Арча, Тәтеш, Минзәлә, Казан педагогия училищеларыннан да күп укытучылар чыга.

Күпне белергә тырышучан укучылар белән эш итү өчен укытучыга даими рәвештә белемеңне үстерергә, коллегаларының тәҗрибәсен үзләштерергә кирәк. Моның өчен 1937 елда Татарстан укытучыларның белемен күтәрү институты оештырылды. Һәр елны аның курсларында һәм семинарларында 7 меңгә якын кеше белемен күтәрә.

Аннан тыш Татарстан мәгариф министрлыгы да үзенең терәк мәктәпләре һәм алдынгы тәҗрибә мәктәпләре аша укытучыларга зур методологик ярдәм күрсәтә.

Педагоглар үз эшләренә иҗади карыйлар. Алар укыту процессының иң алдынгы ысулларын эзлиләр. Менә шуңа күрә дә бездә, Татарстанда, укытуның яңа тибы — проблемалы укыту ысулы барлыкка килде һәм киң колач алды.

Аның асылы нәрсәдә соң!

Укытучы, дәрес барышында, укучыны уйларга, куелган сорауларга, проблемаларга җаваплар эзләргә мәҗбүр итә. Менә шуңа күрә дә ул «проблемалы» дип атала.

Бу ысулны өйрәнү өчен хәзер Литвадан да, Кыргызстаннан да, Башкортстаннан да, Чувашиядән дә, Дагестаннан да, РСФСР өлкәләреннән дә педагоглар килә.

Хәзерге совет мәктәпләре, шулар исәбеннән Татарстан мәктәпләре дә КПССның XXIII съезды куйган бурычларны хәл итү өстендә эшлиләр. Съезд карарлары нигезендә илебездә гомуми урта белем бирүгә күчә бару күздә тотыла.

Без урта мәктәпне халыкка якынлаштырырга телибез. Шул максат белән мәктәпләрне эреләндерү бара. Өч ел эчендә урта мәктәпләрнең саны 280 нән 464 кә үсте.

Гомум белем бирү мәктәпләре парталарында хәзер 700 мең укучы утыра. Барлык балалар да укый. Республика халкы артуы сәбәпле һәр ел шәһәрләрдә һәм авылларда яңадан-яңа мәктәпләр ачыла.

Әңгәмәне **В. БАЙДЕРИН** язып алды.

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ КӨРӘШТӘШЕ

*Немец язучысы һәм тәрҗемәчесе Леон Небенцаль — Германия Демократик Республикасында Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын башлап тикшеручеләрнең берсе. Күптән түгел Татарстан язучылар союзы аңа хат җибәрде. Хатта түбәндәге сүзләр язылган иде: «Муса Җәлилнең һәм аның иптәшләренең соңгы көннәре турында Берлин архивларыннан Сез тапкан документларны алдык. Бу эшне армый-талмый дәвам итүегез өчен Сезгә барлык татар язучылары исеменнән ихлас күңелдән зур рәхмәт. Җәлил җитәкчелегендәге патриотик группаның язмышын ахырынача ачыкларга ярдәм иткән һәм чиксез зур кыйммәткә ия булган документларны эзләп табу өчен Сез үзегезнең унике елга якын гомерегезне багышладыгыз. Без моны бик яхшы аңлыйбыз».*

*Моннан берничә ай элек Германия Демократик Республикасына шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилова барып кайтты.*

*Леон Небенцаль белән бергәләп алар җәлилчеләр көрәшкән урыннарда булдылар. Бу сәяхәт вакытында Җәлил группасының эшчәнлегенә бәйләнешле кызыклы гына фактлар һәм документлар табылды. Леон Небенцаль биредә әнә шуларның кайберләре турында яза.*

Моннан чирек гасыр элек совет капитаны Лукьянов Дрезден шәһәр төрмәсе камераларының берсендә стенага язылган менә шундый сүзләргә юлыга: «Монда мәскәү журналисты Әхмәт Симаев утырды. Россиядән без унбер кеше. Без икенче Германия империя суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителдек. Кем дә кем бу язуны табып укый һәм Ватанга исән-сау әйләнеп кайта, шул кешенең безнең язмышыбыз турында туганнарыбызга һәм якыннарыбызга хәбәр итүен сорыйм. 1944 елның 24 нче марты».

Бераз вакыт үткәч, капитан Лукьянов стенадагы бу язу хакында Симаевның туганы Фәттахка сөйли. Ул чагында әле Әхмәтнең легендар Муса Җәлилнең көрәштәше булуын беркем дә белми. Аның Муса Җәлил группасында эш алып баруы бары тик соңыннан, Абдулла Алишның тормыш иптәше иренең соңгы хушлашу хатын алгач кына билгеле була. Бу хатны Моабит төрмәсеннән бельгияле антифашист Эмиль Майзон алып чыга һәм аны Брюссельдәге совет илчелегенә тапшырган була.

Үзенең хатында Алиш яшерен оешма членнарыннан татар хәрби әсирләре арасында листовкалар таратуда гаепләнгән биш кешене, шул җөмләдән Симаевны да телгә ала.

1967 елда Көнбатыш Берлиндагы бер сенаторның секретаре аркылы төрмә папкасыннан Җәлил, Симаев һәм Шабаев группасындагы әсирләрнең фамилияләре язылган ике карточканың фото-копиясе кулга төшерелде. Шул көннән Җәлил группасы членнарының 1944 елның февраль—март айларында Дрезден төрмәсендә утырулары һәм аларга хөкем карарының шунда чыгарылуы ачыкланды дип исәпләргә мөмкин.

Элек шәһәр төрмәсе булып хезмәт иткән һәм аның караңгы камераларында антифашистлар газапланган бина хәзер бөтенләй үзгәргән. Ул яңа баштан үзгәртеп корылган һәм Югары техник мәктәп карамагына тапшырылган. Элек аның нинди бина булуын бүген хәтта күз алдына китерүе дә кыен. Ләкин ул хакта беркайчан да истән чыгарырга ярамый. Монда укучы студентлар үз мәктәпләрендә антифашистик музей оештыру турында тәкъдим кертәннәр. Музей өчен берничә камера һәм әсирләрне җәзалап үтерү урыны элекке килеш калдырылган.

Арно Виттиг тарафыннан фашизмга каршылык күрсәтүче көрәшчеләргә багышланып эшләнгән һәйкәл каршында Әминә Җәлилова тетрәнеп бик озак басып торды. Музей житәкчесе аңа узган ел эчендә генә дә бу һәйкәл янында йөз меңнән артык кеше булганлыгын хәбәр итте. Җәлил группасы өстеннән суд процессы барган бүлмәгә Әминә Җәлилова бары тик ярым ачык ишек аша гына күз төшерә алды: бу вакытта анда студентлар контроль эш эшлиләр иде. Әминә ханымның карашы дәфтәрләре өстенә иелеп сочинение язып утыручы яшьләргә төбәлде. Әйе, Моабит төрмәсендә утырганда Муса хыялланган яңа Германия вәкилләре иде бу яшьләр!

Сүзне яңадан Симаевка күчерик. Җәлил группасын хөкем итүгә сәбәп булып алынган бер бик кызыклы гаепләү турыдан-туры Әхмәт Симаев исеме белән бәйләнгән. Бу гаепләүнең төп сәбәбе — хәрби әсирләрдән фашистлар төзегән «Идел — Урал» татар-башкорт легионында оештырылган лагерьда листовкалар таратудан гыйбарәт.

«Идел — Урал» легионында тәрҗемәче һәм немец теле укытучысы булып Фридрих Биддер хезмәт иткән. Җәлил группасы эшчәнлегендәге кайбер яңа нәрсәләрне бу юлларның авторына нәкъ әнә шул Биддер сөйләде дә.

«Бервакыт,— дип искә ала Фридрих Биддер,— лагерьда зур шау-шу күтәрелде. Легионерларның салам матрацлары арасыннан күп санлы листовкалар таптылар. Бу листовкаларда Гитлер фашизмына каршы көрәшкә өндәүче сүзләр язылганлыгы үзеннән-үзе аңлашыла. Ул листовкаларны мин үзем күрмәдем, әмма аларның дефекты булган нинди дер машинкада рус литерында басылганлыгын мин яхшы беләм. Листовкаларны һәм машинканы әнә шул дефект буенча эзлиләр... һәм аны Геббельсның пропаганда министрлыгыннан табалар!»

Чын мәгънәсендә фантастик булып тоелган бу факт кайбер аңлатмалар бирүне сорый. Пропаганда министрлыгының һәм басып алынган Көнчыгыш өлкәләрнең Розенберг җитәкчелегендәге министрлыгының «Винета» дип аталган гомуми бер бүлеге була. Бу бүлек «Көнчыгышка юнәлтелгән гомум пропаганда» белән шөгыльләнә. Анда тәрҗемәчеләр булып төрле халыкларның вәкилләре эшли. Шуларның берсен — Әхмәт Симаевны гитлерчылар диктор итеп файдаланмакчы булалар.

1943 елны Берлинны бик еш бомбага тоталар. Шунлыктан, кайбер учреждениеләрдә махсус төнге дежур оештырыла. «Винета» бүлегендә төннәрен дежур торуга хезмәттәге барлык кешеләр тартыла. Фридрих Биддер менә болай дип расльш: «Нинди дер татар әсире үзе дежур торган төннәрнең берсен рус шрифтындагы машинкада күп санлы листовкалар басу өчен файдалана».

Җәлил группасының исемлеге белән танышканнан соң дежурда торган әлеге татар әсиренең, башка беркем дә булмыйча, Әхмәт Симаев булганлыгын тулы ышаныч белән әйтергә мөмкин. Фашистларга каршы язылган листовкаларны Геббельс министрлыгының борын төбендә үк бастырып ул искиткеч кыюлык һәм батырлык эшли.

ЛЕОН НЕБЕНЦАЛЬ.
Берлин.

# КЕШЕЛЕКЛЕ СОЛДАТЛАР

Без күбрәк катлаулы хәрби операция планнарын коруда һәм аларны тормышка ашыруда катнашкан командирларның истәлекләрен укырга күнеккәнбез. Алар белән танышып, без туган илнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган дәһшәтле бәрелешләрне, бигрәк тә Бөек Ватан сугышының аерым күренешләрен, ә кайберләрендә хәтта аның бөтен бер панорамасын күз алдына китерәбез, совет халкының күмәк батырлыгын, аның мораль-политик бердәмлеген, какшамас көч-куәтен тоябыз, байтак хәрби җитәкчеләрнең талант-сәләтен, холык-фигылен төсмерлибез. Мондый истәлекләр яшьләребезне өлкән буыннарның революцион һәм сугышчан традицияләрендә тәрбияләргә булыша. Ләкин әлеге язмаларның бер ягы (кимчелекле ягы дип әйтергә кыймыйбыз, чөнки ул объектив сәбәпләрдән килеп чыга) бар: аларда сугышның, күмәк батырлыкның аерым эпизодлары, ваклыклары, кагыйдә буларак, җентекләп тасвирланмый, солдат тормышы, солдат образы бөтен тулылыгы белән гәүдәләнми. Чөнки хәрби җитәкче бик күп кешеләрне берләштергән частьлар, берләшмәләр белән эш итә һәм шулар хакында яза. Зур хәрби җитәкчеләрнең, командирларның истәлекләрендәге әнә шушы җитешмәгән якны түбәнрәк чиндагы хәрбиләрнең язмалары тулыландыра. Аларның истәлекләрендә солдат тормышының ваклыклары бәян ителә, солдатларның җанлы образлары тудырыла. Ике төрдәге шушы мемуарлар үткән тарихи бәрелешләрнең тулы картинасын, аларда катнашкан кешеләрнең җанлы образларын күзалларга ярдәм итәләр.

Татарстан китап нәшрияты күптән түгел дөньяга чыгарган «Сусыз дәрья» дигән китап[1] мемуар әдәбиятның әнә шул икенче төренә керә. Аның авторы — Габдулла Шәрәфи. Бусы — авторның әдәби псевдонимы. Ә чын исем-фамилиясе — Габдулла Шәрәфетдинов. Бу исем газета-журналларда чыгып килгән мәкаләләре, очерклары, парчалары, әдәби язмалары буенча матбугат яратучыларга таныш булырга тиеш.

Ул кавырсыны да катмаган «сары томшыклы» малай чагында ук Совет Армиясе сафларына алына, Ерак Көнчыгышта хәрби хәзерлек үтә, 1945 елның август — сентябрендә, солдат-радист булып, япон милитаристларының сыртын сындыруда катнаша. Һәм менә чирек гасырга якын вакыт узганнан соң китап сөючеләргә үзенең истәлекләрен юллый.

Байтак еллар бергә эшләгән бу тыйнак каләмдәшемнең яңа әсәрен «ташка басылган» хәлендә дикъкать белән укып чыгам. Аерым бүлекләрен кулъязма хәлендә үк күздән кичергән булсам да, сары тышлы бу бәләкәй китап кабат укыганда да су кебек йотыла. Моның сере нәрсәдә? Минемчә, истәлекләрнең табигыйлегендә, самимилегендә, урыны белән юморга төреп, урыны белән хискә сугарып язылуында.

Автор вакыйгаларны, ул вакыйгаларда катнашучыларны моннан 24 ел элек ничек кабул иткән булса, шул килеш тасвир итә, аларга бәяне дә шул чор күзлегеннән карап бирә. Бу алым китапның самимилеген, тасвир көчен арттыра. Әмма шуннан ук әлеге язмаларның бер кимчелеге дә килеп чыга. Сүз 1945 елгы солдат офыгын 1969 елгы журналист офыгы белән алыштыргалап алу зарурлыгы турында бара. Автор, вакыйгаларның табигый агышы һәм үз күргән-белгәннәре белән артык мавыгып китеп, аерым урыннарда кирәкле гомумиләштерүләр ясамый, ягъни үзе хезмәт иткән хәрби берләшмәнең узган юлын тулаем зур тарихи бәрелеш кысалары белән чагыштырып бару, бүгенге көн вакыйгаларына да күз ташлаштыргалап алу җитенкерәп бетми. Ә бит шундый публицистик алымның әйбәт нәтиҗә бирүен дәлилләгән

[1] Г. Шәрәфи. Сусыз дәрья. Казан. 1969 ел.

моментлар китапның үзендә дә бар. Автор бер урында Жәхә шәһәрен кулга төшерү вакыйгасын сөйли һәм мәгълүм хәрби начальник И. А. Плиевнең истәлекләренә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, әлеге вакыйганың әһәмияте бердән күтәрелеп, совет хәрби җитәкчелегенең кыюлыгы, өстенлеге калкуланып китә.

Г. Шәрәфи үзенең китабында гадәти солдат тормышын көндәлек детальләрдә сурәтли. Юк, автор хезмәт иткән часть искитәрлек, күккә күтәреп мактарлык батырлыклар да эшләми кебек, аңа хәйләкәр дошман белән олы бәрелешкә керергә дә туры килми. Ләкин ул, башка гаскәри берләшмәләр белән берлектә, сусыз, ач күзле чүлләр, хыянәтчел Хинган таулары аша, Бөек Кытай стенасы аркылы Көнчыгыштагы сугыш учагына су сибәргә бара, ничә еллар буе япон империалистлары изүеннән интеккән кытай халкына азатлык алып бара.

Автор коралдаш туганнары белән һәрвакыт куркыныч янап торган озын юл үтә. Юлда иптәшең үзеңнән яхшы булсын, ди халык мәкале. Һәм, чыннан да, совет солдатлары шушы зирәк мәкальгә һәрчак турылыклы булып калалар. Китапның төп эчтәлеген, төп пафосын совет солдатларының, төрле милләт вәкилләренең эчкерсез дуслыгын, бер-берсенә туганнарча мөнәсәбәтен гәүдәләндерү тәшкил итә. Автор олы дуслыкның чагылышын гадәти эпизодларда, җанлы штрихлар белән сурәтли. Ул дуслык-туганлык турында буш сүзләр белән лаф ормый, ә шуның көч-куәтен җанлы вакыйгалар, тормышчан детальләр аша бирә.

Әнә чуваш егете Максимов поход вакытында арып бер йотым су өчен гаҗиз булып хәлсезләнеп егылган коралдаш дусты янына ашыга. Менә ул флягасын «солдатның кипшенгән иреннәренә тидереп, зур саклык белән күтәрә башлый. Фляга инде иреннәр өстендә авызы белән капланып ук тора диярлек, ә суы һаман күренми. Ниһаять, солдатның бугаз төене кузгалып, кашлары селкенеп куя. Тузан кунган иягенә нечкә генә ак юл сызып су ага. Башка солдатларның да бугаз төеннәре тамак төпләрен еш-еш капшыйлар. Ләкин бу сусаудан гына түгел. Анда йота алмаслык төер. Күзләр дымланып Максимовка төбәлгән. Рәхмәт сиңа, чандыр дус, диләр иде алар».

Тагын радиостанцияне һәм радист татар егетен хәвефтән коткару өчен, бар көченә чабып килгән ат каршына ташланып күкрәген җәрәхәтләгән карел егете Николай Соколов хәтергә кереп кала. «Төш вакытында да ял озак бармады, тагын кузгалдык — дип яза автор.— Соколов үзе белдермәскә тырышса да, сизәм — хәле әйбәт түгел. Моны безнең олаучы казакъ егете Сарсынбаев та чамалап килә икән.

— Әйдәле, туган, арбага утыр да атны тотып бар,— дип көчли-көчли дилбегәсен аңа тоттырды. Ләкин Николай озак бармый, төшә дә: «Бар, син дә бераз ял ит!» — дип, мине алыштыра».

Беренче карашка күзгә әллә ни бәрелеп тормаган әнә шундый детальләр аша Г. Шәрәфи төрле милләт вәкилләренең дуслыгын, Совет Армиясенең шушы дуслык-туганлык хисе белән көчле булуын калку итеп сурәтләп бара. Нәкъ менә әлеге хис авыр юлларны җиңеләйтә, көчле һәм хәйләкәр дошманның өнен ала.

Совет солдатының гуманизмын, патриотизмын, интернационализмын автор аның япон милитаризмы изүе астында интеккән кытай халкына мөнәсәбәте аша тагын да тәэсирлерәк итеп ача.

Япон милитаристлары бу илне, аның халкын коточкыч бөлгенлеккә дучар иткәннәр. Автор үзенең язмаларында әлеге тарихи гаделсезлекне читләтеп үтми, сирәк кына булса да бу хакимлекнең җан өшеткеч нәтиҗәләрен күрсәтеп яза. Г. Шәрәфи кытайлар белән беренче очрашуын түбәндәгечә сурәтли: «Юл буенда ялангач халык төркеме. Ирләр, хатыннар. Балалар анадан тума. Олылар исә бары гаурәтләрен генә каплаганнар. Ябыклар». Яки менә шундый бер деталь. Эчке Монголия башкаласы Калган юнәлешендәге ныгытылган район Кытай стенасы буйлап сузылган булган. Дзот һәм дотлардан, чәнечкеле чыбыклардан, җир асты юлларыннан торган бу ныгытмалар челтәрен самурайлар, кытай һәм монгол крестьяннарын куып китереп, биш ел эшләткәннәр. Ә соңыннан, серне саклау өчен, төзелештә катнашкан меңнәрчә һәм меңнәрчә кешене, үтереп, исән чакта үзләреннән үк казыткан чокырларга күмгәннәр... Империализм дөньясы, аның ерткыч законнары эш сөючән кытай халкын әнә шундый хәлгә төшергәннәр. Менә шушы фонда Совет Армиясенең, совет кешеләренең азатлык миссиясе, изелгәннәргә ярдәм кулы сузуы бигрәк тә калку булып күренә. Совет солдатлары кытай халкына азатлык алып килү белән генә чикләнмиләр, ә аның тормышын аз гына булса да җиңеләйтү өчен мөмкин булганның барсын да эшләргә тырышалар. Әнә алар ялангач кытай кешеләренә кием-салым тараталар. Әнә

алар кытай крестьяннарына ишәкләр өләшеп бирәләр. Хәтта үзләре белән бергә озын поход юлы үткән һәм күңел юанычы булган соңгы патефонга хәтле бүләк итәләр. «...Үзебезнең газиз Совет Армиясе, аның изгелеге, кешелеклелеге өчен күңелем горурлык һәм чиксез шатлык хисләре белән ташып, күзләремнән яшь бөртекләре тамды. Әмма мин солдат булганнан бирле беренче һәм соңгы мәртәбә тамган бу саран яшьләремнән оялмадым», дип язуы белән автор үз коралдашларының уртак хисләрен чагылдыра.

Истәлекләрнең кытай халкына кагылышлы урыннарын укыганда, бу халыкның үзен азат итүче совет солдатларын рәхмәт хисләре белән колач җәеп каршы алуын җанландырган сәхифәләрне күздән үткәргәндә, уйлар ирексездән аның бүгенге фаҗигале язмышына күчә. Совет халкына, Коммунистлар партиясенә котырынкы яла ягу кампаниясе алып баручы кытай идарәче даирәләренең искиткеч гаделсезлегенә, башсызлыгына, дуслык-туганлык хисенә тәкереп каравына, пролетар интернационализм принципларын аяк астына салып таптавына тагын бер кат нәфрәтләнәсең. Күңелдә: юк, кытай халкы андый авантюраны, андый мәгънәсезлекне кабул итмәс, ул үзенә азатлык китергән, яңа тормыш төзүдә эчкерсез булышлык күрсәткән совет халкының изгелеген онытмас, кытай халкына якты көннәр тагын әйләнеп кайтыр, дигән өмет арта.

Г. Шәрәфи китабының тагын бер үзенчәлегенә аерым тукталасым килә. Сүз истәлекләрнең баштан ахырга кадәр җылы юмор белән өртелгән булуы хакында бара. Моңа истәлекләргә көлкеле эпизодлар керту юлы белән дә, гадәти вакыйгаларны елмаю аша уздыру алымы белән дә ирешелә. һәм бу бик табигый килеп чыга, әсәрнең оптимистик рухын көчәйтә. Чөнки гадәттә үзенең хаклылыгына, изге эш башкаруына, җиңүенә нык ышанган, идеаллары якты булган кешеләр генә шат күңелле, җор сүзле булалар, авыр минутларда да күңел күтәреп алырга, эч бушатырга вакыт табалар.

Автор вакыты белән не ікә хисле лирик та була ала. Моны әсәрдәге байтак эпизодлар раслап тора. «Рәйхан» көен тыңлаганда туган уйлар, дуслары Сәлимовның фаҗигале үлемен сурәтләгән урыннар, туган илне, туган якларны искә төшергән моментлар — әнә шундыйлардан.

Җыеп әйткәндә, Г. Шәрәфи кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне патриотизм һәм интернационализм рухында тәрбияләргә булышырдай истәлекләр яңарткан. Дөрес, әсәрне тагын да яхшырту җәһәтеннән автор кайбер камилләштерүләр дә эшли алган булыр иде. Әйтик, чүл, сахра, таулар кичүне сурәтләгән урыннар озынгарак китә. Шул ук вакытта япон милитаризмы китергән бәла-казаларны сурәтләүгә күбрәк урын биреп, контрастны тагын да көчәйтергә мөмкин булыр иде. Совет солдатларының мораль-политик бердәмлеген уңышлы гәүдәләндерү белән бергә, шул бердәмлекне тәэмин иткән идея-тәрбия эшен аерым штрихлар белән күрсәткәндә, әсәр тагын да ота төшәр иде. Анннары истәлекләр, ничектер, кетегрәк тәгәлләнә, койрыгы зәгыйфьрәк чыга кебек. Хәер, монда әллә ни зур зарар юк, канатлары көчле булгач, кошкай зәгыйфьрәк койрык белән дә билгеләнгән урынга очып барып җитә алыр.

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.**

# ХӘРБИ МЕМУАРЛАР

Сәяхәтнамәләр һәм юлъязмалар, өлкән буын кешеләренең истәлекләре һәм көндәлек дәфтәрләре, кыскасы, һәртөрле документаль әдәбият бүгенге укучылар тарафыннан зур кызыксыну белән каршы алына. Онытылмас вакыйгалар һәм очрашулар хакындагы язмалар — революцион эстафетаны кабул итеп алган яңа буынларның кыйммәтле мирасы. Үткән көннәр турында мәгълүмат бирүче әсәрләр арасында тарихи вакыйгаларда үзләре катнашкан кешеләрнең язма истәлекләре, ягъни мемуарлар аерым урын тота.

В. И. Ленин мемуар әдәбиятка югары бәя бирә, аның зур тәрбияви әһәмиятенә ия булуын күрсәтә. 1905 елгы коралды декабрь восстаниесен искә алу уңае белән, ул пролетариатның революцион көрәше, әлеге көрәштә катнашкан геройлар хакында истәлекләр җыярга чакыра, баррикадаларда корбан булганнарның тормыш юлларын сурәтләгән брошюралар чыгарырга

киңәш итә. «Андый брошюра,— дип яза В. И. Ленин,— яшь эшчеләр өчен иң яхшы уку китабы булачак, шуның буенча һәр аңлы эшче ничек яшәргә һәм көрәшергә кирәклеген аңлаячак» [1].

Мемуар әдәбият гаҗәеп күп төрле. Һәм ул кеше эшчәнлегенең төрле якларын, төрле вакыйгаларын (хәрби, әдәби һ. б. һ. б.) чагылдыра. Мемуар әдәбият өлкәсенә карый торган темалар даирәсе дә бик киң: зур сугышлар һәм көндәлек тормыш вакыйгалары, бөтен бер илләр һәм аерым кешеләр язмышы, тарихи борылыш моментлары һәм кешенең шәхси кичерешләре, дәвернең хәлиткеч мәсьәләләре буенча җитди бәхәсләр һәм вакытлы әрепләшүләр. Шуларның һәммәсе, авторның (еш кына әлеге вакыйгаларның үзендә катнашкан кешенең) йөрәге, күңел күзе аша уздырыла. Шуңа да мемуар әсәрнең теле, стиле, хикәяләү тоны авторның нинди кеше булуына, сәләтенә һәм шәхси үзенчәлекләренә бәйле.

Совет чорындагы мемуар әдәбиятның иң зур һәм иң төп өлеше нигездә Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына, илебез халыкларының фашизмга каршы алып барган героик көрәше сәхифәләренә багышланган. Шул ук фикерне үзебезнең татар әдәбиятына карата да әйтергә мөмкин.

Гадәттә туплар тынуга, мемуарчылар эшкә тотына. Корал көче белән сугыш кырларында башланган бәхәс соңыннан каләм көче ярдәмендә дәвам иттерелә. Бөек Ватан сугышына караган андый язмалар исә туплар тынганчы ук күренә башлый. Язучыларның турыдан-туры сугышның үзендә катнашулары татар әдәбиятында көндәлек һәм юлъязмалар жанрын активлаштырып җибәрә (Г. Әпсәләмов. Көндәлектән. 1942 ел; Ш. Маннур. Журналист блокнотыннан. 1942—43 еллар; Г. Галиев. Зур юлдан мәкаләләр. 1945 ел һ. б.). Аларда сугыш чоры чынбарлыгының күп төрле яклары сурәтләнә: фронт тормышының көндәлек, гадәти күренешләре белән янәшә үк истә калырлык кызыклы эпизодлар, героик характерлар, халык өстенә басып алучылар китергән җәбер-золым, кайгы-хәсрәт һәм дошманнан азат ителгән изге җиребез, тагы бераз соңрак Европа халыклары тормышы сәхифәләре... Ул әсәрләр патриотизм һәм гражданлык хисләренең активлыгы белән аерылып торалар. Сугыш елларындагы татар публицистикасы халыкта илбасарларга карата тирән нәфрәт хисләре тәрбияли, Ватан улларын изге көрәшкә туплаша. Гитлерчыларга каршы көрәштә ныгыган халыклар дуслыгы аның төп темасы була.

Сугыштан соңгы елларда мемуар әдәбият бермә-бер активлашып, җанланып китә. Бу шулай ук аңлашыла торган нәрсә. Беренчедән, сугыш күп кенә мәсьәләләргә башкачарак, яңачарак күзлектән карауны таләп итте. Аннан соң, мемуарчылар вакыйгаларның кайнар эзеннән баруны яратып ук бетермиләр. Аларга шулай ук мәгълүм бер вакыт аралыгы кирәк. Шунсыз үзләре катнашкан вакыйгалар хакында төплерәк фикер әйтү, тарихи вакыйгаларның һәм фактларның мәгънәсен, асылын ачып бирү шактый кыенга туры килә.

Узган сугышта күп кеше һәм мөмкин булган бөтен төр техника катнаша. Сугыш операцияләре белән һәр гаскәрнең үз командирлары җитәкчелек итә. Фронт командующиеның күзәтү пунктында танкист белән авиатор да, артиллерист белән сапер да һәм медик белән политхезмәткәр дә торырга тиеш була. Һәм шуларның һәрберсе диярлек сугышны үзенчәрәк күрә, аны үз манарасыннан торыбрак бәяли.

Хәзер шул кешеләр истәлекләр язалар. Чиннары — гади солдаттан алып генералга кадәр. Талант һәм сәләт дәрәҗәләре дә төрлесенеке төрлечә. Алар көче белән иҗат ителгән мемуар әдәбият эчтәлек, күләм ягыннан да чуар һәм күп төрле: теге яки бу аерым эпизодка багышланган газета мәкаләсеннән алып күп планлы әсәрләргә, гади көндәлек язмаларыннан алып архив документларын һәм махсус әдәбиятны файдаланып язылган җитди китапларга кадәр булган продукцияне үз эченә ала. Һәм без, шатланып, шуны әйтә алабыз: татар генераллары Г. Сафиуллин һәм Ф. Булатов язган истәлекләр [2] әлеге күп төрле, чуар ташкын эчендә югалып калмады. Материалга бай булулары, вакыйгаларының яңалыгы һәм мавыктыргыч итеп язылулары белән, алар киң катлау укучылар массасы һәм тарихчылар арасында зур кызыксыну уяттылар.

Билгеле булганча, мемуарчы күптән булып узган тарихи вакыйгалар, ул вакыйгаларда катнашкан конкрет кешеләр турында сөйли. Яңа буыннар әлеге вакыйгалар һәм кешеләр турында аның язганнарына — аның хөкеменә таянып фикер йөртә-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Рус телендә. 16 том. 334 бит.

[2] Г. Сафиуллин. Җиңү юллары буйлап. Казан. 1962 ел; Ф. Булатов. Генерал язмалары. Казан. 1966 ел.

чәк. Шуңа күрә истәлек авторының намуслы, гадел булуы, тыйнаклыгы — үтә мөһим һәм җитди мәсьәлә. Гаделлек дигәндә, барыннан да бигрәк, мемуарчының кайчандыр үзе белән иңгә-иң торып көрәшкән кешеләр хакында гадел хөкем йөртүен күздә тотабыз. Г. Сафиуллин да һәм Ф. Булатов та үзләренең ярдәмчеләре һәм кече командирлар, шулай ук сугышта катнашкан хатын-кызлар — санитаркалар, врачлар, элемтәчеләр хакында зур ихтирам белән язалар. Кайбер истәлекләрнең төп җитешсезлеге шунда: аларның авторлары күбрәк үз шәхесләре белән мавыгалар, теге яки бу тарихи вакыйгада үзләре уйнаган рольне күпертеп күрсәтергә тырышалар. Бәхеткә каршы, безнең генералларның истәлекләрендә андый нәрсә дә сизелми диярлек. Әгәр Ф. Булатов күпмедер күләмдә үз яшьлеге турында яза икән, моны дөрес аңларга кирәк. Шушы мәсьәләгә тукталып, автор үзе болай ди: «Язмалар ахырында, бәлки, үткәннәргә кайту да кирәк түгелдер. Сөйләсәң, романнардагыча башта сөйләргә кирәк булгандыр. Әмма мин роман язмыйм. Мин мемуарчы. Үземнең яшьлегемне искә төшерәм икән, моны да фәкать Совет Армиясенең солдатлары да, генераллары да гади халык арасыннан чыкканлыгын күрсәтер өчен генә эшлим» (265 бит). Булатов фикерләрен генерал Сафиуллин дәвам иттерә: «Бу истәлекләрне язарга кулыма... каләм алырга мине данга кызыгу түгел, бөтенләй башка уйлар мәҗбүр итте. Империалистик илләрнең агрессив даирәләре шашынып хәзерләнгән сугышның халыкка иге-чиге булмаган бәла-казалар алып киләсен мин, хәрби кеше булганлыктан, яхшырак аңлыйм. Сугыш уты кабызучыларга каршы көчле нәфрәт безнең йөрәкләребездә бер генә минутка да сүнмәскә тиеш» (6 бит). Һәм чыннан да безнең генералларыбыз үз шәхесләрен күтәрү, үз-үзләрен мактау кебек вак эш белән мавыкмыйлар. Аларның шәхси тормышы башка сугышчылар тормышындагы вакыйгалардан аерылгысыз. Алар узган данлы юл барлык командирлар өчен уртак: сугышның беренче айларындагы кыен хәлләр һәм чигенү күренешләре, шуның белән бәйле авыр кичерешләр, аннан һөҗүм сугышлары, соңгы дәвер истәлекләрдә зур күтәренкелек һәм пафос белән сурәтләнә. Кыскасы, татар генералларының истәлекләре буенча без бөтен кораллы көчләребез узган сугышчан юлны күз алдына китерә алабыз. Шуңа да ул истәлекләрнең кыйммәте тарих галимнәренә фактлар, ә солдат массаларына тәрбия бирү белән генә чикләнми.

Беренче карашка, истәлекләрнең теле, стиле авыррак һәм корырак тоела, хәрби приказлар, һәртөрле донесение һәм бәлешмәләр дә кирәгеннән артык күп китерелгән кебек. Әмма бу тыштан карагандa гына шулай. Бер кызыксынып киттеңме, мавыгып, аерыла алмыйча укыйсың. Иң мөһиме шунда: һәр ике истәлек төбендә кеше язмышы, гади солдат язмышы турында. Үткәннәргә борылып карап, авыр сугыш еллары хакында уйлана башлауга генераллар күз алдына гади солдат килеп баскан. Хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнү яки аның йомгак-нәтиҗәләре хакында сүз барамы, әллә дошманнан яулап алган җирләрне ныгыту мәсьәләсе куеламы — алар ни хакында гына язмасыннар, игътибар үзәгендә һәрвакыт солдат язмышы булыр. Ф. Булатов язмаларының күп бүлекләре солдат батырлыгын күрсәтүгә багышланган. Менә Г. Сафиуллин китабыннан бер өзек: «Шунда Кәримов яраланды, әмма ул шуышуын дәвам итте, артыннан кар өстендә кызыл эз сузылып барды. Ул һәрвакыт сугышта кыю һәм тәвәккәл иде. Кәримов бер сикерүдә өй алдына барып керде һәм, ишекне ачып, дошманга ике граната тондырды. Унбер фашист офицеры кырыла, уникенчесе яралы хәлдә әсир төшә»... (81 бит).

Истәлек язу — күп хезмәт куюны сорый торган мәшәкатьле эш. Бер хәтергә генә таянып эш иткәндә, хәтта тәҗрибәле язучы да ялгышырга мөмкин. Әдәби иҗат эшендә махсус әзерлеге һәм тәҗрибәсе булмаган мемуарчы турында инде әйткән дә юк. Шуңа да, укучы хөкеменә чыгарганчы, ул үз язмаларын кат-кат тикшерергә тиеш. Бу эштә аңа төрле документлар һәм фотолар, вакыйгаларда катнашкан кешеләрнең күрсәтмәләре зур ярдәм итәчәк («Җиңү юллары буйлап» китабына язган кереш сүзендә Г. Сафиуллин болай ди: «Бу истәлекләрне язганда үземнең көндәлекләремне, архив материалларын, фронтта бергә сугышкан иптәшләремнең минем үтенеч буенча җибәргән материалларын файдаландым»). Һәм дөрес тә: мемуар әдәбият авторның шәхси кичерешләренә генә нигезләнергә димәгән. Архив материалларын, шулай ук башка документларны өйрәнү эшкә файда гына китерәчәк. Г. Сафиуллин һәм Ф. Булатовларның иҗат тәҗрибәсе шул турыда сөйли. Ватан сугышы чорындагы вакыйгаларга бүгенге көн таләпләреннән чыгып бәя бирә алу исә ул истәлек-

ләрнең кыйммәтен бермә-бер арттырган, аларны озын гомерле иткән, заманча яңгырашлы әсәрләр дәрәҗәсенә күтәргән.

Бөек Ватан сугышы турындагы мемуар әдәбиятның шактый зур бер тармагын көндәлекләр тәшкил итә. Аерым мәсьәләләрдә истәлекләрдән калышсалар да, аларның үз көчле яклары бар. Иң әүвәл, көндәлекләр вакыйгаларның кайнар эзләре буенча язылалар. Шуңа аларның төгәллек һәм дөреслек дәрәҗәсе дә зуррак була. Хәтерем ялгышмаса, бездә хәрби мемуарларның бу төре әллә ни күп түгел шикелле. Аның каравы, шул аз санлы әсәрләр арасында әдәбиятыбызның казанышы булып саналырлык бер көндәлек бар. Ул — Хәйретдин Мөҗәйнең «Сугыш язмалары».

Гаҗәеп язмышлы бу кешенең тормышы һәм иҗаты белән укучылар күптән түгел танышты. Башта С. Шакирның республика газета-журналларында басылган мәкаләләре аша без аның тиңдәшсез батырлыгы белән таныштык. Соңыннан Татарстан китап нәшрияты язучының әсәрләрен басып чыгарды [1].

Хәйретдинов Мөҗәһит Хәйретдин улы 1901 елда Башкортстанның Туймазы районы Төрекмән авылында туа. Унсигез яшеннән армия сафларына алына. Башта кызылармеец, соңыннан взвод, рота һәм батальон командиры булып Урта Азиядә һәм Ерак Көнчыгышта илебез чикләрен саклый. Бик яшьли, авыл мәктәбендә укыган елларда ук шигырьләр яза башлый. Әдәби иҗат эше белән шөгыльләнүен армия хезмәтендә дә дәвам иттерә: шигырьләр, очерклар, хикәяләр, пьесалар яза.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Х. Мөҗәй алгы сызыкка күчерелә. Сугыш тынып торган араларда хикәяләр, шигырьләр яза, «Сугыш язмалары» алып бара.

Х. Мөҗәй җыентыгының сүз башы һәм ахырындагы искәрмәләре белән танышкач, көндәлек дәфтәрләренең шактый кызыклы тарихы ачыклана. Билгеле булганча, «Сугыш язмалары» дүрт дәфтәрдән тора. Шуларның өчесе гарәп, берсе рус хәрефләре белән язылган булган. Беренче дәфтәрнең күпчелек битләре карандаш белән, 15—20 бите генә шәмәхә төстәге кара белән язылган. Икенче дәфтәр блокнот формасында булып, тышлыгына: «Грензаид — смешно и горько. Аның турында язарга кирәк», дигән сүзләр язылган. Өченче дәфтәр шактый калын булган. Беренче биткә: «Х. Мөҗәй. Өченче дәфтәр. Сугыш көндәлеге. 1941—42 еллар» дип куелган. Дүртенче дәфтәр шулай ук шактый калын икән. Беренче һәм ахыргы битләре, кулдан-кулга йөреп, ертылган һәм югалган.

Бер караганда, «Сугыш язмалары»н аерым дәфтәрләргә бүлеп йөртү формаль бер эш кенә кебек. Автор, телиме-юкмы, бер дәфтәр беткәч икенчесен, анысы беткәч өченчесен башларга мәҗбүр булган. Әмма шул күчеш аерым дәфтәрләрнең стиль үзенчәлекләренә дә йогынты ясаган. Һәр дәфтәр саен әсәрнең тоны, яңгырашы үзгәрә тора. Беренче дәфтәр:

«Шәһәр.

Зур сугышлар тора алда»,—

дигән сүзләр белән тәмамлана. Бу сүзләрдә беренче дәфтәргә — башкарган эшләргә йомгак ясау да, алдагы эшләргә, иртәгесе көнгә күз ташлау да сизелә.

«Сугыш язмалары»ның табылу тарихы да гыйбрәтле.

1942 елның җәендә көньяк-көнбатыш юнәлештә немецлар каты һөҗүмгә күчәләр. Мөҗәй командалык иткән 789 нчы полк та ярым боҗра эчендә кала. Үзенең «Сугыш язмалары»н саклап калу өчен, полк командиры кызылармеец Кожевниковны махсус рәвештә тылга җибәрә. Кожевников исән-сау килеш фронт сызыгын үтә һәм дәфтәрләрне Мөҗәйнең хатыны Марьям ханымга тапшыра. Ул тапшырган дәфтәрләрдәге соңгы язмаларның берсе шундый:

«Бүген төнге 12 дә атака.

Бу инде безнең Прохоровкага бишенче, әгәр 8 декабрьны исәпкә алганда — алтынчы атака...

Бу атнадан соң, бәлки, безнең күбебез өчен Прохоровка да, дөнья да юк булыр. Без моны да бик яхшы аңлыйбыз. Ләкин минем үлемем әле минем Ватаным, минем сыйнфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без:

— Безгә үлем юк! — дибез».

Мөҗәй полкы дошман боҗрасында айдан артык сугыша. Аларның азык-төлекләре, сугыш кирәк-яраклары бетә. Ахырдан окопларда, блиндажларда кул сугышлары башлана. Әнә шул чагында каты яралы Мөҗәйне немецлар әсир итәләр. Лагерьдан лагерьга йөри торгач, ул Мюнхенга килеп эләгә. 1944 елның 4 сентябрендә, фашистларга каршы яшерен оешма тәэсучеләрнең бер вәкиле буларак, ерткычларча җәзалап үтерелә...

...«Сугыш язмалары»ның беренче дәфтәрләре «Совет әдәбияты» журналында су-

[1] Х. Мөҗәй. Сугыш язмалары. Казан, 1966 ел. Тәзүчесе һәм сүз башын язучы С. Шакир.

гыш елларында ук басылып чыга. Шул чор әдәбиятына хас кайбер гомуми кимчелекләрдән, билгеле, Х. Мөҗәй дә котыла алмаган. Сугышның беренче айларында безнең гаскәрләрнең чигенүләрен ул алдан уйланган, хәтта планлаштырган бер маневр төсендәрәк аңлатмакчы. 19 йөздә Россия алып барган сугышлар тәҗрибәсенә нигезләнеп, әлеге нәрсәгә хәтта фәнни төс бирергә тырышып карый (201 бит). Монда бер Мөҗәйне генә гаепләп булмый. Ул чагында әдәбият сугышның беренче айларындагы кыен хәлне китереп чыгарган сәбәпләрне ачыклап өлгермәгән иде.

Икенче яктан, безне башлап кырыгынчы елларда ук дөнья күргән язмаларның чын мәгънәсендә кыю, тәвәккәл һәм принципиаль характерда булуы таң калдыра. Сугыш күренешләре һәм вакыйгалары турында язганда Х. Мөҗәй искиткеч гаделлек күрсәтә, фронт тормышында очраган кимчелекләрне, ямьсез якларны яшереп калдырмый. Ул сугыштагы хәлне белми торып, приказлар җибәреп яткан түрәләрне тетә, солдатларны корал, кием һәм азык-төлек белән тәэмин итүдәге җитешсезлекләрне тәнкыйтьли.

Х. Мөҗәйнең көндәлекләре чын күңелдән язылган. Ул алдашмый, масаймый, үз шәхесен, үз ролен күтәрү белән мавыкмый. Аны барыннан да бигрәк Ватан язмышы борчый. Көндәлек битләре үзенә тапшырылган кешеләр, аларның тормышы өчен борчылу хисләре белән тулы. Г. Сафиуллин һәм Ф. Булатов истәлекләрендәге сыман, Х. Мөҗәй көндәлекләренең төп герое да — гади совет солдаты. Ул аның туземлегенә соклана, батырлыгына, тапкырлыгына дан җырлый. Х. Мөҗәй үзе дә күп тапкырлар шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә. Түбәндә китерелә торган эпизод нәкъ менә шул хакта сөйли:

«Күпер ягыннан урамга йөзләп кешедән гыйбарәт бер колонна кереп килә. Бераз томан һәм караңгы төшеп барганлыктан, колонна бездән 100 метр гына булса да, үзебезнең кешеләрме, яки немецлармы, аерып булмый...

...— Отвечайте, кто! Стрелять буду! — дип кычкырдым.

Минем бу тавышка колонна алдында торучы берәү бозык тел белән: «Русь, капут, руки верх!» — ди.

Немец икәннәре ачык беленде.

Пулеметны әзерләргә һәм, урам чатыннан чыгарып, көпшәсен минем аяклар арасыннан колоннага төзәргә куштым. Хәзер булгач миңа әйтегез дидем. Үзем ике кулны да югары күтәреп «сдаюсь»не белдердем.

Минем гәүдәм пулеметчыларны да, пулеметны да яшерә. Колонна алга таба килә башлады. Менә ул миннән 60 метр чамасы. Иплəп кенә пулеметчыларга «тизрәк» дим. «Булдык» диделәр алар.

Чатка сикердем, «Огонь!» дидем.

Пулеметчылар бөтен лентаны бетергәнче атуны туктатмадылар. Лента бетте. Мин кире чыгып колоннага карадым, ләкин минем күз алдымда колонна юк иде инде, тик кычкырышып, ыңгырашып ятучы тере һәм үле гәүдәләр генә калган иде». (39—40 битләр).

Әйткәнемчә, сугыш тынып торган араларда гына язылсалар да, дәфтәрләрнең гомуми күләме шактыйга җыела. Язмаларның һәр юлыннан авторның формалашып җиткән язучы булуы сизелеп тора. Х. Мөҗәй сугыш күренешләрен гади теркәп бару, кәгазьгә төшерү белән генә чикләнми, аларны ул хәрби трактатка, бәләкәй хикәягә, нәсергә әйләндерә:

«...Тонык Днепрның тын өстенә карап торам. Ул кылт та итми, тик сирәк-сирәк кенә уйный торган балыклар аның өстен шадраландыралар.

Бүген икенче урынга күчәргә приказ алынганда, мин Днепр буенда идем...

Мин тагын бер тапкыр Днепрга, җимерелгән Шевченко каберенә карыйм да, аларның барысы белән дә саубуллашып, командный пунктка китәм.

Хуш, Днепр!

Хуш, бөек шагыйрьнең кабере!

Күпер, якын киләчәктә без сине тәэтербез!

Кабер, якын киләчәктә без сине тагын чәчәкләрбез!» (33 бит).

Мондый шигъри юлларны «Сугыш язмалары»ннан теләсәң никадәр китерергә мөмкин.

Язмаларның авторы безне үзенең аңбелем дәрәҗәсе, интеллектуаль культурасы, әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-политик карашларының югарылыгы белән дә әсир итә. Фашизмны китереп чыгарган сәбәпләр турында уйланганда да, немец халкының киләчәге хакында фикер йөрткәндә дә Хәйретдин Мөҗәй тормышының агышын алдан күрүчән җитлеккән партия эшчесе, марксизм-ленинизм тәгълиматы белән ныклап коралланган коммунист икәнлеген күрсәтә.

**М. МАННУРОВА**

**Равил Фәхретдинов,**
археолог, тарих фәннәре кандидаты

# БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

## Шәһәрләр һәм шәһәрлекләр

Х йөз башларында ук инде Идел һәм Кама буйларында сәяхәтчеләрнең игътибарын җәлеп иткән болгар шәһәрләре булуы мәгълүм. Башка урыннардагы кебек үк, алар авыл хуҗалыгыннан һөнәрчелекнең аерылып чыгуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мондый шәһәрләрдә һөнәрчелекнең төрле тармаклары (төзелеш-архитектура, ювелир сәнгате, металл, агач, сөяк, күн эшкәртү, тукучылык, чүлмәк ясау һәм башкалар) нык алга киткән. Һөнәрчелектән тыш, болгар шәһәрләрендә тагын әле сәүдә итүгә хирeслек көчле булган. Гомумән, Европа шәһәрләренә караганда, Шәрыкъ шәһәрләре үзләренең зуррак булулары белән дә аерылып торганнар. Сүз, беренче чиратта, әлбәттә, һөнәрчелек-сәүдә үзәкләре булган шәһәрләр турында бара. Алардан башка кечерәк шәһәрләр, бәк (феодал) утарлары һәм кальгалар (хәрби крепостьлар) булган.

Идел буенда яшәгән халыклардан, шул исәптән болгарлардан, калган матди культура истәлекләре бик күп. Бу истәлекләрне, беренче чиратта, шәһәр калдыкларын өйрәнү эше хәзер фән оешмалары тарафыннан моңарчы күрелмәгән күләмдә алып барыла. Киләчәктә татар телендә дә археологик әдәбият булдыру, археологик истәлекләргә фәнни анализ ясау кыска һәм ачык терминология таләп итә. Шәһәр калдыкларының бүгенге көнгә сакланып калган урыннары рус археологиясендә «городище» исеме белән йөртелә. «Ище» кушымчасы биредә зурлык төшенчәсен түгел, ә борынгы заманда халык тормышы белән бәйле булган урынның калдыкларын атау термины итеп кулланыла. Әйтик, стойбище, селище, жилище, гробовище. «Ище» кушымчасын татар телендә «лык-лек» кушымчасы белән алыштыру урынлы булыр. Мәсәлән, шәһәрлек, авыллык, каберлек. Билгеле, соңгысы телебездә күптәннән кулланыла инде, тегеләре дә кереп китәр.

«Городище» сүзе феодализм чорында барлыкка килгән шәһәрләр, феодаль замоклар һәм крепостьларның урыннарын атау өчен генә түгел, бәлки ыруглык-кабилә заманыннан калган ныгытмаларны атау өчен дә кулланыла. Димәк, городище, ягъни шәһәрлек сүзенең мәгънәсе бик киң.

Нинди зурлыкта һәм характерда булуларына карамастан, аларның барысы да җирдән өелгән үрләр (валлар) һәм тирән канаулар белән тирәли әйләндереп алынган булган. Болгар ныгытмаларының үзләренең үзенчәлекле ягы бар: аларның үрләре 8—10 метр киңлектә киселеп, капкалар эшләнгән. Шәһәрнең зурлыгына карап, кап-

калар бердән алып унга кадәр була. Җир өрләр хәзер дә әле шактый биекләр, канау төбеннән санаганда биш-алты метрга, сирәк очракта ун метрга кадәр җитәләр. Кайбер язма истәлекләрдә җир өрләр өстендә өстәмә агач ныгытмалар булганлыгы хәбәр ителә. XII йөз уртасында Болгар иленең башкаласында булган әл Гарнати шәһәр стеналарының имәннән салынуын әйтә [1]. 1220 елда русларның Ошель исемле болгар шәһәрен алулары турындагы хәбәрдә дә шәһәр ныгытмаларының өрләрдән һәм имән стеналардан булганлыгы әйтелә [2]. А. П. Смирнов һәм О. С. Хованскаяларның Суар, Болгар шәһәрләрендә алып барган казу эшләре күрсәткәнчә, өрләр өстенә имән бүрәнәләрне бурап стеналар һәм манаралар ясалган булган. Шундыйрак мәгълүматларны безнең Бүләрдә былтыр башкарган тикшеренүләребез дә раслады. Болгар шәһәрләрендә таш стеналар булуы турында чыганаклар табылганы юк. Гомумән, бер Болгарда гына түгел, ә бөтен Көнчыгыш Европаның беренче феодаль шәһәрләрендә таш стеналар булмаган.

Археологик истәлек булу ягыннан шәһәрлекләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин.

Беренчедән, чын мәгънәсендәге шәһәр урыннары. Төрле чорларда Болгар җиренең башкалалары (Бүләр, Болгар, Иске Казан) яки князьлек үзәкләре (Суар, Ошель, Кашан, Җукәтау, Тубылгытау, Кирмәнчек, Тәтеш, Кабан). Болардан башка һөнәрчелек-сәүдә пунктлары булган гадәти шәһәрләр. Әлеге төркем өчен берничә дистә, хәтта берничә йөз гектарны биләгән зур мәйдан, ике-өч рәт өрләрдән торган көчле ныгытмалар, калын һәм бай культура катламы хас [3].

Сан ягыннан күпчелекне тәшкил иткән икенче төркем шәһәрлекләр — кечкенә шәһәрләр, шулай ук бәк утарларының калдыклары [4]. Боларның да ныгытмалары бик көчле, әмма мәйданнары берничә гектардан артмый, культура катламы да беренчеләрнеке кебек үк бай түгел. Ике төркем өчен дә хас сыйфатларны санап үтәргә мөмкин. Мондый шәһәрлекләр күпчелек очракта түгәрәк формада булып, түбәнлек җирдә яки яр буйларында урнашканнар. Тирә-якларында авыллыклар, ягъни ханнарга һәм бәкләргә буйсынган авыл урыннары тезелеп киткән.

Өченче төркем шәһәрлекләр: чик буйларын һәм сәүдә юлларын саклау өчен, дошман һөҗүме мөмкин булган башка урыннарда күзәтү алып бару өчен төзелгән кальга, хәрби ныгытма урыннары. Гадәттә, алар биеклеге 100 әр метрга җиткән һәм аннан да артып киткән тау башларында, биек-биек яр өсләрендә урнашкан булганнар. Мәйданнары кечкенә, ныгытмалары да артык катлаулы түгел, культура катламы бик юка яки бөтенләй юк. Авыл урыннары очрамый диярлек.

Җыйнап әйткәндә, шәһәрлек — оборона ныгытмалары булган борынгы шәһәр, феодал утары һәм кальгаларның бүгенгесе көндә сакланып калган урыннарын атау өчен кулланыла торган археологик төшенчә. Безнең якта шәһәрлекләрне, беренче чиратта болгар шәһәрлекләрен, татарлар «кала-тау» яки «кызлар каласы» дип, руслар «татарский городок», чувашлар «хула вырын» дип атыйлар.

Болгар шәһәрләре турында фәнни хезмәтләр үткән йөзнең икенче яртысында күренә башладылар. А. Артемьев һәм К. И. Невоструевның кызыклы мәкаләләре чыкты [5]. Шиһап Мәрҗани үзенең фәнни эшләрендә, бигрәк тә мәгълүм «Мостафад әл-әхбар»ында, бик күп язма һәм фольклор истәлекләргә таянып, болгар шәһәрләре

---

[1] А. А. Монгайт. Абу Хамид ал-Гарнати и его путешествие в русские земли 1150—1153 гг. «История СССР» журналы. 1 сан. 1959 ел. 171 бит.

[2] Полное собрание русских летописей. (Алга таба ПСРЛ дип кыскартылып бирелер.) IX—X томнар. 1965 ел. 83 бит.

[3] Археологиядә культура катламы дип, борынгы шәһәр, авыл һәм башка яшәү урыннарыннан калган йорт калдыклары, һәртөрле эш-сугыш кораллары, тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары һ. б. шундый әйберләр белән тулы җир катламы атала. Күп гасырлар һәм еллар үтеп китү нәтиҗәсендә, мондый катламнар җир астында калганнар, алар өстендә яңа катламнар хасил булган. Тормышның ни дәрәҗәдә интенсив булуына карап, ул шәһәр-авыллардан калган культура катламнары берничә сантиметрдан алып берничә метрга кадәр була.

[4] Мондый утарлар русларда «замок», Көнбатыш Европада «бург» дип атала.

[5] А. Артемьев. Древний булгарский город Жукотин. Спб. Рус телендә. 1851 ел; К. И. Невоструев. О городищах древнего Волжско-Болгарского и Казанского царств в нынешних губерниях Казанской, Симбирской и Вятской. Труды 1 Археологического съезда в Москве. II том. Рус телендә. 1871 ел. 521—594 битләр.

**турында күпкырлы мәгълүматлар бирде. Казанда IV археологик съезд үткәрелү һәм университет каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте төзелү болгар-татар матди культурасын, шул исәптән шәһәрләрне өйрәнү эшендә зур адым булды. Съездга багышлап, университет профессоры С. М. Шпилевский болгар шәһәрләре турында гаять тә әһәмиятле фәнни хезмәт язды[1]. Казан археологы П. А. Пономарев беренче тапкыр буларак, болгар шәһәрләрен археологик яктан өйрәнә башлап, болгар культурасының үзенчәлекле якларын күрсәтеп бирде[2]. Җәмгыять әгъзалары Е. Т. Соловьев, Г. Әхмәров, И. А. Износков, В. А. Казаринов һәм башкалар күп кенә болгар шәһәрлекләрен табып һәм беркадәр өйрәнеп, киләкле эш башкардылар. Рус совет археологлары А. С. Башкиров, В. В. Гольмстен, А. П. Смирнов, Н. Ф. Калинин Биләрне, «Муромское городище» дигән шәһәрлекне[3], Суарны, Болгарны, Иске Казанны казып, болгар тарихын өйрәнүгә зур өлеш керттеләр. Сугыштан соңгы елларда Татарстанның археологик картасын төзү эше башланып китте, яңа болгар истәлекләре табылды. Н. Ф. Калинин республикабыз җирендә урнашкан 40 лап шәһәрлекнең картасын төзеде һәм алар турында мәгълүматлар җыйнап бирде[4].**

**Соңгы ун елда болгар истәлекләрен, шул исәптән шәһәрлекләрне өйрәнү эше нык җәчәеп китте. Татарстан җире, бигрәк тә аның Тау ягы һәм Кама аръягы, өлешчә Казан арты җитди өйрәнелде. Күрше республика, өлкәләрдә дә шактый гына истәлекләр табылды. Бүгенгесе көндә Урта Идел географик районында 140 болгар шәһәрлеге билгеле. Шуларның 109 ы Татарстанда, 24 е Ульяновск өлкәсендә, дүртесе Чувашстанда һәм өчесе Куйбышев өлкәсендә. Сугыштан соңгы елларда Казан археологлары тарафыннан 96 шәһәрлек өйрәнелде.**

**Хронологик яктан бүленеш түбәндәгечә: 79 шәһәрлек монголларга кадәрге чорга, 35 шәһәрлек Алтын Урда дәверенә карыйлар, 26 шәһәрлекнең төгәл датасы билгеле түгел. Укучыларыбызга болгар шәһәрлекләренең археологик картасын тәкъдим итәбез. Болгар шәһәрләре турында бүгенге көнгә билгеле булган мәгълүматлар фәндә беренче тапкыр җыйнап бирелә[5].**

**Кайда урнашкан булуларына карап, археологик истәлекләргә исем-адрес бирелә. Мәсәлән, «Камаевское городище» дип әйтәләр икән, димәк, бу шәһәрлек Камай авылы янында урнашкан дигән сүз. Без дә картага өстәп, ул шәһәрлекләр табылган авыл исемнәрен бирәбез. Исемлектәге номерлар картадагы номерларга туры килә, алар**

---

[1] С. М. Шпилевский. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. Рус телендә. Казан. 1877 ел. С. М. Шпилевскийның бу хезмәтендә 100 гә якын болгар шәһәрлеге турында мәгълүмат җыйнап бирелгән. Бу истәлекләр урыннардан алынган хәбәрләр буенча гына тупланса лар да, соңга табарак үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә аларның болгарларныкы икәнлеге ачыкланды. Барлык булган язма истәлекләргә дә тирән фәнни анализ ясап язылган әлеге китап бүген дә археологның аерылмас юлдашы булып тора.

[2] П. А. Пономаревның Ошель, Җүкәтау, Кашан, Тубылгытау, Биләр турындагы хезмәтләре «Известия Общества археологии, истории и этнографии» (кыскартылып ИОАИЭ) дигән җыентыкның X, XI, XXX томнарында басылган.

[3] Самар тугаенда урнашкан иң зур болгар шәһәрлекләренең берсе. Муром исемле рус шәһәре белән катнашы юк. Ни өчен болай аталуы билгесез.

[4] Н. Ф. Калинин, А. Х. Халиков. Итоги археологических работ за 1945—1952 гг. Рус телендә. Казан. 1954 ел.


[5] Журналның 1967 ел 7 санында басылган «Болгар тарихына яңа истәлекләр» исемле мәкаләдә без Болгар иленең үзәк җирләрендә урнашкан археология истәлекләре картасын биргән идек. Бүгенге картада бөтен Урта Иделдә урнашкан болгар шәһәрлекләренең тулы җыелмасы бирелә. Картага чыганак итеп совет археологларының 1920—1968 елларда туплаган һәм СССР Фәннәр академиясенең Археология институты, аның Ленинград бүлеге, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивларында, Мәскәү, Ленинград, Казан, Куйбышев, Ульяновск, Чабаксар музейларында саклана торган археологик мәгълүматлар алынды. Болардан башка, революциягә кадәрге чыккан әдәбияттагы кайбер истәлекләр дә файдаланылды.

Шәһәрлекләрнең югарыда күрсәтелгән өч төркемгә бүленеше картада да чагылыш тапты, һәрбер төркем өчен аерым билге алынды. Болгар шәһәрлекләрен классификацияләүдә беренче тәҗрибә буларак, картада аерым төгәлсезлекләр китүе мөмкин. Мәсәлән, зур булмаган шәһәр урыннарын бәк утарларыннан аеру шактый кыен нәрсә. Теге яки бу чорда берәр бәк тарафыннан төзелгән утар, һөнәрчелек үсү нәтиҗәсендә, шәһәргә әверелеп китә — мондый күренешләр тарихта күп булган. Аларны бер-берсеннән төгәл аеру өчен эзлекле казулар алып барылырга тиеш. Алар киләчәктә эшләнер һәм безнең картага да теге яки бу дәрәҗәдә төзәтмәләр кертелер.

елга системасы буенча сугылдылар. Әгәр дә берәр шәһәрлек теге яки бу тарихи шәһәрнең урыны икәне билгеле булса, җәя эчендә шул шәһәрнең исеме куела.

Әйтергә кирәк, рус елъязмалары, гарәп-фарсы һәм өлешчә татар язма чыганаклары буенча түбәндәге болгар шәһәрләренең исемнәре билгеле: Бөек шәһәр, шул ук Бүләр, Бряхимов (Ибраһим), шул ук Болгар, Суар, Ошель (Ашлы, Аш иле), Кашан, Жукотин (Җүкәтау), Тубылгытау, Кирмәнчек, Тәтеш, Казан (Иске Казан), Кабан, Арск (Арча), Гормир, Тухчин (Тукчын!), Торцк (Төрек!), Басов, Исбил яки Асбал, Марк, Арнас, Тәхшу, Йасу, Мерджа. Боларның барысын да ул чыганаклар шәһәрләр дип атыйлар. Бүгенгесе көнгә баштагы 12 шәһәрнең генә археологик яктан урыны билгеле. Калганнарын әлегә теге яки бу шәһәрлек белән бәйләве кыен. Җитмәсә, алар русча һәм гарәпчә язылганнар.

Картада күрсәтелгән барлык шәһәрләр турында журналда мәгълүматлар бирү мөмкин түгел, әлбәттә. Шулай да, татар телендә борынгы тарихи һәм археологик әдәбиятның юк дәрәҗәсендә аз булуын искә алып, без иң күренекле болгар шәһәрләренең тарихына тукталырга булдык.



## БОЛГАР ШӘҺӘРЛЕКЛӘРЕ УРНАШКАН ХӘЗЕРГЕ АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ[1]

| | | |
|---|---|---|
| № 1 | Коротково | Ульяновск өлкәсе |
| № 2 | Красный яр | „ |
| № 3 | Иске Тимошкино | Аксубай районы |
| № 4 | Яңа Мокшы | „ |
| № 5 | Карасу | „ |
| № 6 | Илдерәк | „ |
| № 7 | Ширбән | „ |
| № 8 | Чуваш Кичүе | Әлки районы |
| № 9 | Яңа Әлмәт | „ |
| № 10 | Яңа Әмзә | „ |
| № 11 | Биләр (Бүләр) | Алексеевск районы |
| № 12 | Иске Татар Әдәмсуы | „ |
| № 13 | Атлашкино | Аксубай районы |
| № 14 | Савгач | „ |
| № 15 | Изгар | Чистай районы |
| № 16 | Керәшен Ялтаны | „ |
| № 17 | Горка | Алексеевск районы |
| № 18 | Балынгуз тавы | „ |
| № 19 | Николаевский Баран | „ |
| № 20 | Иске Камка | Әлки районы |
| № 21 | Татар Борнае | „ |
| № 22 | Түбән Кәчи | „ |
| № 23 | Чуваш Аппагы | Ульяновск өлкәсе |
| № 24 | Парау | „ |
| № 25 | Подбелкино | „ |
| № 26 | Никольское | „ |
| № 27, 28 | Белый Яр | „ |
| № 29 | Андреевка | „ |
| № 30 | Ивановка | „ |
| № 31 | Юрманка | „ |
| № 32 | Красная Река | „ |
| № 33 | Тинарка | „ |
| № 34 | Налеткино | Куйбышев районы |
| № 35 | Иске Рәҗәп | „ |
| № 36 | Грязнуха | Ульяновск өлкәсе |
| № 37 | Татгородок (Сувар) | Куйбышев районы |
| № 38 | Якимова Стрелка | Әлки районы |
| № 39 | Кокрять (Тукчын) | Ульяновск өлкәсе |
| № 40 | Шмелевка | „ |
| № 41, 42 | Танкеевка | Куйбышев районы |
| № 43 | Полянки | „ |
| № 44 | Балымер | „ |
| № 45 | Болгар (Болгар) | „ |
| № 46 | Ширбәт | „ |
| № 47 | Татар Төгәлбәе | Әлки районы |
| № 48 | Кошки | „ |
| № 49 | Гусиха | Куйбышев районы |
| № 50 | Иске Куйбышев | „ |
| № 51 | Иске Нократ | Әлки районы |
| № 52 | Иске Матак | „ |
| № 53 | Караваево | Алексеевск районы |
| № 54, 55 | Войкино | „ |
| № 56 | Бураково | Куйбышев районы |
| № 57 | Березовая Грива | Алексеевск районы |
| № 58 | Балакчино | „ |
| № 59 | Алексеевск | „ |
| № 60 | Остолопово | „ |
| № 61 | Кыркүл | „ |
| № 62 | Нарат Елга | Чистай районы |
| № 63 | Актау | „ |
| № 64 | Утяково | „ |
| № 65 | Данауровка (Җукәтау) | „ |
| № 66, 67 | Змеево | „ |
| № 68 | Булдырь | „ |
| № 69 | Малая Полянка | „ |
| № 70 | Рус Сарсазы | „ |
| № 71 | Малый Толкиш | „ |
| № 72 | Иске Роман | „ |
| № 73 | Югары Никиткино (Тубылгытау) | „ |
| № 74, 75 | Сосновка | „ |
| № 76, 79 | Яңа Чишмә | „ |
| № 77 | Слобода Екатерининская | „ |
| № 78 | Слобода Черемуховая | „ |
| № 80 | Татарское Утяшкино | „ |
| № 81 | Кулмаксы | „ |
| № 82 | Ошинский | Түбән Кама районы |
| № 83 | Кызыл Чапчак | „ |
| № 84 | Алабуга—„Чертово городище" | Алабуга районы |
| № 85 | Котловка | „ |
| № 86 | Красная Горка | Мамадыш районы |
| № 87 | Грахань | „ |
| № 88 | Омарский Починок | „ |
| № 89 | Рус Кирмәне (Кирманчек) | „ |
| № 90 | Дегетле | „ |
| № 91 | Тәбердино Чаллысы (Чаллы) | Балык Бистәсе районы |
| № 92 | Сорочьи Горы | „ |
| № 93 | Сорочьи Горы (Кашан) | „ |
| № 94 | Шуран (Кашан) | Лаеш районы |
| № 95 | Өтернәс | Саба районы |
| № 96 | Кабан күле (Кабан) | Казан шәһәре |
| № 97 | Казан Кремле (Казан) | „ |
| № 98 | Арча (Арча) | Арча районы |
| № 99 | Камай (Иске Казан) | Биек Тау районы |
| № 100 | Свияжск | Югары Ослан районы |
| № 101 | Әлмән | Чуваш АССР |
| № 102 | Тау Иле | Зеленодольск районы |
| № 103 | Зур Өтәк | „ |
| № 104 | Луковское | „ |
| № 105 | Старое Янашево | Чуваш АССР |
| № 106 | Старая Тояба | „ |
| № 107 | Тигашево | „ |
| № 108 | Дәвеш | Апас районы |
| № 109 | Чуваш Бизнәсе | Чүпрәле районы |
| № 110 | Кама Елга | „ |
| № 111 | Киртәле | Тәтеш районы |
| № 112 | Килдеш | „ |
| № 113 | Богдашкино (Ошель) | „ |
| № 114 | Хулаш | „ |
| № 115 | Старое Алейкино | Ульяновск өлкәсе |
| № 116 | Иске Әнәле | Апас районы |
| № 117 | Льяшево | Тәтеш районы |
| № 118 | Зеленовка | „ |
| № 119 | Танай Турай | Апас районы |
| № 120 | Чури Бараш | „ |
| № 121 | Шонгуты | „ |
| № 122 | Олы Карилә | Кама Тамагы районы |
| № 123 | Уразлино | „ |
| № 124 | Куйбышевский Затон | „ |
| № 125 | Сюкеево | „ |
| № 126 | Тәтеш (Тәтеш) | Тәтеш районы |
| № 127 | Колунец | „ |
| № 128, 129 | Ундоры | Ульяновск өлкәсе |
| № 130 | Городище | „ |
| № 131 | Поливной овраг | „ |
| № 132, 133 | Криуши | „ |
| № 134 | Сенгилей | „ |
| № 135 | Буераки | „ |
| № 136 | Елаур | „ |
| № 137 | Бектяшка | „ |
| № 138 | Жигулевск | Куйбышев өлкәсе |
| № 139 | Валы — „Муромский городок" | „ |
| № 140 | Александровка | „ |

[1] Шәһәрлекләр исемлектә күрсәтелгән авылларның я янында ук, я алардан бер-ике чакрым ераклыкта урнашканнар.

# Бүләр — Бөек шәһәр

Шәһре Болгарны җимергәннән соң, Аксак Тимер Бүләргә юнәлә. Күпмедер вакыт узгач, аның гаскәре шәһәр янына килеп җитә һәм кочле ныгытмалар алдында туктап кала. Тимер сугышырга җөрьәт итми. Бүләр ханы исә шәһәр халкы белән киңәшә. Нишләргә! Дөньяны тетрәткән шушы каһарман явына каршы торып булырмы! Халык бу эшне хәл итүне ханның үзенә тапшыра. Шулай да хан бер акыл иясенә мөрәҗәгать итә. Хәким биек манарага менә, дошманның диңгез кебек гаскәрен күреп, сугышмаска киңәш итә. Капкалар ачыла. Аксак Тимер гаскәре шәһәргә керә һәм күп кешене кыра.

Җиһангирнең сәер бер гадәте була. Халыкның уй-фикерен белер өчен, икенче көнгә киенеп, ул төнлә кеше арасында йөрергә һәм бәла-казаның каян килгәнлеген сорашырга яраткан. Әгәр дә шунда берәрсе Тимерне гаеп итсә, ул икенче көнне үк аның нәсел-нәсәбенә кадәр кырып бетертә. Инде кемдер бәла аның өстенә алла тарафыннан җибәрелгән дип сөйләсә, ул кешегә Тимер яхшылык кыла, тарханлык бирә.

Бүләрне алган төнне дә җиһангир шәһәргә чыгып китә. Күп кеше: шул «аксак» кына харап итте үзебезне, ди. Әмма шунда бер морзаның тол калган хатыны: «Куегыз! Әгәр дә безнең булдыксыз остазларыбыз һәм тәңре булмаса, бер Тимер генә ни эшли алыр иде соң!» дип, аларга каршы төшә. Икенче көнне Аксак Тимер бу хатынга һәм аның бөтен ыруына азатлык бирә, кая теләсәләр шунда китәргә рөхсәт итә. Бикә, үзенең Инсан бәк һәм Ихсан бәк атлы уллары белән Бүләрне ташлап, икенче урынга күчеп утыра...

Бу — легенда. Еллар түгел, гасырлар кичеп, буыннан-буынга тапшырылып килгән әлеге легендага да, башкалары кебек үк, тарихи дөреслектән азмы-күпме тайпылу хас. Әмма хикмәт анда түгел. Татар халкының борынгы мәшһүр калаларыннан берсе булган Бүләр турында сакланып калган шушы риваять халкыбызның бай тарихын ачыклауда матур бер истәлек булып тора, халыкның үзенең данлы шәһәрен онытмавы турында сөйли. Хикмәт менә шунда.

Инде ышанычлы мәгълүматларга күчик.

Рус елъязмаларының иң әһәмиятлеләреннән саналган Лаврентий елъязмасы күрсәтүенчә, князь Андрей Боголюбский 1164 елда үзенең улы, туганы һәм Муром князе белән берлектә Болгар иленә һөҗүм оештыра. Руслар болгарларны җиңделәр, болгар князе үзенең дружинасы белән Бөек шәһәргә кереп бикләнде, ә руслар кайтышлый болгарларның данлы Ибраһим шәһәрен һәм тагын берничә шәһәрне алдылар, дип хәбәр итә елъязма [1]. Әлеге шәһәрләрнең, шул исәптән Бөек шәһәрнең дә кайдалыгы әйтелми. Ләкин бу турыда икенче хәбәрдән беләбез. Болгар дәүләте элек-электән үзенең күршесе рус дәүләте белән сәүдә иткән. Иделнең югары агымында һәм Ока елгасы буенда урнашкан рус шәһәрләрендә болгар товарлары сатылган. Менә көннәрдән бер көнне Рязань, Муром кебек шәһәрләрнең билгесез юлбасарлары җыйналышып, болгар сәүдәгәрләрен талыйлар, җитмәсә аларның шәһәр-авылларына зыян китерәләр. Мондый башбаштаклыкка чик куюны үтенеп, болгарлар Владимир князе Всеволодка мөрәҗәгать итәләр. Всеволод сәүдәгәрләргә тияргә ярамау турында тирә-юнь шәһәрләргә боерыклар җибәрсә дә, юлбасарларны авызлыклар өчен катгый чаралар күрми. Ачулары чыккан болгарлар 1183 елда Городец, Рязань, Муром шәһәрләрен тар-мар итеп кайталар. Шуннан соң Всеволод болгарларга каршы сугышу өчен Киев князе Святославтан ярдәм сорый. Святослав гаскәр белән үзенең улын җибәрә. Чернигов, Север, Переяславль, Смоленск князьләре дә Святослав кушуы буенча Всеволодка ярдәмгә киләләр. Алар, барысы бергә җыелып, 1184 елның язында Болгар иленә сугыш башлыйлар. Төп удар Бөек шәһәргә юнәлдерелә. Башкаланы сакларга болгарларның башка шәһәрләреннән дә атлы һәм җәяүле гаскәрләр килә. Руслар Бөек шәһәрне ала алмыйча, кире кайтып китәләр [2].

Биредә инде Бөек шәһәрнең Чирмешән елгасы буенда икәнлеге әйтелә. Бу шәһәр рус елъязмаларында шуннан соң да берничә тапкыр телгә алына.

---

[1] ПСРЛ. 1 том. 1962 ел. 352 бит.

[2] ПСРЛ. 1 том. 1962 ел. 389—390 битләр; В. Н. Татищев. История Российская. III том. Рус телендә. 1964 ел. 128—130 битләр.

1232 елда монголлар Болгар иленә бәреп керәләр. Ләкин әллә ни уңышка ирешә алмыйлар. Бөек шәһәрне ала алмыйча, шуннан ерак түгел бер урында кышларга мәҗбүр булалар. 1236 елда Батый хан армиясе Европаны яулап алу походын башлый, иң беренче итеп Болгар иле буйсындырыла. Монголлар Бөек шәһәрне алалар («взяша славный Великий город болгарский) [1]. Урта гасырның иң зур тарихчысы Рәшидетдин дә Болгар иленең башкаласын Бөек шәһәр дип атый [2].

Менә шушы Бөек шәһәрне бездә Болгар итеп карау гадәткә кереп киткән. Моның белән килешәсе килми: ул Болгар түгел, Бүләр булган дияргә килә. Беренчедән, югарыда күреп үткәнебезчә, Лаврентий елъязмасы Бөек шәһәрне Чирмешән буенда, ягъни хәзерге көндә Бүләр шәһәренең калдыклары урнашкан елга буенда итеп күрсәтә. Икенчедән, кайбер көнчыгыш сәяхәтчеләре бу вакытлардагы Болгар иленең башкаласы итеп Бүләрне саныйлар. Мәсәлән, Әбү-әл-Фида [3]. Гарәпләр Бүләр сүзен гарәпләштереп Болгар дип атыйлар ди, Әл-Гарнати [4]. XIII йөз Кытай елъязмачысы Юан ши-ао пи-ши Батый хан гаскәре басып алган зур шәһәрләр һәм халыклар арасында Болгарны түгел, ә Бүләрне күрсәтә [5]. Билгеле, кайбер гарәп-фарсы географлары X—XIII йөздә болгар шәһәрләре арасында Бүләрне белмиләр. Мәсәлән, XIII йөз тарихчысы Җуәйни: «Монголлар Болгар шәһәрен алдылар, ул дөньяда халкының күп санлы һәм бик көчле ныгытылган шәһәр булу белән мәшһүр иде» [6], ди.

Менә шушы сүзләр һәм, гомумән, Бөек шәһәр эпитеты Бүләргә бик туры килә. Бу археологик мәгълүматлар белән дә раслана. Профессор А. П. Смирновның күп еллар буе алып барган тикшеренүләре күрсәтүенчә, монголларга кадәрге чорда Болгар кечкенә генә шәһәр булган. Аның бүгенгесе көнгә сакланып калган 7 чакрымга якын озынлыктагы үрләре һәм калын культура катламы Алтын Урда заманына карый. Ә инде Бүләрдән калган көчле оборона ныгытмалары нәкъ менә монголлар килгәнче корылганнар, аның төп культура катламы да шул ук дәвергә керә. Тагын да әйтәсе килгән сүз шул: гарәп орфографиясе җирле атамаларны һәрвакытта да дөрес бирә дип уйларга ярамый.

Монголлар тарафыннан җимерелгәч, Бүләр элекке куәтен югалта. Алтын Урда чорында Болгар җиренең яңа үзәге — шәһре Болгар нык үсеп китә. Алай да Бүләр бөтенләй үк яшәүдән туктамый, әле бер заман үзендә акча да сугыла башлый. Бүләрдә табылган иң соңгы акча 827 [1423] елга карый. Шуннан соң инде Бүләрнең яшәү-яшәмәве турында мәгълүматлар юк. Хәер, 1677 елда Казан өязе татарларының патшага җибәргән бер үтенече сакланып калган. Татар морзалары әле Казан ханы Сафа Гәрәй заманында ук үлгән Мәгълүм хуҗа исемле Бүләр ханының кабере өстенә куелган төрбәне (мавзолейны) саклауны татарларга тапшыруны һәм шул тирәдәге җирләрне дә үзләренә кайтарып бируне үтенәләр.

Моннан чыгып кына Казан ханлыгы вакытында да Бүләрнең үз ханы булган икән дип әйтүе кыенрак. Чөнки әлеге документ, Мәгълүм хуҗа үлеп, шактый вакытлар үзгач язылган. Мәгълүм хуҗаның элегрәк яшәп, аның турында истәлекләрнең XVII йөз ахырларына кадәр саклануы бик мөмкин. Җитмәсә, аның кабере өстендәге төрбә дә җимерелмәгән булган.

Казан Рус дәүләте составына кертелгән заманда Бүләр бөтенләй бушап калган хәрабә рәвешенә килгән булган. Шуннан соң бер гасыр үткәч, 1654 елда Бүләр урынына стрелецлар килеп утырган. Әкренләп монда рус авылы үсеп киткән һәм ул, элекке исемен югалтмыйча, ләкин бераз русчалаштырып Билярск дип йөртелә башлаган. Ул авыл әле дә бар һәм борынгы шәһәр мәйданының өчтән бер өлешен алып тора [7].

---

[1] ПСРЛ. 1 том. 460 бит.

[2] Рашид-ад-дин. Сборник летописей. II том. Рус телендә. 1960 ел. 37 бит.

[3] Д. А. Хвольсон. Известия о хазарах, буртасах, болгарах... Рус телендә. Спб. 1869 ел. 88 бит.

[4] А. А. Монгайт. Күрсәтелгән хезмәт. 171 бит.

[5] E. Bretschneider. Mediaval Researches from Eastern Asiatik Soures. Vol I. London, Инглиз телендә. 1910 ел. 300 бит.

[6] В. Г. Тизенгаузен. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. II том. Рус телендә. М.—Л. 1941 ел. 23 бит.

[7] Элеккеге район үзәге. Хәзер Алексеевск районына кушылган, татарча Биләр дип йөртелә.

Бүләр хәрабәләре турында беренче тапкыр XVIII йөз атаклы рус тарихчысы В. Н. Татищев язып калдыра. Ул бик зур бер мәчетнең ярым җимерек калдыкларын һәм күп кенә манаралар булуын әйтә. Икенче бер тарихчы һәм географ Н. П. Рычков 1769 елда Биләрдә була һәм үзенең көндәлегендә күп кенә җимерек таш биналар күргәнлеген яза. Әйләнәсе 24 аршин (16 метрдан артык) һәм кызыл кирпечтән салынган манара калдыгы нык аерылып тора. Рычков күргәндә ул бары тик 3,5 метр биеклектә генә калган була. Бер карт аңа 30 еллар чамасы элек манараның бик биек, аның тирә-ягында тагын таш биналар булганлыгы хакында сөйли. Рычков үзе дә манара калдыгы янында таш хәрабәләр күрә. Ләкин аларның ташларын Биләр халкы үз кирәк-ярагына ташый.

Шул ук заманда Биләрдән 2 чакрым ераклыкта, Чирмешәннең икенче ягында тау башында, берничә таш бина һәм күп кенә кабер ташлары була. Бер татар мулласы Н. Рычковка бу эпитафияләрнең яхшырак сакланганнарын укып та күрсәтә. Бер ташка Мәгълүм хуҗа, янәдән берсенә Шәвәли хуҗа исемнәре язылган була. Әйбәтрәк сакланган ике ташта 1173 һәм 1434 елларны укырга мөмкин була. Мәгълүм хуҗа исеме башка чыганакларда да очрый. Мәсәлән, XVI йөз татар тарихчысы Шәрәфетдин әл Болгари шул ук тау өстендә «хуҗа» эпитеты белән өч таш барлыгын, шуларның берсе Мәгълүм хуҗаныкы икәнен яза. Академик Х. Френ да борынгы бер язма таба һәм анда Биләр тавы өстендәге әлеге хуҗаның кабере турында хәбәр укый. Без югарыда 1677 елда патшага язылган үтенеч кәгазендә дә Мәгълүм хуҗа исемен күреп киткән идек. Бу исем бүгенге көндә топонимик атамага әверелгән. Әлеге тауны Биләр руслары Балын-гузя яки Балынгуз дип йөртәләр. Татар телендәге «м» авазының рус телендә «б»га әверелүе нәтиҗәсендә Мәгълүм хуҗа Балын-гузя булып киткән.

Бүгенгесе көндә билгеле булган болгар кабер ташларының барысы да Алтын Урда чоры истәлекләре. Югарыда телгә алынган 1173 елгы кабер ташы, әгәр мулла дөрес укыган булса, болгар эпиграфикасының уникаль истәлеге булыр иде. Кызганычка каршы, тау өстендәге бер генә таш та сакланмаган, Биләр халкы соңга табарак аларны да чиркәү һәм йорт нигезләрен салырга ташып бетергән.

Бүләр хәрабәләре XIX йөздә җирле халык тарафыннан тагын да көчлерәк талана. 1812 елда Биләрдә Казан университеты адъюнкты Кондырев була һәм борынгы шәһәр мәйданындагы ярым җимерек архитектура истәлекләре белән кызыксына. Аның 1831 елда икенче тапкыр килүендә ул хәрабәләрдән бары тик таш өемнәре генә калган була, бая телгә алынган манара калдыгы да бик аз гына күренә, аның кирпечташлары шулай ук Биләр чиркәвенең нигезенә китә.

Борынгыдан калган таш-кирпеч бина калдыкларын һәм кабер ташларын төзү материалы итеп файдаланудан тыш, Биләр крестьяннары төрле табылдыкларны сатып зур файда күрәләр. 1877 нче ачлык елны алар шәһәр мәйданында берничә зур чокыр табалар. Ә һәр чокырдан 200 потлап сөяк чыга. Мәгълүм булганча, болгарларда һөнәрчелекнең күп төрләре рәтеннән сөяктән әйберләр ясау киң таралган була. Әлеге чокырлардагы сөякләр дә эзерләнеп куелган чимал булганнардыр. Шунда ук эшләнеп беткән әйберләр дә очрый. Бер 1877 елда гына да 3 000 сумлык сөяк сатыла. Мондый төшемле эшнең тәмен белеп алалар, сөяк җыйнап, шәһәрлекнең культура катламына зур зыян килә, хәтта ныгытмаларны да чокырлап бетерәләр. Болардан кала, сукаланган җир өстендә чиксез санда башка табылдыклар очрый. Әйтик, алтын-көмештән эшләнгән төрле ювелир әйберләр, кыйммәтле савытлар һәм металл көзгеләр, аннан башка бакырдан, кургаш һәм аккургаштан коелган предметлар, чуен, тимер һәм сөяктән эшләнгән эш һәм сугыш кораллары, башка төрле хуҗалык кирәк-яраклары. Болар да сатыла. Сатып алучылар — борынгы әйберләр белән кызыксынучы помещиклар, чиновниклар, офицерлар. Кызганычка каршы, бу калдыкларның күбесе фән өчен мәңгегә югала, тик беразы гына очраклы рәвештә музейларга эләгә.

Болгар матди культура истәлекләрен фәнни әйләнешкә кертү нияте белән Казан археология җәмгыяте Болгар белән беррәттән Бүләрне дә ныклап тикшерергә карешә. 1881 елда В. А. Казаринов, 1914 тә П. А. Пономарев, 1928 дә профессор А. С. Башкиров бирегә тикшеренүләр алып баралар, кызыклы материаллар туплыйлар.

Болгарларның монголларга кадәрге тарихын тирәнтенрәк тикшерү һәм халкыбызның килеп чыгыш мәсьәләләрен тулырак яктырту максаты белән, Бүләрне археологик өйрәнү янәдән башланып китте. Иң элек Кече Чирмешән елгасы буйлап тикше-

ру ясалды. 1964 һәм 1965 елларны без бу елганы тоташтан йөреп чыктык һәм искиткеч күп материаллар тупладык. Әгәр дә бүгенгесе көндә болгарларның 1620 археологик истәлеге билгеле булып, шулардан 1321 истәлек Татарстан җирендә урнашкан икән, аларның да 408 е Кече Чирмешәнгә туры килә. Күрәсез, бу елга буйлары борынгы Болгар илендә халыкның иң тыгыз урнашкан җире булган.

Буләрнең үзен дә ныклап өйрәнергә тотындык. Менә ике ел инде без — Казан археологлары — һәр җәйнең июль аенда шәһәрлекнең үзәк мәйданында казынып ятабыз. Экспедициянең җитәкчесе — тарих фәннәре докторы А. Х. Халиков. Җыйналган мәгълүматлар турында сөйләгәнче, бер-ике сүз белән генә шәһәрнең тышкы күренешен күзаллау зарури булыр.

Шәһәр ике өлештән торган: уртада эчке шәһәр, ягъни шәһәрнең үзәге — хан сарае, җамигъ мәчет, эре сәүдәгәрләр, руханилар йортлары, шәһәр гарнизоны урнашкан район. Ул биш чакрым озынлыктагы ике рәт үрләрдән һәм имән стеналардан корылган ныгытмалар белән әйләндереп алынган. Аның әйләнәсендә һөнәрчеләр, игенчеләр һәм башка гади халык яшәгән. Бу инде шәһәрнең төп өлеше. Аны әйләндереп алган өч рәт үрләрнең озынлыгы 11 чакрым. Менә шул үрләргә менеп басасың да — хәйран каласың. Нинди көчләр түзгән соң моны! 11 чакрым дидем. Ул аның әйләнәсе, ә аркылыга-буйга үлчәсәң, өчәр чакрымнан арта. Әйе, әйе, бер башыннан икенче башы күренми, мәйданы 573 гектар. Менә шул урынга бүген шәһәр төзеп кара әле. Ә без бит урта гасырлар шәһәре турында сөйлибез. Чын мәгънәсендә Бөек шәһәр булган ул. Зурлыгы ягыннан Буләр белән тиңләшерлек башка шәһәр бер Болгар илендә генә түгел, бөтен Көнчыгыш Европада булмаган ул заманда. Киев, Новгород, Рязань аңа караганда күп кечкенә булганнар.

Шушы борынгы шәһәр мәйданына күз сирпеп алган кеше җир үрләрдән башка тарихи истәлекләрне күрмәс иде. Әмма археолог күзенә бодай үскән җир тигезлеген бозып торучы төрле калкулыклар килеп бәрелә. Болар инде, һичшиксез, борынгы бина урыннары.

Һәр археологның хыялы — шәһәр кадәр шәһәр казып, бер таш хәрабә табу. Булган-булган, әйтик, хан сарае яки зур бер мәчет булсын инде ул. Ак, сары, зәңгәр, яшел төсләрне җыеп эшләнгән мозаик стеналы, ярым колонналар белән әйләндереп алынган мәһабәт бер сарай! Аннан килеп, хан кабере өстенә куелган төрбә, ә аның эчендә кайчан куелганын күрсәтеп язган кабер ташы табасың инде. Яки бер сәүдәгәр йорты булсачы дисәң, аның эчендә акча табылмый калмый — менә сиңа дата! Билгеле, хыялланып-хыялланып та, гади генә агач йорт калдыгына эләккән чаклар да була. Беренче елны безнең белән дә шулай булды. Ярый әйдә, хәере белән булсын. Бигрәк шәп — һөнәрче йорты. Тормышның нигезен материал байлыклар тәшкил итә. Ә аларны һөнәрче җитештерә. Тимер келәшчә, чүкеч, тишкеч, балчык савытлар һәм барысыннан да кызыклысы — терекөмеш тутырып йөртү өчен кулланылган сфероконус исемле кечкенә генә ябык савытлар. Терекөмеш металлургиядә бик кыйммәтле, металл әйберләрне, әйтик, бронза көзгеләрнең өстен ялтырату өчен кулланыла. Сфероконусларның кечкенә генә бер склады да табылды. Димәк, көзгеләрне биредә дә ясый белгәннәр.

Йорт белән янәшә тимер эретү мичләре дә казылды. Шәһәр оборона системасын өйрәнә башладык, шактый кызыклы булырга охшый. Икенче елга шәһәрнең иң зур капкасы булган урынны казырга ниятләнәбез.

Игеннәр урылып алып, җир сукаланып, җир өстендәге борынгы бина эзләрен күрергә мөмкинлек ачылгач, без янәдән Буләргә юл алдык. Сентябрь аеның матур бер көне. Күктә кояш елмая, бер генә болыт әсәре дә юк. Көн безнеке! Шәһәр мәйданын аэро-фотога төшерү өчен бирелгән самолетка утырам һәм өскә күтәреләм. Мин бер чакрым биеклектә, ә аста чал тарих хәзинәсе.

И мәшһүр шәһәр! Төзелүеңә мең ел вакыт үткән, өч-дүрт гасыр гомерең булган, изге туфрагың кан белән юылган, батыр улларың, даныңны саклап, газиз башларын җуйганнар. Әле дә син мәһабәтсең. Әнә ул синең сарай-пулатларыңнан калган кызыл кирпеч өемнәрең, ул кара туфрак өстендә ярылып яткан йорт-каралты нигезләрең, ул җептәй тезелеп киткән рәт-рәт урам эзләрең, ул еландай сузылып яткан үрләрең-канауларың! Бераз мактанырга да хакыбыз бар. Әгәр дә ялгышмасам, аэрофото төшерүләр безнең илдә моңарчы Харәзем экспедициясе тарафыннан гына алып

барылды булса кирәк. Менә шундый эшләрне быелтыр Биләрдә башкару бәхетенә ирештек. Ул гына да түгел, кулга компас-буссоль алып, шәһәр мәйданын аркылыга-буйга йөреп чыктык. Очраган барлык йорт эзләрен картага төшердек. Бу эшләр ярты айга сузылды. Әмма аның каравы, гаҗәеп бай фәнни мәгълүмат тупланды. Уйлап кына карагыз: шәһәрнең сукаланган өлешендә 1207 бина эзе. Шуларның 29 ы таш һәм кирпеч йорт калдыклары; күбесе эчке шәһәр мәйданында. Җаның кайсын тели, күпме гомерең бар — казы. Киләчәктә дә уннарча буынга җитәрлек. Бөек шәһәр үзенең серләрен ача гына әле.

Бөек шәһәрнең тарихын өйрәнү эше әле бер Биләр шәһәрлеген казу белән генә чикләнмәс. Аның бөтен тирә-юне — археолог күрәсен көтеп яткан борынгы хәрабәләр белән тулы шәһәр-авыл урыннары. Җөмләдән, бая телгә алынган Балынгуз тавы. Зурлыгы ягыннан Биләр шәһәрлегеннән бераз гына калыша торган икенче бер шәһәрлек бар шул тау янында. Әйләнәсе 9 чакрым, хәтта Болгар, Суарлардан да зур. Кайсы шәһәр калдыгыдыр — әйтүе кыен. Хәер, фараз кылу зыян итмәс. 1184 елда рус кнәзьләренең Бүләргә походы вакытында башкаланы сакларга болгарларның бүтән шәһәрләреннән гаскәр җыелуы турында әйткән идек инде. Менә шунда Торцк [Төрек] шәһәреннән атлы гаскәр килүе хәбәр ителә [1]. Кайда булган ул шәһәр? Аның исеме бүгенгесе көндә берәр җирле атамада сакланмаганмы? Ә менә Балынгуз тавының итәгеннән, әлеге шәһәрлекнең ерак үрләре яныннан бер кечкенә генә елга агып төшеп, Чирмешәнгә коя. Елганың исемен руслар Торцкая дип атыйлар. Билгеле, бу гына әле Балынгуз тавындагы шәһәрлекнең Торцк шәһәренең калдыгыдыр дип әйтергә дәлил була алмый. Әгәр дә инде берәр болгар-татар елъязмасы табылып, шунда борынгы шәһәрләребезнең кайда урнашкан булулары турысында бәйнә-бәйнә хәбәрләр укысак, мондый фараз итүләрдән бәлки азат та булыр идек. Әмма, нишләмәк кирәк, андый елъязмалар сакланмаган; һәрхәлдә, бүгенгесе көндә юк. Шуңа күрә болгар шәһәрләренең тарихи топографиясен күз алдына китерүдә археология, топонимика, гидронимика һәм башка чыганаклар кирәкле мәгълүматлар бирер дип ышанырга хакыбыз бар. Нәрсә генә булмасын, Балынгуз янындагы шәһәрлек Бүләр тарихының яңа сәхифәләрен ачуга үзеннән зур өлеш кертер.

Балынгуз тавы үзе генә дә тарихның телсез бер шаһите. Никадәр таш-кирпеч семнәре белән тулы ул тау. Ташларның теле булса, ул да күргәннәрен сөйләр иде, диләр. Археологның эше — менә шул ташларның телен белү. Заманында Н. Рычков күргән кабер ташлары һәм таш пулатлар, инде әйткәнемчә, җимерелеп беткәннәр. Алардан калган таш-кирпечләрнең зурлыкларына караганда, бу пулатлар Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры истәлекләре булырга ошый. Болар тау башында. Тауның Чирмешәнгә караган сөзәклегендә, урта бер җирдә бик зур бер бина нигезе бар. Үткән гасырда ул урыннан һәрбере 30 ар потлы ташлар чыккан. Бирәдә мәчет булган икән дигән хәбәр дә бар [2]. Менә шул бина нигезе яңа сукаланган кара җир өстендә кызгылт бер тап булып ярылып ята, еракта, хәтта Биләр яныннан ук күренә.

Балынгуздан бераз көнбатышка табарак, Чирмешәннең шул ук уң як ярында, «Хуҗалар тавы» дип йөртелә торган икенче бер тау башында да борынгы хәрабәләр булганлыгы мәгълүм. Алар хәзер юк инде. Шушы тау башында заманында күзәтү пункты булгандыр дияргә хакыбыз бар. Ул якларда иң бөек нокта буларак, аның өстеннән бөтен тирә-юнь ап-ачык күренеп ята. Гадәттә, еракта дошман явы күренсә, шундый биек тау башларында ут ягып, куркыныч туу турында хәбәр итә торган булганнар.

«Хуҗалар тавы» белән күршедәге Николаев Баран дигән авыл арасында янәдән бер шәһәрлек бар. Монысы да шактый зур, үрләре хәтта Бүләрнекеннән дә биегрәк. Бусына да археолог кулы тимәгән әле. Кыскасы, Бөек шәһәр һәм аның тирә-ягы халкыбыз тарихының яңа һәм бай сәхифәләрен ачардай олы бер хәзинәдер, бабаларыбыздан калган бәһале бер мирастыр.

---

[1] ПСРЛ. I том. 1962 ел. 390 бит.

[2] В. А. Казаринов. Описание Билярских и Баранского городищ. ИОАИЭ. Рус телендә. III том. 1880 ел. 115 бит.

# Шәм Суар

Хәзерге Куйбышев районының Кузнечиха авылыннан көнбатышка карап 2 чакрым тирәсе җир китkәч, бер шәһәрлек урыны бар. Әйләнә-тирәдә яшәүче руслар аны «Татарский городок» яки Сувар дип йөртәләр. Хәзер бу тирәләрдә андый-мондый хәрабәләр күренми, мәйданы сукаланган, бары тик ике рәт итеп өелгән һәм озынлыгы биш чакрымга җиткән үрләр генә биредә кайчандыр зур шәһәр булганлыгы хакында сөйлиләр. Тирә-юньдә куе урман, астарак бормаланып Утка елгасы ага. Елганың борынгы үз исеме Ватигь [وتيغ]; һәрхәлдә, 922 елда Багдаттан Болгар иленә сәяхәт кылган атаклы Ибн Фадлан аны шулай атаган. Ни сәбәптәндер, Ибн Фадлан язмаларында болгар шәһәрләре турында хәбәрләр юк. Андый хәбәрләр икенче бер гарәп географы әл Бәлхинең хезмәтендә сакланган. Әл Бәлхи Болгар җирендә ике шәһәр — Болгар һәм Суар шәһәрләре булуын, һәр икесендә җамигъ мәчет барлыгын һәм һәр икесендә дә 10 мең кеше яшәгәнлеген әйтеп уза[1]. Кышын халык агач йортларда тора, ә җәй җиткәч, киез тирмәләргә күчә, дип тәмамлый сүзен әл Бәлхи. Бу язмалар төрле редакциядә X йөзнең башка күренекле географлары, мәсәлән, әл Истахри [950 ел], Ибн Хәукаль [970 ел], әл Мөкатдәси [985 ел] әсәрләрендә дә һәм «Хөдүд әл галәм»дә дә очрый. Мөкатдәси, боларга өстәп, Суарда уңдырышлы җирләрнең һәм һәртөрле байлыкның күп булуын әйтә.

Табылган кадәр нумизматик материал да X йөздә Суар исемле шәһәр булу турында сөйли. Мәгълүм булганча, Багдад хәлифәлегендә Саманилар династиясе хөкем сөргән заманда [IX—X йөзләрдә] Европа белән Азия сәүдә әйләнешендә гарәп дирһәмнәре, ягъни көмеш тәңкәләр зур роль уйный. Мондый акчалар Багдадның үзендә генә түгел, ә аның йогынтысына элаккан башка шәһәрләрдә дә сугыла. X йөзнең 20 елларыннан башлап болгарлар, гарәп дирһәмнәренә охшатып, ләкин аларның кайда һәм кайчан сугылган булуларын үзгәртмичә, үз дирһәмнәрен эшли башлыйлар. Мәсәлән, Микаил Ибн Җәгъфәр атлы болгар ханы исеменнән сугылган Сәмарканд, Шаш [Ташкент], Бәлх, Нисабур акчалары булуы билгеле[2]. Күп тә үтми, болгарлар үз акчаларын да суга башлыйлар. Бүгенгесе көнгә билгеле булган андый акчаларның иң беренчесе 931 елда Суарда Насыйр Ибн Әхмәт тарафыннан сугылган. Суарда шулай ук 948—958 елларда Талиб Ибн Әхмәт суктырган акчалар да мәгълүм. Талибның туганы Мөэмин хан акчалары бер үк 976 елда Суарда да, Болгарда да сугылалар. Ә менә 976 дан 980 елга кадәр икенче бер Мөэмин хан [Ибн Хәсән] заманында акчаларны бары тик Болгар гына суга. Бу хәл Суарның элек шактый зур сәяси әһәмияте булып та, X йөз ахырында инде мөстәкыйльлеген югалтып, тулысынча шәһре Болгарга буйсынуын күрсәтсә кирәк[3].

Суарның исеме көнчыгыш әдәбиятында соңга табарак та очрый әле. XI йөз географлары Мәхмүт Кашгари һәм әл Мәрвәзи аның исемен телгә алалар[4]. XIV йөздә фарсы язучылары Хәмдулла һәм Фәрһәнг Суарны Алтын Урданың һәм болгарларның зур шәһәре дип атыйлар. Шуннан соң инде бу шәһәр язма истәлекләрдә очрамый.

---

[1] Дөресрәге, 10 мең ир-зат бар ди. Безнеңчә, ир-зат сүзен корал йөртүче гаскәр дип күз алдында тотарга кирәк. 982 елда язылган «Хөдүд әл галәм» әсәрендә Болгар шәһәренең 20 мең атлы гаскәре булу турында әйтелә.

[2] Микаил Ибн Җәгъфәр Болгар иленә Ибн Фадлан килгән заманда идарә иткән Алмуш ханның улы булса кирәк. Моңа Микаилның Җәгъфәр улы булуы ишарә ясый. Мәгълүм булганча, Алмуш хан ислам дине кабул итеп тә, мөселман исеме йөртмәвенә риза булмый һәм Багдад хәлифәсе Җәгъфәр әл Мөкътадиргә ияреп үзенә Җәгъфәр исеме куша.

[3] Ул заман болгар акчаларының таралыш географиясе шактый зур. Җиргә күмелгән хәзинәләр составында алар үткән йөздә Рязань, Тверь, Псковь губерналарында, хәтта Скандинавия илләрендә, мәсәлән, Даниядә табылалар.

[4] Әмма Кашгари Суарны Саксин шәһәре белән бер итеп карап хата җибәргән. Ул үзе Суарда булмаган, шуңа күрә аның урынын да Иделнең уң ягында һәм Каспий диңгезе буенда итеп ялгыш күрсәтеп үткән. Суарның калдыклары, мәгълүм булганча, Иделнең сул ягында һәм Каспийдан бөтенләй еракта, Болгар шәһәре янында урнашкан. Барлык башка гарәп язучылары да Суарны Болгар белән янәшә итеп күрсәтәләр. XII йөздә Саксинны үз күзе белән күргән әл Гарнати бу шәһәрне чыннан да Каспий янында күрсәтә, аннан Болгарга (Бүләргә) кадәр Идел буйлап 40 көнлек юл ди.

Суарның урыны кайда булуы үткән йөзнең ахырларына кадәр бәхәсле булып килде. Берәүләр аны Свияжск белән бәйлиләр, икенчеләре Спасск түгелме икән диләр, Сембер урынында булмагае диючеләр дә була. Тик 1893 елда беренче татар археологы Гайнетдин Әхмәров кына Суарның бая телгә алынган Кузнечиха янында булганлыгын ачыклап кайта. Әхмәров фикере кабул ителә, борынгы шәһәрнең кайда булуы хакындагы бәхәсләр дә шуның белән туктала. Соңга таба Казан профессоры В. Ф. Смолин да Суарга кечерәк сәяхәт кыла, шул тирә кешеләреннән бераз материал җыйный. 1933—1937 елларда А. П. Смирнов биредә казу эшләре алып бара.

Экспедициянең нәтиҗәләре монголларга кадәрге чор болгар тарихы өчен гаҗәп тә кызыклы була. Археологлар көтелмәгән зур уңышка ирешәләр, шәһәрнең нәкъ уртасында кирпеч сарай калдыгы табалар. Ике катлы итеп салынган бу сарай үзәк җылыту системасы белән җылытылган булган. Бинаның алгы ягында ярым терәкләр (колонналар) белән бизәлгән портал эшләнгән, янында манарасы булган. Бик яхшы яндырылган кирпечләрдән өелгән стеналар штукатурланып, зәңгәр төскә буялганнар. Йортны тирәли койма әйләндереп алган, койманың калынлыгы 70 см, ул да яндырылган кирпечтән өелгән. Ишек алды ярым яндырылган кирпечләрдән түшәлгән, өсте цемент белән катырылган. Сарай X—XI йөзләрдә салынып, монголлар һөҗүме вакытында җимерелгән, ләкин яңадан торгызылган һәм XIV гасыр азагында шәһәр белән бергә бөтенләй яшәүдән туктаган. Димәк, бина — монголларга кадәрге дәвернең дә, Алтын Урда заманының да истәлеге. Шуңа күрә анда ике чорның да архитектура стиле чагылыш тапкан. Ике чорда да квадрат формада, яхшы яндырылган кызыл кирпечләр булган, тик аларның үлчәмнәре генә төрлечә. (Башта алар 28×28×6 см яки 30×30×5 см зурлыкта булып, Алтын Урда чорында кечерәк итеп эшләнгәннәр, мәсәлән, 24×24×5, 23×23×5, 22×22×5 см).

Әлеге сарайдан башка гадирәк йортлар да казыла. Суар халкы бурап эшләнгән агач өйләрдә торган. Шулай ук чыбыктан үрелеп, эченә чүп тутырылган һәм ике ягы да балчык белән сыланган, тигез түбәле, агач идәнле йортлар да булган. Археологлар төрле зурлыктагы 90 лап чокыр табалар. Яннары һәм төпләре имән агачтан түшәлгән бу базларда болгарлар ашлык саклаганнар.

1962 һәм 1964 елларда мин Суар урнашкан Утка елгасы, күрше Майна һәм Раткуль елгалары буендагы болгар истәлекләрен өйрәнеп чыктым. Суар тирәсендә 30 дан артык авыллык һәм 3 шәһәрлек табылды. Беррәттән шунда тирә-яктагы татар авылларында Суар турында риваять-мазар сакланмадымы икән дип тә кызыксындым. Инде әйткәнемчә, Суарның әйләнәсендә руслар яшиләр, ә менә аннан 10—15 чакрым ераклыкта болгар чорыннан ук калган татар авыллары бар, мәсәлән, Иске Рәҗәп, Йорт Күл авыллары. Бу авылларда Суарның даны зур. Картлар аны Шәм Суар дип йөртәләр, элек бик матур, мәһабәт шәһәр булган, тик Батый хан харап иткән үзен дип сөйлиләр. «Шәм» эпитетының нәрсәдән алынганлыгын төгәл әйтү кыен. Күренекле эпиграфист, этнограф һәм археолог мәрхүм Һарун ага Йосыпов миңа бу сүзне гүзәллек, яктылык символы булуы мөмкин дигән иде. Шулайдыр. Шәмс гарәпчә кояш дигән сүз бит. Шул сүздән булса кирәк, шәмсә, ягъни орнамент сүзе дә ясалган. Кама аръягында Шәмсуаров фамилияле татарлар да очрый әле. Кыскасы, халкыбызның бүген дә үзенең борынгы шәһәрен олылап телгә алуы матур бер күренештер.

**ГАРИФ АХУНОВ. Дусларым янында. Повесть, хикәяләр һәм очерклар. 1969.**

Гариф Ахунов үзенең яңа җыентыгын «Дусларым янында» дип атаган. Чыннан да бу җыентыктагы «Яшьлек яме» повестен, андагы хикәяләрне һәм очеркларны укыганда, авторны үз геройлары, аның инде якын дуслары булып әверелгән кешеләр арасында итеп тоясың. Язучы аларның һәркайсының характерын, гореф-гадәтләрен, нинди уйлар, нинди кичерешләр белән яшәүләрен яхшы белә, аларның һәркайсына карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә, хөкемен чыгара. «Яшьлек яме» повестенда ул безне Таһир һәм Гөлнур, Мостафа һәм Дилбәр кебек шат күңелле, тормыш сөючән студент яшьләр белән таныштыра. «Хазбулатның яңа гадәтләре» хикәясендә исә кайчандыр лирик герой белән бергә ВУЗда укыган колхоз председателе Сиражиев белән дуслаштыра. Ә инде «Күлләр» очеркында безне ул Арча районының Сикертән һәм Казаклар авылы балыкчылары янына алып бара.

Гариф Ахуновның дуслары барлык яклары да килгән, кем әйтмешли, коеп куйган идеал геройлар түгел. Алар көндәлек тормышларында, эшләрендә еш кына ялгышалар, сөртенәләр. Әмма аларга үз-үзләренең көчләренә ышану, һәртөрле кыенлыкларны, ялгышлыкларны җиңеп чыгарга омтылу хас. Икенче сүзләр белән әйткәндә, язучы һәрбер героен хәрәкәттә, үсештә бирә. Гариф Ахунов тормышыбызның алга барышына тоткарлык ясый торган кимчелекләрне дә читләтеп үтми. Моңы бигрәк тә аның очеркларында ачык тоярга мөмкин. Бу яктан караганда «Мал куучы Мәһди», «Яңа хуҗа», «Авыл түбәсен яба» һәм югарыда телгә алынган «Күлләр» очерклары аеруча игътибарга лаеклы. Аларда автор хуҗалыктагы теге яки бу кимчелекләрне санап үтү белән генә чикләнми, ул кимчелекләрдән тизрәк арынуга ярдәм итәрдәй матур-матур тәкъдимнәр дә әйтә. Ул очеркларның хикәягә тартым булуларын һәм мавыктыргыч итеп язылуларын күргәч, әдипнең бу жанрда тагын да активрак эшләвен телисе килә.

«Дусларым янында» җыентыгындагы әсәрләр белән танышып чыккан укучы үзенә яңа дуслар тәкъдим иткән өчен язучыга рәхмәттән башка сүз әйтмәячәк.

**ЭДУАРД КАСЫЙМОВ. Бир кулыңны, дустым. Повесть һәм хикәяләр. 1969.**

Эдуард Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» повесте әдәбият сөючеләрдә төрле фикерләр, төрле бәхәсләр уятты. Ләкин ничек кенә булмасын, укучылар бу әсәрне нигездә җылы каршыладылар. Язучының повесть һәм хикәяләре тупланып чыгарылган яңа җыентыгы әнә шул әсәр белән ачыла. Анда укучы әлеге повестьтан тыш тагын «Көмеш язулы кылыч» повесте, «Мүкләнгән таш», «Күңел кошы», «Этиләр», «Дөньяда ни иң ямьле?», «Өчтән берәү», «Саумы, тургай», «Аның рәсеме» хикәяләре һәм китапның ахырына урнаштырылган юмористик парчалар белән танышачак.

Язучының бу җыентыгына кергән барлык әсәрләре дә диярлек безнең яшьләребезнең мораль сафлыгын, ил һәм халык алдындагы бурычын үтәгәндәге фидакарьлеген, өлкәннәр ышанып тапшырган эстафетаны лаеклы дәвам итүләрен тасвирлауга багышланган. «Көмеш язулы кылыч» повестен укыганда безне гражданнар сугышы елларында тиңсез батырлыклар күрсәткән һәм соңыннан тыныч хезмәт фронтында алгы сызыкта атлаган Гыйлаҗетдинның гадилеге, эш сөючәнлеге, кешелеклелеге сокландыра. Дустының үле гәүдәсен дошманга бирмәс өчен Гыйлаҗ-күзәтче үзе козгыннар тырнагына эләгә. Аны озак вакытлар җәфалыйлар, арка тиресе суелып, телгәләнеп чыкканчы камчы белән суктыралар, өстенә менеп таптыйлар, күкрәк тиресен тунап, йолдыз уялар. Ләкин ул дәшми. «Ахырда ярсуларыннан тәмам шашкан алтын погонлы җәлладлар кан эчендә аңын җуеп ятучы кызыл сугышчының эндәшмәс телен кисеп ук алалар...»

Тыныч хезмәттә кайнап байтак еллар уза. Мең тугыз йөз кырык беренче елның чәчәкләр исе аңкып торган июнь таңында кинәт дәһшәтле сугыш башланып китә. Иргетләр һәр тарафтан изге яу кырына кузгалалар. Гыйлаҗлар гомер кичергән авылдан да бик күбәүләр көнбатышка карап юл ала. Менә шунда өстенә күн тужурка, зәңгәр галифе, аякларына күн итек һәм башына кызыл йолдызлы шлем кигән Гыйлаҗ китүчеләрнең беренче төркемен вакытында озатып җибәрү ягын кайгыртып йөрүче авыл советы председателе Сәетгәрәй янына килеп баса. Бер мизгелдән ул калын күкрәк тавышы белән үзенчә нәрсәдер әйтеп, киту-

челәргә ишарә ясый һәм батырлыгы өчен кайчандыр үзенә бүләк ителгән көмеш язулы кылычны җәһәт бер хәрәкәт белән кынынан тартып чыгарып, сугышка китүче егетләрнең берсенә суза.

Ил-җирнең иминлеген саклау өчен кулларына корал алган ир-егетләр революция ветераннарының ышанычына тап төшермиләр, сугышта да, аннан соңгы елларда да үз антларына тугрылыклы булып калалар; көрәшәләр, җиңәләр, килачәк буыннар хөрмәт белән искә алырлык итеп яшиләр. Җыентыктагы хикәяләрнең күбесендә әнә шуларның һәм аларның улларының-кызларының тормышы, иҗади хезмәте, бер-берләренә карата булган мөнәсәбәтләре сурәтләнә. Бу хикәяләрнең отышлы ягы тагын шунда: алар гади сюжетка корылганнар, ялыкмыйча укырлык итеп кыска һәм җыйнак язылганнар.

Шулай да китапны укып чыкканнан соң күңелдә бер канәгатьсезлек туа. Ул да булса, җыентыкның башында яки ахырында язучының тормыш һәм иҗат юлы турында аңлатма сүз бирелмәве. Язучының әсәрләрен яратып кабул иткән укучы аның үзе турында да, иҗаты турында да күбрәк белергә тели. Укучының бу урынлы таләбе киләчәктә Татарстан китап нәшриятына да ишетелсен иде.

**ХӨСНИ КӘРИМ. Ике дус. Шигырьләр, хикәяләр, очерклар. 1969.**

«Ике дус» китабының беренче битен ачу белән безнең карашыбыз яшь чырайлы, мөлаем йөзле бер кешенең рәсеменә текәлә. Бу — революциягә кадәр үк һәм аннан соңгы елларда күп кенә шигырьләр, хикәяләр һәм очерклар иҗат иткән язучы Хөсни Кәрим. Аның әнә шул әсәрләре бергә тупланып, күптән түгел Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыкты. Ул җыентыкка кергән әсәрләрдә иске тормыш күренешләре, байларның-сәүдәгәрләрнең комсызлыгы, ярлыларның җәбер-золым астында яшәүләре гәүдәләнә. «Ике дус» хикәясендәге сәүдәгәр Тимерша, «Ак песи» хикәясендәге персонажлардан байлык өчен җанын сатарга әзер торган Фәхретдин, «Ертылган приказ»дагы Бәдри мулла һәм башка шундый образлар укучы күңелендә бу типларга карата тирән нәфрәт хисе уята. Бу хикәяләрдә язучының үзе яшәгән чордагы вакыйгаларны, шул вакыйгалар эчендә кайнаган кешеләрне яхшы белүен, иҗатында шуларга таянып эш итүен тоясың.

Җыентыкка кергән очерклар арасында «Исемдә калганнардан» һәм «Нәриман ага Нәриманов турында истәлекләрем» дип аталганнары аеруча игътибарга лаеклы. Аларда автор татарның күренекле әдипләре Сәгыйт Рәмиев, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәһит Әхмәдиев, башкорт революционеры Шәһит Ходайбердин, Кавказдан Астраханьга сөргенгә җибәрелгән әзербайҗан революционерлары Нәриман Нәриманов белән очрашулары турында яза.

Китапның «Хикәяләр һәм очерклар» бүлегенә урнаштырылган «Станоклар докторы» һәм «Ачлар шатлыгы» язмалары да зур кызыксыну белән укыла. Хөсни Кәрим үзенең чәчмә әсәрләрендә дә, шигырьләрендәге кебек үк, тел өстендә эшләүгә, фикерне образлар, картиналар аша чагылдыруга зур әһәмият бирә. Шуңа күрә дә аның шигырьләре дә, хикәя-очерклары да бик җиңел укыла.

Зәйнәп ханым Кәримова төзегән бу китапка сүз башын И. Гыйльфанов язган. Ул укучыны Хөсни Кәримнең тормыш һәм иҗат юлы белән шактый киң таныштыра.

**ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВ. Сайланма әсәрләр. 1969.**

> **Иң кадерле — әнием,**
> **Әнием тиң — илем!**

Балаларның яраткан язучысы Җәвад Тәрҗемановның «Кызлар һәм малайлар» дип аталган җыентыгына әнә шушы шигъри юллар эпиграф итеп алынган. Китапның нәкъ әнә шундый җыйнак һәм тирән мәгънәле сүзләр белән ачылып китүенә без һич тә очраклы нәрсә итеп карамас идек. Бу язучының иҗаты дөрестән дә һәркайсыбызның иң якын кешесе булган, һәркайсыбызга тормыш бүләк иткән анага тиң туган илгә мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Җәвад Тәрҗеманов үзенең шигырь һәм җырларында булсын, әкият һәм хикәяләрендә булсын балаларда туган җиргә карата иң мөкатдәс хис — аны ярату, кадерләү һәм хөрмәт итү, аңа ихлас күңелдән бирелгәнлек хисе тәрбияли.

> **Йолдызлар арасында без**
> **Матур җырлар көйлибез:**
> **— Һаман үсә, күтәрелә**
> **Гөл бакчасы — Илебез, —**

ди автор «Илебез — гөл бакчасы» җырында. Моннан 34 ел элек язылган булуына да карамастан, бу җыр әле һаман да үз көчендә кала.

Җыентыктагы шигырьләр тематик яктан өч циклга — «Кояшлы иртә», «Бердәм семья» һәм «Мәктәпкә» дигән циклларга бүленгән. Югарыда телгә алынган җыр белән без «Мәктәпкә» циклында очрашабыз. Әлеге циклларга тупланган шигырь һәм җырларын автор укучыларга «Ачкыч һәм баскыч» дигән бүлеккә берләштереп тәкъдим итә. Әмма бу бүлек язучының кайчандыр шул исемдә басылып чыккан китабына кергән шигырьләрне эченә алу белән генә чикләнми. Автор аны соңгы елларда иҗат иткән яңа шигъри әсәрләре белән дә тулыландырган.

**Китапның** икенче бүлеген язучының әкият һәм хикәяләре тәшкил итә. «Алтын бабай» хикәясе белән башланып киткән бу бүлеккә язучының төрле елларда һәм төрле темаларга язылган унҗиде хикәясе һәм әкияте урнаштырылган. Аларда балаларның эчке дөньялары теге яки бу вакыйганы, күренешне күз алдына китереп бастыра алырлык конкрет образлар һәм детальләр аша ачыла. Менә шуңа күрә дә «Әни сүзе» хикәясендәге Назыйм һәм Алсу,

«Гөлшат газетасы»ндагы Гөлшат, «Чыршы бәйрәме»ндәге Фәрит кебек малайларны һәм кызларны балалар үз араларында итеп тоялар. Вакыйганы балаларның үз исеменнән сөйләтү — Җәвад Тәрҗемановның яраткан алымы. Бу алым аңа әсәрдәге кечкенә геройларның уй һәм кичерешләрен кинрәк ачарга, аларның әйләнә-тирәдәге пәрсәләргә карата булган мөнәсәбәтләрен тулырак сурәтләргә мөмкинлек бирә. Әнә шул яктан караганда, җыентыктагы уңышлы хикәяләр рәтенә «Алтын бабай» һәм «Иөткерткеч» хикәяләрен кертергә мөмкин.

Соңгы елларда балалар өчен әкиятләр иҗат итүче язучыларыбызның иң активы— Җәвад Тәрҗеманов дисәк, һич тә ялгышмабыз. Аның күпчелек әкиятләре шигъри проза стилендә языла. Ә андый әкиятләрне кечкенәләр бик җиңел укыйлар һәм тиз истә калдыралар. Язучының «Койрык турында боерык», «Инеш буенда — сабан туенда», «Күбәләк-җилбәзәк» һ. б. әкиятләре балаларның яратып укый торган әсәрләре булып әверелделәр.

Мәктәп сәхнәләре өчен пьесалар язучы әдипләр бездә бик аз. Җәвад Тәрҗеманов бу өлкәдә дә уңышлы гына эшләп килә. Укучы аның «Без театр уйныйбыз», «Судан табылган хат», «Мәктәбем, туган мәктәбем минем», «Кыш бабайга безнең бүләк», «Шуктуган» «Концерт дәвам итә» һәм «Менә сиңа табышмак» исемле пьесаларын «Сайланмалар»ның «Без театр уйныйбыз» дигән бүлегендә таба ала. Китапның ахырында язучының үз иҗаты турындагы балачак истәлекләре һәм аның кыскача тормыш юлын чагылдырган белешмә урнаштырылган.

Филология фәннәре кандидаты Нур Гыйззәтуллинның җыентыкка язган сүз башында әйтелгәнчә, Җәвад Тәрҗемановның «Кызлар һәм малайлар» китабын безнең кечкенә дусларыбыз яратып укыр, шулай ук ул балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр, башлангыч мәктәп укытучылары өчен дә һәм, гомумән, безнең күпчелек укучыларыбез өчен кызыклы да файдалы да булыр дип, һич шикләнмичә әйтергә мөмкин.

**ИСЛАМ БЕЛЯЕВ. Кояш законы. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1969.**

Ислам Беляев — нигездә лирик шигырьләр язучы автор. Аның күпчелек шигырьләрендә туган җирен, туган ягын, дусларын һәм якыннарын ихлас яратып яшәүче кешеләрнең күңел җылылыгын, хис һәм кичерешләрен тоясың. Ул шигырьләр күтәренке рухлы да, шул ук вакытта бераз моңсу да булалар. Күптән түгел аның «Кояш законы» дип исемләнгән яңа җыентыгы басылып чыкты. Күләме белән әллә ни зур булмаган бу китапка утызга якын шигырь тупланган. Шулар арасындагы «Менеп бассам Лобач үренә», «Туган җирдә», «Малайларның күргән төшләре», «Эрләү», «Әткәм йорты», «Җир өннәре» дигән шигырьләрне укыганда, син инде лирик геройдан, аның хисләреннән аерыла алмыйсың. Ул синең күңелеңә иң якын дусың булып кереп кала.

> **Җырлап печән чапкан җырларемнән**
> **Иөзеп бара минем җилкәнем;**

Яисә:

> **Ил турында, туган җир турында**
> **Малайларның күргән төшләре, —**

кебек юлларны син бер укуда отып аласың һәм менә шундый юллардан торган әчкерсез шигырьләрнең күбрәк булуын телисең. Кызганычка каршы, «Кояш законы» җыентыгында «Бул дегустатор кук», «Кара урман, кереп куеныңа», «Сандугач һәм этәч», «Көзге чебеш», «Кавказ — җырстан» шикелле йомшак шигырь һәм мәсәлләр дә юк түгел. «Тозак» әкияте дә күңелдә әллә ни матур хисләр уятмый. Ислам Беляевның вакыты-вакыты белән шигыренең техник эшләнешенә тиешенчә игътибар биреп җитмәве күзгә ташлана. Моны раслар өчен бу җыентыкка кергән шигырьләрдә «Читеннәнәнкәмнән», «Юлларым-калганын», «ясаткан-улактан», «җитәрлек-әнә бит»кә охшашлы рифмаларның шактый күп булуын әйтеп китү дә җитә. Бу кимчелекләр бәлки Исламның аз язуы, поэзия өлкәсендә даими эшләмәве белән аңлатыла торгандыр. Шуңа күрә киләчәктә аның активрак эшләвен күрәсе килә.

# *ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...*

**Сафа Сабиров**

# СИХЕР ЗӘХМӘТЕ

хикәя



Егет булып буйга житкәч, өйләнә торган йола бар бит. Менә көннәрдән бер көнне мин дә өйләндем...

Өйләнгәч, билгеле инде, балабыз да булды, һәм ул безнең башка дөнья кадәр мәшәкать алып килде.

Мәшәкатьнең иң кыены — бала караучы эзләү булды. Мин үзем бу эшкә бик җиңел генә караган идем. Әмма эзли башлагач, тәмам гаҗизлеккә төштем. Икебезгә дә ошаганын табу, кәләш эзләүдән дә кыенрак икән.

Чынлап әгәр, менә үзегез уйлап карагыз. Берсе карчык, аның үзен карарга кеше кирәк. Икенчесе бик яшь, әле үзенә акыл кереп җитмәгән, аңа ничек баланы ышанып калдырасың? Өченчесе яшь тә түгел, карт та түгел, холкы-фигыле дә ярыйсы гына кебек. Миңа болай бик кулай тоелды, әмма хатын ничектер якын да җибәрми. Мөгаен, чибәрлегеннән курыкты булса кирәк...

Шулай да, эзли торгач, ниһаять, таптык. Хатынның туган-үскән авылыннан Сәрвәр исемле бер яшүсмер кыз китерттек. Башта безгә булышыр, аннары, бала тәпи йөри башлагач, үзен берәр җиргә эшкә урнаштырырбыз дидек.

Болай үзе акыллы һәм эшкә уңган кыз икән. Калын итеп үрелгән кара толымнары биленә хәтле салынып төшкән. Баланы да әйбәт кенә карый. Бер өйрәткәч, эштән кайтуыбызга өйне дә җыештырган була, ашын-суын да пешереп куя. Безнең кебек эш кешесенә анысы да кирәк бит.

Әмма кызның бер уңайсыз гадәте бар — төнлә йоклаган чакта борыны сызгыра торган булып чыкты бу.

Хәер, әнисе моны үзе дә яшермәгән иде. Кызын безгә китерә килгәч тә, барысын да сөйләп бирде:

— Кызым сокланып туйгысыз иде. Кайсыдыр бер алла каһәрләгәне сихерләп харап итте, шуннан сызгыра торган булып калды,— дип бик тә өзгәләнеп зарланган иде.

Ул чакны без кечкенә-кечкенә ике бүлмәле квартирада тора идек.

Кече якта бала белән хатын йоклый. Алгы бүлмәдә бер стена буенда мин, каршы якта зур сандык өстендә Сәрвәр ята.

Әмма төнлә сызгыру дигәнең бик тә бимазалы нәрсә икән ул. Эштән арып кайтып яткач, рәхәтләнеп йокыга китәм дигәндә генә Сәрвәрнең борыны сызгырырга тотына. Курай дисәң курай түгел, ниндидер сәер тавыш белән сузып-сузып сызгыра, үзенә бер көе дә бар сыман. Мин аны кайдандыр концерт бирәләр дип торам, хәтта радионы да борып куйдым... Бактың исә мескен Сәрвәр сызгырып ята икән.

Башта мин моңа игътибар итмәскә тырышып карадым. Аннары, түзәр хәл калмагач, колакка мамык тыгып ята торган булдым. Инде алай да котыла алмагач, башны мендәр астына тыгам, баштанаяк калын юрган белән капланам... Юк, барыбер яман ишетелә, һич тә йоклар әмәл юк.

Бездән ерак түгел күршедә генә ара-тирә им-том белән шөгыльләнүче Шәрифулла исемле бер карт бар иде. Тукта, мин әйтәм, күршекүлән аңар тикмәгә генә йөрмидер дим. Бер бушрак арада мин дә моңар барып чыктым. Һәм үземнең зарымны сөйләдем. Итагатьле карт икәнлеге әллә кайдан күренеп тора, сүземне бер дә бүлдермичә игътибар белән тыңлады һәм шырпы тартмасына салып көл сыман бер нәрсә дә өшкереп бирде.

— Монысын ул йоклагач, башына — чәч арасына сибәрсез,— ди.— Аннары изгеләргә атап садака адарыныгыз, теләкләрегез аллага тизрәк ирешер,— ди бу.

Үзем болай барсын да нәкъ ул әйткәнчә эшләгән кебек идем: көлен дә сиптем, садакасен дә адарындым. Әмма, ни гөнаһ шомлыгыдыр, Сәрвәргә шифасы булмады. Кызыбыз әүвәлгечә һаман сызгыра да сызгыра.

Аптырагач, көннәрдән бер көнне урынымнан тордым да:

— Сызгырма,— дип, мин моның иңбашына төртеп алдым.

Сәрвәр бер мәлгә тукталып торды да, мин йокыга китеп барганда гына тиздән тагын сызгыра башлады. Мин янә барып кызның иңбашыннан селкеп уяттым. Ләкин ул бераздан тагын башлап җибәрде, һәм мин төн буе ике арада ары-бире йөреп тәмам хәлдән таеп беттем.

Шулай да иртәгесен тагын төн буе ике арада йөреп азапланмас өчен үземчә бер әмәлен таптым шикелле: һич тә көтмәгәндә хатынның бала чүпрәкләрен элеп киптерә торган тасмасы күземә чалынды да башыма кылт итеп бер уй килде. Озын-озак уйлап тормадым, йокларга ятар алдыннан, шул тасманы алып бер очын кызның толымына, икенче очын үземнең карават башына бәйләдем. Сәрвәр сызгыра башлауга, юрган астыннан кулны чыгарып тасманы тартуым була, кызым шундук туктый да кала...

Ләкин тасманың көче озакка бармады. Сәрвәребез моңа да бик тиз күнекте, күрәсең, акрын гына тартканга уянмый башлады бу. Ниһаять, ачуым кузгалып, янә катырак тартып җибәргән идем, мескен кызый сандык өстеннән идәнгә дөп итеп егылды да төште. Хәтта үземә дә бик уңайсыз булып китте...

Иртән мин соң уяндым. Төнлә рәтләп йокламаудан булса кирәк, кәеф шәп түгел, баш та авырта. Ишетәм: күрше бүлмәдә Сәрвәр сеңелкәй минем хатынга нидер зарлана.

— Түзәр хәлем калмады, авылга кайтып китәм,— ди бу.— Җизни әллә сихерләп маташа инде, чәчемә көл сибеп башымны чүпләп бетерде. Хәзер инде бөтенләй үк бәйләнә, төннең төне буе йоклатмыйча газаплый...

Йоклаган булып сиздерми генә тыңлап ятам. Ишетәм, бу сүзләрдән хәтта хатынның тавышы калтырый башлады... Алай да шундук кабынып китмәде, шомлы әкрен тавыш белән кыздан сораштыруын дәвам итте: ничек бәйләнә, ниләр әйтә, янәсе...

Һәм Сәрвәр үз белгәнен берсен дә яшермичә, тасма белән чәч толымын тартуымны да, сандык өстеннән егылып төшүен дә — барысын да сөйләп бирде. Тик шуннан соң гына хатынның эченә җылы керде бугай. Ул, тыела алмыйча, кинәт үзеннән-үзе кычкырып көлеп җибәрде.

Күпмедер вакыт үткәннән соң, без Сәрвәрне докторга алып барып күрсәттек. Доктор кызның борынында ниндидер полип барлыгын һәм аны кистерергә кирәклеген әйтте.

Һәм, ни дисез, ләгънәт төшкән полип дигән нәрсәне кистерткәч, кызыбыз йоклаганда сызгырудан туктады да калды. Аңа әнә шул полип дигән чуан комачаулаган икән... Ә мин юләр, кеше сүзенә ышанып, әллә нинди хафаларга батып беттем...

# ЯМАН ТӨЕР

ХИКӘЯ

Инде бик күптән, әле мин тугыз яшьлек малай вакытта ук булган хәл бу.

Без ул чакта Бишбалта бистәсенең Бакалтайга караган арткы урамында җиргә яртылай иңеп кергән бәләкәй генә бер өйдә тора идек. Әле дә исемдә, әни пристаньга эшкә төшкән саен, син олы малай дип, өйне дә, энекәшем Миңнеханны да миңа ышанып калдыра иде.

— Зинһар, Миңнеханның үзен генә урамга чыгара күрмә, ат таптап харап итмәсен,— дип кабат-кабат кисәтеп китә торган иде.

Ә ул юньсез малайга урам җене кагылган кебек, ике күзе һаман тәрәзәдә генә. Урам чатыннан җигүле ат күрендеме, бар дөньясын онытып чыга да чаба.

Бу юлы да шулай булды. Мин өйалдында идән себереп маташа идем. Урамда арба дөбердәгән тавыш ишетелүгә, Миңнеханым, койрыгына ут капкандай, атылып чыгып та китте.

Дөресен әйтергә кирәк, сүз тыңламыйча ачуны бик китергән чакларында мин аңа эләктереп тә алгалый идем. Хәзер дә шундый уй туды. Тукта, мин әйтәм, бик узынды бу малай, аркасын кашып алмыйча булмас ахры, дим.

Шулай ачуым кабарып артыннан йөгереп чыксам, ни күзем белән күрим, озын арбага юан-юан бүрәнә төягән бер абзый атын көч-хәл белән тыеп, тау түбән төшеп бара, ә минем энем — кай арада менеп өлгергән диген — бүрәнә өстенә атланган да рәхәтләнеп барамы бара,— авызы колагына җиткән... Үзенең өстендә күлмәге дә юк, кыска ыштаннан гына. Кәләпүше баш очында чак кына эләгеп тора.

Шул чак көтмәгәндә ат читкә тарттымы, яки йөк үзе бераз авышып киттеме, анысын мин күрми дә калдым. Миңнеханның кәләпүше бер якка очып китте, үзе икенче якка мәтәлеп төште һәм арбаның арткы көпчәге аны таптап та үтте...

Мин йөгереп килеп җиткәндә энекәшем җирдә тын да алмыйча ята, сул боты тездән югарырак янчелеп калган иде.

Шул арада, атын туктатып, олаучы абзый да йөгереп килеп җитте. Ул Миңнеханны биләгенә салып өйгә керткән вакытта энемнең тапталган боты сынган турыдан бөгелеп тора иде.

Ярый әле, ул олаучы абзый әйбәт кеше булып чыкты. Миңнеханны өйгә кертеп салгач, үзе барып врач чакыртты, кибеттән күчтәнәчләр алып кайтты.

Ниндидер эпидемия вакыты булды бугай, Миңнеханны больницага алып китмәделәр. Яхшылап караганнан соң, врач аның аягын гипслап куйды, дару бирде һәм чыгып китәр алдыннан әйтте:

— Һич кыймылдамыйча ятсын...— диде.— Көненә өч мәртәбә менә шушы даруны эчерегез... Бик чәрдәкләнгән булса да, яшь сөяк, бер ай ярымнан ялганырга тиеш...

Бу кайгылы хәбәрне әни пристаньда ук ишеткән булган һәм бик хафага төшкән. Эштән кайтышлый ул үзе белән бер карчык алып килде.

Тәбәнәк буйлы, әмма үзеннән озын таякка таянып йөрүче бу әбине мин моңарчы күреп кенә белә идем, очрашкан вакытта да мин аның күзенә чалынмаска тырыша торган идем. Бу юлы да почмакка кереп постым да күзәтә башладым. Ә ул әни китереп куйган мендәр өстенә утырды да башындагы чәчәкле шәлъяулыгын ике якка ачып җибәрде, авыз эченнән пышылдап бик озак дога кылды. Аннары кул сырты белән Миңнеханның башына, гипслы аягына кагылды, як-ягына төкереп алды һәм иң азактан:

— Инде моннан соң алла үзе ярдәм итәр, төзәлер,— диде.— Тегени, бакыр табарга кирәк. Шуны ашатсаң, сөяк тиз тоташа... Олы урамдагы чулак Сәйфинең кулын да былтыр мин шулай дәвалаган идем.

Әни кайдан бакыр табарга икән соң, бер дә белмим бит әле дип аптырап калды. Әмма әбинең күзе үткен икән. Кашыклар арасында эленеп торган зур чүмечне күреп алды.

— Килен, кара әле, теге сары чүмечегез бакыр түгелме соң? Кая әле карыйм.

Әни аңа чүмечне китереп бирде.

— Һи, нинди авыр — саф бакыр ич бу... — диде әби.— Шуны ашатырга кирәк. Пычак белән кырыгыз да икмәккә сибеп бирегез...

Һәм без Миңнеханны шулай дәвалый башладык. Әни эшкә киткәч, бар мәшәкать миңа төшә. Башта энекәшкә врач кушкан даруны эчерәм. Аннары өстәлгә чиста ашъяулык җаям дә кайчандыр Мәкәрҗәдән әти алып кайткан бакыр чүмеч сабын пычак белән кырырга тотынам.

Мин бар көчемә тырышам, кыра-кыра тирләп чыгам, кулларым авыртып бетә. Гел урында ятып мескен Миңнехан да тәмам ялыкты. Тизрәк савыгырга тели: чыраен сытып булса да, кырылган бакырны икмәккә сибеп тә, шикәр комы кебек манып та ашый. Бер атна эчендә энекәшем бөтен чүмеч сабын ашап бетерә язды.

Хәер, ашавы бушка китмәде. Ай ярым чамасы вакыт үтмәгәндер, аягын гипстан алдылар. Тиздән саклык белән генә өйдә йөри башлады, аннары бөтенләй савыкты һәм безнең башка төшкән бу бәла озакламый бөтенләй үтеп китте.

Ләкин шуннан соң күп тә үтмәде, Миңнеханның эче авырта башлады. Болай бик каты өздереп авыртмаса да, борчый, күрәсең, энекәш әледән-әле кәефсезләнә торган булып китте. Аптырагач, берничә мәртәбә теге әбидән өшкертеп тә карадык. Корсагында яман төер бар ди, әби. Батырыбрак капшап караганда кулга да сизелә, эченә җен оялаган булса кирәк ди... Шулай да моның нидән икәнлеген, ничек дәваларга кирәклеген ул да тәгаен генә әйтеп бирә алмады.

Ә Миңнеханның хәле көннән-көн кыенлаша барды бит. Тиздән, бөтенләй түшәк кастасы булгач, без аны больницага илтеп салдык. Анда аны рентгенга күрсәткәннәр, тикшергәннәр. Ахыр чиктә, берничек тә барып чыкмагач, энекәшкә операция ясарга булдылар.

Бу эшкә әни дә каршы килмәде. Теге әбигә садака адарынды да операция ясарга ризалык бирде.

Берничә көннән Миңнеханга операция ясадылар. Эчен ярып карасалар, энекәшнең ашказанынннан тавык йомыркасы хәтле таш кебек каты төер табып алганнар. Операция тәмам булганнан соң, шул төерне ватып карагач, врачлар, бу хәлне башларына сыйдыра алмыйча, бик аптырап торганнар. Минем энекәшне харап итә язган теге хәтәр төер ашказа[illegible]кан... бакыр булып чыккан...

Радик Фәизов

# КЫБЫРСЫК ҺАБИЛ



Ул жыйнак, җиңел гәүдәле кеше. Ул игенче, балта остасы, мич чыгара, киез итек баса, кирәк икән хәтта чабата үрә белә. Ул тракторчы, комбайнчы, шофер. Ул минем яшьтәшем. Без дөньяга утызынчы еллар башында килгәнбез.

Хәтерлисездер, үткән сугышның бомбалары, чын мәгънәсе белән, безнең авыллар өстенә дә төште. Күпме йортлар, каралтылар урынында чокырлар, җимерек моржалар гына торып калды. Чәчәк атып утырган күпме бакчалар юкка чыкты.

Әнә шундый бер чокыр өстенә авылдагы беренче яңа йортны минем кордаш Һабил салды. Көндез басуда эшләде ул, ә кичен кулына балта алды.

— Вакыт җитми, акча җитми. Үләм...— дип зарланды ул. Әмма йортның кәттәсен салып куйды.

— Тәүлек кыска, елы кыска. Мине кырыкка бүләләр,— дип сөйләнде ул. Һәм язын тракторда, көзен комбайнда эшләде. Кышка керсә, кулына балта, сәнәк, көрәк алды.— Начар эшлибез, начар яшибез,— дип көенде һәм өенә терәп зур кухня салып куйды.

— Культурадан артта калдык,— дип пошынды ул. Авылда салына башлаган яңа клуб бүрәнәсенә беренче булып балта чапты. Өенә пар кертте, түргә зур радиоалгыч алып куйды.

— Бар белгәнебез токмач, эшмени бу! — дип тавыш күтәрде ул җыелышта. Тракторы белән канаулар казып, болындагы сазлыкны киптерде. Агайлар белән бәхәскә кереп, сазлык өстендә йодрык кадәр помидорлар, берәр потлы кәбестәләр, шалкан кадәрле суганнар үстерде. Кишерләрен тагын үз өе янында казынды. Бөтен авылга дан итеп, менә дигән җиләк-җимеш бакчасы үстерде.

Ә үзе һаман да зарланды.

Әле беркөн тагын дөньяның тетмәсен тетә. Үзен-үзе яман тирги.

— Бер дә яши белмибез без дөньяда,— ди.— Ярлы кешенең акчасын яман товар бетерә дигәндәй, моннан ике ай элек кенә телевизор алган булган идем. Бүген кибеткә керсәм, галәмәт яхшысы, зуры кайткан. Экранына минем телевизор әрҗәсе-ние белән кереп утыра алырлык! Бәяләрендә дә аерма чыпчык борыны кадәр. Кара инде син бу ахмакны, бу сабырсызны,— ди.— Ачудан бер кочак китап алдым,— ди.

Күр дә тор, колхозга май заводы, консерва заводы, культура паркы кирәк дип, иртәгә председательнең теңкәсенә тиячәк. Җиңел машинам юк, асфальт юллар юк, дип зарланыр. Тагын агайлар белән бәхәскә кереп, нәрсә өчен булса да ду кубып йөри башлар.

Холкы бик «начар» аның. Булганына шөкер итми торган, кыбырсык җанлы кеше ул минем яшьтәшем Һабил.

# СӘГЫЙТ РӘМИЕВ

Булмас артык олуг бәр эш
Илгә хезмәт итүдән.

*С. РӘМИЕВ.*

Шушы елның 24 февралендә татар әдәбиятының классигы Сәгыйт Рәмиевнең тууына 90 ел тулды.

Әтисенең төп кәсебе, урман эшләтүче байларга ялланып, сал агызу, агач белән сату итү булганлыктан, С. Рәмиевнең бала чагы төрле җирләрдә үтә. Булачак шагыйрь «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала һәм шунда укыта, Оренбургтагы революцион оешмалар белән аралашып, прокламацияләр таратуда катнаша.

С. Рәмиев иҗтимагый-политик көрәш мәйданына буржуаз-демократик хәрәкәтнең актив бер эшлеклесе сыйфатында килеп керә. 1906 ел башларында ул, яшерен типография өчен хәрефләр төяп, Казанга килә. Бирёдә «Таң йолдызы» газетасын чыгару эшенә катнашып китә. Газетаның 10 санынннан ул инде аның редакторлык вазифасын үз өстенә ала һәм «мөкатдәс вазифасы булган эшче сыйныфының интересын саклау юлында кулымнан килгән кадәр, чын күңелем илә хезмәт итәчәкмен» дигән декларация белән чыга. Самодержавие строен бәреп төшерергә чакырып, «бөтен халыкка җир һәм ирек» таләп итеп, ялкынлы мәкаләләр яза.

Иҗтимагый-политик эшчәнлеге белән аерылгысыз рәвештә аның шигъри таланты ачыла. Ул әлеге газетада үзенең беренче шигырьләрен, М. Горькийның «Кояш чыга да, бата да...» җырын, «Марсельеза», «Матәм маршы» һ. б. революцион җырларны, шигырьләрне зур осталык белән тәрҗемә итеп, кайсын тулысынча, кайсын өлешчә бастырып чыгара бара. Патша хөкүмәте С. Рәмиевне туктаусыз эзәрлекли, газета әледән-әле конфискацияләнә. Редактор С. Рәмиев берничә мәртәбә кулга алынып, төрмәләрдә утыра. Яңа архив материаллары күрсәткәнчә, 1907 ел башларында булган бер тентүдән соң, «дәүләт җинаятьчесе» сыйфатында жандарм идарәсенә чакырылгач, Казаннан китеп яшеренеп йөри. Казан губернаторы исә С. Рәмиев турында эчке эшләр министры Столыпинга язып торган.

Илдә кара реакция башлангач, С. Рәмиев революция чорында үзе катнашкан вакыйгаларның кайнар эзләренә кайтып, 1905 елда «Хөсәения» мәдрәсәсен ташлап чыгу вакыйгасы турында «Низамлы мәдрәсә», газетада эшләү вакытларын чагылдырып, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьесаларын иҗат итә. Бу әсәрләрдән искелеккә ялкынлы протест, бунтарь рух бөркелеп тора. «Яшә, Зөбәйдә...» 1908 елда басылып чыккач, карагруһларның көчле басымы астында, нәширләре тарафыннан җыеп алынып, утта яндырыла.

С. Рәмиевне атаклы шагыйрь итеп таныткан әсәре — «Таң вакыты». Бу шигырьне ул беренче мәртәбә 1908 елның 2 январенда әдәбият кичәсендә укый. Шагыйрь аллага ышануның татар халкын гасырлар буенча фанатизм йокысында биклэп тотуын тасвирлый һәм уянырга өнди, актив хәрәкәткә чакырып набат кага:

Бетмә надан, түг яңадан
Мәгърифәтле анадан!
Бул кеше, үзең тырыш, өмет итмә,
Хата ул өмет алладан!

С. Рәмиевнең бу чыгышы зур шау-шу кузгата. Шигырь иң элек рус матбугатында югары бәя ала, татар матбугатында исә аны беренче булып уңай яктан билгеләп үткән кеше Х. Ямашев була. Соңыннан Г. Ибраһимов бу әсәрне «татарның таң вакыты» дип атады. Шагыйрьнең «Таң вакыты», «Мин», «Син», «Ул» шигырьләре, кульязмасыннан тәрҗемә ителеп, беренче мәртәбә рус телендә басылалар.

Караңгы реакция чорында язылган «Мин» шигырендә С. Рәмиев дин, самодержавие һәм аның кануннарыннан мәсхәрәләп көлә:

«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,
Миңа бер зур көч керә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

«Мәҗит сүзе» әсәрендә күк тәхетен нигезенә хәтле ватып көл итәргә ярсып ташлана. Шагыйрь ни бар бәхете тартып алынган кешенең үзен чиксез югарылыкка күтәрә. Романтик буяуларда гади татар кызының күкләрне сәҗдәгә иңдерү генә түгел, хәтта алланың үзен гакылдан шаштырып кол итәрлек мәһабәт, гүзәл образын тудыра:

Күлмәсен! Күлсә бетерә, юк итә дөнья йөзен;
Күрмәсен! Күрсә күлүен, кол итәр алла үзен.
(«Җәмилә»).

Бу әсәрләрнең эчтәлегенә тирән демократизм хас. Ләкин шагыйрьнең көрәш методы ялгыз каһарманның бунты рәвешендә була. Яшәп килүче стройны, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне бунт белән генә җиңеп булмавын аңламады. Шуңа күрә, С. Рәмиев лирикасында пессимистик ноталар да яңгырап китте. Шул ук вакытта шагыйрь буржуаз җәмгыятьнең ялган морален, «кеше — кешегә бүре» законын кайнар нәфрәт белән ләгънәтләде, фаш итте:

Көләләр шулар, сөйләшәләр,
Гакыл, мәгънә юк сүз һәм эшендә,
Бозыклык, ялган, ачу күрәм
Хакыйкать, гыйффәт, мәхәббәт эчендә.
(«Минем төн»).

Әдип үзенең повесть һәм хикәяләрендә хезмәт ияләренең авыр язмышын, байларга карата ачу тойгыларын тасвирлый.

1910—1914 елларда, Астраханьда «Идел» газетасында эшләгәндә, С. Рәмиев Н. Нәриманов белән якыннан аралаша. Аның Н. Нәриманов, Х. Ямашев, Г. Тукай турындагы мәкаләләре бу эшлеклеләргә олы ихтирам һәм самими мәхәббәт белән сугарылган. Әдипнең мондый мәкаләләрен, газета битләрендә Н. Нәриманов мәкаләләрен, деспотизмга каршы юнәлтелгән тәрҗемә әсәрләрне бастыруы эзсез калмый. Патша хөкүмәте С. Рәмиев өстеннән яшерен күзәтү оештыра, «Идел» газетасын яба һәм шагыйрьне Астраханьнан сөрә.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында С. Рәмиев, большевик шагыйрь Д. Бедный, Некрасов, Щепкина-Куперник әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, ирекле тәрҗемә рәвешендә язылган «Сука белән Пушка», «Аналар», «Күлмәк җыры» шигырьләрен бастыра һәм шуның белән татар поэзиясендә беренче булып империалистик талау сугышына каршы агымны башлап җибәрә. С. Рәмиев шулай ук рус әдәбияты классикларыннан Гоголь, Тургенев, Лермонтов, Толстой, Горький иҗатын киң пропагандалый. Аның үз иҗаты белән М. Горький кызыксынган.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң С. Рәмиев Югары Урал, Чиләбе, Уфа шәһәрләрендә партия-совет органнарында эшли, «Кызыл Урал» һ. б. газеталарда язышa, «Саботаж» хикәясен, «Иблис тә дердерәде» дигән философик-атеистик әсәрен һ. б. бастыра, «Мәсихы хөррият» («Азатлык Христосы») дигән поэмасын яза, «Спартак» романын, Коммунистлар партиясе гимны «Интернационал»ны тәрҗемә итә. Ләкин озак дәвам иткән үпкә авыруы 1926 елның 16 мартында әдипнең гомерен кисә. Бу турыда «Правда», «Известия» һ. б. үзәк газеталар язып чыгалар. Татар, башкорт, әзербәйҗан, кыргыз, үзбәк, казакъ һ. б. телләрдәге газета-журналларда басылган күп санлы мәкаләләрдә С. Рәмиевнең вафаты татар әдәбиятында зур тарихи югалту, мәңге онытылмас классик шагыйрьне югалту итеп карала.

С. Рәмиев — дөнья әдәбияты классиклары Байрон, Шиллер, Лермонтов традицияләрен үзенчәлекле дәвам итеп, XX йөз башы татар әдәбиятында романтизм агымын башлап җибәргән шагыйрь. Прогрессив романтизм исә критик реализмны баетуда, татар совет әдәбияты үсешендә әһәмиятле роль уйнады. С. Рәмиевнең татар шигыренә керткән яңалыкларын һ. Такташ һәм башка шагыйрьләр үстереп, татар поэзиясен яңа биеклеккә күтәрделәр.

Шәйхи САДРЕТДИНОВ.

## БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМ

10—11 декабрьда Мәскәүдә, Союзлар йортының Колонналы залында СССР иҗат союзлары — язучылар, художниклар, кинематографлар, композиторлар союзлары правлениеләренең берләштерелгән пленумы булды. Пленумда театр җәмгыятьләре, архитекторлар һәм журналистлар союзлары вәкилләре катнашты.

Пленумда «Совет әдәбиятында һәм сәнгатендә ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык принципларын гәүдәләндерү турында» дигән мәсьәлә куелды.

Пленумда Татарстан вәкилләреннән «Казан утлары» редакторы шагыйрь Зәки Нури, композиторлардан Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Алмаз Мөнасыйпов катнашты.

## ТЫНЫЧЛЫКНЫ ЯКЛАП

Ноябрь урталарында Мәскәүдә «Художник-сатириклар тынычлык өчен көрәштә» дигән темага халыкара күргәзмә ачылды. Күргәзмәне СССР культура министрлыгы, СССРның Художество Академиясе, СССР художниклар союзы, СССР журналистлар союзы, СССР Тынычлыкны саклау комитеты, СССР Тынычлык фонды һәм РСФСР художниклар союзы оештырган. Бу күргәзмәгә СССР, Болгария, Югославия, Польша, Чехословакия, ГДР, Румыния, Вьетнам, Франция, Италия, Дания, Чили, США һ. б. илләрнең карикатурачы-художниклары катнашты.

Күргәзмәгә Татарстан художникларыннан И. Әхмәдиев, Л. Бочкова, И. Бобровский, Э. Гельмс, Ю. Денисов, В. Игнатьев, Л. Насыйров, Б. Старчиковларның 17 әше куелды.

Якташларыбызның әсәрләренең югары сәнгать дәрәҗәсендә торуларын билгеләп үттеләр, Б. Старчиков һәм Л. Бочкова әсәрләре өчен икенче һәм өченче премияләр һәм истәлекле бүләкләр бирелде.

Күргәзмәдә катнашучы барлык иптәшләргә истәлекле медальләр тапшырылды.

## БАШКАЛАДА КУНАКТА

Ноябрь аенда Мәскәү Союзлар йортының Колонналы залында Татарстан үзешчәннәре чыгыш ясадылар. Анда республикабызның профсоюз клублары, культура йортлары һәм культура сарайлары каршында эшләүче үзешчән сәнгать коллективларының иң яхшы вәкилләре катнашты.

Концертны сәхнәгә Татарстанның атказанган артисты И. Солтанов куйды. Үзешчән сәнгать коллективларына зур ярдәм курсәтеп килгән композиторлар З. Хәбибуллин, Б. Мулюков һәм Е. Хисамовлар да кичәдә чыгыш ясадылар.

В. И. Ленинның беренче революцион адымнары белән бәйле булган Казан шәһәре үзешчәннәренең чыгышларын мәскәүлеләр яратып карадылар.

## ҮЗЕШЧӘННӘРНЕҢ РЕСПУБЛИКА СМОТРЛАРЫ

Халык җәүһәрләрен барлау, профессионал белгечләр тарафыннан аларны бәяләү, ярдәм итү традициясе республикабызда бик күптәннән килә. Халык үзешчәннәренең быелгы республика смотрлары исә В. И. Ленинның тууына 100, республикабыз төзелүгә 50 ел тулган көннәргә багышланып үтте.

Республикабыз районнарында үткәрелгән зона смотрлары узган еллар белән чагыштырганда, катнашучылар санының артуы, профессионал осталыкның арта төшүе, сәнгать төрләренең күбәюе белән аерылып тора.

Кама тамагы, Саба, Лениногорск, Питрәч, Азнакай һ. б. зоналарда үткәрелгән үзешчән коллективлар смотрларын әзерләүдә, халык талантларын сайлап алуда язучылардан Риза Ишморат, Зәки Нури, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Роберт Батуллин, Нәби Дәүли, Рәшит Гәрәй, Рәнсә Ишморатова иптәшләр актив катнаштылар.

* * *

7—19 декабрьларда Казанда халык театрларының республика смотр-декадалары булып үтте. Шәһәрнең культура сарайларында Казан шәһәренең Совет районы культура сараеның театр коллективы, Урицкий исемендәге культура йорты театр коллективы, Чаллы, Әтнә, Әгерҗе, Биектау, Тәтеш, Азнакай район халык театрлары, Түбән Кама «Төзүче» клубы халык театры, Түбән Кама районы Уратмә авылы халык театры, Казан шәһәре укытучылар йорты халык театры, Казан шәһәренең Маяковский исемендәге клуб халык театры, Зеленодольск шәһәренең Родина культура сарае халык театры, Казан шәһәренең Житен комбинаты культура сараеның халык театры коллективлары Т. Гыйззәтнең «Башмагым» комедиясен, Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ен, Р. Ишморатның «Давылга табан», М. Әмирнең «Тормыш җыры» драмаларын, Ю. Әминовның «Тамырлар», «Үмырзая чәчәкләре» дигән әсәрләрен, Р. Ишморатованың «Әйтер идем йөрәк серемне» пьесаларын, Туфан Миңнуллинның «Очкалда кагынганда», Б. Лавреньевның «Ата хакы — тәңре хакы», Л. Рахмановның

«Тынгысыз картлык», Ш. Галиевның «Энә һәм штык» әсәрләрен һ. б. сәхнәгә куйдылар.

21 декабрьда Казан шәһәренең Галимнәр йортында смотр йомгакларына багышланган конференция булып үтте. Конференциядә жюри председателе, татар Академия театры директоры, ТАССРның атказанган артисткасы Рәшидә ханым Жиһаншина, жюри председателе урынбасары, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе драматург Риза Ишморат, шагыйрь Зәки Нури, язучы Аяз Гыйләҗевлар чыгыш ясадылар. Һәр коллективның эше җентекләп тикшерелде. Нәтиҗәдә: Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» әсәре белән Әтнә халык театры, Риза Ишморатның «Давылга табан» әсәре белән Казан шәһәре Маяковский клубы халык театры РСФСРның зона смотрына куелырга лаек дип табылды.

«Башмагым» спектаклен куйган Түбән Кама «Төзүче» клубы, «Тамырлар» пьесасын куйган Урицкий исемендәге культура йорты, «Яшь йөрәкләр»не сәхнәгә куйган Уратмә авылы коллективы, «Очканда-кагынганда» әсәре белән Әгерже районы үзешчәннәре һәм «Тынгысыз картлык» әсәрен сәхнәгә куйган Укытучылар йорты коллективы смотрда уңай бәя алдылар.

## М. ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА КИТАПЛАР

Патриот шагыйрь Муса Җәлилнең онытылмас батырлыгы әдәбият, сәнгать һәм фән эшлеклеләрен яңадан-яңа әсәрләр тудыруга рухландырып тора. Әле үткән елларда гына да Мәскәүдә, Ленинградта, Чиләбедә Муса Җәлил турында яңа китаплар басылып чыкты. Шагыйрьнең тормыш юлына һәм иҗатына багышлап Ленинградның «Мәгариф» нәшриятында К. Барская китабы, Мәскәүдә «Фән» нәшриятында Казан галиме В. Г. Воздвиженскийның «Моабит дәфтәрләре» дигән фәнни китабы чыкты. Чиләбе китап нәшриятында В. Г. Альтов «Муса Җәлилнең яшьлеге» һәм шагыйрьнең туганы Хәдичә Җәлилова «Абыем турында» дигән китаплар бастырып чыгардылар.

## ТАТАР КИТАПЛАРЫ ТӘРҖЕМӘДӘ

Татар язучыларының иң яхшы әсәрләре төрле телләргә тәрҗемә ителеп илебезнең төрле нәшриятларында басылып чыга. 1970 елда гына да түбәндәге китаплар Мәскәү нәшриятларында басылачак.

«Советская писатель» нәшрияты Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» китабын кабат бастырачак. «Художественная литература» нәшрияты Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Хәсән Туфанның биш табаклы шигырьләр җыентыгын чыгарачак.

«Советская Россия» китап нәшрияты Гариф Ахунов һәм Марсель Зариповларның «Без Казаннан, Иделдән» дигән китабын, фәннәр доктору Гыйлем Камайның «Хыялга карап» дигән әсәрен, Салих Батталның «Сигезенчесе кем» исемле повестен, Рафаил Төхфәтуллинның «Зәңгәр кыңгыраулар» китабын, Зыя Мансурның «Ләйсән яңгыр» дигән шигырьләр җыентыгын чыгарачак.

«Детская литература» нәшрияты Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» әкиятен, Ләбибә Ихсанованың «Саралан малайлары» дигән, Сибгат Хәкимнең «Заветная книга» дигән китапларының икенче басмаларын, Рафаэль Мостафинның «Шагыйрь эзләре буйлап» дигән китапларын укучыларга тәкъдим итәчәк.

* * *

Мәскәүнең «Детская литература» нәшрияты «Җыр, хыял һәм мәхәббәт» дигән китап чыгарды. Биредә бары тик шагыйрәләрнең генә шигырьләре тупланган. Аларның тормыш юллары һәм иҗат үзенчәлекләре турында белешмә бирелгән, фоторәсемнәр урнаштырылган. Китапка Советлар Союзында яшәүче төрле миллләт халыкларыннан 66 шагыйрә катнашкан. Татар шагыйрәләреннән Саҗидә Сөләйманова һәм Клара Булатовалар да бу җыентыкка бер бәйләм шигырьләр белән катнашканнар.

* * *

Гарәп теле белгече Гаяз ага Ишмөхәммәтов Г. Тукайның «Шүрәле» әсәрен гарәп теленә тәрҗемә итеп Мәскәүдә бастырып чыгарды. Китап шагыйрьнең рәсеме, матур оформление белән яхшы кәгазьдә басылган.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап Төркмәнстанның башкаласы Ашхабад шәһәрендә ике теллелек һәм күп теллелек проблемалары буенча Бөтенсоюз фәнни конференциясе үткәрелде. Бу конференциядә Казан галимнәреннән Казан дәүләт педагогия институты ректоры, филология фәннәре докторы, профессор М. З. Зәкиев һәм СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты сотрудникы, филология фәннәре кандидаты Р. Х. Субаева иптәшләр Татарстан АССР шартларында ике теллелекнең үзенчәлекләре һәм спецификасы турында доклад һәм чыгыш ясадылар.

* * *

8—9 декабрьда Мәскәүдә СССР язучылар союзының секретариаты булды. Утырышта балалар әдәбиятының торышына караган мәсьәләләр буенча язучы Сергей Михалков доклад ясады. Секретариатта балалар язучысы Ләбибә Ихсанова да катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

ТАССР язучылар союзының консультация бүлеге республикабызның шәһәрләрендә һәм районнарында яшәүче яшь

язучыларны чакырып Казанда семинар уткәрде. Семинарда Сарман районы газетасы сотруднигы Хәниф Хәйруллинның «Үлгәннәр дә кайта» повесте, Буа районы газетасы сотруднигы Хәмзә Кашаповның «Тәмамланмаган язмалар» повесте, Балтач районы газетасы редакторы Рифгать Сирайның «Дусларга хат» повесте, Башкортстаннан Зиннур Насыйбуллинның шигырьләре тикшерелде.

Семинарда Түбән Кама әдәби берләшмәсе членнары Әхмәт Гаязов (Әхмәт Гадел) шигырьләренә һәм Фәтхулла Абдуллинның хикәяләренә дә анализ ясалды.

Язучылардан һәм шагыйрьләрдән Нури Арсланов, Нурихан Фәттах, Шәүкәт Галиев, Сарьян Хәсәнов, Илдар Юзеев, Газиз Мөхәммәтшин, Марс Шабаевлар семинар җитәкчеләре булып катнаштылар.

* * *

Пермь өлкәсенең Гремячинск шәһәрендә яшәүче яшь шагыйрь Р. Закировның консультация бюросы индивидуаль семинарга чакырып алды һәм соңгы ике елда язылган шигырьләре буенча сөйләшү уткәрде. Семинар эшендә шагыйрьләрдән Шәүкәт Галиев, Рәшит Гәрәй һәм Илдар Юзеевлар катнаштылар.

Рифгать Закировның яхшы дип табылган шигырьләре аерым җыентык итеп Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

* * *

Чираттагы семинар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетындагы әдәбият түгәрәге членнарының иҗатын тикшерүгә багышланды. Түгәрәк бюросы председателе Р. Бәшәров үзләренең эше белән таныштырганнан соң, Фәннур Сафин һәм Роберт Миңнуллинның шигырьләре буенча җанлы сөйләшү башланды. Шагыйрьләрдән Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гәрәй Рәхим һәм Зөлфәт Маликовлар яшь шагыйрьләрнең һәрбер шигыренә аерым тукталып, анализ ясадылар.

Бер үк вакытта язучылардан Аяз Гыйләҗев һәм Туфан Миңнуллиннар яшь прозаиклардан Альберт Сафин белән Азат Ганиев хикәяләрен тикшерделәр.

Яхшы дип табылган әсәрләр матбугатка тапшырылды.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Совет театр сәнгатен үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен һәм туууна 60 яшь тулу уңае белән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты — ТАССРның халык артисты Мингали Ислам улы Надрюков КПСС өлкә комитетының һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## ХАЛЫК ИҖАТЫ КИЧӘСЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан язучылар һәм композиторлар союзлары, республика Халык иҗаты йорты берләп татар халык иҗаты кичәсе уткәрделәр. Кичәне язучы Гомәр Бәширов ачты. Филология фәннәре кандидаты И. Надыйров тамашачыларны татар халык иҗаты белән таныштырды.

Программада рус, татар һәм удмурт халык әкиятләре, татар халык бәетләре, җырлары, биюләре һәм табышмаклары киң урын алган иде.

Тамашачылар РСФСРның халык артисткасы З. Хисматуллина башкаруында В. И. Ленинга багышланган татар халык җырларын җылы каршыладылар. Татарстанның халык артисткасы В. Минкина, артистка Ф. Хәмитова әкиятләрне, Татарстанның атказанган артисты Г. Фәтхуллин, артист Р. Абулмамбетов бәетләрне оста башкардылар.

Кичәнең икенче өлеше Ленин исемендәге культура сараеның хор (хормейстер С. Шагиева) чыгышы белән башланды.

Кичәдә Казанның Урицкий исемендәге, Куйбышев исемендәге культура сарайларының биючеләре, Кукмара, Апас районы үзешчәннәренең җырлары, Совет районы культура сараеның халык уен кораллары ансамбльләре чыгышлары да кызыклы булды. Җырчы Ф. Сөләйманова башкаруындагы «Сенелесе әйтә тутасына», «Сәхралар» диган Себер татарлары җырлары да тамашачылар тарафыннан яратып каршыланды.

Кичәдә табышмаклар әйтү һәм аларга җавап табу да бик күңелле узды. Мондый тапкырлык ярышында җиңгәннәргә бүләкләр бирелде.

Фойеда татар халык иҗатын туплаган китаплар: галимнәр, язучылар, шагыйрьләр һәм художникларның бу өлкәдәге хезмәтләре һәм әсәрләреннән күргәзмә дә оештырылган иде. Анда шулай ук татар орнаментлары белән бизәлгән милли киемнәр, читек-түбәтәйләр, сөлгеләр, бизәнү әйберләре һәм башкалар бар иде.

## ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮЛӘР

26 ноябрьдә гидроспецстрой эшчеләре шагыйрь Илдар Юзеев һәм драматург Туфан Миңнуллин белән очраштылар. Язучылар татар совет әдәбиятының соңгы яңалыклары турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен тыңладылар, күп төрле сорауларга җавап бирделәр.

* * *

3 декабрьдә Илдар Юзеев һәм Р. Гатауллиннар Казан шәһәренең 1 нче номерлы тегү фабрикасы эшчеләре белән очраштылар. Үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария институтында студентлар һәм галимнәр язучы Нәби Дәүли белән очраштылар. Кичәдә катнашучылар язучының әсәрләре турында фикерләр әйттеләр, Нәби Дәүли үзенең иҗат планнары турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

* * *

Г. Зәйнашева һәм С. Шакир Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова, музыкант Флера Хөрмәтова белән бергә Чаллы районының XXI нче партсъезд исемендәге, «Якты Йолдыз», Ильич васыятьләре исемендәге, «Алга», Чкалов исемендәге колхозларда һәм Бигеш балалар йортында шигырь һәм җыр кичәләре уздырдылар.

Бу кызыклы очрашуларда сүз совет чорында җыр сәнгатенең үсеше, соңгы елларда язылган җырларның уңышлары һәм кимчелекләре турында барды.

## ӘДӘБИ АТНАЛАР

Республикабызның рус язучыларыннан Юрий Белостоцкий, Николай Беляев, Валерий Синев, Рөстәм Кутуй, Виктор Байдерин Биектау районы эшчәннәре белән очраштылар. «Дружба», «Семиозерный», «Беркут» совхозларында һәм «Серп и молот» колхозында үткәрелгән очрашуларда 2 меңнән артык укучы катнашты.

* * *

Ноябрь аенда Лаеш районы хезмәт ияләре татар әдәбияты атналыгы үткәрделәр. Атналыкта катнашкан язучылар Аяз Гыйләҗев, Газиз Мөхәммәтшин, Марс Шабаев, Рәдиф Гатауллин, Вакыйф Нуруллин һәм рус язучыларыннан Юрий Белостоцкий һәм Михаил Скороходовлар Кече Елга, Иманкискә, Пәрәү, Державино, Атабай, Хәерби авылларында колхозчылар, укытучылар һәм укучылар белән очраштылар. Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында булган әдәби кичәдә дә катнаштылар.

* * *

Баулы районында да әдәби атналык булып узды. Атналыкта язучы Әмирхан Еники, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, шагыйрьләрдән Галимҗан Латыйп, Әдип Маликов, Гәрәй Рәхим, Ренат Харисов, Рөстәм Мингалимов, яшь шагыйрьләрдән Мөдәррис Әгъләмов һәм Рәшит Әхмәтҗановлар катнашты.

## МЕҢ ЯРЫМ

Республика Курчак театры язучы Нәби Дәүлинең «Бәхет турында җыр» спектаклен декабрь аенда мең ярымынчы тапкыр күрсәтте. Соңгы спектакль Буа районында үтте. Спектакльдән соң авторның үз катнашы белән Буа шәһәрендә тамашачылар конференциясе үткәрелде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге кызыклы очрашулар үткәрүен дәвам итә. Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Сажидә Сөләйманова, Юныс Әминов, Фазыл Мостафин һәм үзешчән композитор Мәсгут Имашев соңгы вакытта гына да Лениногорск районының «Дружба», «Спартак», Куйбышев исемендәге, «Шушма», Әлмәт районының «Родина», «Путь коммунизму», «Красный маяк», Азнакай районының «Октябрьның 40 еллыгы» һәм Сарман районының «Игенче» колхозларында әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар.

* * *

Башлап язучылар өчен оештырылган әдәбият түгәрәгенең өч утырышы үткәрелде. Түгәрәк утырышының берсе яшь шагыйрь Ф. Гыйззәтуллинаның соңгы 3—4 ел эчендә язган шигырьләрен тикшерүгә багышланды. Түгәрәк утырышында сайлап алынган шигырьләр аерым китап итеп чыгарырга лаек табылды һәм нәшриятка тәкъдим ителде.

* * *

Әлмәттә яшәүче язучылар шәһәр мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләре белән эшлекле кызыксынып, укытучы иптәшләргә даими практик ярдәм күрсәтеп киләләр. Язучыларның булышлыгы белән хәзер шәһәрнең бөтен мәктәпләрендә диярлек татар теле һәм әдәбияты кабинетлары җиһазландырылды, татар әдәбияты классиклары һәм Әлмәт тирәсендә яшәүче әдипләр турында махсус стендлар оештырылды. Укучылар һәм ата-аналар белән очрашулар да күркәм традициягә әверелеп бара. Шушы араларда гына 4, 14 мәктәпләрдә язучыларның чыгышлары булып узды.

* * *

15 октябрьда бүлек утырышында Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн» исемле яңа поэмасы турында фикер алышу булды. Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова, Ю. Әминов, К. Булатова һәм күп кенә яшь язучылар катнашында узган бу утырыш поэманы уңай бәяләде һәм тагын да яхшырту юнәлешендә авторга күп кенә файдалы киңәшләр бирде. Шул ук утырышта яшь язучы Р. Зыятдиновның яңа юмористик хикәяләре дә укып тикшерелде.

* * *

15 октябрьда СУ-2 клубында Әлмәт хезмәт ияләре каршында Мәскәү язучылары — И. Маркин, Д. Паттерсон, Г. Чистякова, Әлмәт язучылары — Р. Фәйзуллин, С. Сөләймановалар чыгыш ясадылар.

* * *

Шагыйрьләрдән Г. Афзал, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин, Ә. Маликовлар Әлмәткә — мәктәп директорлары киңәшмәсенә килгән иптәшләр алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Казан шәһәреннән Н. Беляев, Әлмәттән — Р. Фәйзуллин иптәшләр Сәүдә техникумы, «Татнефтегаз» трестының газ чыгару промыселе, вышкалар монтажлау идарәсе коллективлары алдында чыгыш ясадылар. Совет поэзиясенең 50 ел эчендәге казанышлары турында сөйләделәр, үзләренең шигырьләрен укыдылар.

* * *

29 ноябрь көнне Баулы районының Урыссу эшчеләр поселогы клубында язучы Р. Төхфәтуллинның иҗатына багышланган конференция булды. Конференциядә автор үзе дә катнашты.

## *Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210